# Казан утлары



4
АПРЕЛЬ
1967



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

4

АПРЕЛЬ

1967

## Бу санда:

ПОВЕСТЬЛАР, ХИКӘЯЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР

**А. Велюгин. Иделдән искән җилләр.** Поэмадан ике өзек. З. Нури тәрҗемәсе . . . . . . . . 3

**З. Воскресенская. Йокысыз төн.** Хикәя. Г. Иделле тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . 8

**Ә. Атнабаев. Эш. Мирас. Кешегә нәрсә җитми. Юлда. Кирәк икән. Бер генә. Үлем килгәч.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 15

**Ф. Хөсни. Язмыш шуклыгы.** Повесть . . . . . 17

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Р. Харисов. Шигырьләр** . . . . . . . . . 56

**Х. Әюпов. Шигырьләр** . . . . . . . . . . 59

**Р. Идиятуллин. Шигырьләр** . . . . . . . 61

**Р. Фазлыев. Шигырьләр** . . . . . . . . . 63

МЕМУАР

**Г. Сафиуллин. Днепрны кичү** . . . . . . . 65

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

**Г. Курчаков. Г. Насыйров. Кем идек һәм кем булдык** . . . . . . . . . . . . . . 74

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

**Г. Ахунов. Җир һәм күңел җылысы** . . . . . 87

ГАЗИ КАШШАФКА 60 ЯШЬ

**Г. Минский. Халыкка хезмәт** . . . . . . . 96

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Д. Вагыйзов. Принцип . . . . . . . . . 98
Э. Касыймов. Карт рәссам белән очрашу . . 102

КОНКУРСКА КИЛГӘН ӘСӘРЛӘР

Т. Миңнуллин. Бәхетле кияү. Пьеса . . . . 107

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. Галиев. Ислемай. Актүш һәм велосипед. Басмалар саный Әсма. Шакир һәм шикәр. Колмак. Кыяр-кыймас. Багана . . . . . . . . 117

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Р. Миңнуллин. Тукай Астраханьда . . . . 120
В. Скворцов. Архив киштәләреннән . . . . 122
Х. Гобәйдуллин. Габделрәүф Ниязбаев . . 126

ТӨРЛЕСЕННӘН

Җ. Фәйзи. Чәчкап альбомы . . . . . . . . 129

УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

А. Дубин. Тормыш көзгесендә . . . . . . . 137

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ә. Нигъмәтуллин. Безнең Ильич . . . . . 144
С. Әдһәмова. Күкчәтау далаларында . . . . 146

ӘДӘБИ КОНСУЛЬТАЦИЯ

Н. Арсланов. Хатлар актарганда . . . . . 148

УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

«Казан утлары» журналы турында кайбер фикерләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 151

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Ә. Фазылҗанов. Юморескалар . . . . . 153
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 157

*Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары»*

*Анатолий Велюгин*

# Иделдән искән җилләр



*Поэмадан ике өзек*

## Ирек сулышы

Базар шаулый. Кайгы-сагышларның
Ниндиләрен базар күрмәгән...
— Килер әле бүтән Пугачевлар! — дип
Карт бер эшче яңый төрмәгә.

Тау башында шушы таш читлектә
Күпме кеше яга ябылып.
Алар хәтта язгы яфракларга
Кул тидерә алмый кагылып.

Көтә алар, тик бер нәрсә көтә:
Якты ирек безгә килерме?
«...Уртак язмыш безне очраштырды,
Тәрәзәләр ләкин тимерле...»

Базар шаулый: — Дегет сатам! — Бал бар.
— Кемгә кирәк киез каталар?..

И сандугач! Моңлы жырчы! Сине
Бик арзанга монда саталар.

Кошлар бик күп — песнәк, күгәрченнәр...
Баласын ал... яки олысын ал.
Читлек, читлек — ул бит нәни төрмә,
Тау башында әнә зурысы бар.

Ә Володя тыңлый. Яз авазы
Үтеп керә кайнар йөрәккә.
Ул дусларын дәшә: — Сандугачны
Тыңлыйк әле, әйдә, тирәктә!..

Сайрый кошчык, нинди матур сайрый,
Ераклларга моңнар чыңлыйлар.
Гимназистлар, куакларга посып,
Сандугачның жырын тыңлыйлар:

«Сайра кошчык, сайра иркенлектә,
Тукталмыйча сайра, син оста!..»
Һәм күрәләр кинәт: ике жандарм
Бер агайны илтә Венецка.

Конвоирлар ашыктыра аны,
Кырыс эш ул төрмә эше бик.
Кош сөюче малай, кара әле,
Агай сиңа таныш кеше бит...

Ул актара хәтер язмаларын,
Уйлар илтә сазлы таллыкка.
Дус-ишләре белән Володя да
Килгән иде шунда балыкка.

Бер аягы ярдан таеп китеп,
Сазга төште, билдән чумды ул.
Бата бара... упкын йота аны...
Калтырады каушап, туңды ул...

Иптәшләре ярдәм эзләп чапты...
Тавышлардан яңгырап торды яр...
Һәм шул чакта аны коткарырга
Килеп җитте шушы кочегар.

Ә ни өчен хәзер тау башына
Алып менә аны сакчылар?
Шуны күргәч барча балалар да
Читлекләрен кинәт ачтылар.

— Ичмасам, кош иркенлеккә чыксын,
Канат язып күктә уйнасын...

Ирек, ирек! Зәңгәр күккә менде
Кошлар ташлап читлек-оясын.

Шундук кинәт мылтык шартлаулары...
«Качма! Тукта! Барыбер табабыз!..»
Аңлашыла: куе куаклыкка
Кереп шылган теге агабыз.

## Яшерен юл

Володя гел житдиләнә бара,
Шар тибүләр дәвере, инде хуш!
Ә Аполлон Коринфский аңа
Хәзер кыю һәм иң якын дус.

Китап сөя, бик күп шигырь яза,
Эчтән генә һаман жыр көйли.
Классташка, якын теләктәшкә
Бу Аполлон шундый сер сөйли:

— Аяк-кулы богауланган килеш
Пугачевны япкан урынга —
Караңгы һәм тынчу, тар подвалга
Яшерен юл тиеш булырга.

Кулга алгач, мужик хөкемдарны
Асраганнар Сембер җирендә, —
Ярыймы соң бөркет канатына
Җилпенергә ирек бирергә?!

Кыю бөркет шунда җәза көтеп
Яткан икән агач читлектә.
Каныкканнар бояр, байлар аңа
Каргап та һәм мыскыл итеп тә...

Без шул йортта, нәкъ шул төштә хәзер
Бер дә гамьсез уйнап йөрибез.
Юк, ул подвал яшерен юлсыз түгел,
Әйтә кебек: табыгыз, керегез!

Йөр, Емеля, иркен далаларда,
Бу зинданнан кыю ир качсын! —
Шулай диеп монда фетнәчеләр
Казыганнар юеш җир астын.

Дусның сүзе ничек тетрәтмәсен,
Дөреслек зур чөнки сүзләрдә.

Һәм Аполлон яшь бөргеге күрә
Бераз кысык коңгырт күзләрдә.

... Наяннар да, шуклар-шаяннар да
Ул сөйләсә тынып калалар.
— Чу! Володя кызык шигырь сөйли! —
Дип барчасы колак салалар.

Ә шигырьдә Сембер каласының
Зур түрәсе Панин үзе бар,
Һәм аңарга тоткын Пугачевның
Җавап итеп әйткән сүзе бар:

«Козгын түгел — мин баласы гына!
Тиздән козгын үзе киләчәк.
Ул тукларны чукыр һәм теткәләр,
Ә ачларга ризык бирәчәк.

Ишет мине, коллар биләсәң дә,
Сиңа әйтәм уйда ни барны:
Халык барыбер тагын кузгалачак
Һәм җимерәчәк сезнең диварны...»

Шигырь сөйли... Дәртле Володяны
Һәммә яктан сырып алалар —
Салкынлыктан ашыгып утка очкан
Күбәләктәй булып балалар.

Ул бик шаян, ул бик өлгер шәкерт,
Яхшы укый, матур көлә ул.
Кышкы көндә калын боз астыннан
Эре балык тота белә ул.

Ярата ул җәйнең чыклы таңын,
Колак сала серле моңнарга.
Ярата ул бераз «салып» алган
Бурлакларның җырын тыңларга.

Кыр казлары алтын ачкыч белән
Көз капкасын ачкан көннәрдә,
Латин телен яхшы өйрәнергә
Булышмады соң ул кемнәргә?!

Барчукларның купшы сүзләрен ул
Бер шаян сүз белән үтерә.
Ә тыелган «Ни эшләргә?» сүзен
Дусларына табып китерә.

... Караңгы кич. Гимназия йорты.
Җир казыйлар. Кызу эш бара.
Йолдызлар да карап кына тормый,
Алар белән гүя шаяра.

Андреев Митя — көчле малай.
Көрәк, фонарь алган кулына.
Аяк асты — юеш һәм үкле таш.
Кабер исе бәрә борынга.

Җир асты бу. Тар юл, яшерен сукмак.
Дуслар монда армый, иренми.
Өс-башларга пәрәвезләр сырыша,
Бер нәрсә дә күзгә күренми.

— Чү! Фонарьчы, яле, күтәрә төш!.. —
Һәм бер шәүлә куя авышып.
Кемдер атлый алар каршысына, —
Ишетелә аяк тавышы.

Очрашалар. Мондый чакта кемнәр
Каушап калмас һәм шаккатмаслар.

Һәм Володя кочегарны күрә.
— Таныйсызмы мине, якташлар?

Күз алдына килә Венец юлы.
— Сакчылардан сез бит качгыгыз?
Курыкмагыз, без бик кыска телле,
Без дошманга серне ачмыйбыз.

— Анысы бик шәп. Сак булу да кирәк.
Бер нәрсәдән курыкмас идек тә,
Дөреслекне әле яратмыйлар,
Ул богауда әле, ул биктә.

Шуңа күрә мин дә менә мәҗбүр
Качып-посып гомер итәргә.
Җәйләр тизрәк яфраклансын иде.
Жигулига кирәк китәргә.

Анда — ирек. Анда ят күзләрдән
Саклый урман — яшел дустыбыз...—
Володяның кулын кыса агай.
— Дуслар, рәхмәт, ярый, хушыгыз!

— Пугачевны күрдек, ахры...— диеп
Кемдер әйтте өскә чыкканда.
Атладылар алар таңга карап,
Атладылар карап Чулпанга.

Ә Иделдән җиләс җилләр исә
Ярны капшап буйдан-буена.
Ә Иделдә — саллар. Салда — учак,
Җир жылына аның куенында.

Саллар килә Урал якларыннан,
Саллар килә ерак Камадан.
Сөрген ягы — Себерләрдә туган
Җырлар яңгырый монда яңадан.

Уфтана да, ыңгыраша да кеше
Һәм елый да җырлыйм дигәндә.
Идел буйлап кайнар күз яшенең
Күпме тозы агыла түбәнгә.

Суда — утлар. Ярда — таллар шаулый.
Коринфский әйтә: — Язларын
Дөнья матур! — уйлый булса кирәк
Шагыйрь булгач шуны язарын.

Үсмер дуслар биек ярда тора.
Төне якты язның. Идел киң.
Шушы төндә әйттең син, Володя:
— Без көрәшеп яшик! — дидең син,

Синең кулны эшче шулай кысты.
Һәм син кыстың кулын эшченең.
Шул тәүге төн бәлки башлагандыр
Җиңүләрең бөек эшеннең.

**Белорусчадан З. НУРИ тәрҗемәсе.**

*Зоя Воскресенская*

# ЙОКЫСЫЗ ТӨН

*Хикәя*

Каты җил кузгалды, ургылып Җәйге бакчага килеп керде, агач һәм куак башларындагы кар бөрекләрен очыртып төшерде, аллеялардагы көртләрне кузгатып, кар бөртекләрен өерәөерә, Фонтанка аша себереп алып китте. Пантелеймон урамындагы фонарь да җилдә тибрәлә һәм тар гына фонарь яктысы чиркәү стенасы буйлап йөгергәли, андагы борынгы славян хәрефләре белән чуарлап язылган «Бу храм император Бөек Петр патшалык иткән вакытта салынды» дигән сүзләрне яктыртып-яктыртып ала иде.

Изге Пантелеймон чиркәве чаң суга башлады, чаң тавышына аш бүлмәсендәге сәгать сугуы кушылды.

Надежда Константиновна кулына кысып тоткан булавкасын китаптан алды да сәгать сукканны тыңлый башлады.

— Сигез... тугыз... ун... — дип пышылдап санады. — Сәгать ун. Ильич озакламый кайтып житәргә тиеш.

Аның бармаклары янадан китап битендәге хәрефләр өстендә кызу-кызу йөрергә тотынды. Ул китап битенә булавка очы белән генә чәнчеп ала, шулай итеп юл артыннан юлны тиешенчә «эшкәртә» бара, күрә карау зур күзләре булавкага текәлеп караган. Тышы бизәкле бу матур китапны иптәшләр кулларына алгач та, аның битләрен яктыга куеп карап чыгарлар һәм булавка белән чак кына беленерлек итеп тәрткеләр тишелгән хәрефләрне күчереп алырлар. Ул хәрефләрне махсус шифр таблицасы буенча тезеп куйганнан соң, Ленинның: узган 1905 елның көрәш тәҗрибәләрен өйрәнергә, кирәк табылган урында яңадан подпольега күчәргә, алдагы яңа көрәш-сугышларга әзерләнергә, дигән наказын укырлар.

Шул вакыт ишекне шакыдылар.

Надежда Константиновна булавкасын тиз генә кофтасына кадады да, иягенә таянып, «укуга» чумды.

— Керегез!

Ишектән, яны белән борылыбрак, хуҗа хатын килеп керде һәм, ялагай елмаеп, мичтән ис чыкмыймы дип, самоварым яңа гына кайнап чыкты — квартирантка чәй эчәргә теләмиме? — дип сораган булды.

— Рәхмәт, — диде Надежда Константиновна. — Иремнең кайтканын көтәм әле. Ул дуслары янына преферанс уйнарга киткән иде.

Хуҗа хатын морҗа капкачы яхшы ябылганмы дип тикшергән булды һәм кызыксынып китапка күз салды.

— «Испания королевасының муенсасы», — дип, китапның исемен укыды. — Бик кызыклы китап ахры, миңа да укып торырга бирмәссез микән? — диде.

Юк, кызганычка каршы, квартирантка китапны бирә алмый икән, аны иртәгә иртүк таныш бер хатынга кире кайтарырга кирәк, шуна күрә бүген укып бетерергә ашыгам, ди.

Хуҗа хатын:

— Бик кызганыч! — дип, тирән сулап куйды. Шулай да чыгып китәргә җыенмады. Аның эче поша иде, күрәсең, бераз лачтит сатып утырырга да исәбе юк түгел иде бугай. — Сезнең, Прасковья Евгеньевна, фамилиягез бик матур... Онегина... Ә исемегез бик гади — Прасковья.

Надежда Константиновна аның сүзен җөпләп:

— Әйе шул, — дип тиз генә җавап кайтарды.

— Полицейский сөйләп торды әле, — диде хуҗа хатын, — аның участогына бу Онегина дигән хатын каян килеп чыкты икән? — дип, пристав үзе кызыксына икән, ди.

Надежда Константиновна, мондый паспорт белән озак яшәп булмас, ахры, дип, борчуга төште... Прасковья Онегина... Миңа шундый сәер яңгырый торган исем-фамилияле паспорт юнәтергә иптәшләрдән кайсының башына килгәндер... Менә бит хәзер бу төпченүчән хатын аның белән ничек кызыксына, бигрәк хәтәр...

Хуҗа хатын тагын нәрсәдер сорамакчы булды, тик әңгәмә барып чыкмасын аңлады, күрәсең, бүлмәдән, кергәндәге кебек, яны белән тавыш-тынсыз гына чыгып китте.

Надежда Константиновна янадан үз эшенә керешге.

Хат язылып бетте. Китапны күзенә якын ук китереп, ул һәр битен җентекләп тикшерде, юлларны капшап карады. Әйбәт эшләнгән, булавка очы белән чәнчеп язылган битләрне охранка күрә алмас. Надежда Константиновна бу төгәлләнгән эшне ридикюленә салып куйды.

Хәзер инде яна килгән почтаны карап, укып чыгарга кирәк. Ул, озын итеп тегелгән постау юбкасы кесәсеннән хатларны алып, һәркайсын игътибар белән укып чыкты. Кайбер урыннарын Ильич өчен дип ятлап алды, бала чагындагы кебек, күзләрен йомып, иреннәрен кыймылдатып, яттан өйрәнде.

Арадан бер хат аеруча аның игътибарын җәлеп итте. Язылу вакыты — «1906 елның феврале», — шулай дип астына сызып куелган. Бу — шартлы билге. Хатта яшерен язу бар. «Тагын кофтаны үтүкләргә туры килә инде», дип елмаеп куйды Надежда Константиновна, хатларның укылганнарын сул кесәсенә, укылмаганнарын уң кесәсенә яшерде.

Ярдәмчел хуҗа хатын үтүккә күмерне үзе салды, коры чыра яндырып, үтүкне мич юллыгына куйды.

— Сез ишеттегезме: безнең йорттан әле генә ике курсистканы кулга алдылар... — диде ул; шундый күңелсез хәлне шатланган тавыш белән әйтте. — Социалист кисәкләре! Кара син оятсызларны, ә! Дөнья болгатып ятучы шундыйларның барысын да тизрәк бетереп ташласыннар иде, аннары, ичмасам, безгә, намуслы кешеләргә, тынычрак яшәргә мөмкин булыр иде.

— Аннан безгә җиңел булыр микән соң? — диде Надежда Константиновна һәм үтүк тишегенә каты гына өрә башлады.

— Ышаныгыз, мадам, анысына шикләнмәскә мөмкин!

Надежда Константиновна түгәрәк тишекләреннән утлы күмер күренеп торган үтүкне алды да суынып барган самовардан бер чынаяк чәй агызды һәм, хуҗа хатынга хәерле йокы теләп, үз бүлмәсенә кереп китте.

Ишекнең келәсен элде. Иң элек Ильичның съездга карата әзерләгән заметкаларын яшерергә кирәк иде. Жандармнарның бирегә дә килеп чыгулары мөмкин, ә ул кыйммәтле кулъязманы ничек кенә булса да саклап калырга кирәк...

Хатларны шифрлау өчен, кулъязмаларны саклау өчен аның ридикюлендә һәрвакыт берничә китап була. Шундый «саклау урынын» алар китап төпләүче бер партияле иптәш белән бергәләп уйлап тапканнар иде.

Надежда Константиновна инглиз язучысы Свифтның «Гулливер ли-

липутлар илендә» исемле китабын алды, тышлыгының алтынланган коленкорын саклык белән генә кубарып, ике арадагы калын катыргыны тартып чыгарды. Шул катыргы урынына Ленинның кулъязмасын урнаштырды, коленкорны яңадан җилем белән ябыштырды һәм шуннан соң китапны ридикюленә яшерде. Кулъязма хәзер ышанычлы җирдә иде.

Өстәлгә сөлге җәйде, шуның өстенә хатны куйды, аны кулы белән тигезләде дә хат өстенә җай гына итеп кызу үтүк басты. Үтүк белән шулай берничә тапкыр басты. Һәм, ниһаять, хат юллары арасыннан чак күренә торган кызгылт-көрән ноктадар сыман шифрлар пәйда булды.

«Бу яшертен шифрны ачу өчен нинди ачкыч кирәк икән? Язылу вакыты астына дулкынлы сызык сызылган... Ә, әйе!.. «Тау башлары төнге карангылыкта йокыга талган».

Надежда Константиновна — партия Үзәк Комитеты секретаре. Ул күп оешмалар белән элемтә тота һәм аңа бик күп нәрсәне: уннарча төрле шифр ачкычларын, яшерен язу рецептларын, яшерен очрашу квартираларының бик күп адресларын, парольләрне, псевдонимнарны... бик күп нәрсәләрне белергә кирәк, белергә генә түгел, боларның барысын да беркая язмыйча хәтердә сакларга кирәк, югыйсә, кәгазь дигән нәрсә белән тотылуың бар.

Менә иптәшләр Себердән язалар. Анда, сөргендәгеләргә, бер-бер артлы авыр, күңелсез хәбәрләр килеп тора икән. Мәскәүдәге декабрь восстаниесе җиңелүгә дучар булган. Нижний Новгородта, Пермьда эшчеләр восстаниесе бастырылган, «Новороссийск республикасы» бетерелгән. Революция дулкыннары Себергә дә барып җиткән, ләкин анда да эшчеләрнең восстаниеләре мәрхәмәтсез рәвештә бастырылган. «Димәк, революция тәмам җимерелгән? Бөтенесе югалган? Ә партия яшиме соң?» — дип сорыйлар иптәшләр.

Кешеләрнең перспективаны югалтуларын, ә аннан да куркынычрагы — җиңүгә булган ышанычны югалтуларын Надежда Константиновна аңлый. Аларга кичекмәстән җавап язып җибәрергә кирәк. Хуҗа хатынга күренеп торсын өчен ул кара тасма белән каймаланган соры кофтасын үтүкли, үзе җавап хаты турында уйлана...

Хат бик озын булып чыкты. Тыштан караганда ул гади, юк-бар сүзләрдән генә гыйбарәт бер хат кебек күренә, һәм цензура аңа һич тә игътибар итмәячәк иде. Әмма юл араларына күренми торган махсус кара белән бик күп нәрсә язылган... Революция бетмәгән, ул дәвам итә. Пролетариат корал ташламаган, авылларда крестьяннарның баш күтәрүләре дәвам итә, армиядә дә тыныч түгел, бигрәк тә — флотта. Партия үзенең эшен дәвам иттерә. Партия яши, эшли һәм ул һәлак була алмый. Беркайчан да! Кояшны сүндерерлек көч булмаган кебек, пролетариат партиясен юкка чыгарырлык көч тә дөньяда юк. Эшчеләр сыйныфының эшне ахырына кадәр җиткерә алырлык революцион сәләте барлыгына Ильич һич шикләнми...

Аш бүлмәсендәге сәгать бер тапкыр сукты. Надежда Константиновнаның йөрәге кысылып китте. «Күпме булыр бу? Беренче яртымы? Берме? Икенче яртымы? Беренче ярты гынадыр?» — дип үзен тынычландырырга тырышты ул. Бүген Ильичның меньшевиклар белән бик каты бәрелешү көне. Тикшереләсе мәсьәлә бик җитди: ничек итеп мужикны революциягә тартырга? Эшчеләр сыйныфы крестьяннарны үз артыннан ияртә аламы?

Бу бәрелешкә Владимир Ильич көне буе диярлек әзерләнде. Алар төнге унбердән дә соңга калмыйча таралырга тиешләр иде, ә ул һаман юк әле. Мөгаен, шымчылар тагын аның эзенә төшкәннәрдер һәм ул, шундый хәтәр «койрык»тан котылу өчен, урамнар буйлап тик әйләнеп йөри торгандыр...

«Кайтыр, менә-менә кайтып житәр». Надежда Константиновна асылмалы лампаны түбәнгәрәк төшерде, утны сүндерде: аның йокламый утыруын хужа хатын белмәсен, төнлә тәрәзә яктырып тормаска тиеш.

Караңгы күктән кар коя да коя, урамга ак юрган яба.

Надежда Константиновна, күзләрен йомып, чыңлап торган тынлыкка колак салып, тәрәзә янагына таянып тора...

Менә тәрәзә төбеннән, кар шыгырдатып, кызу-кызу кемдер узды. Надежда Константиновна күзләрен ачмады — юк, бу ул түгел, аның аяк атлавы түгел. Аның йөрешен, атлавын ул мең кеше арасыннан да аера.

Күңеленә кинәт: «Ә бит Володя жылы пиджак кимичә генә чыгып киткән иде», — дигән уй килде. Гардероб ишеген, шыгырдамасын дип, сак кына ачты да караңгыда капшанып карады. Куллары мамыктай йомшак йонга кагылды, сыпырып карады,— бу жилетны ул аңа моннан ике ел элек Женевада сатып алган иде. «Ничек мин аны жилетсыз чыгарып жибәрдем соң? Тышта шундый салкын», — дип, үкенеп куйды.

Аның башында шундый хәвефле уйлар чуала, йөрәге борчылып тибә иде.

«Юк, болай ярамый, бүтән нәрсәләр, шатлыклы нәрсәләр турында уйларга кирәк».

Моннан сигез ел элек ул, әнкәсе белән, Шушенскоега, Владимир Ильич янына, сөргендә аның белән бергәләп үз срогын да тутырырга дип киткән иде. Гаять дулкынланган иде ул. Барыннан да бигрәк — очрашуның беренче минутларыннан курыккан иде. Аңа бүләккә дип яшел абажурлы лампа алган иде, аны, юлда ватыла күрмәсен дип бик куркып, саклап алып барган иде. Алты мең чакрым юл буе шул лампаны кулыннан төшермәгән иде.

Май аеның кояшлы бер көнендә озын юлның соңгы чакрымнары да артта калды. Килеп життеләр. Көймәле арбадан ул, кулына шул лампаны тоткан килеш, тантаналы рәвештә төшеп жиргә басты. Тирә-яктагы өйләрнең тәрәзәләре ачылып китте, һәм алардан кешеләр башларын сузып, кызыксынып карый башладылар. Бары тик Зыряновлар өенең тәрәзәләре генә ябык иде. Барысын да белеп торучы малайлар Владимир Ильичның ауга чыгып киткәнлеген һәм кич соң гына кайтачагын әйттеләр.

Владимир Ильичның нәкъ әнә шул моментта өйдә булмавы аяныч иде. Боларның барысы өчен Енисей елгасы гаепле иде, әлбәттә: аның, бозлары күтәрелеп, дингез булып жәелеп киткән чагы иде һәм шул елганы кичеп чыгу өчен, алар, әнкәсе белән, суның ярларына төшеп утыруын көтәргә мәжбүр булганнар иде...

Владимир Ильич кич белән генә ашыгып кайтып керде, ишекне киң итеп ачты да, почмакка өеп куелган әйберләргә карап, тукталып калды.

Надежда Константиновна такта белән генә бүленгән икенче якта тын да алмыйча басып тора иде. Ул монда артык түзеп тора алмады, Ильич янына чыкты. Владимир Ильич чиксез шатланып: «Надюша!» — дип пышылдады...

Стенадагы сәгать биш тапкыр сукты. Вакыт иртәнге биш иде инде. Шулай ук кулга алындымы икәнни? Көтәргә, түземлек белән көтәргә кирәк, дип, Надежда Константиновна яңадан хатирәләргә бирелде.

...Икенче көнне кич Шушенскоеда сөргендәге бөтен компания жыелды: Оскар Энгберг, Проминский һәм аларның күп санлы семья членнары... Владимир Ильич яшел абажурлы лампаны кабызып жибәрде, үзе шуңа гел карап-карап ала иде.

Надежда Константиновна Питер турында сөйләде. Аннары жырлап утырдылар. Владимир Ильич Надежда Константиновнаның шигырь укуын үтенде. Адам Мицкевичның бала чактан ук таныш булган шигырьләре ул кичне гажәп яхшы яңгырадылар:

Әйдә, дуслар, кулны кулга тотышыйк!
Һәм жир шарын безнең сафлар урасын.
Бердәм булсын теләкләр һәм фикерләр,
Кыю жырлар көр тавышка жырлансын.
Кузгалыр жир, яңгырар жыр — без аны
Яңа юлдан йөретербез моннан соң...[1]

Чиркәү чаң суга.

Аңа кушылып, аш бүлмәсендәге сәгать суга.

Надежда Константиновна Ильич барырдай барлык очрашу квартираларын, куңып чыгу урыннарын күз алдына китереп чыга. Аларның һәркайсы Ильичның кайда икәнлеген хәбәр итәрләр иде. Димәк...

«Юк ла, юк! — дип, ул күңелсез уйларын башыннан чыгарып ташларга теләде. — Юкка борчылам мин. Шулай тоткарланып калган чаклары аз буламыни... Менә кайтып керер дә, Мартовның,Данның дәлилләрен ничек итеп жимергәнлеген, мәсьәлә тавышка куелганда күтәрелгән кулларны ничек кычкырып санап торуын һәм үз резолюциясенең күпчелек тавыш алуын күреп ничек шатланганын — барысын да тәфсилле итеп сөйләп бирер».

Бүлмәгә әкренләп иртәнге салкын яктылык керә башлады, барлык әйберләргә тоныксоры төс инде. Тышта дворникның көрәк белән шалтырап эшләп йөрүе ишетелде. Атлы трамвайның беренче звонoклары яңгырап китте. Квартира эчендә дә хәрәкәт башланды. Буяулы идәнгә кухарканың ялан аяк басып йөрүе, самоварны шалтыратып, әвәрә килүе ишетелде. Хужа хатын бала-чагаларын ни өчендер тирги, иртәнгә хас исләр — самовар кабызганда яндырган чыра исе, аяк киемен чистарткан май исе, сабын исләре — бөтен квартирага тарала иде.

Надежда Константиновна бүлмә буйлап йөренде, абайламастан көзгегә күзе төште һәм кашларын жыерды: йокысыз үткән бу бер төн эчендә ул ябыгып киткән, агарынган иде. «Болай ярамый», — дип, үзүзен шелтәләп алды ул һәм юынырга чыкты. Салкын су сафландырып, рәхәтләндереп жибәрә бит.

«Сәгать тугызга чаклы көтәм дә аннары Книповичларга барам, нишләргә кирәген киңәшәм», — дигән карарга килде ул. Өстен күгелжем төтен сыман эләпә каплаган салкын чәйне йотлыгып эчте дә, дәфтәрдән бер бит кәгазь ертып алып, кара савыты төбенә каләме белән төртә-төртә, язасы сүзе турында бераз уйланып утырды.

Ачык, пөхтә хәрефләр белән: «Дус хатыныма киттем, уникедән соң кайтырмын», — дип язды. Төнлә яшерен хат язган булавкасын кофтасыннан алып, язуны шуның белән челтәр пәрдәгә беркетеп куйды. Бу, шулай, күпне тикшерүчән хужа хатын өчен генә эшләнә. Надежда Константиновна аңлый: Ильич монда кайтып кермәячәк инде.

Тәрәзәгә тыштан кар белән бәрәләр. Бер, ике, өч. Кемдер бик төз бәрә.

— Кем булыр бу? Үзе микәнни? — дип үз алдына пышылдады Надежда Константиновна һәм, адымнарын кечкә тыеп, тышкы ишекне ачарга чыкты.

Тышта бик салкын ахры, тимер келә бармакларны көйдереп ала, ул аны ача алмый азапланды.

— Хәзер, хәзер, — диде, бармакларын салкын тимергә өшетеп.

Ниһаять, келәне ычкындырып, ишекне ачып жибәрде. Бусагада буена караганда бик озын куртка, башына колакчынлы бүрек кигән бер малай басып тора иде, жилкәсенә, таякка элеп, буш капчык аскан иде.

Малай, зур кара күзләрен ялтыратып:

— Иске-москы алабыз, шурум-бурум жыябыз, — дип, ятлап алган сүзләрен кабатлады. Надежда Константиновнаның борчулы кыяфәтен

---

[1] Зәки Нури тәржемәсе.

күреп: — Хәтерләмисезмени? — дип сорады ул. — Мин — Ромка, карчыга баласы. Мин сезне беләм, сез Күчмә музейда эшлисез.

— Тс-с-с!.. — дип, Надежда Константиновна бармагын иреннәренә куйды. — Әйдә, бүлмәгә кер.

Ромка, итекләрендәге карны кагып, Надежда Константиновнага иярде.

— Мин сине, Роман, күрү белән таныдым. Берәр нәрсә булдымы әллә? — диде Надежда Константиновна, йөзенә чыккан куркуын яшерә алмыйча.

— Борчылмагыз, — диде Ромка, чак ишетелерлек тавыш белән. — Ефим абый ул-бу юк дип әйтергә кушты. Сезгә хат та бар. Киез итек эчендә, хәзер чыгарам, — дип, малай зур киез итекләрен салды һәм: — Менә, — дип, бераз бөгәрләнгән жылымса конверт сузды.

Надежда Константиновна суыктан һәм дулкынланудан һаман әле калтырап торган бармаклары белән конвертның кырыен ертты да аннан бер бит кәгазь кисәге тартып чыгарды.

«Хөрмәтле Прасковья Евгеньевна, — дип язылган иде анда. — Бездә һавалар бик начарланып китте. Аякларны өшетмәс өчен, яңа киез итекләр сатып алырга туры килде. Сезнең сәламәтлегегез турында бик борчылабыз. Бүген безгә килегез, көтәбез. Акка зәңгәр бизәк төшерелгән хрусталь вазаны да алып килегез...» Акка зәңгәр бизәк төшерелгән хрусталь ваза... — дип кабатлады Надежда Константиновна һәм шатлыктан күзләре ялтырап китте.

«Нинди бәхет, ул исән, кулга алынмаган. Эзәрлекләүләр бик хәтәр булган. Финляндиягә качып яшеренергә туры килгән... Менә «Ваза» дачасында көтә», — дип уйлады Надежда Константиновна.

— Рәхмәт, дускай, рәхмәт, — дип, малайның кулларын кысты. — Бирегә ничек килеп җитә алдың син? Артыңда «койрык-мазар» сизмәдеңме?

— Сез нәрсә? Әллә мине кечкенә дип беләсезме? — диде Ромка. — «Койрык» белән мин бирегә килеп тә тормас идем.

Надежда Константиновна сумкасыннан «Испания королевасының муенсасы» дигән китапны чыгарды.

— Моны Ефим Петровичка тапшыр, хәзер үк. Ә менә монысын үзеңә ал, — дип, Ромкага чәчәкләр, рәсемнәр белән бизәлгән кызыл тышлы китап сузды. Аның тышына, алтынланган түгәрәк эченә, зур хәрефләр белән «Жюль Верн әсәре. Серле утрау» дип язылган иде.

Ромка китап битләрен ачкалап карады да аны күкрәгенә кысты — китапның рәсемнәре бик күп икән һәм барысы да бик кызыклы рәсемнәр икән!

— Кызыклымы? — дип сорады.

— Бик кызыклы китап. Бала чагымда мин, аңардан аерыла алмыйча, рәттән ике тапкыр укып чыккан идем, — диде Надежда Константиновна һәм бүләкнең малайга охшавына бик канәгать булып калды.

— Моны миңа бөтенләйгә бирәсезме? — диде Ромка, шулай буласын өмет итеп.

— Әйе, әйе, әлбәттә.

Малай ике китапны да саклык белән генә күен эченә салды.

— Рәхмәт. Мин чаптым, — диде ул кинәт ашыгып.

— Үзеңә рәхмәт, — диде Надежда Константиновна. — Ефим Петровичка миннән сәлам тапшыр, аңа әйт, вазаны мин бүген үк илтермен.

Ромка китте. Надежда Константиновна Владимир Ильичның йон жилетын, үзенең кара тасма белән каелган соргылт кофтасын һәм тагын башка вак-төякләрне юл сумкасына тутырды.

«Менә безнең барлык мал-мөлкәтебез шунда. Әйбәт! Әйберләр кешене бер урынга бәйләп тота», — дип уйланды ул.

* * *

Надежда Константиновна поезддан Куоккала станциясендә төште. Ап-ак карда күзне камаштырырлык булып кояш нурлары чагыла. Карлы кыр буйлап урманга чаклы ак тасма сыман сукмак сузылган. Урман эче тып-тын. Агач башларыннан жем-жем итеп бәс коела. Агачларның инде жылына башлаган кәүсәләре төбендә чокырлар хасил булган, болары инде яз якынлашу галәмәтләре.

Урман эчендә, зур ябалдашлы наратлар астында сыенып утырган кечерәк кенә агач йорт бүген аеруча матур булып күренә: манаралы веранда өстендәге кар бүрек һәм карнизләрдән тәрәзәләргә асылынып төшкән кар өемнәре бу йортка әкияттәгедәй гажәеп төс биреп тора иде.

Надежда Константиновнаны Владимир Ильич тәрәзәдән үк күреп алды һәм аны каршы алырга чыкты.

— Ниһаять, килдең! Син бик дулкынлангансың, борчылгансыңдыр, бөтенләй йокламагансыңдыр? — дип, борчылып сорашты ул.

— Юк, юк, үлеп йокладым, — дип җавап кайтарды Надежда Константиновна. — Иртә белән мине Ромка килеп уятты. Ефим Петровичтан хат китерде. Миңа бөтенесе билгеле. — Өйдән ишетелгән тавышларга колак салып: — Синдә халык җыелган дамыни инде? — дип сорады.

— Әйе. Съездга тактик платформа әзерлибез. Әйдә, керик, син дә безгә булышырсың.

Надежда Константиновна сумкасыннан Свифт китабын чыгарды:

— Синең заметкаларын миңа шушында.

— Гулливер эчендә?!. Нәкъ кирәк вакытында килеп житте.

Владимир Ильич Надежда Константиновнаны аш бүлмәсенә алып керде.

Ул, үзен сиздермәскә тырышып, почмактагы бер буш урындыкка шыпырт кына барып утырган иде, ләкин шунда ук аны иптәшләр чолгап алдылар, шау-гөр килеп сәламли-тәбрикли башладылар.

Ул игътибар үзәгендә булуны бер дә яратмый иде, уңайсызланып калды һәм үзенең шундый оялчан булуына ачуы да килде, шуңа күрә тагы да каушый төште. Аны бу хәлдән Владимир Ильич коткарды.

— Ярый, дәвам итик, — дип, ул иптәшләрне үз янына чакырды.

Владимир Ильич өстәл яныннан торды да маңгаен, башын сыпырып алды һәм, кулын күтәреп, илһамланып сөйләп китте:

— Эшчеләр сыйныфы артыннан халыкларның киң массасы күтәрелә, һәм бу көч буржуаз-демократик революцияне тулы җиңүгә илтеп житкерер, ә шуннан соң эшчеләр, ярлы крестьяннар белән бергәләп, көнбатышта социалистик переворот эпохасын башлап җибәрерләр. Ничек? — дип бәхетле бер көлү белән көлеп җибәрде ул. — Уйлап кына карагыз, иптәшләр, хәзерге күнелсез тынлык — давыл алды тынлыгы гына бит ул. Әйе, контрреволюция тантана итә. Әмма бу тантананың гомере кыска. Бөтен дөнья өстенә алсу таң җаелә. Пролетар революция булачак һәм ул җиңәчәк, һичшиксез, җиңәчәк, иптәшләр...— Я, я,— дип, шатланып шаулаша башлаган иптәшләрен туктатты ул. — Бераз хыялга биреләдек, әйбәт хыялландык, ә хәзер, ягез, безнең чираттагы революцияне тикшереп карыйк. Дәүләт Думасын без парламент дип түгел, полиция канцеляриясе итеп таныйбыз һәм ул сайлаулар кәмитенә катнашуны кискен рәвештә кире кагабыз. Бу мәсьәлә буенча да безгә меньшевиклар белән якалашырга туры киләчәк...

Монда җыелган Питер эшчеләре гади эскәтер җаелгән зур аш өстәле тирәсенә утырышканнар. Һәркайсының алдында — язып тутырылган дәфтәр... Берләштерү съездына әзерлекнең иң кызу чагы бу. Эшчеләр сыйныфының эш-хәрәкәткә керешү өчен бердәм программалы — большевистик программалы — бердәм партиясе булырга тиеш.

ГАЗИЗ ИДЕЛЛЕ тәрҗемәсе.

*Әнгам Атнабаев*

## Эш

Эшнең нинди дә җиңел түгел,
Эшнең нинди дә арыта:
Билләреңне бөгеп, станокта
Деталь кырып кара — арыта,
Озын көннәр буе комбайнда
Иген урып кара — арыта,
Шигырь өчен рифма корып кара —
Арыта.

Ул арыта беләк мускулларын,
Ул арыта акыл мускулын.
Арытучы шушы авыр йөкне
Үз җилкәмә сала үз кулым.

Бу йөкне мин җиңеллектән түгел,
Кирәк булган өчен күтәрәм.
Мәҗбүри дә,
ләкин кадерле дә
Бу йөк миңа бик күп йөкләрдән.

Ышанычлы бар байлыгым шунда —
Ашарыма икмәк шул йөктә,
Киярemә күлмәк шул йөктә,
Туган илгә терәк шул йөктә;
Авыр икән, әйдә, авыр булсын!
Һәм булсын ул һәрчак биектә!

Мин ризамын, билләремне бөгеп,
Станокта деталь кырырга,
Озын төннәр буе йокламыйча
Шигырь өчен рифма корырга...
Арырга!
Тик язмасын минем язмышыма
Бер минутка эшсез калырга.

## Мирас

*(Улыма)*

Үзем үлгәч,
сиңа мирас итеп,
Биреп калдырырлык мөлкәт юк:
Алтын-көмеш тулы келәт юк,
Йорт-җирләре белән бакчам юк,
Саклык кассасында акчам юк...
Уңга баксам,
сулга баксам — юк.
Мин калдырам сиңа мирас итеп —
Эш эшләргә куллар калдырам;
Бу тормыштан күпме байлык тия —
Шул кулларың эшләп алырлар.
Мин калдырам сиңа мирас итеп —
Юл йөрергә аяк калдырам;
Бу тормышта күпме барыр җирең —
Шул аяклар алып барырлар.
Мин калдырам сиңа мирас итеп —
Күрер өчен күзләр калдырам;
Бу тормышта күпме гүзәллек бар —
Шул күзләрең ятлап алырлар.
Һәм калдырам сиңа иң кыйммәтен —
Мираслардан мирас — баш бирәм;
Бу тормышта ничек торырыңны
Үзең уйла шушы баш белән.

## Кешегә нәрсә җитми

Бу кешегә һәрчак нәрсә җитми:
Кара икмәк булса, ак җитми,
Шуышып йөргән чакта аяк җитми,
Җәяү йөргән чакта ат җитми,
Аты булса машинасы җитми,
Очар өчен ракетасы җитми...
Планетасы җитми...
Күк җитми...
Бу кешегә ифрат күп җитми!

Шул кешегә ләкин кайчагында:
Башларына кайгы төшепме,
Бинахакка гаеп күтәрепме,
Гамьсезлектән җаны өшепме,
Ап-акны да кап-карага буяп,
Матурны да ямьсез күргәндә,
Якты дөнья белән бәхилләшеп,
Һәлакәтен эзләп йөргәндә,—
Шул юлыннан тартып алыр өчен
Кешегә бит ифрат аз җитә —
Бер җылы сүз —
Күңел эретерлек наз җитә!

## Юлда кирәк икән...

Юлга чыккач, юлда кирәк икән —
Чишмәләрдән сорап су алдым;
Дингезенә барып житалмадым,
Чишмә тирәсендә чуалдым.
Юлга чыккач, юлда кирәк икән —
Батырлардан сорап көч алдым;

Бозау кебек юаш малай идем,
Күпме дошманнардан үч алдым.
Юлга чыккач, юлда кирәк икән —
Юлчылардан сорап тоз алдым.
Сорар идем, сорар кешесе юк,
Сорап тормаенча кыз алдым.

## Бер генә

Баш өстемдә кояш — бер генә,
Аяк астымда жир — бер генә,
Йөрәгем — бер,
яшәр гомерем — бер...
Мәхәббәт тә микән бер генә?

Тик бер генә микән жан яраткан,
Кабатланмас микән кабаттан?
Жирдәгене миңа буйсындырып,
Күктәгене миңа караткан
Көнем кайтмас микән кабаттан?

Ул еракта инде, еракта.
Үзе китми ләкин йөрәктән.
Нинди мәрхәмәтсез законнар
Кешеләрне шулай өйрәткән —
Бер мәхәббәт китми йөрәктән!

Баш очымда янган ут шарыдай,
Аяк аста яткан жир шарыдай,
Мәхәббәт тә икән бер генә.
Шул бер генә өчен бу дөньяда
Газапланмый икән кем генә?!

## Үлем килгәч

Килдеңме?
Гомер итте — житте, дидеңме?
Фани дөньялардан тегесенә
Алып китәргә дип килдеңме?

Рәхмәт инде —
исем-фамилиямне,
Адресымны сорап белгәнсең,
Әллә кайда, бигрәк ерак тора,
Бармыйм димәгәнсең,
килгәнсең.

Килгәнсең дә...
Ләкин бик тиз генә
Китеп булмас әле бирелән,
Чөнки жибәрмиләр:
Бурычы күп, диләр, бирергә.

Санап бетергесез
бурычым күп:
Уттан ялкын алдым — бирмәгән,
Судан салкын алдым,
Табигатьтән
Күпме акыл алдым — бирмәгән;
Кешеләрне күпме мәшәкатьләп,
Күпме вактын алдым — бирмәгән,
Тау зурлыгы бәхет вәгъдә итеп
Хатын алдым...
Бәхет бирмәгән.
Бирмәгәнмен жиргә туган өчен,
Жирдә торган өчен бирмәгән,
Белләгемдә,
йөрәгемдә ята —
Биреләсе көчем бирмәгән.

Алып жыйганмын да бирмәгәнмен,
Гомер үтеп бара тиктәскә;
Шулай булгач, китеп булмый инде,
Туры килә пока үлмәскә.
Үлем тикле олы башың белән,
Дәрәжәсен төшереп данының,
Син башкача үзең килеп йөрмә,
Вакыт житкәч, үзем барырмын.



*Фатих Хөсни*

# Язмыш шуклыгы

*Повесть*

## I

Бик үк зурдан булмаса да, пөхтә җыештырылган, стеллажлары академик басмадагы томнар, ялтыратып төпләнгән башка бик күп китаплар белән шыплап тутырылган тын, җайлы кабинетында көндәлек почтаны караштыргалап утыручы Хәнәфи Ризвановка хатыны Гайшә ханымның һич искәртүсез килеп керүе ошап ук җитмәсә дә, аны-моны сиздермәде, төсенә чыгармады.

— Я, хуш, нанысай, кичектерергә ярамый торган берәр сүзең килеп чыктымы әллә? — дип, шаярту катыш чәнчеп куйды ул, газеталарын бер якка таба шудырып. Бу сүзләрдәге, бигрәк тә аларның әйтелешендәге җиңелчә иронияне шундук сизеп алган Гайшә ханым шулай да озак нечкәртеп тормады. Аның, чынлап та, җитди бер сүз әйтү өчен кергәнлеге ире янына бик үк якынлашмыйча туктап калуыннан ук сизелеп тора иде.

— Сүзем бар иде шул, әтисе, — диде Гайшә ханым, беравык тын торганнан соң, — синең янына килергә дә куркыныч, ай-һай, бик эшем кешесе булып киттен соңгы вакытларда.

Озак еллар бергә гомер иткән ир белән хатын арасында батмый торган тәкәллефне бер якта калдырып, Гайшә ханым шундук ире өстендәге халатның төймәләрен ычкындыра башлады.

— Шушы каткан халатыңнан чыгасың булмады, әгәр өстеңнән йолкып алмасаң.

— Тән иләшкән шуна, нишләтәсең... Бер иләшкәч менә синең белән дә, көпә-көндез кешене чишендерергә тотынган хатын белән дә торырга туры килә, — дип шаярткан булды тегесе, бүтәнчә каршы килә алмагач.

Җинсез свитердан гына калган доцентның итсез калак сөякләре килешсез тырпаеп тора иде. Бер башлагач, хатын свитерга да бәйләнергә тотынды:

— Хәзер үк бусын да, бөтен өстен-башыңны алыштыр. Үзеңне тәртипкә китер. Тиз генә менә бу щетинаңны кырып алганда да ярар иде.

Юк, кайда монда җорлык белән генә котылып калырга! Монда ачыктан-ачык ниндидер көтелмәгән бер вакыйга өлгереп килүе күз алдында, ә көтелмәгән вакыйга Ризвановны һәрвакыт уйга калдыра, шиккә төшерә, вәсвәсәгә батыра иде.

— Һич югы әйтеп сөйләш, Гайшә. Нишләргә кушасың син миңа? Ягъни сакалны-мыекны кыргач, өсне-башны алыштыргач, ни булачак дигән сүзем?

Бу — нәкъ шул Гайшә ханым көткән минут иде булса кирәк. Хатын сынын бераз турайтты, тантаналы-горур кыяфәт алды һәм, һич кабаланмыйча, шул ук вакытта икеләнергә урын да калдырмаслык итеп әйтеп салды:

— Безнең Рөстәм бүген үзенең кызын, синең белән минем булачак киленебезне алып кайтам дип китте.

— То-есть ничек? Мин аңлап җитмәдем. Бөтенләйгәме?

Ризвановның кинәт аптырабрак калганлыгы тавышына, төсенә бәреп чыкты, дөресен әйткәндә, мондый хәбәрне ишетергә ул бөтенләй әзер түгел, бу турыда уйлаганы да, башына китергәне дә юк иде. Хатыны аңарга ярдәмгә килергә ашыкты.

— Котың очмасын, хәзергә әле бөтенләйгә түгел. Безгә күрсәтәсе килә булса кирәк. Шул уңайдан кыз да безне күреп китсен ди торгандыр.

— Нишләп куркыйм, ди. Алып кайта бирсен, күрсәтә бирсен... Тик әле болай гына... Малай гына дип йөри идем бит әле мин аны... Үзе шулай дидеме? Синең коткың белән эшләнгән эш кенә түгелме? Ай-һай! Кызу тоталар хәзерге яшьләр эшне, кызу тоталар.

Әлеге шул калак сөякләрен калкытып күрсәтә торган җинсез свитердан килеш, нәрсәгә барып тотынырга һәм ни дип әйтергә белмичә, өстәл тирәли бераз йөренгәннән соң, ул чыгып киткән Гайшә ханымны яңадан чакырып кертте.

— Кара әле, Гайшә, — дип башлады, бу юлы инде батыррак тавыш белән, — әллә, мин әйтәм, аяк астыннан килеп чыккан бу ыгы-зыгыны миннән башка гына уздырып җибәрәсезме? Беләсең минем нинди вакыт икәнлеген... һәм, гомумән, килен сайлау эшендә мин үземне бик профан кешедер дип уйлыйм.

Ләкин аның бу тырышлыклары нәтиҗә бирмәде. Гайшә ханым үз дигәнендә нык тора, мондый тантаналы эштән картын читтә калдырырга һич риза булырдай күренми иде.

Алайга киткәч, хәер, Ризванов та сынатмаска булды. Тиз генә сакал-мыекны кырып атты. Өстен-башын алыштырды. Хәтта берара меланхолиягә бирелеп:

— Шулай картаеп та барабыз микәнни без? Картаябыздыр шул, малаең шундый эшләр артыннан йөри башлагач, — дип үзалдына сөйләнеп тә алды. Аннары бер сәбәпсезгә хатыны янына кухняга чыгып, нидер әйтергә җыенып та әйтмичә, янә борылып керде. Залдагы өстәлгә — кардай ак ашъяулык җәелеп әзерләнеп куелган табынга күз төшерде. «Берәр вино-мазар куяргамы икән соң? Әллә ул чаклысы килешмәсме?» дип уйлап торды, нинди дә булса бер карарга килә алмады, бу чаклысын үк хатыныннан сорауны шулай ук килештерми иде. Кыскасы, һич көтмәгәндә килеп чыккан бу ыгы-зыгы фәннәр докторлыгына диссертация яклау алдында торган үтә җитди Ризвановны яхшы ук чыгырыннан чыгарып ташлаган иде.

Бер караганда, сәбәбе дә юк түгел монын: әнә бит, һич уйламаганда малае үсеп җиткән, кыз күрсәтергә дип йөри, имеш. Бәлки, аптырарга түгел, шатланырга кирәктер бу эшкә. Димәк, анын малае цивилизациянең читенә үк барып чыккан шыр сыйрак түгел икән, әти-әнисе белән исәпләшә, аларның киңәшен көтә, имеш. Ләкин шул ук вакытта Хәнәфи Ризвановны уйланырга мәҗбүр иткән икенче сәбәп тә юк түгел: нинди киңәш бирергә икән соң мондый вакытта? Һәм гомумән үзен ничек тотарга тиеш булыр икән ул? Бирерсең бер киңәш, ә соныннан үз киңәшең үз башына бәла булып килеп төшсә? Бигрәк аптырата торганы тагы шул: моңарчы бит ул малаен бар дип тә белмәде. Бөтенесен Гайшә ханым кайгыртты. Гайшә ханым улының өсте-башы турында уйлады, мәктәпкә — ата-аналар җыелышына чакырсалар, Гайшә ханым чапты. Ә әти кеше, доцент Хәнәфи Ризванов, акча эшләп китерүче — минем шул җиткән, дигән төслерәк бер караштa йөрде. Соңга таба малай анасын да артык борчымыйча һәм, кайбер булдыксыз иркә җаннар кебек, блат эзләп таныш-белешләренең ишекләрен кагарга мәҗбүр итмичә, югары уку йортына керде, азмыйча-тузмыйча укыды, әле хәзер дә менә, дүртенче курс студенты булгач та, һич гарьләнмичә, малай чактагы кебек, киного барыр өчен әнисеннән акча килеп сорый... Кыскасы, акыллы малай, башлы малай булып чыкты кебек аларның Рөстәмнәре. Ләкин, нәкъ менә шушы хакыйкатьне аңлый барган саен, Хәнәфи Ризванов үзендә беркадәр уңайсызлану хисе тоя. Уйлана. Уйларының очына чыга алмый. Моңа хәтле үз акылы белән йөреп торган егет нишләп соң әле бүген генә әтисеннән акыл сорый? Монда анын берәр яшертен үпкәсе, кинаяләп әйтергә җыйналган дәгъвасы ятмыймы?

Хәнәфи Ризванов, үз-үзеннән качарга теләгән кебек, яңадан кабинетына керде, шүрлекләрдәге китапларның әле берсен, әле икенчесен алып, актарып карады, ләкин берсеннән дә үзенең бу минуттагы рухи халәтен аңлатырлык киңәш сүзе яки, алай-болай җае чыгып, әйтергә туры килсә, яшьләргә ачык кына әйтеп бирерлек кулай цитата тапмады.

— Кара әле, Гайшә ханым, — дип куйды ул кинәт, галәттәгечә үтә нәзакәтлелек күрсәтергә тырышып, — бәлки, син мине бу мәшәкатьтән коткарырсың, ә? Мин сиңа ышанам, әгәр ни... теге килен булачак кеше сиңа ошаса, миңа, шат, ошар. Минем кичектерергә һич ярамый торган бик важный бер эшем бар икән.

Ләкин әти кеше китеп өлгерә алмады, ишектә звонок зыңлады һәм шаулап сөйләшә-сөйләшә яшьләр килеп керде.

## II

Ике кеше дип чамалап көткәннәре өчәү булып чыкты. Егет белән кыз икәүдән-икәү генә күренергә яхшысынмаганнар булса кирәк, кызлары икәү, икесе дә Рөстәм белән бер курста укучы студенткалар булып чыкты.

— Таныш булыгыз, дүрт елдан бирле минем белән бергә укучылар, — дип таныштырды Рөстәм.

Картлар икесе дә бердән таркалып калдылар. Гайшә ханымның яшен тизлегендә «Боларның кайсысы икән?» дигән кызыксыну белән алды. Шулай да ул, әләп саклап, гөрли алганча гөрләргә, ачык чырайлы булырга, нәзакәтлелек күрсәтергә тырыша иде. Ә Ризвановка килгәндә, аның турында ни дип әйтергә дә мөмкин түгел, кызлар ишектә күренүгә, ул сәер бер халдә калды: битеннән алсу-кызыллык йөгереп узды, курыккандай кинәт артка чигенде, шундук үзен кулга алырга тырышып, сүз кыстырырга маташты, теле әйләнмәде, сүз урынына билгесез бер ымлыклар гына килеп чыкты.

— Әйттем ич мин, картлар үзләре югалып калмаса, безгә югалып калырга урын юк, дип...

Бу минутта иң айнык һәм иң сүзчән кеше — яшь Ризванов үзе иде. Ул, кызларның әле берсе, әле икенчесе каршына килеп, ничек тә булса өлгерлек күрсәтергә тырыша: кулларындагы әйберләрен алып куя, тиз генә зал ишеген ачып, кунакларны залга чакыра, гөрли алганча гөрли, гөрләве барып чыкмаса, яшьләрчә тәкәллефсезлек белән бераз таушалган шуклык әйтүдән дә тартынмый иде.

Яшьләрнең үзара ыгы-зыгы килүеннән файдаланып, тизрәк кабинетына кереп, күздән югалырга ашыкты карт Ризванов. Әмма бу тантаналы-тынгысыз минутта Гайшә ханымның да ялгыз гына каласы килми иде булса кирәк.

— Син, әтисе, һич югы кунакларны табынга утырткач тотынып иден эшеңә, юкса бу яшь-җилкенчәк арасында ялгызым гына югалып калуым бар минем, — дигән булып, иренә каршы төште.

— Каушама, әни, әтине алыштырырга монда мин калам, — дип, тагын бер гөрләп алды Рөстәм. Егетнең бу минуттагы күтәренкелеге картлар арасындагы каударлануны кунакларга сиздермичә күмеп калдырырга бик тә җитәрлек иде һәм, гомумән, үтә ачыктан-ачык иде ул бу минутта, — мин генә җитмәсәм, менә Муся... Юк, ялгыш ычкындырдым, Мәнәвәрә бар.

Һәм ул, кызларның икесенә берьюлы мөрәҗәгать итеп, ярым шуклык, ярым кисәтү белән, аларның исенә төшереп узуны кирәк тапты:

— Җае чыкканда, комментарий бирә китим, безнең бу өйдә жимереп булмый торган ике табу бар: берсе — бездә кешеләрнең исемнәрен бозып әйтү категорически тыелган. Икенчесе — бездә самообслуживание, кадерле кунаклар. Кыстатып торыш юк. Кайда нәрсә кулга төшерә аласың, шунда ук кап та йот. Шулай бит, әни?

— Кеше ышандырырсың юк-бар сүзләрең белән, — дип, «ычкынып киткән» малаен тизрәк урынына утыртырга ашыкты Гайшә ханым. Шулай да ул, табынга ваза белән алма китереп куйган арада, ялгыш кына күзе төшкәндәй итеп, Мәнәвәрә атлы кызга игътибар беләнрәк карап узмыйча кала алмады. «Әллә шушысымы икән?» дип уйлап куйды күңеленнән. Малаеның бу кыз тирәсендә үтә тырышлык күрсәтеп бөтерелүе шулай уйларга да нигез калдыра иде, әлбәттә. Хәер, Гайшә ханымга табышмак корып озак баш ватарга туры килмәде, табынга утыруга, Рөстәм, мона чаклы аңарда һич күрелмәгән уенчаклык белән, алдын-артын уйлап тормастан, тезеп китте:

— Менә бу Мөнәвәрә атлы кызда, әни, гаҗәеп бер чир кузгалган. Төнлә йокысыннан уянып әнисен сагынып елап утыра, имеш. Врачлар аңарга общежитиедә торуны категорически тыйганнар. Врачлардан да бигрәк комендантка барып ишетелгән. Ә комендантлары бик алама нәрсә: кирәкми миңа елак кыз, дип куйган мәсьәләне. Кая барсын ул хәзер? Институтны бетерергә күп калмады, әллә, мин әйтәм, бездә генә торсынмы укып бетергәнче? Елап тик ятсын безнең теге бакчага карый торган кечкенә бүлмәбездә.

— Без ничек карарбыз бит әле? Җибәрербезме икән соң? — дип, шуклыкка каршы шуклык белән арага керергә маташты кызларның икенчесе. Бу икенчесе, Клара атлы кыз, үзен гомумән бик иркен тота, җае чыкканда сүзгә кесәгә кереп тормый, тик менә алманы гына тиешенчә таныл җиткерми икән, кызыл дип алданып, иң каты әнис алмага сузылды да инде хәзер шуны ничек бетерергә белмичә азаплана, үзе бертуктаусыз сөйләнә, шул башлаган әче алмасын бетерсә, әле тагын да күбрәк сөйләнер кебек күренә иде. Үзен шулай артык хөр тотып, юкны-барны күп сөйләвеннән һәм шуңа ук алма таный белмәвен дә кушып, Гайшә ханым эченнән генә үзенчә хөкем чыгарырга да өлгерде:

«Юк, бусы түгелдер, Рөстәмнең башын-күзен әйләндерә алмас бусы. Түгелдер».

Аның каравы кызларның икенчесе, Мөнәвәрә атлысы, аз сүзле булуы, тыйнаклыгы һәм, дөньяга бүген генә килгән кеше кебек, оялчанлыгы, ризыкка кыяр-кыймас кына сузылуы, барыннан да бигрәк, бөтен торышыннан, үзен тотышыннан бөркелеп торган самимилеге белән Гайшә ханымны яхшы ук җитди уйландырган иде. «Авызыннан сүзен ала алмыйча тецкәң корыр, әгәр бусы киленең булса», — дип уйлап куйды ханым бер яктан. Шул ук вакытта: «Бөтенесе эчендәдер әле, хәзергә соңга калып чыккан каз бәбкәсе кебек читтә генә чүгеп торса да»,— дип тә шикләнә иде.

Әмма кызның бер ягы аны һич искәрмәсез һәм тоташы белән үзенә җәлеп итте: бу — кызның күз карашы иде. Нәрсәдер моңлы, яшертен серле, бер үк вакытта назлап та, өркетеп тә ала торган тылсымлы ут бар иде аның күз карашында. Бичара ана нишләсен, үзен тыеп торырга, ашыгыч нәтиҗәләр ясамаска бик тырышса да, үзенә-үзе әйтмичә булдыра алмый: әйе, ул риза, ул бу сөйкемле кызны үз баласы итеп өйләренә алырга башы-аягы белән риза, тик менә малаеның бик ерык авызланып сөйләнеп утыруын гына ошатып җиткерми — «Үен гына түгелме икән аларның бу йөрүләре?»

Өстәл янынннан кузгалышып, кунаклар китәргә җыенгач, игътибар итте Гайшә ханым: бу Мөнәвәрә дигәне буйга артык зур да түгел икән. Бик алай күзгә ташлана торган җире дә юк, хәтта яшенә караганда бераз бала сымаграк та күренә икән. Шулай да чыгып киткән чакта, әлеге теге мөлаем карашын сирпеп, кыяр-кыймас кына:

— Хушыгыз, Гайшә апа... зинһар, гаепләп калмагыз, — дигән берничә сүз белән Гайшә ханымның күңелен бөтенләй эретеп китте кызый.

Юк, Гайшә ханым бу мәсьәләне болай гына уздырып җибәрер дәрәҗәдә түгел иде. Шунлыктан, кунаклар китеп, карты күренү белән, шелтәле итеп:

— Бик килеште инде шулай... балалар кебек кешедән качып калу,— дип ирен тиргәп алды. Ләкин бу сәгатьләрдә, әле өйдә яшьләрнең шаушулы өне сакланган һәм үз күңеле билгесез сөенеч тоеп рәхәтлек кичергән бу бәхетле сәгатьләрдә ул — ана кеше — үпкә саклап озак тора алмады. Табынны җыеп, анысын ары, монысын бире куйганнан соң, күңелен кытыклап торган зур сүзне тизрәк бүлешергә теләп, иренең кабинетына барып керде. Һәм чын-чынлап аптырап калды: ире Хәнәфи Ризванов, әле генә «Эшем куп!» дип өтәләнгән кеше, бер нәрсә дә эшләмичә, утә нык таркалып, кулларын күкрәгенә кушырып утырган хәлдә, тәмам оеп калган иде.

Аяк тавышыннан кинәт сискәнеп куйды ул... Ә инде хатыны әле күптән түгел генә чыгып киткән кунаклар, аларның ошап-ошамаулары турында сүз кузгаткач, күкерт кебек кабынып китүен үзе дә сизмәде.

— Үз мәшәкатьләрем дә муеннан... Зинһар, башымны катырмагыз юк-бар сүзләрегез белән.

Гадәттә үзен рамкада тота белә торган утә интеллигент һәм бик тә назакәтле иренең кинәт болай ташып чыгуы Гайшә ханымның башына суккан кебек булды. Ләкин бу ташып чыгуның сәбәпләрен ул әлегә белми иде. Ә сәбәпләрен белмәү, үз нәүбәтендә, аны бигрәк тә борчый иде.

## III

Малайлары Рөстәм, мәсьәләне икенче көнне үк кабаттан яңартырга ашыкмаса да, олыларның фикерләрен ишетергә бик теле, җае чыкканда, читләтеп-читләтеп кенә булса да, әнисеннән бу турыда сорашкалап та куйгалый иде. Җаялар эчендә шуны да әйтергә мөмкин, ул гомумән күп эшен әнисе аша эшли. Кинога акча кирәк булса, — әни. Костюмы

туза башлаганны сизсә, алдан ук әнисенең исенә төшерә. Соңгарак калып кайтасы булса, ишек ачарга шулай ук әни кирәк. Әтисен ул, әллә артык зурлаганлыктан, әллә тегенең эшкә чумган бер кеше булуын истә тотып, бик сирәк борчый, хәтта — хәзерге күзлектән караганда бераз ятрак та янгырый — аңардан чак-чак кына өркә дә иде булса кирәк.

— Теге икесен ошатмаган булсагыз, тагы икене алып килеп күрсәтә алам, безнең институтта кызлар күп, — дип, шаярткан булып, сүз кузгатты ул бер көнне. Малайның әлеге эшне онытмаганлыгы, онытырга җыенмавы, олыларның фикерен ишетәсе килгәнлеге әллә кайдан сизелеп тора иде. Ә менә Гайшә ханым аңарга ачык кына берни дә әйтә алмый, ачык әйтә алмавының сәбәбе — хәзергә кадәр бу турыда картыннан үзенең ачык бер җавап ала алганы юк иде. Хатыны алай-болай кыек атып туры тидерергә маташа башлады, Ризвановның сүзе гел бер:

— Ул турыда уйларга вакыт тигәне юк, кычытмаган җирецне кашырга ашыкма, — белән бетерә килә иде. Хәзергә олылар фикерен көтеп тыныч кына йөргән яки шулай күренергә тырышкан Рөстәм көннәрнең берендә, бу юлы инде һич искәртүсез, әлеге теге «каз бәбкәсе» Мөнәвәрә белән янә кайтып керде. Хәер, кызыклы хәл, егетнең әнисенә Мөнәвәрә бу юлы бик алай «каз бәбкәсе» булып күренмәде. Беренче күрүендә ялгышканмы, хәзер күзләре саташтырамы, бәлки, өстенә кигән күлмәге үзгәртебрәк җибәргәндер, бу юлы кыз Гайшә ханымга ничектер үскән сыманрак булып күренде. Теге вакыттагы артык оялчанлыгы, йомыклыгы да югалган, кыскасы, гап-гади җәйге күлмәктән, бернichек тә кырланып-сырланып тормыйча килеп керде дә самими генә итеп күреште һәм әлеге шул талгын-моңсу карашын бер сирпеп куйды. Бөтенесе әнә шул булды. Шул арада әни кеше улы Рөстәмгә дә күз төшереп алды. Бу юлы аның Рөстәме дә ничектер үзгәргән, теге вакыттагы кебек күп сүзле түгел, теләнә ни кылсә шуны атып тормый, басынкы, әмма ничектер яктырып, эчке балку белән балкып киткән сыман күренә, ихтимал, кыз белән искәртүсез генә кайтып керү, әнисе алдында уңайсызланып басып тору аны шулай тыйнак иткәндер. Бик үк кычкырып әйтергә ярамый торган йомышы булган икән әнисендә: бераз читкәрәк алып китте дә әнисеннән киногa акча сорады. Кошелокның шундук ачыла башлавын күреп, шулай да гадәттәге шуклыгына бирелмичә кала алмады:

— Син инде, әни, бу юлы ике билетлык итеп бир безгә. Өстәвенә берәр морожныйлык та зыян итмәс.

Бирмичә кара әнә шулай сораганнан соң! Һәм әни кеше, сокланып, рәхәтләнеп, аларның артыннан карап калды. Ишектән озатканнан соң, тәрәзәдән карап торды. Кара әле аларның китеп барышларын! Кул очларыннан гына тотынышканнар, иңнәре икесенеке бер тигезлектә диярлек тирбәлә, ничек тигез итеп, җинел итеп, бер тактка баскандай атлыйлар! Күз генә тия күрмәсен... Хәзер инде Гайшә ханымга аларның йөзләре түгел, җилкәләре генә күренә. Ләкин барыбер, һич икеләнмичә әйтә ала Гайшә ханым: урамдагы барлык башка җилкәләр арасында әнә ул ике җилкә тигезрәк, килешлерәк. Бирелеп карый торгач, янә бер кабат ышангандай булды әни кеше: юк, алай кеше күзенә күренмәслек кечкенә түгел икән ул кыз, кыскасы, бөтен җире үз урынында. «Буса габызга баса икән, әйдә, төкле аягы белән бассын!»

Шул кичне, урынга ятар алдыннан, картының эшем кешесе булмыйчарак торган бер минутын тотып, янә шул турыда сүз кузгатты Гайшә ханым:

— Бүген тагы икесе бергә кайтканнар иде, — дип башлады ул, кем турында сүз барганлыгы үзеннән-үзе аңлашылган кебек итеп. — Үзеннен яшь чагыңны хәтерлә, эчеңдә ни бар, бөтенесен селкеп йөрдеңме

икән? Ул балалар турында безгә ныклабрак уйларга вакыттыр, Хәнәфи. Тиздән институтны бетерәчәкләр, кайсын кая җибәреп бетергәнче әллә алар бу турыда уйламыйлардыр дисеңме?

— Мин генә тың йөрәк... Мин генә балалар язмышы турында бер дә кайгыртмыйм инде алайса.

Бу — Хәнәфи Ризвановның хатыны сүзенә каршы килүе дә, аңарга кушылуы да түгел, бу, әгәр шулай әйтергә ярәса, караңгы почмакка карап бер уфылдау, аның үзенә бик мәгълүм булып та, үзеннән башка берәүгә дә, хәтта хатыны Гайшә ханым алдында да чишелмәгән чияләнгән бер төенне ничек чишәргә белмичә өзгәләнүе иде. Әмма эчтән өзгәләнү белән генә бу четерекле хәлдән котылып булмаячагын, гаилә китереп куйган әлеге мәсьәләне озак җавапсыз калдырырга мөмкин түгеллекне, калдырып булмаячакны соңгы көннәрдә Ризванов үзе дә сизенеп йөри башлаган иде инде.

— Син мина, әнисе, һич югы бер атна форсат бир, — дип куйды ул, бу юлы үтә җитди итеп. Һәм, ир белән хатын арасында бу чаклы киеренке җитдилекне ошатып җиткермичә булса кирәк, үзенчә шаярту кыстырып, йомшартырга маташты: — Дипломатия өлкәсендә булса, мондый чәбәләнгән эшкә бер генә атна сорамаслар иде. Мин шул беркатлы, ничә әйтсәң дә. Мужиктан азган доцент.

**Автор искәрмәсе.**

*Хәзер сүзне Хәнәфи Ризвановка бирик. Сөйләү өчен түгел, аның уйлануларын, аның гыйбрәтле эчке монологын, үзе белән үзе сөйләшүен тыңлау өчен.*

*Яшерен-батырын түгел, кеше үз гомерендә яхшылыкны да, яманлыкны да эшли, болар турында икенче берәүгә сөйләгәндә, ул аларның яхшыларын күпертә төшеп, яманнарын киметеп җибәрә, киметеп җибәрүе дә мөмкин, диген сүзебез. Әмма узганы турында үзе белән үзе сөйләшкәндә кеше мондый «тартып җиткермәүләр»не яки, киресенчә, артык «тырышып тартуларны» ясый алмый, үзенә-үзе ялганлый алмый. Шулай икән, нигә безгә Хәнәфи Ризвановның үзен генә калдырып, аңарга узганнары турында иркенләп бер уйланырга ирек бирмәскә? Хәтта моның, без сөйләгәнгә караганда, кызыграк булып чыгуы да мөмкин ич!*

IV

«...Кадалып кына киткере, кайдан калкып чыкты соң әле бу «гордиев узел»? Онытылган иде бит, җиде кат җир астында калган кебек булган иде. Хәер, нигә соң әле мин, чигә чәчләрем агара башлаган карт ишәк, доцент Хәнәфи Ризванов, андый юк нәрсәләргә игътибар итеп, баш ватып утырам? Шул гына калган иде. Докторскийны яклау өчен бөтен игътибарны туплар бер вакытта. Бәлки, әле бу гади бер охшашлык кынадыр? Бәлки, бөтенләй ул түгелдер, мин уйлаган кешенең кеме дә түгелдер? Азмыни бу дөньяда шундый охшашлыклар, саташулар, шул нигездә килеп туган мажаралар, хикмәтләр... Язучылар, сюжетка аптырап йөрүчеләр, шуның белән тамак туйдыручылар азыгы. Яза бирсеннәр, чуарлый бирсеннәр кәгазьне... Ә син, Хәнәфи, эш кешесе, тиздән... булачак профессор. Баш ватма юк белән.

Ә шулаймы соң? Юк нәрсәме соң? Теге чакта да син, тавә кошыдай, башыңны комга тыгып калдың. Турысын гына әйткәндә, куркаклык күрсәттең, качып калдың, егет кешедән сорала торган бер генә адым да, бер генә тәвәккәллек тә ясамадың. Ә нишләп куркаклык? Бәлки, ул вакытта мин инде аңардан суынган ук булганмындыр? Артык бәйләнчеккә әйләнә башлаган иде, шулай түгелме? Төс тә салды, кирәк-кирәкмәс вакытта күренеп, әйгә дә килеп йөри башлады.

Шулаймы? Шулай булдымы соң? Хаталанмыйсыңмы, Хәнәфи Ризванов? Үзеңә үзең ялганлау кылешмы, барысын да төптән уйла. Һич югы егерме биш елдан соң, инде ул эшләр узгач, үзең әйтмешли, инде син зур кеше булгач, объектив була бел, дөреслекне әйтә, хакыйкатьнең күзенә карый бел.

Ә шулаймы? Объектив булыргамы, дөрес булыргамы? Алайса, дөресе аның менә шушы: матур иде ул, акыллы иде, үзен тота белә иде, чибәр кызларга килешә торган дәрәҗәдә чак-чак кына тәкәббер дә иде. Менә бусын инде һич арттырусыз-киметүсез әйтәм, аның белән булганда мин, әлбәттә, бәхетле... бәхетлерәк булачак идем. Хәзер дә, Гайшә белән дә мин үземне төшеп калган кеше дип санамыйм, әмма Маһирә белән һичшиксез икенчерәк булган булыр иде. Ничек булган булыр иде? Анысын әйтә алмыйм. Бәлки, фәкыйрьрәк тә булган булыр идек. Менә мондый өч бүлмәле квартирабыз, импортный мебелебез, шәһәр читендәге дачабыз, доцент дигән дәрәҗәле исемебез, бәлки, булмас иде. Ләкин күңелне һәрвакыт нурландырып, җылытып, гел яхшылыкка, яктылыкка өндәп, бер үк вакытта гел тынгысызлап, минем обывательлегемне гел искә төшереп торучы гадел хөкемдарым-аллам булган булыр иде. Ә хәзер минем ул юк, юк.

Тагын да чишелебрәк ташларгамы? Ничек булган, ни белән беткән — барысын да искә төшерергәме? Әмма татлы да, ләззәтле дә, шигърияткле дә соң бу! Бер үк вакытта, ай, газаплы, әрнүле, җан көеге бер эш йөклисең син үзеңә, Хәнәфи Ризванов.

Нәрсә булса — шул. Баштан икән — баштан. Моны бит үзем генә беләм, үземә генә сөйлим. Аннан кемгә зыян? Я булмаса кемгә файда?

...Утыз бишенче ел иде, җәй башы иде, хәтерлим, дымык кына җәйге кич иде. Безнең пединститутта чыгарыш кичәсе булды. Ул вакытта пединститут үзенең элекке бинасында, паркта иде. Парк, җәй башы, чыгарыш кичәсе, яшьлек. Кыскасы, күңелнең урыныннан купшуы өчен бөтен шартлар җитәрлек иде. Менә шунда, минем әни ягыннан кардәш тиешле кыз туганым, медфак студенткасы Фирдәвес, үзен чакырганга иптәш кызын да ияртеп, безнең институтка килеп керде.

— Менә бу Маһирә булыр, минем подругам, ләкин алдана күрмә, нәнә абый, минем кебек ачык авызлардан түгел, — дип, шундук характеристикасын да биреп, саклыкка да чакырып, мине ул кыз белән таныштырды. Мин, әлбәттә, Фирдәвеснең ул сүзләренә әллә ни игътибар итмәдем. Дөньяга җинел караучы һәм, гомумән, тормышны гел болын өстендә очып йөрү диебрәк аңлаучы бу күбәләк кыз — Фирдәвескәй-кара күзкәй — андый җәйге кичтә ничек кенә очынмас та, нәрсәләр генә сөйләмәс. Мин генә түгел, Маһирә дә игътибар итмәде кебек аның ул сүзләренә. Маһирә дип таныштырган ул кыз кулының очын гына сузып минем белән күреште, андый вакытта әйтелә торган гади генә бер-ике сүз әйтте бугай, нәрсә дип әйткәнен мин, әлбәттә, ишетмәдем, шул арада бу, «Шушымыни инде Фирдәвеснең бик һушы китеп сөйләгәне!» дигән кебек итеп, маңгай астыннан гына диярлек миңа бер карап алды. Бәлки, бернинди мәгънә салып та түгелдер — кешегә кеше карамый буламыни! Әмма мин үзем шунда ук мәгънә салып өлгердем бу карашка. «Бу кыз белән, һичшиксез, танцевать итәчәкмен бүген!» дип, үземә үзем бик ышанып, уйлап куйдым мин эчемнән. Әмма ләкин мин дигәнчә булмады. Кичәнең рәсми өлешендә һәм концертында утырганнан соң, Маһирәбез кайтып китәргә булган. Бер заман минем янга Фирдәвес-очкалак йөгереп килеп җитте:

— Нәнә абый, җан кисәгем, — ди бу, тыны бетеп, — теге Маһирәм минем, «гадкий утёнок», танецка калмыйча кайтып китәргә җыена.

Мин бераз танцевать итмичә китә алмыйм, эти килеп итәгемнән тартса да китмәс идем. Будь рыцарем, абый җаным, озатып куй шул елакны.

Шулай итеп, минем ул Мәһирә атлы кыз белән биергә дигән планым барып чыкмады. Бик үк теләп булмаса да, мин сенелемә ризалык бирдем. Дөресен әйткәндә, килгән-килгән, минем үземнең дә чак кына аякларның тузанын кагып китәсем килә иде.

«Әйдә, кайдан килеп кая китмәгән, сеңел сүзен тыңлап, бер озатып куям икән, савабы әрвахларга булыр», — дип, беркадәр тәкәбберлек күрсәтебрәк, кызга хезмәтемне тәкъдим итсәм, ни колагым белән ишетим, бу «гадкий утёнок» минем рыцарьлыктан баш тарта. Һәм, әйтергә кирәк, чын-чынлап. Имештер, ул кайтыр юлны үзе дә бик яхшы белә һәм хәзергә, аллага шөкер, бернидән дә курыкмый. Ягъни миңа, институт бетереп чыккан яшь филологка, өстендә өр-яңа бостон костюмы утырып торган егеткә һәм шул бостон костюмлы иңбашына кош бастырып куйсаң, кошны тотып торырлык кавалерга шулай ди. Мактанып әйтүем түгел, хәер, бер караганда мактансам да җирендә, ул чагында мин хәзерге кебек тиле сөяк һәм акыллы расчет капчыгы түгел идем, кызларга нинди дә булса тәкъдим ясап, тәкъдимемнең кире кагылуын һич хәтерләмим. Ә бу «гадкий утёнок», төнге энгердә, исе дә китмичә, шәһәрнең бер читеннән икенче читенә олагырга әзер торучы Болак арты кызы, минем тәкъдимемне кире какты. Әле җитмәсә, мыскыл иткән кебек, авызының чите белән генә көлеп куйды. Юк, мыскыл иткән кебек түгел, ул сүзне болай, аптыраганнан әйттем. Мыскыл итеп түгел, ничектер ялварып, моңлы һәм коткылы итеп бер карап куйды бу миңа. Арттырып яки киметеп әйтергә гөнаһысыннан куркам, мине берьюлы куырып алгандай булды ул шул карашы белән. Минем бөтен тәкәбберлегем минуты-секунды белән юкка чыкты, мин әрсезләнеп, үчегеп, үземне үзем белештермичә, сагызланырга тотындым: янәсе, озатам булгач озатам!

Хәер, озак ялындырмады. Турысын гына әйткәндә, егетләр тирәсендә кырык төрлегә бөгелеп-сыгылып, үзенең бәясен күтәртергә маташучы кәҗә бәрәне түгел иде ул. Соңыннан да, ныклабрак танышып китеп, очрашкалый башлагач та мин аның алай «тычканлы-мәчеле» уйнаганын белмим. Әйтте икән «барам» дип, өстенә таш яусын, бара. Бармаска икән, димәк, бармаска — кабат-кабат әйтеп теленне дә талдырма. Сүз уңаеннан тагын бер әйбәт сыйфаты искә төшә — башка хатын-кызлар кебек, чүпрәккә исе китми торган иде. Мин аның чук кебек киенеп чыккан чакларын да күргәләдем, гадәти генә өс-баш белән дә килеп чыккалый иде. Хәер, минем дә төрле чак булгандыр. Ләкин бервакытта да ул моны сүз итеп телгә алып тормады. Мин аның «Менә яңа күлмәк алдым. Килешәме?» дип, кыланып, иңбашларын сикерткәләп торганын хәтерләмим. Хәер, нәрсә кисә, шул килешә иде үзенә — соңыннан булса да әйтим.

Болар гынамы соң! Боларын әле күз алдына килгәннән әйтеп узуым. Кыскасы, үзе шулай чандыр гына булса да башлы кыз, үзен тота белә торган кыз иде. Күрәсең, әти-әниләреннән кергән булса кирәк. Әтисе аның яшьтән үк байларда приказчик булып йөреп, шунда аз-маз газета, китап күреп, революция алдыннан һәм революция елларында эшчеләр хәрәкәтенә теләктәшлек күрсәткән, үзе ише приказчиклар арасында аз-маз агитация эше алып барган, унҗиденче елда партиягә кергән, НЭП елларында, ул чактагы катлаулы сәясәтне аңлап җитмичә, сөрлеккәләгән, ләкин соңыннан яңадан үзенең яраткан эшенә — сәүдә системасына кайтып, совет сәүдәсе өлкәсендә тыйнак кына эшләп килүче намуслы бер совет эшчесе иде. Әйтсә, туры әйтә торган иде. Үз тирәсендәге кешеләрне дә шулай пакь итеп күрергә теләве, беркатлылыгы, яңа төр комсызлыкны күреп җиткерә алмавы башына җитте булса кирәк, шуңарга, бәлки, туры сүзле булуы да килеп кушылгандыр.

Хәер, бу турыда мин әле алда тукталырмын, хәзергә сүз атисе турында түгел, кызы Маһирә турында. Дөресрәге, кыз белән беренче танышуым, аны беренче мәртәбә өйләренә озатып куюым турында. Үзегез беләсез, бу эшнең уставы юк, кем ничек булдыра ала — шулай эшли. Әйтергә кирәк, без култыклашып бармадык. Беренче өне, беренче сүзләре белән үк Маһирә мине ничектер өркетеп өлгергән иде инде. Тротуарның икебез ике читеннән диярлек барабыз, сүз ничектер ялганып китми, бәйләнешсез сүзләр дә ычкынгалый булса кирәк. Һәм шунда кинәт, бер дә уйламаган бервакытта, Маһирә миңа:

— Сез Фирдәвескә бер дә охшамагансыз, Фирдәвес сезнең бик кыланчык. Бертуган сеңелегезме соң ул сезнең? — дигән сорауны биреп куймасынмы! Моны әйткәндә ул йөзен чак кына миңа таба борды, якынлашарак төште. Без якты урамнан бара идек, мин аны беренче мәртәбә аермачык әнә шунда күрдем. Иңеннән яртылаш салынып төшкән җәйге юка шарфы аның тыңлаусыз калын чәчен, әлбәттә, каплый алмаган, шулай ук озын керфекләре дә күзләрен каплый алмаган, ул ачык, рәхимле, ничектер мөлдерәп карый һәм шул мөлдерәмә күзләрендә чак-чак кына ятсыну да бар кебек иде. «Син, егет, барасың инде баруын... тик белеп бар, бернинди дә мәгънә чыкмаячак синең бу штиблет туздырып йөруләреңнән», — дигән кебек күренде аның бу карашы. Әмма теге: «Сез Фирдәвескә бер дә охшамагансыз, Фирдәвес сезнең бик кыланчык», — дигән сүзләре, ул сүзләрне әйткән вакытта тавышының җылы-йомшак яңгыравы минем җаныма кереп урнашкан иде инде.

Тагы шул: капка төпләренә кайтып җиткәч бу, һич көтелмәгән кыюлык белән: «Утырып торыйк бераз, киче бик әйбәт», — дип, капка төпләрендәге эскәмиядән урын күрсәтте. Утырдык. Утыргач, нәрсә турында булса да сөйләшмичә дә калмаганбыз, ләкин нәрсә турында сөйләшкәнебезне һич хәтерләмим. Мин тоташым белән аның, янымда утыручы ул кырыс кызның, ул сөйкемле кызның тәэсире астында исереп калган идем. Әлбәттә, ул вакытта мин инде бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел, кызлар халкын аз-маз күргәләгәнем бар, «кызлар янында гел исереп кенә утырсаң, алар сине мәми авызга саныйлар» дигән ялган теорияне дә белә идем. Шуларның барысын да искә алып булса кирәк, бер заман мин, үзем дә рәтләп сизмәстән, тегенең куллырына сузылганмын. Бары тик сузылганмын гына. Маһирәгә шул җитә калды, утырган урыныннан кинәт сикереп торды, чак кына янгарак тайпылды һәм, сүзләрен өзек-өзек итеп, икеләнергә һич тә урын калдырмаслык ачык итеп, ярып салды:

— Шушының белән точка, егет. Беренче очрашуда ук кулын тик тота алмаган кеше белән соң...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, әйтеп бетергән булса, бәлки, күңелне алай тырнамаган да булыр иде. Һәм минем әйткәнне дә көтмичә, хәтта артына әйләнеп тә карамыйча, капкаларыннан кереп китте.

## V

Юк, мин «точка» куя алмадым бу эшкә. Киресенчә, Җәйге кичтә булган шул беренче очрашудан соң, мин Маһирәләр ягына гел омтылам, аны гел күрәсем килә башлады. Нәрсәсе, кай ягы өчен тартылганымны әйтә алмыйм, әмма күңел гел шул якны каера иде. Фирдәвес сеңелкәш артыннан бер мәртәбә кинога барырга тәкъдим дә ясатып караган идем, батмады. Маһирә, нәрсәнедер сылтау итеп, минем чакыруымны кире какты. Хәер, минем дә гел аны гына уйлап торырга вакытым юк, яна гына аспирантурага калдырылган яшь филолог, сизеп йөрим, өмет белән карыйлар, көтәләр, ашыктыралар. Менә минимумны тапшырырга да әкренләп кандидатлык диссертациясе турында уйлый

башларга, әкренләп кеше арасына керә барырга кирәк. Барып чыкса әгәр, тешкә йомшак кына бер тема да бар, заманына күрә бик отышлы булыр дип уйлыйм: «Соңгы ун еллар эчендә матур әдәбиятта Сталин образының чагылышы». Кафедра үзе тәкъдим итеп тора, кыскасы, көннең кадагы. Ә материалга әллә кая барасы түгел, шагыйрьләр аның исемен тәсбих урынына тартып торган чак.

Шулай да, эш арасында булса да, Маһирә дә искә төшкәләп тора иде, каһәр. Бер кичне шулай, шәһәр комсомол активы җыелышында, күземә күренәме дип торам, моны очратам. Тәнәфес вакыты иде, коридорда озак кына сөйләшеп йөрдек. Сүз күбрәк шул көнге эшләр, доклад, чыгышлар турында барды. Бер сүзе шулай да хәтердә калган: «Мина ошамый, күп сөйлибез, яшьләр тормышына эчкәрәк үтеп керергә куркабызмы дип әйтим, әллә тешебез үтмиме?»

Шунда ук ул: «Ахры, мин китәрмендер», — дип тә куйды. Ничектер, бик күзгә карап әйтте бу «китәрмендер»не, минем ничек каравымны белергә тырышкан кебек әйтте. Мин нәрсә диярга дә өлгерми калдым, тәнәфес беткәнлекне белдереп, звонок яңгырады. Без аерылдык.

Ләкин кыз китмәгән иде, җыелыштан чыгышлый мин аны тагын очраттым. Бу юлы ул күңеллерәк күренә иде, хәер, шундук мин моның сәбәбен дә белеп алдым: җыелышның вакытында бетүе өчен икән!

— Ярты төнгә хәтле сузарлар дип курыккан идем, ярый, вакытында яба белделәр, башлары хоть шуңа житте,— диде ул, гадәттәгечә, җиңел ирония белән. Һәм шуннан соң ук, урамга чыгу белән, бик үз иткәндәй, һәрхәлдә, минем каршы килмәслегемә алдан ук ышангандай итеп:

— Өстән явып тормый, әллә мине озатып куясыңмы, Хәнәфи абый,— дип тәкъдим ясады. Мин, озатырга бик үк исем китеп тормаганлыкны сиздереп, авыз эчемнән нидер мыгырдандым, ләкин соңыннан булса да икърар итмичә булдыра алмыйм: исем киткән иде, шайтан алгыры! Кызның бүген шулай ачыклыгына, эчкерсезлегенә, күңелендә ни бар — шуны сөйләп торуына, барыннан да бигрәк, үзе башлап озатып куярга әйтүенә исем киткән иде...

Озатканга карап, әлбәттә, әллә нәрсә булмады. Әлеге шул капка төбендәге эскәмиядә чак кына утырып тору, берсе бетмичә икенчесе башланып китә торган өзек-төтек сүзләр... һәм иң ахырда уйландыра торган бер сүзе булды:

— Син, Хәнәфи абый, безгә килгәлә. Минем әти белән әни гаепчән кешеләр түгел, вакытың булганда тот та килеп чык. Аягың тартса, дим, әлбәттә.

Аягымнан да бигрәк күңелем тартты бугай... Күрәсең, ул чагында минда әле яшьлек сафлыгы бетеп житмәгән булгандыр. Иң хәтәре: күңелгә кереп өлгергән иде ул кыз. Шуңарга бераз үземне күрсәтергә теләү дә килеп кушылгандыр: уен-муен түгел, аспирантурага калдырылган егет, өстә дә шома гына, галстугым да әйбәт утыра. «И-и-и... нәрсә булса — шул», — дидем бер көнне. Атнамы, ун көнме узгач, — ә ул миңа ел булып тоелды, — киенеп-ясанып тәвәккәлләдем, киттем мин боларга.

Кызның әтисе Җаббар агайга тап булдым. Төпчекә торган кеше түгел икән, ул яктан җиңел котылдым. Кызлары авылга киткән икән, «менә-менә кайтыр дип көтеп торабыз» диделәр. Кыз турында шуның белән сүз бетте. Дөресрәге, миңа шулай кебегрәк тоелды. Әмма Җаббар агай, беренче күргән ят кешедән тегене-моны бик бөртекләп сорашырга яхшысынмаса да, шулай да кызларын сорашып килгән яшь аспирантны тиз генә озатып җибәрүне килештермәде булса кирәк. Хатынына җәлт кенә берәр стакан кайнар чәй ясап китерергә әйтеп, үзе миңа кайтыр юлны вакытлыча онытып торырга кушты. (Ул шактый ук җор телле карт булып чыкты, җорлыгы вакыт-вакыт ирония белән дә

аралашкалый иде.) Аның белән сөйләшеп утыру күңелсез булмаса да, шулай да, дөресен әйтим, мин үземне бик уңайсыз сиздем ул минутларда. Бер яктан, бу ике олы кешенең мине болай ачык чырай белән бик үз итеп, шул ук вакытта һичбер тәкәллефсез каршы алулары миңа тел белән әйтеп булмый торган эчке тынычлык бирә, мин үземне минуттан-минутка бу йортка якыная барган кебек хис итә идем. Икенче яктан, сыный караган күз карашларын (ә мин ул хистән һич аерыла алмадым) һәрвакыт үзеңнең җилкәңдә тоеп тору яхшы ук читен иде.

Баштан ук минем авыздан «диссертация» дигән сүз ычкыну башыма бәла булып төште. Берьюлы барысы турында сораша башларга яхшысынмыйча утырган Җаббар картка бу тема сүз ялгап җибәрү өчен бер этәргеч булды. Миңа чигенергә урын калмаган, ул турыда сөйләргә иртәрәк булуын үзем белеп торганым хәлдә, мин, ачыктан-ачык хлестаковлык күрсәтеп, шапырынырга, тумаган тайга атланып, билен сындырырга өлгергән идем инде... Шул ук вакытта, бу турыда сүз кузгалу безнең карашларыбызны ачыкларга азмы-күпме ярдәм дә итте.

— Юлбашчы темасы отышлы тема инде болай, хәзерге яшьләр этәч белән тутый кошны аера беләләр, — дип куйды карт, сүзләренә бераз ирония сала төшеп. Ләкин әйтелмәгәне күбрәк, әйтелмичә калганы аның күзләрендә, тавышында, калын кашларының кинәт бер дерт итеп тартылып куюында иде. Эш болайга киткәч, мин дә, әлбәттә, баш селкеп кенә утырмадым.

— Шулаен шулайдыр да.. Ләкин, үзем сизеп торам, нык лап ук тотынырга нәрсәдер җитми.

— Әллә тәвәккәллек җитеп бетмиме? — дип, шаяртып куйды карт һәм шундук җитдиләнеп, үзен-үзе төзәтеп узарга ашыкты: — Яшьлектә төрле чак була, яңа эштән өркебрәк тә каласың кайвакыт.

Ул арада түгәрәк ак подноска куеп безгә куе итеп ясалган кайнар чәй китерделәр. Чәй китерүче Маһирәнең әнкәсе иде, аның кай җирендәдер кызы да иярәп йөргән кебек иде — охшашлык, уртаклык күренә, шул ук вакытта әни кешедән картлык, өшәнгәнлек тә бик сизелә иде.

— Тәвәккәл — таш ярган, сайлаган икәнсез, җиң сызганып тотынгыз, — дип, бүленеп калган әңгәмәне яңадан ялгап алып китте Җаббар агай. Чәйне авызына китерде, кабып карады, авызы пешәрдәй күренгәч, алдына кире куйды. Әмма күңеленә килгән уйны кире куеп тору читен иде булса кирәк, минә ул, миңа сөйләүдән бигрәк, үзе белән үзе сөйләнгән кебек, авыз эченнән генә мыгырданырга тотынды:

— Теге «нәрсәдер җитми» дигән сүзегез колакка кереп калды. Шул турыда уйлап алдым әле мин дә. — Җаббар абзый чал башын кинәт турайтып, сынагандай миңа бер карап куйды, аның күзләрендә моңарчы күренмәгән очкын күреп алдым мин. — Ә кем белә, бәлки, халыкка булган мәхәббәт җитеп бетми торгандыр? Ә халыксыз юлбашчы — канатсыз кош, ишкәксез көймә, яумыйча узган болыт ул. Уйлаганыгыз бармы сезнең шул хакта?

Минем ул турыда уйлаганым юк һәм, дөресен әйтим, уйларга кирәк дип санаганым да юк иде. Шунлыктан, каршыда утыручы чал чәчле ул карт алдында ничектер аптырабрак калдым. Аптырабрак һәм икеләнебрәк: турысын гына әйткәндә, кирәкме икән ул турыда алай нечкәләп уйлап торулар? Әгәр дә, әйтик, сүз минем турыда бара икән, минем темам кафедра җитәкчеләре тарафыннан уйланачак, төрле яклап үлчәнәчәк, аларныкы, үз чиратында, алардан өстәрәк торучылар тарафыннан уйлана торгандыр һәм, үзем практикага йөргән база мәктәбендәге бер укытучы әйтмешли, «һәм шулай ук алга таба». Карт буын инде ул шулай, төрлесен уйларга, шикләнергә, вәсвәсәләнергә өйрәнгән. Һәр кеше шулай үзенчә уйлый, үзенчә йөри, үзенчә план кора башласа, нинди башбаштаклыклар килеп тумас та нинди анархиялар баш калкытмас.

Шундыйрак караштa идем мин ул минутта. Һәм ул карашымны үзгәртергә яки аның нинди дә булса кимчелекләрен эзләргә җыенмый да идем. Әмма хөрмәткә лаек олы кешенең уйланып һәм миннән җавап көтеп әйткән сүзләрен игътибарсыз калдыру, шулай ук, килешмәс кебек иде. Шунда мин, үзем дә сизмәстән, судан коры чыгу юлын таптым.

— Хафаланмагыз юкка, хөрмәтле Җаббар абзый, — дидем мин, тавышымны мөмкин чаклы нык тотарга тырышып.— заманага аеграк күз белән караганда, искитәрлек берни дә юк. Көймәбез ишкәксез калса, моторны ходка җибәрербез. Мотор заманы хәзер, ишкәк заманы түгел.

— Сез шулай уйлыйсызмы? — дип сорау белән җавап кайтарды карт, миңа игътибар беләнрәк тагын бер карап алып. Беравык сакалын авызына кабып тынып утырды. Минем һава янгыратып ярып салган егетләрскы җавабым белән килештеме ул, әллә килешмәдеме? Үзара гына әйткәндә, минем анда эшем юк. Бәхәскә кермичә һәм эрелек саклау йөзеннән, мөмкин чаклы азрак сүзле булырга тырышып бераз утырдым да китеп бардым. Ахыр чиктә, миңа карт үзе түгел, аның кызы кирәк һәм мин ул кызны, ниһаять, кулга төшерәчәгемә бик нык ышанган кеше. Шулай икән, карт буын үзенең катып калган иске фәлсәфәсе, шик-шөбһәләре белән ник шунда чәнчелеп китми...

Мин шулай уйлыйм... дөресрәге, шулай уйларга тырыша идем. Ләкин шул ук вакытта, бигрәк тә Җаббар абзыйларда булып кайткан нан бирле, кайдадыр күңел түремдә вакыт-вакыт икеләнүле сораулар да кузгала: чынлап та, шулаймы, безгә ясап күрсәткәнчә барамы соң бу дөнья? Мин Җаббар картка шикләнеп карыйм, үз чиратында, Җаббар карт миңа салам-торхан диебрәк караса? Аннары тагын... нишләп мин үзем дә уйламаска тиеш? Кем әйтте? Бөтен эшне һәм бөтен кешеләр өчен нишләп әле ул «югарыдагы» бер кеше генә уйларга тиеш, ди?

«— Тьфү-тьфү! — дим мин кеше юк чагында як-ягыма төкеренеп.— Минем эшемме? Мин нишләтә алам? Шулай төзелгән. Шулай бара. Кыскасы, син үзеңнең кандидатлык диссертацияң өчен теманы дөрес сайларга тырасың, Хәнәфи Ризванов!»

Картларның әйтүенә караганда, Маһирә инде авылдан кайткан да булырга тиеш. Күрәсе иде ул шайтан кызны. Тагы нинди кирелекләре артып кайтты икән? Әһә, берсен менә күрсәтергә дә өлгерде. Фирдәвес артыннан, киногa барырга чакырып, кош теледәй генә кәгазь бирдергән идем, «кош телем»нең артына бик тә пөхтә итеп һәм, филолог кеше белән фольклор телендә сөйләшеп, болай дип язып җибәргән: «Безнең авылда энә җеп артыннан түгел, җеп үзе энә артыннан йөри. Сүзем шул, Маһирәне бик сагынган булсагыз, үзегез килегез. Мин өйдә юкта килгәнсез ич. Хәзер ник ярамый?» дигән.

Уйланыбрак калдым. Баруын бик барасы, Маһирә тәкәбберне дә күрәсем килә, кай ягы беләндер әтисе карт та ошады. Ләкин, шул ук вакытта, ул өйдә, ул гаиләдә хөкем сөрүче хөрлектән, башка килә торган төрле көфер уйлардан да куркам. Әйтүен әйтеп үк бетермәсә дә, шулай да кинаяләреннән, ярым ымлыклардан, вакыт-вакыт калын кашларының тартылып куелуыннан ук сиздем: карт бүтән кешеләр уйлаганча, мин яки мин белгән кешеләр уйлаганча уйламый. Ул әле, бичара бәндә, дөньяга үз карашын саклап калырга азаплана булса кирәк. Никадәр саташу, картлык кирелеге. Кемгә кирәк аның үзенчә уйлавы да һәм үзенчә уйлавы белән ул нәрсә кыра алачак? Бичара карт.

Шулай да Маһирә кире беткәнне сагынуым үзенекен итте, бер көнне, киенеп-ясанып, Аркылы Тукай урамындагы ул тын өйгә тагы киттем. Хәер, бу юлы андый хәтәр темаларга сүз кузгалмады. Карт үзе дә, карчыгы да, Маһирә белән без сөйләшкән сүзләргә колак салмыйча, читтәрәк калырга тырыштылар. Шулай да бер җай табып, Җаббар

агай эшемнең барышы, диссертациям белән кызыксынды. Аннары, Маһирә киенергә дип үз бүлмәсенә кереп киткән арада, аның белән бер партия шахмат уйнап алдык — ул кыска арада гына уен, әлбәттә, кызып ук китмәде, әмма шулай да сизеп алдым: Җаббар картның «чарлак» әле яхшы эшли, аның тирәсендә итәгеңне-җиңеңне җыебрак маташмасаң, «мат» калдыруы да бик ихтимал иде.

Бу гаиләдәге хөрлек, кешенең ирегең кысмау бигрәк тә тагы шуннан күренде: кызларын минем белән чыгарып җибәргәндә, нә атасы, нә анасы кисәтү рәвешендә ник кенә бер сүз әйтеп калсыннарчы! Ахрысы, аларның кызларына булган ышанычы һәртөрле шик-шөбһәләрдән өстен иде. Бу факт мине аларга тагын да ныграк якынайта төште.

## VI

Вакыт тигәндә баргалап-кайткалап, кызны озаткалап-каршы алгалап йөрүләрдән башка, Маһирә белән безнең арада телгә алып әйтерлек берни булганын да хәтерләмим. Теге беренче озату вакытында үтә нык куркытып куйганнныкымы, әллә кызның өне шундый каты идеме, әллә ул гаиләдә миңа карата житдилек, ышанып карау кулымны-аягымны бәйләде, нәрсәдән һәм ничек кенә булмасын, мин ул кызга якын килергә, яки күңелемә нинди дә булса йөгәнсез уйлар китерергә һич базмый идем. Була бит шундый кешеләр: син аңарга берни белән дә бурычлы да түгелсең, аның үзең кебек үк гади бер кеше икәнлеген дә белеп торасың, хәтта кай ягың беләндер, әйтик, белемең ягыннанмы, тоткан урының беләнме дигәндәй, син аңардан өстенрәк тә әле, әмма шулай да син аны түгел, ул сине тотып тора. Якын да ул, бер үк вакытта чак-чак кына өркетә дә. Минем Маһирәгә мөнәсәбәт чамача әнә шулайрак урнашып бара иде. Әйтмичә уза алмыйм: бер нәрсәдә ул мине ачыктан-ачык җиңде. Ул опера тыңларга бик ярата, ә мин, дөресен әйтим, операда йоклап ук утырмасам да, оят саклап кына йокламаска тырыша идем. Минем тумыштан килгән мужиклыгым опера тыңлаганда да, алтын каптырмалы манжетларым астында, якама бик шәп ипләнгән модный галстугым белән уралып, нәкъ үз урынында аяк бөкләп утыра иде. Шулай да Маһирә мине җай буе диярлек операга сөйрәп йөртте. Ул елларда Казанның үз операсы юк, гастрольгә килгән опера коллективы бик бәяле, һәрхәлдә, аспирантурада укучы кешенең кесәсе өчен түгел, иң үтерә торганы — шул оркестр дигәннәре янгырый башладымы, йокы килүгә һич чама юк, вакыт-вакыт мин моны үземнең «каләм кашка» сиздергәләп тә куйгалый идем. Ләкин берничә дә карамастан, еш кына хәлләрдә билет алырга миннән элегрәк үзе өлгереп, Маһирә опера тыңларга тәки өйрәтә язып калды үземне, шайтан кыз. Тәмам өйрәтеп үк җиткерә алмады, чөнки гастрольгә килгән опера труппасы китеп барды, безнең кесәләребез әрчелде, аннары тагы минем аспирантурамның икенче елы башланды, шуларның барысын да исәпкә алып, әлектән килгән кара акылым белән үземә-үзем әйтеп куйдым: «Җитәр сиңа, Хәнәфи дус, мужик башың белән калач ашаучылар рәтенә тыгылырга маташма. Йөрмәдең түгел, йөрдең. Калдыр ул Болак арты кызын, алдыңа кара да атыңны куала», — дидем.

Шулай булмаган кайда! Күрәсең, бу вакытта Маһирәм минем калдырыр яки калыр чикләрне узган иде инде. Күзенә күренмичә, телефоннан шалтыратмыйча ун-унбиш көн торуга, тәмам аптырап, бер көнне минем тулай торакка (мин ул чагында студентлар тулай торагының бер бүлмәсендә, үзем кебек икенче бер аспирант белән тора идем) үзе чабып килеп җиткән бу.

— Син нәрсә, Хәнәфи абый, кинәт безне онытып ташладың? — дип сүз башлады, үпкәләгәндәй авызын турсайтып. Җаныма үтеп керергә теләгәндәй, күзләремә текәлеп карап торды. Һич онытасым юк шул

минуттагы торышын, турсайган иреннәрен. Помышка кергән чәчби кыз бала кебек, ишек төбендә таптанып тора. Түргә дә узмый, артында ишек барлыгын да оныткан. Күзләре белән, ерактан торып кына мине «актарып ташламакчы». Текәлеп карый, күзләрендә бер үк вакытта: сынау да, сагыну да, үпкәләү дә, ялвару да... һәм аларны берьюлы түгелеп китүдән сөрмәле озын керфекләре саклап тора. Күрешми торган шушы ун-унбиш көн төшендә әллә бераз ябыга, суырыла төшкән инде, яңакларына чак кына сизелерлек күләгә кунган, шуны яшерергә тырышып булса кирәк, җиңелчә генә итеп пудра сылаган — ә мин аны сыланган-бизәнгән хәлдә һич күргәнем юк иде. Әлбәттә, бераз гаҗәпләнебрәк тордым булса кирәк. Дөресен әйткәндә, мине бигрәк тә Маһирәнең, үз дәрәҗәсен белә өйрәнгән горур табигатьле бу кызның, көпә-көндез егетләр тулай торагына бәреп керүе гаҗәпләндергән иде. Минем бу эчке халәтемне кыз шундук сизеп алды булса кирәк, аның ябык йөзеннән кинәт үзенә бертөрле оялчан алсулык йөгереп узды, бу минутта ул баш әйләндергеч матур иде. Мин ыргылып аңарга ташланудан, әйткән һәм әлегә әйтеп өлгермәгән борчулары белән, аны дуамал җенләнеп кочып алудан үземне көчкә-көчкә генә тыеп калдым.

— Син ничек... ничек мине бу лабиринтлардан эзләп таптың? — дип сорап куйдым мин, ни дип сүз башларга белмичә, ахмакларча авыз ачып торганнан соң. Маһирәнең беренче «югалып калуы» инде узган иде. Ул кинәт ап-ак тешләрен күрсәтеп көлеп куйды — беләм, беләм, бу тикмә көлү түгел, гадәттә аның мондый көлүе астында нинди дә булса гөнаһсыз бер шуклыгы, хәйләсе, чаялыгы яшеренеп ята һәм ул, шуны тагы да эчкәрәк яшерергә тырышып, шул хәйләкәр көлемсерәве белән юри минем башымны әйләндерергә ярата иде.

— Башына төшкәч, табасың икән, — диде ул, мин куйган сорауга җавап итеп. Ул инде үзенең гадәттәге хөрлегенә әйләнеп кайткан иде. — Ничек әйтәләр әле? Илчегә үлем юк, диләр түгелме? Бу очракта мин әтием картның илчесе булып килдем. Соңгы вакытта сине бик юксына башлады, Хәнәфи килеп чыкса, ичмасам, шахмат тактасында бер көч сынашып карар идек, ди.

Белеп торам: әлбәттә, сынықка сылтау гына бу. Әмма шуны да белеп торам: минем җыештырылмаган хөҗрәмә үзе бәреп кергән бу ялганчы илчегә мин берничек тә каршы килә алачак түгел идем. Аннанмоннан гына өстемне алыштырып, ләкин артыгын һич сораштырып тормыйча, Маһирәгә ияреп мин аларга киттем. Ай-һай ла! Терсәкне тешләп буламыни, бу очракта бераз сорашкалаган булсам да ярыйсы икән, шайтан кызы Маһирә мине күземә карап алдаган икән. Шахмат уйнарга дип чакырган булуы — кунакка алып китүе икән. Җитмәсә әле, нинди кунакка: Җаббар агай белән хатыны Зарифә ханымның бергә тора башлауларына егерме биш ел тулуны билгеләләр, ягъни көмеш туй уздырулары, имеш.

Ә мин, аларның шул алдакчы кызларының сүзенә ышанып, шундый мәҗлескә коры кул белән барып кердем. Ой, моның өчен әзгәләнүләрем! Тагы бер мәртәбә үземнең мәнсезлегемне, дөнья рәте белмәс кеше икәнлегемне күрсәтү дигән сүз иде ич бу. Ә хуҗалар моңа бөтенләй игътибар да итмәделәр. Алар килүемне чын күңелдән хуплап каршы алдылар, шунда ук, үзләренчә зур тәкәллеф күрсәтеп, мине башка кунаклар белән таныштырырга тотындылар. Арттырыбрак җибәрү дә булды кебек, хәер, бер карагандa алар өчен бу бик аңлаешлы да иде. Кызлары ияртеп алып килгән бердәнбер кавалер һәм, җитмәсә әле, фән алмасына үрелергә маташучы яшь кәҗә тәкәсе, — дөресен әйтим, мин үземне әнә шулайрак хис иттем ул минутларда. Шулай да, андый тантаналы ыгы-зыгы арасында уйнап та, уйлап та житкермичә ычкына торган кабарынкы сүзләр арасыннан Җаббар абзый әйткән бер сүзгә игътибар итмичә кала алмадым.

— Тартынмагыз, монда барысы да үз кешеләр, бер агач ботаклары, — дип, мине кыюрак булырга өндәде ул, читкәрәк алып китеп. Һәм шундук, сүзенә шаяру мәгънәсе бирергә тырышып, өстәп тә куйды: — Асылныйм дисәң, ул агачта сиңа да бер ботак бар, егеткәем.

Ләкин күзләреннән, тавышының гөрләп чыгуыннан һәм, үзе дә сизмәстән, кинәт кенә «сез» дән «син»гә күчүеннән сизеп алдым: юк, картым һич шаярмый, мин килгәнгә бик шат, бераз кәефләнеп алгач, бер арада хәтта ул минем колагыма:

— Синең безнең арада булуың өчен Зарифә апаң да куанып бетә алмый, рәхмәт, туганкай, илтифатың өчен, — дип пышылдап китәргә дә өлгерде. Моны, әлбәттә, карт күңелнең бераз йомшарып калуыннан дип тә уйларга мөмкин иде. Ләкин мин алай уйламадым. Ник дисәң, минем үземнең дә күңел нечкәргән, мәсьәләне катлауландырасым килми, ихлас күңелле кешеләргә карата ихлас күңелле буласым килә иде. «Юк, Ханәфи дус, бу йортта сиңа уен итеп карамыйлар, син үзең дә бу эшкә уен итеп карамаска тиешсең!» — дип, үземне-үзем үгетләп куйдым мин.

Әмма сизеп торам: үгетләмичә дә эш җитдигә китеп бара, эчеләсе вино да эчелә иде. Дөресен әйтим, утыра-утыра без яхшы ук кәефләндек. Төрле темага сүз китте, уен-көлке китте. Пиджакларны салып, урындык аркаларына элеп куйдык. Муеннардан галстуклар очты — көмеш туй икән, көмеш туй булсын, бакыр белән генә чикләнеп калмыйк, дип барды Җаббар агай. Әйе, ул ялган көмешкә генә риза түгел, ул чын күңелдән һәм эчтә һич тутык калдырмыйча балкуны көтә иде. Бераздан, бик үк тигездән булмаса да, җырлап та җибәрдек, Җаббар агай кайдадыр кухня тирәсендә әнисенә булышып йөри торган кызын таптырырга тотынды.

— Карале, күгәрченкәем, нигә әле син безгә үзеңнең музыкаль сәләтеңне күрсәтмисең? — дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды. Моны әйткәндә ул, ялгыш кына күзе төшеп киткәндәй итеп, миңа янә бер карап алды. Аның бу карашында: «Юк әле, син белеп бетермисең минем кызның ниләргә сәләтле икәнлеген!» дигән мәгънә, кызы һәм үзе өчен бер горурлану укыгандай булдым мин. Дөрестән дә, белеп бетермәгән булган икәнмен шул. Кайдан алганын, ничек алганын күреп тә өлгермәдек, менә Маһирәнең кулына скрипка менде. Мич тирәсендә чуалудан ул чак кына кызарып та калган иде, шуңа бераз каушавы да өстәлде булса кирәк. Менә ул, башын бер якка кыңгыр сала биреп, скрипканы иягенә китереп терәде. Бер вакытта да бер таракка да буйсынмый торган тыңлаусыз куе чәче көлтәсе белән бер якка ишелеп төште. Кыллар өстеннән җай гына йөзеп, менә смычок узды, өйгә йомшак моң таралды... Атасы һәм кызы — алар бер-берсен күз карашларыннан ук аңлап алдылар булса кирәк; кыстатып тору, тәкәллеф саклау булмады, кызы уйнаганга әтисе, һич ашыкмыйча, һич кабаланмыйча, һичкемгә ошарга тырышмыйча, күкрәгендә ни моңы бар — шуны салып, җай гына сузып җибәрде...

Соңга таба җырга башкалар да кушылды. Әлбәттә, Пятницкий хоры үк килеп чыкмады, Зөләйха Әхметова хоры да чыкмады, шулай да вино пары кергәннән соң без барыбыз да ярыйсы ук җырчылар булып чыктык. Хәер, бик үк ярыйсы булып җитмәгән якларыбызны скрипка моңы каплый бара иде.

Җыр арты тагы сүз китте, һич тә юктан гына бәхәс кузгалды. Андый чакта барың да бик белдекле кешегә әйләнәсең, нигә кирәк булгандыр политикага тыгылу, арадан беребез — миңа каршы якта утыручы, моңа хәтле сүзгә дә, җырга да кушылмаган һәм, ничектер, эчемлек эчеп тә йөзенә чырай кермәгән берәү — уйный-көлә сораган булып, Җаббар абзыйга сүз кушты:

— Хәтерем ялгыштырмаса, теге вакытта сине, НЭП мәсьәләсендәге буталуларыңны искә алып, нәрсәдер тинтерәтеп йөрткәннәр иде шикелле, Җаббар дус. Зур бер универмагны бармак очында әйләндерүенә карагында, хәзергесе көндә син советның коммерция өлкәсендәге сәясәте белән килештең кебек. Шулай да әйтеп узчы: кайсы аягыңа — уңгамы, сулгамы — аксаганлыгыңны хет үзең төшендеңме, канса-канис?— дип сорап куйды. Күрәсең, кайчандыр картны «селкетеп алу» булган, булган да узган, Җаббар карт үзе аны гади бер аңлашылмау дип кенә карый, ул турыда кабаттан хәтеренә төшерергә яратмый иде булса кирәк. Һич уйламаганда, шатлык һәм уен-көлке арасында, җырны бозып дигәндәй, моны хәтергә төшерү картны бераз аптыратыбрак калдырды.

— Үзем онытуын оныткан идем, синең хәтердә сакланган икән, рәхмәт искә төшерүең өчен, Нәбиулла кордаш. — Картның җавабында яхшы ук ачык сизелеп торган ачыну ишетелеп калды һәм мәҗлестә, бигрәк тә хуҗа кеше өчен, моның урынсыз икәнлеген абайлап, ул шундук сүзне уен-көлкегә борырга маташты. Ләкин уен-көлке урынына шуның киресе, гаять җитди һәм ул чор өчен бар кешене дә уйландырырлык, минем үземне, мәсәлән, яхшы ук сискәндергән сүз килеп чыкты.

— Ул чагында, кем, Нәбиулла кордаш, — дип дәвам итте Җаббар абзый, сүзләрен бакыр акча аткан кебек атып-атып, — кем ялгыш атлый, кемне, «ялгыш атламагае» дип, алдан кыйнамакчы булалар, барысын да күреп, кисәтеп торырга Ленин бабаң бар иде. Ул рөхсәт итмәде юк-бар эшләрне.

Әмма теге чырайсыз кеше дә сүзен аста калдырырга риза түгел иде булса кирәк, мыскыллы көлемсерәп беравык тын утырганнан соң, тавышына үзенчә тирән мәгънә салырга тырышып, янә сорау биреп куйды:

— Моның белән син, хәзер андый кеше юк, дип әйтергә җыйналмыйсыңдыр бит?

Һай, ул сорау. Һай, ул сорауны бирүче кеше. Мәҗлестә кинәт шаушу югалды, барыбыз да, авызыбызга су капкандай, тынып калдык. Узган эшкә салават — минем үземдә, мәсәлән, «Нишләп соң әле мин монда килеп каптым?» дигән төслерәк тәшвишле бер сорау кузгалды. Ләкин дуамал гына торып китү уңайсыз иде, мәҗлеснең азагына хәтле утырырга туры килде.

Ишектән озатып калганда Җаббар карт һәм хатыны Зарифә ханым, миңа үзләренең аерым тәшәккерләрен җиткерергә тырышкандай, парлашып гөрләшергә тотынсалар да, мин инде килгәндәге кебек эреп китмәдем. Мәҗлес азагында кабынып киткән бәхәснең кургашындай авыр юшкыны күңелне басып тора иде.

Әлбәттә, мин моны Маһирәгә сиздермәдем. Дөресрәге, сиздермәскә тырыштым. Хәер, кунаклар белән ыгы-зыгы килгән кыз аны-моны сизәрлек дәрәҗәдә түгел, ул әтисе белән әнисенең «көмеш туе»на багышланган мәҗлеснең шулай күңелле, шау-шулы үтүеннән, ул мәҗлестә минем дә катнашуымнан әйтеп бетергесез шат, эчмичә үк исергән иде. Мин, барлык каршылыклы кичерешләремне үзем өчен дә, Маһирәм өчен дә тик бер сәбәп белән генә аңлатырга тырышып, ахмакларча кычкырып ярып салдым:

— Кара аны, кызый... Коры кул белән шундый тамашага алып килеп, хур иттең син мине. Буш калмас бу алдашуың, мин дә сиңа шундый ук бер сюрприз белән җавап кайтарырга тиеш булырмын,— дидем.

Маһирә җавап бирмәде, ул җавап бирерлек дәрәҗәдә түгел, ул шулай матур итеп алдаша белүе өчен бөтен барлыгы белән куанган һәм үз куанычыннан үзе сукыраеп калган иде.

VII

Бәйрәм ашы — кара каршы булып чыкмады, әлеге алдашуы өчен мин Маһирәгә булган әҗәтемне тиз генә кайтара алмадым. Кайда монда алай шаярышып тору, дөньяда житдирәк хәл-әхвәлләр кузгалып китте, уен-муен корып торырга вакыт тимәде. Ул елның кышы, әйтергә кирәк, гомумән бик шыксыз булып чыкты. Кайдадыр өстә властька килергә кызыгып йөрүчеләрнең астыртын хәйләләрен фаш иткәннән соң кузгала башлаган ыгы-зыгы әкренләп безгә дә килеп житкәнче хәвефле шаукымга әйләнде, кешеләрнең узгандагы эреле-ваклы гөнаһларын казып чыгарырга тотындылар, андый гөнаһлары булмаса, кызган баштан андыйларны ясап, тагып куярга да күп алмыйлар иде. Шул жөмләдән, безнең институтта да, укыту һәм программа эшен идея ягыннан яңадан карау сылтавы белән, бер-бер артлы бик шау-шулы берничә жыелыш булып узды. Берничә доцентның баш очында яшен яшьнәтеп, күк күкрәтеп алдылар. Мин — яшь бәрәнге, тоткан урыным юк, артым-алдым чиста, диссертация өчен сайлаган темам тел-теш тидерерлек түгел, киресенчә, булып узган әлеге жыелышларда аны берничә урында үрнәк итеп телгә алып үттеләр. Кыскасы, минем өчен борчылырлык сәбәпләр әлегә күренми иде. Шулай да бик алгы планга чәчрәп чыгарга ашыкмыйм, кеше өстенә сөйләмим, үтә белдекле булып кылануны шулай ук кирәксез саныйм. Шаулап ни бар, авызы ашка гына тигән мин сала бозавына нигә юк-бар шау-шуга тыгылырга — борынның китапка төрт тә кимерә бир «фән гранитларын». Алла сакласын, алла сакласын, бу «фән гранитлары» дигәне кайчандыр, кайсыдыр бер тайпылыш житәкчесе тарафыннан ташланган лозунг бугай тагы. Һәртөрле сүзгә бәйләнә торган бу заманда алдыңны-артыңны карамыйча сөйләшсәң... Кыскасы, берсенә дә итәгең белән генә дә якын бармаганың яхшы!

Әнә шундыйрак бер карашта булдым мин ул чагында. Шуның янына тагы менә вак-төяк дөнья ыгы-зыгысыннан саклый торган корыч калканым да бар, ул — минем Маһирә белән мавыгуым иде. Дөресен әйтим, бу хис миндә көчәйгәннән-көчәя бара, һәрхәлдә, яшьлек шуклыгы рамкаларыннан чыккан, хәер, мин үзем дә яшь ягыннан чигемә житеп барам, егерме биштән узган, әмма Маһирәмнең жылы кочагына ук әле барып житмәгән идем. Маһирә дә уйнап йөргән кешегә һич охшамый, жае чыкканда, читләтеп-читләтеп кенә булса да, уйнап йөрмәгәнлеген сиздергәли иде. Бигрәк тә аның картлары, безнең арабың шулай якыная барып, ахырда бер көнне шаулаган туй белән төенләнеп куелуын бик телиләр иде булса кирәк. Берничә тапкыр инде Жаббар агай үзе минем студентлар тулай торагындагы тормышым, ашау-эчү якларын ничек жайлавым белән кызыксынды. Миңа — аспирантурада укучы кешегә — тулай торакта үткән тормышым белән мактану, әлбәттә, уңайсыз иде. Ләкин, шуның белән бергә, мин әле нинди дә булса бүтән бер карар кабул итәргә дә ашыкмыйм, куркам, уйланам, үземне үзем: «Тукта, ул турыда аспирантура бетергәч уйларсың», «Тукта, иң элек кечкенә булса да үзеңнең ояңны булдыру ягын кара!» — дип тыеп килә идем.

Шул ук вакытта үземнең «оямны булдыру» турында да, әлбәттә, уйламый түгел идем. Уйлыйм гына түгел, чабам, торак органнарының бусагасын таптыйм, хәтта ялганлаудан да тартынып тормыйм: «Ярәшкән кызым бар, икебез ике жирдә саргаеп торабыз, сез моның нәрсә икәнлеген беләсезме?» — дип тә ычкындыргалый идем. Монда берәүдән дә яшерен-батырын түгел, юк, мин теләнә дә белә идем яшь чакта. Хагын, ялганын бергә кушып, шулай теләнә торгач, ахырында, торак органнарындагы агай-энене тәки ышандырдым бугай. Ниһаять, бер көнне минем кулыма ордер тоттырдылар. Аерым квартирага түгел, кеше белән уртак квартираның ун квадрат метрлы бер бүлмәсенә.

Хәер, монысы өчен дә башым күккә тигәндәй булды. Чөнки мохтаҗлыгым зур, тулай торак бүлмәсендә кысылып яшәүдән бик туйган идем. Күңелдә баш калкытырга маташкан һәртөрле шик-шөбһәләрне томалап, булдыра алганча, аспирант кесәсе күтәргәнчә, «оямны» җиһазларга керештем. Алып кайттым китап шкафы. Шкаф өстенә куярга алып кайттым татарның Тукаен. «Нишләп татарныкы гына? Бу ниткән милләтчелек?» — дип бәйләнмәсеннәр өчен, алып кайттым русның Пушкинын. Боларның әле берсенә, әле икенчесенә карап тордым-тордым да тагы шикккә калдым: «Шагыйрь дә шагыйрь, бу ниткән коры эстетлык? Кайда монда политика?» — дип бәйләнә башлаулары бар бит әле, каһәр суккыры. Бигрәк тә үзем «Матур әдәбиятта юлбашчы образы» дигән темага диссертация язарга әзерләнеп йөргәндә. Алып кайттым Сталинның зур гына бюстын. Бу өч сәнгатькә, бер шкаф китапка карап тордым да кинәт үзем өчен дә бик яңа булып күренгән «Америка ачтым»: болар белән генә тамак туймас бит, шайтан алгыры. Нәрсәдер, тормыш кирәк-яракларын да кайгыртырга кирәктер. Һәм шундук чаптым кибеткә. Күтәреп кайттым бик зур ак самовар. Кайткач, актарып карыйм кесәне — өйләнергә, өй кирәк-яракларына дип саклаган акчам очкан. Татар түгел диген инде син мине, нигә кирәк булган миңа башта ук андый кыйммәтле самовар! Өч портрет, бер шкаф китап, бер ак самовар белән утырып калырга туры килде шул, өйләнүне бераз кичектереп торырга булдым.

Шулай да яшь чак — тиле чак, якшәмбеләрнең берсендә, баштагы кердепе-чыктылы уйларны таратып кайту һәм, әгәр туры килсә, Маһирәне алып кайтып бүлмәмне күрсәтү өчен, шәһәр читенә чаңгыда йөрергә чакырып, аларга киттем. Маһирә минем тәкъдимне һич киреләнүсез кабул итте, әнисеннән барып сорады, әнисе шулай ук каршы килмәде.

— Нигә әтиеңнән дә сорамадың? — дип шаяртып куйдым мин, өйдән чыккач. Ләкин Маһирәнең бу темага бик шаяртасы килми иде булса кирәк, җитди генә итеп сүземне бүлде:

— Әти картны тынычта калдырыйк, Хәнәфи абый. Соңгы көннәрдә ул болай да борчылыбрак йөри.

Һәм ул, башта бик алай сөйләргә теләмәсә дә, миннән яшереп торуны яхшысынмады булса кирәк, әкренләп-әкренләп чишелде: Җаббар агай директор булып эшли торган универмагның складында ниндидер саксызлык аркасында янгын чыгып, шактый гына товарга зыян килгән. Тикшерә торгач, янгыннан килгән материаль зыян белән кабул итеп алынган һәм бүлекләргә чыгарылган товарлар арасында очы-очка ялганмаулар булганлыгы беленгән. Сату-алу эшендә зирәклеге чамалы булган Маһирә, бәлки, моны рәтләп сөйли дә белмәгәндер, бәлки, минем тыңлавым, аңлавым шуның кебегрәк булгандыр, кыскасы, шаушулы җәнҗал килеп чыккан аларда. Склад мөдирен шундук, әлбәттә, утырткannar, җитмәсә тагы, анысының растрата аркасында әлектә дә бер «кутыры» булган, имеш. Киткән тәфтиш, киткән шомлану... Әлеге бәла килеп чыккан көннәрдә Җаббар агай үзе бөтенләй Казанда ук булмыйча, командировкада калуга да карамастан, соңыннан күсәкнең авыр башы картка килеп төшкән: янәсе, бүрек астына бүре балалары яшереп ятучы кеше ул, сукырлык күрсәткән, үз кадрларын тикшермәгән-белмәгән, һәм башкалары, һәм башкалары... Шул бәлаләргә өстәп тагы, Җаббар картның НЭП елларында, ул вакыттагы сәүдә политикасын төшенеп житмичә, элеккеге «каты тараканнар»ның ярыклардан терелеп чыгуларына каршы бунт күтәреп йөрүләрен дә китереп такканнар, имеш. Тегә «көмеш туй» вакытында кайсыдыр берсе казып чыгарырга маташкан иде ич, күрәсең, хәзер шуны чынлап торып әвәләгәннәр. Маһирәнең миңа әйтүенә караганда, мәсьәләгә политик төс бирергә маташалар, ди. Шуны булдырмас өчен бичара карт хәзер, та-

мам тамактан калып, тикшерү органнарына, алардан райкомга, райкомнан партконтрольгә чаба икән.

Мондый болганчык чакта килешәме соң шулай чәчрәп йөрү. Иелгән башны кылыч кисми, ди халык мәкале. Башыңны иясе дә торасы мыштым гына. Мин Маһирәгә, әлбәттә, болай дип үк әйтмәдем, Маһирәнең шул үк этисе кызы булганлыгын, турылык, гаделлек яратучы горур табигатьле кеше икәнлеген белә идем. Ләкин шулай да күңелемнән дерт итеп бер сорау узды: «Бик ешлый башламадыммы мин бу гаилә тирәсендә?»

Хәер, чаңгы базасыннан прокатка чаңгылар алып, шәһәр читенә чыккач, карлы дала кочагына, тау-чокырлы Казанка тугайлары арасына ташлангач, икебез дә андый борчулы уйлардан җиңеләеп калган кебек булдык. Барыннан да бигрәк, бер хис биләп алды: без монда икәүдән-икәү генә идек. Шуның өстенә Маһирә бүген гаҗәп килешле итеп, кышның үзенә охшатыбрак, актан киенеп килгән, әмма, кайбер кыланчык кызлар кебек, ничек кенә булса да бөтен җирен — булганын да, булмаганын да — күпертеп куярга тырышмаган иде. Аннан бирле күпме вакыт узган, күпме су аккан, күпме яңгыр яуган, юылырга да вакыт иде, югыйсә. Ә менә юылмаган. Ул кыз, аның килешле сурәте минем күз алдымда бүгенгедәй басып тора: башында куян мамыгыннан бәйләнгән йомшак ак берет, берет читеннән әлеге тыңлаусыз чәче бөтәеп чыккан, өстендә утыртма якалы кышкы ак свитер, керфеккашларында ак бәс, дөньяны баскан шул йомшак аклык эчендә, кышкы ак фонда аның юка гына, чандыр гына фигурасы уйный. Йөрми, шумый да, әллә ничек менә кырлар өстеннән, күзнең явын алып, уйнаклап баргандай итә. Мин моны Маһирәнең чаңгыда үтә шәп йөрүеннән дип әйтмәс идем, ул яктан без икебез дә бер чамалырак идек. Күрәсең, гашыйклык мине шулай тилерткәндер. Ә ул кышкы иртәдә, каш-керфеккә бәс сылый торган салкын иртәдә, тын һәм кырыс иртәдә мин ул кышкы кубәләккә башым-аягым белән гашыйк идем. Йөрәкне әйтмим дә инде, ул чаклысына минем телем дә, сүзләрем дә җитмәс, аңысын шагыйрьләр әйтсеннәр. Шулар өстенә, шуларның барысы өстенә мин чак-чак кына юләрләнә дә башлаган идем шикелле. Юкса, кем соң, акыллы кеше, тора торгач кыр уртасында кызга минем кебек дуамал бәйләнә башлар икән. Ә мин менә бәйләнә башладым:

— Күтәреп карыйсым килә сине, Маһирә. Авырлыгың бармы икән синең? Рөхсәт итәсеңме? Күтәреп карыйммы бер? — дип, телемә салынып, ә үзем, нәрсә әйткәнемне һич аңышмыйча, дуамал очыну белән аңа якынлаштым. Кыз, куркынып, артка тайпылды һәм, алай-болай якын килә башласаң менә күр, дигәндәй, таягын ук күтәрде. Таягын күтәреп, миңа кизәнеп һәм шулай кизәнгән арада наян көлемсерәп, мине үчекләп торганда ул баш әйләндергеч сөйкемле, дөньядагы бөтен күңелсезлекләрне онытгырырлык ямь тарата иде. Теге вакытта коры кул белән мине «көмеш туйга» илтеп тыккан өчен үч алыр минут нәкъ менә шушы иде инде, югыйсә. Ә мин, арыш камыры, аның шул наян көлемсерәп, чаңгы таягы белән куркытып, шаяртып үчекләвеннән исерәдем дә калдым.

Аннары без, беребез артыннан икенчебез, әллә ни калышмыйча, тагы шуып киттек. Көн төшлектән кичкә авышканчы йөрдек, ашыйсыбыз килеп бетте, арыдык та бугай, ләкин беребезнең дә сер бирәсебез килми, кайтыйк дигән сүзне беребезнең дә башлап әйтәсе килми иде. Ләкин арыганлык нык кына сиздерә башлаган иде инде. Күрәсең, Маһирәдә бу бигрәк тә көчле булгандыр, инде шәһәргә кайтып җиттек дигәндә, рус зираты артында сөзәк кенә бер таудан шуып төшкәндә — гомердә булмаган хәл — аның аяклары, яна тәпи киткән сабыйныкы кебек, як-якка чалышайды, бер аягындагы чаңгысы, ычкынып, аска шуды, кыз үзе дә мәтәлеп китте. Ләкин аның җиңел гәүдәсен тотып

калырга күпме генә кирәк, очарга әзерләнгәндәй кулларын җәюе һәм чырылдап бер кычкыруы җитә калды, әйләнеп үк барып төшмәде. Нәкъ менә шушы куркынган һәм уңайсызланган минутында — юри шулай эшләгәндер дип һич башыма китерә алмыйм — чайкалып минем кулыма килеп төште ул. Авызы ачылып калган, чәчендә кар, ә тәне ут кебек яна иде. Бәлки, теге вакыттагы алдашуы өчен «уч алу» минуты да нәкъ менә шушы төштә булгандыр. Бар күк тәвәккәллекне туплыйсы да, башын чак кына үземә таба каерып, ачык авызыннан суырып үбеп аласы иде. Юк, мин шул форсаттан да файдалана белмәдем, дөресен генә әйткәндә, ачык авыз Мәһирә түгел, ачык авыз ул мин идем. Кызны биленнән тотып аягына бастыру, өстеннән карын кагу һәм аска шуып киткән чаңгысын алып килеп бирү белән чикләндем. Бүтәнчә эшләгәндә, янәсе, тупаслык күрсәтү, әдәпсезлек, кулга ирек бирү була. Шул чагында күрсәткән әдәплелегем өчен гомер буе терсәгемне тешләргә маташып йөрим менә.

Әмма ул минутта минем кулда икенче козырь бар иде. Минем әле үземә аерым бүлмә алуым турында Мәһирәгә әйткәнем юк, шул турыда әйтеп, Мәһирәдән сөенче алу һәм, әгәр күндереп булса, аны алып кереп бүлмәмне күрсәтү — минемчә, бүгенге шатлыклы көннең тажы нәкъ менә шушы сюрприз булырга тиеш һәм, әгәр минем мәкерле планым барып чыкса, күптән теш кайрап килгән «уч алу» да нәкъ әнә шунда, аулакта, шаһитлар күзеннән читтә булырга тиеш иде.

Мәһирәне күндерү ул хәтле читен булмады. Күрәсең, ул миңа ихлас күңелдән ышанган һәм, шуның өстенә тагы, бүлмәне күрергә теләве дә бик көчле иде булса кирәк. Кергәч тә иң элек минем оя башы итеп алып куйган беренче покупкамнан — бер почмакта, патша дворнигы кебек, медальләре белән ялтырап утыручы ак самовардан рәхәтләнеп көлдек. Түләем алганда, бүлмәм Мәһирәгә бик ошады, бүлмәдән дә бигрәк минем төшеп калганлыгым, әйбер ала белмәвем ошады аңарга.

— Кара аны, икенче минем киңәштән башка әйбер аласы булма,— диде ул, үзен бу кечкенә бүлмәнең чын хуҗасы кебек тотып. Алай торарга бераз иртәрәк икәнлеген чамалап булса кирәк, сүзне шундук уенкөлкегә борырга маташты: — Ә хәзергә шундый зур самоварың булгач, сиңа бик җиткән. Шуның борынынннан кайнамаган су суырып, ялгыз башың караватыңда аунап ята бир. Сүз чыккач, искә төште: караватың бармы соң синең?

— Хәзергә миңа шушы да бик җиткән, — дидем, элекке хуҗалардан сатып алып калган биек артлы иске диванны күрсәтеп. Һәм алдан әзерләнеп куелган мәкерле планымны гамәлгә ашыра башларга вакыт җиткәнлеген сизеп, уен-көлке белән һәм шуңа чак кына хәйлә дә кушканлыгымны ачыктан-ачык сиздереп, китап шкафының аскы бүлегеннән ярты бутылка ал мускат, ике рюмка, бер такта шоколад чыгардым,— эчәбез дисәк, салкын чәйдән башкасы да бар. Сез мине әйбер ала белмәүдә юкка гына гаепләсез, туташ.

Эчемлекне күреп, Мәһирәм ничектер шүрләп калды һәм бер үк вакытта чак кына сагая да төште кебек. Ул, сүзсез калып, әле миңа, әле, башка урын булмаганлыктан, газета җәеп, тәрәзә төбенә утыртылган мускат шешәсенә кашларын җыерып карап торды.

— Чынлап та, минем бу хөҗрәмне һәм синнән башка әйбер ала белмәвемне нәрсә беләндер билгеләп үтмичә ярамас бит, Мәһирә, — дидем мин, эчемлек тутырылган рюмканы аңарга сузып. Һәм шундук, үзем моның тиз буласына гәрчә бик үк ышанып җитмәсәм дә, ишарә ясап үтәргә дә онытмадым: — Менә синең белән икәү булгач, кирәккирәкмәскә акча әрәм итмәбез, кирәген генә алырбыз.

Бу соңгы ымлау Мәһирәмне, бичараны, сизелерлек йомшартты, ул рюмканы кыяр-кыймас кына кулына алды...

Аннары без бераз гына сөйләшеп утырдык. Озак түгел, Маһирәмнең утлы күмердә утырганлыгын, уңайсызланганлыгын, сүзләрне өзеп-өзеп калдырганлыгын күреп тора идем. Арып-талып кайткан ул чандыр кызга әлеге теге ярты рюмка мускат ярыйсы гына тәэсир итте булса кирәк, ул үзен бик уңайсыз тота иде. Кинәт, балалар кебек, тиз генә сикереп торды да:

— Мин кайтыйм инде, Хәнәфи абый... мине өйдә югалтканнардыр, — дип сөйләнә-сөйләнә, ишеккә таба атлый башлады.

— Һич югы, чак кына ухаживать иткән булыйм, — дип, аның каршысына чыгып бастым. Кадактан беретын алып кидердем. Телемә кайдандыр сүзе дә туры килеп торды:

— Әйтмичә калсам, йокым йокы булмас, сиңа бу шапкаң бик килешә, Маһирә, — дидем һәм шул тирәдә чуалган кулым белән тиз генә аның башын үземә таба каерып, бит очыннан гына суырып үбеп алдым.

— Теге чакта этиләреңнең «көмеш түе»на алдап алып барганың өчен бусы, белеп тор! — дидем, шаркылдап көлә-көлә.

Маһирә, текәлебрәк, миңа бер карап куйды, ләкин ачуланганга бер дә ошамый иде.

## VIII

Шул очрашудан соң байтак вакытлар безнең ара өзелеп торды. Минем үз мәшәкатьләрем килеп чыкты, Маһирәләр өендә... ай-һай ла, «мәшәкать» дигән төшенчәгә генә сыеп бетми торган хәлләр килеп туган: әлеге теге склад янгыны белән бәйләп Җаббар агайны утыртып куйганнар. Маһирәнең соңыннан миңа аңлатуына караганда, монда ул янгын мәсьәләсенә өстәп тагын нәрсәләрнедер искә алганнар, хәтта бу «тагы нәрсәләрдер» дигәне беренче планда ук булмадымы икән?

Гомумән, кайбер шомлы хәбәрләр болардан башка да ишетелгәли иде инде. Мин, эш белән мавыгып, аларга колак салмаска тырышам, кеше белән аралашмыйм, бәлки, Маһирәләргә бармый йөрүем дә шуннан булгандыр.

Әмма тормышта яшәп, шул ук вакытта тормышны өеңә кертмичә, бикләнеп ятарга мөмкинме соң! Кичләрнең берендә Маһирә минем ялгыз бүлмәмә үзе килеп керде. Бу факт үзе үк инде мине сискәндерә калды. Үз дәрәҗәсен яхшы белә торган һәм гомумән тотрыклы әдәп кагыйдәләрендә тәрбияләнгән интеллигент табигатьле кыз, төнгә каршы дигәндәй, ялгыздан-ялгыз егет бүлмәсенә килеп керсенче әле. Болай да юка тәнле чандыррак кына кыз — күрешми торган бу вакыт эчендә ул тагын да ябыккан, күзләре эчкә баткан, йөзендә сәер аклык һәм шул аклык аралаш үтә бәреп чыккан гаҗизлек-аптырау чагылган иде.

— Син тыныч бул, Хәнәфи абый, минем монда кергәнне берәү дә күрмәде.

Исәнме юк, саумы юк, шушы чәнечкеле сүзләре белән үк ул мине көйдереп алгандай итте, — ул, әлбәттә, үпкәләгән иде миңа. Үпкәләгән, әмма килгән. Димәк, бүтән чарасы калмаган, димәк, бүтән таяныр кешесе юк. Мин, булдыра алганча, ачык чырайлы, киң күңелле һәм элеккечә үк игътибарлы булырга тырыштым. «Булдыра алганча» дим, чөнки Маһирәнең борчулы кыяфәте бик очынырга ирек бирми, күңел шундук көтелмәгән хәл барлыгын сизеп алган иде инде. Шулай да гадәттәге уенчаклыкны берьюлы гына җиңеп бетерә алмадым.

— Ин әлек әйбәт кенә итеп күрешик, — дидем мин, борынгыларча, ике кулымны да сузып, — аннан соң... ничек соң... Кайсы җил китереп ташлады сине мондый кичке сәгатьләрдә?

Сүз арасына «мин сагынганны белдеңме, үзең сагынып килдеңме?» дип, җыр кисәкләре дә кыстырып һәм мөмкин чаклы шаулап, тегенең

өске киемнәрен чишендермәкче булдым. Ләкин Мәһирәм — тел белән әйтүдән бигрәк, кискен хәрәкәте белән — минем бу куштанлыгымнан баш тартты, шулай чишенмәгән көйгә, бер читтәге урындыкка, ничек эләксә — шулай ташланган китапларны бер якка алып куеп, сак кына килеп утырды. Шундый ук саклык белән миңа бер мизгел сүзсез генә карап торды. Бу минутта аның эчкә баткан кара күзләре гаҗәеп бер моң белән тулып, өзгәләнеп һәм ялварып, бер үк вакытта өшеткеч шелтә белән карый иде. Мин дә, ихтыярсыздан, сүзсез калдым.

— Кемне җирләгән сәгать булды бу, болай телсез калып?

Мин ахмакның да теленә килде бит сүз. Мәһирәм утырган җиреннән, сынган гөл кебек, сыгылып төште, битен учына яшереп, кинәт елап җибәрде.

— Кем белә... бәлки, минем эти картны җирли торганбыздыр? Күпме кирәк олы яшьтәге кешегә.

Аның сүзләре яшь аралаш өзек-өзек чыга, сүзне ул миңа әйтүдән бигрәк, үзенә-үзе әйтә иде шикелле. Минем юатырга, җылы сүз табарга, «сынган гөл»не яңадан үз урынына утыртырга тырышуларым файда итмәде, Мәһирә, йөзеннән учларын алмыйча, әкрен генә елады-елады да, бераз тынлыга төшеп, әмма бу юлы инде миңа әйткәндәй итеп һәм миңа әйткәнлеген аермачык сиздерергә тырышып әйтте:

— Син мине гафу ит, Хәнәфи абый... Башка барыр кешем булмагач, килдем. Үзең килмәссеңме дип көттек башта. Бигрәк тә әнкәй көтте.

Мәһирәнең болай өзгәләнүләре миңа аңлашыла, ул бик аптыраган. Шул ук вакытта минем үз хәлем дә хәл: бу өзгәләнгән минутларында мин соң аны нәрсә белән юатыйм? Ничек итеп аның хәсрәтенә иңемне куйыйм? Бигрәк тә, шундый болганып торган бер заманда.

— Тынычлан, Мәһирә, ачыкланмаган нәрсә юк бу дөньяда, барсы да ачыкланыр, — дим мин авыз эчемнән ботка пешереп. Шундук тагы үземә-үзем һич хисап биреп тормастан, бу вәгъдәмнең арты ничек булачагын уйлап карамастан, шактый ук барабанга әйләнеп, ярып салам:— Минем бит әле бу хәлне беренче мәртәбә ишетүем. Менә барырбыз, сорашырбыз. Кирәк икән, тиешле сүзен әйтербез.

Кыз бу сүзләргә, әлбәттә, җитди әһәмият бирмәде. Хәтта ул аларны рәтләп ишетмәде дә булса кирәк. Шулай да ул инде яхшы ук тынычланган, «Әле бөтенләй үк ялгыз түгел икәнмен!» дигән кебек, мөлдерәп миңа карап тора иде.

Әйтеп сүз, уйлап баш җитмәслек гаҗәеп бер минут булды бу. Мин тоташ каршылыклы хисләр эчендә идем. Әмма шулар арасында иң көчлесе, әчүе җиткән бал кебек, берьюлы башка суга торганы шул: мин Мәһирәне сөя, сулышым белән тартып алырлык булып сөя идем. Менә ул миннән кул сузымы гына җирдә шарфын рәтләгән булып басып тора. Күзләреннән яше кипмәгән, ябыккан, хәсрәтле, әйтергә дип килгән сүзләрен рәтләп әйтә алмады һәм шул әйтелмәгән сүзләре аның юка иреннәрен көйдергәндәй кызартып тора иде. Кайдандыр гомердә булмаган көч-тәвәккәллек ташып чыкты, тәкәллефсез рәвештә ташланып, кызны үземнең кочагыма тартып алдым, битен, шарфын, шарф астыннан таралып чыккан хуш исле чәчен, муенын үбә башладым — кыскасы, мин сукырайган идем ул минутта һәм шул сукырайган хәлемдә дөньяның бердәнбер бәхетлесе ул мин идем.

— Син — минеке. Син бөтен барлыгың, кайгың-хәсрәтең, үпкәләвең-күз яшең белән минеке, Мәһирә. Син һәрвакыт... Любой минутында мине үзеңнең терәгең дип исәплә!.. — Тыным бетә-бетә әнә шулай кабатларга тотындым мин. Кыз, оялыпмы, ачуланыпмы, чак кына кычкырып куйды һәм, моның урынсыз чыкканлыгын чамалап, шундук пышылдауга күчте:

— Нәрсә әйтергә синә, Хәнәфи абый... Алайса минем дә бер кешем бар икән әле.

Ул китмәкче булып ишекне тартты, ләкин ишекнең английский биге бикләнеп өлгергән икән, тиз генә чыгып китә алмады.

— Тукта, мин сине озатып куям, — дидем мин, тиз генә эшләпәмне алып. Маһирә, «Чынлап әйтәме бу?» дигән кебек, миңа туры гына бер карап алды. Шундук, гадәттәге кырыслыгына кайтып, боерык тоны белән әйтте:

— Җүләр сатып йөрергә уйлама. Юлны синнән башка да беләм. — Һәм, акылсызлык эшләргә җыенган балага акыл бирергә теләгәндәй, йомшак һәм назлы тавыш белән өстәде: — Гел болай булып тормас, ускәнем. Өлгерербез. Озатышырга да, сентиментальничать итәргә дә өлгерербез.

Шулай да мин аны тыңламадым, мин кирәгеннән артык бәхетле идем ул сәгатьләрдә. Өйләренә хәтле озатып куйдым, ләкин гадәттәгечә чөкердәшеп бару булмады. Ул мине мөмкин чаклы кеше йөрми торган караңгырак урамнардан алып барырга тырыша иде. Хәер, дөресен әйтим, мин үзем дә моңа каршы түгел, кеше күрмәве хәтта хәерлерәк тә; урамга чыккач, салкын һавада янә минем салкын акылым эшли башлаган иде: «Күргәннән күрмәүләре хәерлерәк. Белгән юк, әллә ничек булып чыгуы бар дөнья эшләренең!»

Барып җиткәч, элекке гадәт буенча, капка төпләрендәге эскәмиядә чак кына утырып торырга тәкъдим ясап карадым. Маһирә бу турыда авыз да ачтырмады. Шулай да минем элеккечә якын итеп каршы алуым, аннан да бигрәк, кеше-кара күзенә чалынудан курыкмыйча озата килүем аны тереләткән, өенә керешли ул, минем кулымны кулыннан ычкындырмыйча, күңелендәге тәмам бушатып китәргә ашыкты:

— Син, Хәнәфи абый, шулай да безне ташлап бетермә, яме, — дип башлады ул, балаларча беркатлылык белән. Һәм болай беркатлануны эчке горурлыгы килештереп җиткермәде булса кирәк, шундук сүзне әнисе исеменә күчерде: — бигрәк тә әнкәй өчен әйтәм бу сүзне. Бик бетереште соңгы вакытта, бичара. Әйтеп-әйтеп карыйм да, гомере буена ир канаты астында сыенып яшәгән кешегә кызы әйткән сүз генә сүзмени. Ичмасам, сирәк булса да син күренгәләп китсәң, карчык кеше, ни дә булса уйлап, чак кына юанмасмы икән, дигән сүзем.

Ул бу сүзләрне әнисе исеменнән әйтте, ләкин тел төбеннән бик ачык сизелде: монда аның үз уйлары, үз сүзләре дә, әлбәттә, җитәрлек иде.

## IX

Һични белән аклый да, аңлата да алмыйм, шуннан соң мин ай буена диярлек Маһирәне күрмәдем. Күрәсем килеп очынган минутларым булмады түгел, бигрәк тә кичләрен ялгыз булмагә кайтып кергәч, кинәт эчем пошып, аны искә төшергән минутларым булгалап тора иде. Ләкин ай-һай ла! Итәкне-җиңне җыеп тотарга мәҗбүр итә торган сәбәпләр дә күп иде шул ул елларда.

Әнә шундый шомлы көннәрнең берсендә һәм, узара гына әйткәндә, үз аягыма үзем тышау салып, Маһирә белән бәйләнешле «тиле уйларны» берәм-берәм күңелдән йолкып ата барганда, исән-сау гына торасынмы, бер көнне институт канцеляриясенең секретаре, карап торырга мокыт кына Сәрьянов, безнең кафедрага үзе йөгереп килеп, шунда булган бөтен кеше алдында:

— Сезне Максудова дигән бер бәндә телефонга чакыра, трубканы эләмәдем, тиз бул, — дип дәшеп китте. Чыксам, бу әле китеп тә житмәгән, ишек төбендә мине көтеп торган булган, имеш. Тавышын кыса төшеп (һәрхәлдә, миңа шулай тоелды ул минутта), сүз кушты:

— Кара әле, Ризванов, ул Максудова дигән бәндә теге халык дошманы итеп репрессияләнгән Максудовларның берәр чыбык очы түгелме? Кеше алдында сорарга кыймадым.

— Белмим. Телефонда мин сөйләшмәдем, син сөйләшкәнсең ич. Сорарга ие соң, — дип төксе генә җавап кайтардым һәм соңыннан бу төксилегем өчен үзем үк уңайсызланып калдым: «Нишләп әле болай энәләремне торгызып эндәштем мин? Әллә нәрсә булган кебек!». Югыйсә, билгеле ләбаса: «Максудовлар дөньяда бер безнекеләр генә түгел. Маһирәнең әтисенә килгәндә, аның эше бөтенләй башка, аны сәясәт белән бутый алмаслардыр. Шулай да секретарь мокытның төпченеп дәшкән тавышы күңелне шомландырырга җитә калды.

Телефонга чакыртучы, чынлап та, Маһирә иде. Күңелдә дөрт итеп кузгалган шикнең юшкыны телне бәйләде булса кирәк, мин аның белән бик коры сөйләштем. Теге үзләренә килеп чыгуны үтенгәч, «Вакытым юк, белмим, булдыра алмамдыр... ышандыра алмыйм», — дип җавап бирдем дә трубканы элеп куйдым.

Әмма вакытым бар, ул кичне бер җиргә дә барасым юк иде, инде хәзер, аннан соң күп еллар үткәч, үз-үземнән һич яшермичә әйтергә була: Маһирәнең чакыруын мин, бернинди тышкы сәбәпләр аркасында түгел, бары тик үземнең куркаклыгым аркасында кире кактым.

Кире кактым һәм шундук күңелемнән үз-үземне битәрли дә башладым. Чынлап та, дуңгызлык булды бит бу минем тарафтан. Моңа хәтле йөргән, вәгъдәләр бирешкән, ашларын ашаган, курка-курка гына булса да үбешеп карарга да өлгергән. Ә менә хәзер, кешенең борчулы вакытында, борыны төбендә шап итеп ишекне ябып куй, имеш. Ул көнне эшем эш булмады, үземне түбән җанлылыкта, эгоистлыкта, куркаклыкта гаепләп бетердем. Шул ук вакытта күңелемнең кайсыдыр бер почмагында мондый уйлар да бутала: «Булса соң! Өзсәң соң! Син гаепмени? Үзләре гаепле. Дөресрәге, әтисе гаепле. Күрәсең, кесәсендә таш йөрткәндер. Шуны теге янгынга китереп өстәгәннәрдер. Бөтенесенең дә үзенә күрә логикасы бар. Бала булма, белмәгәнгә салышма, кысылмаганың яхшы. Итәгеңне-җиңеңне җыеп йөргәнең яхшы. Синеке әле алда. Тем более диссертацияңне яклау алдыннан...»

Шулай да үземне җиңеп кала алмадым, кич булып, көнгә караңгылык төшкәч, арткы урамнардан, Кабан буйларыннан урап, Аркылый Тукай урамына — Маһирәләргә киттем. Тәрәзә пәрдәләре корулы, парадный ишекләре эчтән бикле, ут бер генә тәрәзәдә — Маһирә бүлмәсендә генә иде. Күршеләрен кузгатмас өчен звонокка әкрен генә бастым. Көтеп торганнармы дип әйтим, шундук залга ут алдылар, бераздан баскычтан әкрен генә басып төшкән аяк тавышы ишетелде. Бу — Маһирә адымнары түгел, Маһирә баскычтан атылып-чабып төшә торган иде, бигрәк тә мине каршы алганда мин аның баскычтан атлап кына төшкәнен һич хәтерләмим. Тәрәзәдән күреп алу белән, звонокка кагылганны да көтмичә, ишектер очып төшкәндәй төшә иде. Ә бу килүемдә... Маһирәм бөтенләй күзгә-башка да чалынмады.

— Китапханәгә дип китте, шуннан иптәш кызларына да керәм диде шикелле. — Әнисе Зарифәттәйнең күзләре кызарган, шуны миңа сиздермәс өчен булса кирәк, ишектер түбәнгә карабрак сөйли иде. — Киләсе кеше бар дип көтте ул болай көтүен, күрәсең, ашыгыч йомышлары булгандыр, югыйсә, китмәс иде... Өстегезне салыгыз, утырыгыз, кем белә, бәлки кайтып та җитәр.

Һич югы бер генә тапкыр исемемне телгә алсынчы! Ә бит бу апа элек, урынында да, урыны түгелдә дә, минем исемемне тәсбих урынына телдән төшермичә сөйли иде. Димәк, озак вакытлар күренми торуның файдасы тигән — бу җылы күңелле гаилә белән мин утын пүләне арасыннан төньякның салкын җилләре үтәргә өлгергән... Барыннан да хәтәррәге шунда: Маһирә беркая да китмәгән, Маһирә өйдә, бары тик

миңа күренмәскә генә булган. Мин моны шундук — Мәһирәнең урындык аркасына эленеп торган ак шарфыннан, кайсы кая атылган киемнәреннән чамалап алдым. Гомумән, аларның өендә гадәттә була торган җыйнаклык, пөхтәлек юк, әйберләр таркау, өйне яхшы ук тузан баскан иде.

— Нишләмәк кирәк өйдә булмагач, ул бәлки ярты төнсез кайтмас,— дидем мин, Мәһирә бүлмәсенең ишегенә юри турырак карап. Дөресен генә әйткәндә, болай ишек төбеннән генә борылып китү минем хәлемне яхшы ук җиңеләйтә иде: килмәдем түгел, килдем, инде шулай миннән качып калуны кирәк тапкан икән, үзенә үпкәләсен. Аның артыннан ялынып йөрергә минем артык вакытым да юк, кешесе дә ул түгел һәм, бигрәк тә, заманы ул түгел.

Борылып чыгып барышлый колагыма чалынып калды: Мәһирә бүлмәсеннән кинәт тонык кына бер дөпелдәү ишетелде. Нәрсә икәнен шәйләп торырга вакыт булмады, ишек ачылган иде инде... Шулай ук аны-моны нечкәләп торырга чамам да юк иде: күренмәгән икән — шулай күренмәгән килеш кала бирсен.

Ләкин тиз генә алай калдырырга мөмкин түгел, минем ул кызга булган мөнәсәбәтем мин уйлаганнан тирәнгәрәк киткән иде булса кирәк. Кайта-кайта башыма килде: ник соң әле мин ул йорттан алай ансат кына борылып чыгасы иттем? Утырырга иде, хәлләренә кереп бераз сөйләшергә, сорашкаларга иде. Мәһирәнең үзеннән сорашып ни дә булса алырга мөмкин түгеллекне беләм, кыз авызы тулы кара кан булса да кеше алдында түкермәячәк, ә менә аны көткән атлы булып утырып калганда һәм шул арада Зарифәттәйдән сорашканда ул борчулы кешеләрнең чак кына булса да күңелләре бушанып калыр иде. Ә бит минем... әйтергә, икърар итәргә оят, Җаббар абзый турында авыз ачып хәтта сүз дә кузгатканым юк. Әйтерсең, андый кеше дөньяда бөтенләй булмаган, әйтерсең, безнең аның белән кара-каршы утырып шахмат уйнауларыбыз шулай ук булмаган, мин аларга барып кергәч, картның, кызыннан да бигрәк ачык чырай күрсәтеп, каршы алулары, минем эшем, укуым, тормышым турында кызыксынып сораштырулары, булдыра алганча киңәшләр бирергә тырышуы, әйтерсең, барысы да төш кенә...

Ул вакытта ярым-йорты гына төшенгән булсам, кызганычка каршы, хәзер, эш узып беткәч, тулысы белән төшендем: ышкысаң пычак үтмәслек калын тиреле дуңгыз булганмын мин ул чагында. Гыйльми дәрәҗә алмасына үрелергә маташучы, шырпы тартмасына кереп бетәрдәй хыял-өметләреннән бүтән нәрсәсе булмаган бака тәнле обывательгә әйләнгәнмен. Шул ук вакытта әле бөтенләй таш йөрәккә үк әйләнеп өлгермәгәнмен булса кирәк. Чөнки кайтып эшкә утыруым белән күңелемне нидер тырнап узган кебек итте. Фикерләремне туплый алмадым. Тордым да, тиз-тиз генә киенеп, тагын шул Аркылы Тукай урамына чаптым. Бу юлы инде планым бик ачык иде: Мәһирәне өйдә очрата алсам, аның алдында, ул юк икән — әнисе белән иркенләп бер сөйләшеп утыру, хәлләренә керә алсам — хәлләренә керү иде. Ләкин йөрүем бушка гына китте, бу баргында аларның бер тәрәзәләрендә дә ут күренми, алар инде ятканнар иде.

Кинәт миңа дөнья бик күңелсез булып китте. Өйгә борылып кайтасым килми, бүтән барыр җирем юк иде. Гомердә күренмәгән хәл, сөйрәлеп ресторанга барып кердем. Анда әллә ни кеше юк, өстәлләр буш — кайсына теләсәң, шунысына утырырга мөмкин иде. Почмактагы бер өстәл янына барып утырдым, ужинга заказ бирдем, йөрәк янганчы аракы янсын дип, чак кына эчеп карарга да булдым. Дөресен әйткәндә, күңелем эчүдә түгел, хәер, ул чагында мин әле эчүнең тәмен дә белми идем. Миннән күрше өстәлдә генә, чама белән минем яшьләр тирәсендәге ике егет, авызны-авызга куеп, бик бирелеп ни турындадыр сөйләшеп утыралар иде. Алларындагы рюмкаларда эчемлекләре

дә бар, ләкин авызларына алганнары күренми, барыннан да бигрәк, аларны әңгәмә мавыктырган иде булса кирәк. Әмма күршеләренә мин килеп утыруга, әңгәмәләрен шундук бүлеп, рюмкаларын кулларына алдылар һәм, тиз генә бушатып, урыннарыннан торып киттеләр. Мин шунда гына аңыма килгәндәй булдым: «Әйе. Шулай шул... белмәгән кеше шул мин алар өчен... нәрсә уйламаслар», — дип куйдым эчемнән. Шул ук вакытта: «Син үзең соң, Хәнәфи дус, белгән... ашларын ашаган, алдагы хыял-өметләренне баглап йөргән кешеләреңнән дә качтың түгелме соң әле?» — дигән мыскыллы уй да килде. Тагы эчке икеләнүләр, үземне-үзем битәрләү башланып китте. Ашап, нәрсә ашаганымны белмәдем, эчеп, аракы алмады. Официантка белән исәп-хисапны өзеп, торып чыгып киттем.

Кызган баштан тагы Мәһирәләргә барып чыгарга булдым. Ярты юлга җиткәч, кире борылдым — нигә ул хәтле койрыгы пешкән мәче булып чабарга? Нинди гаебем бар соң минем ул хәтле?

Әмма өйгә кайткач, җылы истәлекләр белән тулган тын бүлмәдә калгач, тагы иләсләнергә тотындым. Күреп булмаса, һич югы барысын да әйтеп, мин баргач өйдә качып калганлыгын да исенә төшереп һәм, булдырып булса, шул сылтау астында араны өзәргә теләвемне дә сиздереп, озын гына итеп бер хат язып җибәрергә уйладым.

«Мәһирәм — җан кисәгем!» дип куйдым хатымның башына. Бик төче булыр кебек күренде. Аннан да бигрәк мондый эндәштән соң, ике араның суына башлавын, суынырга тиешлеген ничек аңлатмак кирәк. «Мәһирә иптәш!» дип башлап карадым, бик коры, казенный булып тоелды. Әле тегеләй, әле болай башлап һәм кайсын яртылаш язганнан соң, ошатмыйча, ертып ташлап, берничә бит кәгазь исраф иткәннән соң, ниһаять, берниндн эндәш тә ясамыйча, гади генә итеп башлап җибәрдем дә, кайда артык төчеләнеп китүемне, кайда коры чыкканын һич тикшереп тормыйча, су буе озынлыгы хат язып ташладым. Икеләнүләрем оныттылды, сүзләрем чишмәдәй чылтырап агып торды, күңелем әйтеп бетергесез ашкыну белән тулы иде ул минутта. Хәтерлим: мин өстәл яныннан торганда сәгать төнге икенче иде.

Ләкин иртәгесен йокыдан торышка мине тагын салкын акыл билэп алды. «Мондый чакта кеше электә язганнарын ничек кырып юкка чыгарырга белми йөри, ә син, Хәнәфи юләр, бала-чага булып, үз кулың белән үз башыңа бәла әзерлисең. Син җибәрерсең мәхәббәт хаты, тегеләй дә болай дип, ә ул булып чыгар документ». Шуларны уйладым да чишмә урынына җырлап туган сүзләремне кәгазе-кәгазе белән ертып ташладым. Язганда мин бәхетле, сүзләрем ташып, кулларым йөгереп тора иде, ертып ташлаганда үз муеныма үзем элмәк салган кебек булдым. Аның каравы күңелем берьюлы тынычланып калды — юк, тотып күрсәтердәй берниндн дә документ юк безнең арабызда.

### X

Күпмедер вакытлардан соң, һич көтмәгәндә, кичке сәгатьләрдә, Мәһирә янә килеп керде. Яхшы ук аптырап калдым. Шикләнү дә түгел, курку яки сискәнү дә булмады бу юлы, нәкъ менә аптырап калдым. Үз дәрәҗәсен үзе белә торган, кулы сынса җиң эчендә яшереп калдырырга сәләтле, горур һәм тыйнак табигатьле бу кызның, төн пәрдәсе астында урыныннан кузгалып, ялгыз егетнең ялгыз бүлмәсенә килеп керүе, бигрәк тә теге кичне мин баргач качып калуыннан соң, янадан шулай калкып чыгуы гаҗәбрәк иде шул.

Бу килүендә ул алыштырып куйган кебек иде. Барыннан да элек күзгә ташланганы шул булды: таралмаган чәче маңгаена төшкән, чәч астында калган ак маңгай, бу очракта, миннән куркып качкан кебек күренә иде. Күзләре эчкә баткан, йөзе тагы да агара төшкән, шуныкы-

мы, күз төпләрендәге күксел күләгә, сөрмә тарткандай булып, әллә кайдан үзен сиздереп тора иде. Ләкин ул үзе боларның берсенә дә игътибар итмәгән, гомумән, көзгегә күз салмаган булса кирәк, җыеп кына әйткәндә, андый тышкы үзгәрешләргә игътибар итеп торулардан узганга охшый иде. Гади генә итеп исәнләште, кыстатмыйча гына килеп утырды, беренче күргәндәй, булмә эченә күз йөгертеп чыкты, тик шуннан соң гына миңа күтәрелеп бер карап куйды. «Син шулаймы? Элекке Хәнәфи Ризвановмы?» дигән төсле булды аның бу карашы.

— Вакытсыз борчып йөрүем өчен, зинһар, гафу итә күрегез, — дип сүз башлады ул, бераз сынап карап торганнан соң, — әнкәй аптыратканга чыдый алмадым, юкса мондый чакта эш кешесен вакытлы-вакытсыз... юк-бар белән башы әйләнмәгән кешене сискәндереп йөрүнең ярамаганлыгын чамалый идем.

Тиктән генә йөрмәгәнлеген ишектә күренүгә абайлап алган идем, инде менә үзе үк ачыла башлады: кызны, чынлап та, нәрсәдер үтә җитди бер эш китергән булса кирәк.

— Карасана сөйләнеп торган булуын, — дидем мин, мөмкин чаклы ихлас күңелле булып күренергә тырышып, — әллә кайдагы ят кеше кебек. Дөрес, бер көн мин баргач качып калуыңнан соң, болай искә төшерерсен дип көтмәгән идем...

Шулай кыланулардан соң һәм, дөресен әйтим, болай тел белән тегермән тартып маташтырулар Маһирәгә берничек тә тәэсир итмәгәнне күреп, мин дә бик җитди кешегә әвереләдем, кызның, аның үзеннән дә бигрәк, әнисе Зарифәттәйнең хәл-әхвәлен сорашырга тотындым. Бер тел ачылгач, кыяр-кыймас кына булса да, Җаббар абзыйны да искә төшердем.

— Шушы көннәрдә аларга суд булачак, имеш, — диде Маһирә кинәт, күзләрен ничек тә миннән яшерергә тырышып. Кыска паузадан соң, миңа сөйләүдән бигрәк үзенә-үзе, алай да аптыраганнан гына сөйләгәндәй, тонык тавыш белән сөйләп китте: — Әлбәттә, бездән сорап яки безне чакыртып торырлар дип һич уйламыйм. Передача алмауларыннан үк билгеле, эткәйгә икенче бәлаләр дә өяләр булса кирәк...

Кыз кинәт сүзләрен әйтә алмас булды, аның елап җибәргәнлеге, йөзен шундук читкә борып, тизрәк кулъяулыгына үрелүеннән үк билгеле иде.

— Тукта әле син, — дидем мин, тавышымны мөмкин чаклы нык тотарга тырышып, — алдан ук тревога сугарга ашыкма. Юк гаепне ягарга мөмкинме соң? Җаббар абзыйны кайсыбыз белми дә, кем аның чал башына чүп ташларга батырчылык итәр икән? Кайчан суд буласын ничек тә ачыкларга кирәк, керербез, әйтәсе сүзебезне әйтәрбез. Мин, мәсәлән, бөтенләй нейтраль кеше, әгәр мөмкин була икән, судына кертәләр икән, мин дә авызымны йомып калмаячакмын. Революция башыннан партиягә кергән, шул эштә җиң сызганып катнашып йөргән кешене — карт большевикны, понимаешь...

Маһирә минем кызып-кызып сөйләгән бу яклау речемне җитдигә алмады булса кирәк, бик тугарылып китмәде. Шулай да этисенә карата әйтелгән җылы сүзләр аны бераз тынычландыргандай итте, аның экренләп эри барганлыгын, барыннан да бигрәк, яшьле күзләрен миннән алмыйча текәлеп карап торуыннан чамаларга мөмкин иде.

— Әнкәйне әйтәм, яше олыгайган кешенең акыл ягы да зәгыйфьләнәме, ул да менә нәкъ син әйткән сүзләрне әйтә. — Маһирә, «Нишләп әле мин моны сиңа сөйли башладым?» дигәндәй, тукталып калды, сагайгандай булды, әмма паузадан соң яңадан ялгап алып китмичә булдыра алмады, — борчу да бик бетерде, ләкин мин үзем аны, бичараны, гаепләмим: бата барган кешенең саламга ябышуы, күрәсең, шулай була торгандыр инде...

Маһирә тирән генә бер көрсенеп куйды һәм — аптыраганнан булса кирәк — һич урыны түгел вакытта, ак тешләрен елтыратып, көлгәндәй итте. Ләкин әйтер сүзен ул әле һаман әйтмәгән, мин моны сизә идем.

— Зарифәттәйнең хәлен аңлыйм, — дидем мин, Маһирәнең каршына ук утырып, — аның хәле жиңелдән түгел, ләкин бу дөньяда ачыкланмаган бер нәрсә дә юк, барысы да ачыкланыр, Жаббар абзыйның гаепсез икәнлеге беленер. Син, Маһирә сеңелем, моны әниеңә, в конце концов, төшендерергә тиешсең.

Минем дә әкренләп кыза, аларның борчуларына керә барганлыгымны русча кыстырып жибәргән сүзләремнән, кул хәрәкәтләремнән сизеп алып булса кирәк, Маһирә ачыла төште һәм, кинәт тавышын күтәреп, әйтә куйды:

— Ә ул мена шулай төшендереп бирүне сездән... ир кешедән, гафу итегез, егет кешедән көтсә?

Беравык тын торганнан соң, минем белән сөйләшүдән дә бигрәк, үзе белән үзе, үзенең икеләнүләре белән сөйләшкән кебек һәм, мөмкин булса, ул икеләнүләрен шушында коеп китәргә ашыккандай, башын чайкап куйды:

— Белмим, белмим... Әнкәй диванаының сездән нәрсәләр көткәнлеген әйтергә микән? — Маһирә бу минутта искиткеч тәвәккәл һәм аны әйтер сүзеннән туктатыйм дисәң дә туктатып булмаячак иде.— Ул сезнең миңа өйләнеп... безгә килеп, безнең янда, безнең үз кешебез булып тора башлавыгызны көтә. Мин аңа әйтәм: «Ахмак сүз сөйләмә», — дим, ә аның үз туксаны туксан. Аның шул ахмак сүзе буенча... Менә үзем дә ахмакка әйләнеп, вакытсыз сезне сискәндерергә мәжбүр булдым. Хәсрәт дигәнең кешене шулай тилертә икән, Хәнәфи абый.

Маһирә янадан урындыкка сыгылып төште, йөзе белән учына капланып, әле генә үзе әйткән сүзләрдән оялгандай, тынып калды.

— Юк инде, «А»сын әйткәч, «Б»сын да әйт син, Маһирә, — дип әлеп алдым мин, мөмкин чаклы кызны юатырга тырышып, — мондый сүзне беренче кабат ишетәм бит мин, анысын да икенче кеше авызыннан. Зарифәттәй теләге итеп кенә ишетәм... Ә менә син, аның кызы... — һәм шунда, үзем дә сизмәстән, минем телемнән саксыз бер сүз ычкынып китте: — ...ә син соң үзең, Маһирә... син үзең ничек карыйсың бу эшкә?

Маһирә, бу минутта һич көтелмәгән бер кызулык белән торып, минем муеныма ташланды, аның кайнар күз яше минем битемне чылатты. Ул, сулышын тигезле-тигезсез алып, аны-моны абайламыйча, мине үбәргә-кочарга тотынды.

— Синме? Шуны сорап торасыңмы, Хәнәфи абый? Оят түгелме шуны сорап тору?

Ул, кинәт минем битемнән йөзен читкәрәк алып, әмма, кулыннан ычкындырырга курыккан кебек, янымнан жибәрмичә, минем жиңнәремнән тотып торды:

— Белмим, белмим, — дип пышылдап кына янә сүз башлады аннары,— ахмаклык, әлбәттә, минем тарафтан. Кирәк бит шундый вакытта, кит инде, кит...

«Кит инде, кит!» ди, ә үзе жибәрми, чытырдатып жиңнәремә ябышкан, туп-туры күзләремә карый, моңарчы «укып өлгермәгән сәхифәләрне» укырга тырышкандай карый, аның бу минуттагы яшь аралаш ялваручы күзләре искиткеч матур, ул күзләрдән, ул караштан жиңелмичә калу мөмкин түгел иде. Шулай да мин салкын акылымны югалтмадым.

— Бар син кайт, Маһирә. Үзең дә тынычлан, Зарифәттәйне дә тынычландыр, уйлашырбыз, — дигән сүзләрне бик ачык һәм шул ук вакытта бик ук тилерергә юл да куймаслык итеп әйтә алдым.

Уйламадым түгел, күп уйладым мин бу турыда, озак кына баш ваттым. Хәлләренә дә керә идем. Әлбәттә, жиңел түгел булса кирәк аларга. Зарифәттәй карты хәсрәтеннән авырутга сабышкан, Маһирәсе укуын

ташлап берәр җиргә эшкә урнашырга йөри, ләкин бер җирдә дә рәтле эш таба алмый, кая гына барып сугылмасын, әтисе хәлен ишетүгә, әдәпле генә итеп кире кагу ягын карыйлар, имеш. Җитмәсә тагы, карты турында бик сорашып йөри башлагач, карчыкның үзеннән дә туйганнар булса кирәк, бер көнне килеп боларга үз ихтыярлары белән шәһәрдән чыгып китү ягын ук карарга кушканнар. Шундый чакта аларга караңгы тормышларына зәгыйфь кенә булса да нур сибәрлек шәм кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла иде. Ләкин нәкъ менә шундый чакта миңа бик уңай бер сылтау табылды. Безнең институттан, Себер татарлары арасында фольклор материаллары җыю максаты белән, экспедиция чыгарылырга тиеш, экспедициядә күбесе югары курс студентлары, аспирантларга катнашу мәҗбүри түгел, бигрәк тә минем аспирантураны тәгәлләү бусагасында торуымны искә алганда, бу эшкә мине берәү дә мәҗбүр итәчәк түгел иде. Ләкин, нилектән икәнлеген үзем дә белмим, нәкъ шул мәҗбүр түгел эштә, минем катнашуым белән генә артмый да, минем катнашмавымнан гына кителми дә торган эшкә мин үземне һичшиксез катнашырга тиеш таптым. Хәзер инде, аннан бирле күп еллар узганнан соң, үземнән-үзем яшереп торуның хаҗәте дә, мәгънәсе дә юк, мин аны ул чагында ук белдем, белеп, аңлы рәвештә шулай эшләдем: мин куркакка Маһирәнең ачык әйтелгән тәкъдименнән ничек тә булса качарга кирәк иде. Һәм мин атна-ун көн буена, әле тегеләй, әле болай сузып, икеләнеп йөрдем дә бер көнне аларга барып, күземне дә йоммыйча, ялганладым:

— Шундый-шундый эш чыгып тора, Маһирә. Мин катнашырга мәҗбүрмен. Әйтеп карамадым түгел, колакка алмыйлар. Димәк, — дидем мин, ялганга ант итүче кеше кебек кызарып һәм тотлыга-тотлыга, — димәк, Маһирә, әлеге синең миңа бик тә ошаган тәкъдимеңне тормышка ашыруны һич югы өч-дүрт айга кичектереп торырга туры килер. Шуңа чаклы түзәрбез, ятка күңел салмабыз бит, наный?

Сүземнең азагында мин юри авызны ерырга, юмор кыстырып, мәсьәләнең кискенлеген йомшартырга маташтым — хәзер инде, оят булса да, ачыктан-ачык әйтә алам: барысы да фарисейларча ясалып, ак җепләре күренеп тора торган итеп эшләнде. Кеше күңелендә ни барын әллә кайдан сизә торган зирәк акыллы Маһирә моны, әлбәттә, шундук сизеп алды, дөресен әйткәндә, ул моны теге кичне, соңгы мәртәбә минем бүлмәмә килгән вакытта ук сизгән иде булса кирәк инде. — «Белмим, белмим! Ахмаклык, әлбәттә, минем тарафтан. Кирәк бит шундый вакытта... кит инде, кит!» — дип, өзгәләнеп һәм пышылдап әйткән сүзләре белән ук белдерде ул үзенең сизенгәнлеген. Ләкин үзегез чамалыйсыздыр, чирне үзең белү бер нәрсә, аңардан котылу икенче. Бу соңгысы, ай-һай ла, читенрәк шул! Маһирәнең мәхәббәт чире дә, күрәсең, тирәнгәрәк киткән, ул аңардан котылыйм дисә дә тиз генә котыла алмый, икенчедән, ул чагында аның ялгызлыгы да хәттән ашкан бер вакыт иде. Шуның өстенә, бәлки, әнисе карчыкның, беркатлы уйлап, җимерелә башлаган тормышын ничек тә җимермичә саклап калырга тырышуын да колакка алгандыр.

Әйе, Маһирә минем җаһилләрчә боргалануларымны сизенә, ләкин сизенгәнен ничек тә сиздермәскә тырыша иде.

— Нишләмәк кирәк, кияүгә чыгасым килә, дип каравыл кычкырып булмый шул, — диде ул, ахыр чиктә үзе дә сүзне уенга борырга тырышып. Ләкин күзләреннән, бөтен торышыннан, калтыраныл чыккан тавышыннан ук сизелеп тора: бичараның бер генә дә уйнап сөйләшәсе килми иде. Тагы шунысы да бик хәтердә калган: өйдән озата чыкканда, баскыч төбенә төшкәч, ул минем кулымны алып, ике кулы белән берьюлы озак кына кысып торды. Аның куллары хаста кеше кулыдай кызу, үзе — нервланыпмы, бүтән сәбәптәнме — чак кына калтырана, әмма күзләре, куркуны кабул итмичә, түбәнсенүне шулай ук кабул ит-

мичә, ачулы ут белән яна, зур булып ачылган күзләре миңа бик нык текәлеп, минем күңелемдә ни калган — шуны «укый» иде.

— Бәлки, онытканда бер открытка салып җибәрерсең. Аркылы Тукай урамында ялгызы гына утырып калган Маһирә дигән кыз барлыгын онытмасаң, — дип, авызын балалар кебек турсайтып, сөйләнеп куйды ул аннары. Нәкъ шул минутта минем аны тач әнә шул турсайган иреннәреннән бик каты, бик каты итеп суырып үбәсем килде. Ләкин Маһирә бик житди иде бу минутта. Мин, үбәргә теләп, аны үземә таба каера башлагач:

— Я, тилермә юкка, күршеләр күреп торыр, — дип, читкә этәрде.

Һәм мыскыллы елмаерга да, үксеп елап җибәрергә дә әзер бер төс-кыяфәт белән баскыч төбендә басып калды. Юк, баскыч төбендә түгел, минем күңелемдә басып калды. Ә мин киттем — үземнең ялганымны, оятымны, оятсызлыгымны, куркаклыгымны һәм, бер үк вакытта, җиңеләйгән җилбәзәк уйларымны эчемә йотып китем бардым.

Мәхәббәт дигәннәре шуның белән бетте, мин шулай җиңеләеп калган килеш тормыш юлыннан китә бирдем. Маһирәне икенче мәртәбә күрмәдем, икенче мәртәбә андый авыр һәм андый каршылыклы хисләр дә кичермәдем. Һичектер, барысы да, бөтен тормышым яу юкка буш барабан каккан кебек үтә бирде.

Экспедициягә киткән җиремнән мин Маһирәгә бер хат язып җибәрдем, нишләптер җавап килмәде, күрәсең, чамалары хат язышып уйнау тирәсендә булмагандыр. Икенче открыткамны, «адресат монда тормый» дигән билге салынган килеш, үзем кире алдым. Мин экспедициядән кайтканда, Маһирәләр инде шәһәрдә юк, алар, Казандагы фатирларын калдырып, каядыр — якындагы районнарның берсенә күчеп киткәннәр иде. Кайсы районга икәнлеген сорашып тормадым, гомумән мин бу эшкә иләс баштан җырланган һәм хәзер инде онытылган бер җыр шикеллерәк итеп карадым. Миңа, ыштан балакларымны сызганып дөнья куучыга, фән кешесе булырга, карьера ясарга дип чабучы кешегә ул «онытылган җыр»ны кабаттан искә төшереп торырга, хәер, вакыт та тимәде.

Аспирантураны бетереп, диссертация яклагач, кырынган-юнылган фән кешесе булып, тамак төбе белән сөйләшә башлагач, әллә ни романнар корып тормыйча гына, хәзерге хатыным Гайшәгә өйләндем. Башка бик күбәүләр ничек торса, без дә шулай торабыз. Тамак тук, өс бөтен. Күктән йолдыз чүпләмибез, әмма-ләкин модадан да калышмыйбыз. Шушы философия белән тукланып, әлегә хәтле яши бирдек.

Маһирә турында сораштырып йөрмәдем, шулай да бер чакны колагыма чалынып калды: кайсыдыр районда, урта кул бер агрономга кияүгә чыгып, шул агрономы белән торып ятмакта, имеш. Бер кызлары бар дип тә ишеткән идем һәм бу яшьлек тарихы шуның белән беткәндер дип тәмам тынычланган да идем.

Алла юк дип йөргән кеше, кинәт аллам искә төште: ходавәндә! Мине шул яшь вакыттагы чилегем, куркаклыгым, күңелем сайлаган мәхәббәткә артымны куеп, кояштан күләгә якка таба йөгерүем һәм аннары Маһирәнең күз яшьләре өчен болай җәзалыйсың булыр. Истәоста юк чагында кирәк бит яңадан әйләнеп кайтырга. Юк, онытылмаган икән, онытылмаган икән, гөнаһ шомлыгы.

Хәзергә әле төгәл генә әйтә алмыйм, ләкин ул, теге көнне минем Рөстәм — буш кесәгә НЯРЕП кайткан кыз, — Мөнәвәрә атлы диделәр бугай үзен, — шул «онытылган җыр»ның кире әйләнеп кайтып, микем өемә керергә маташуы бит инде! Кеше раславы да кирәк түгел, күңелем үзем әйткәнне дә тыңламый. Күз сирпеп бер караву, ак маңгае, озын керфекләре һәм — ничек дип әйтим икән? — колакны иркәли торган йомшак тавышы җитте: бу шул — я Маһирәнең кызы, я нинди дә булса кодрәт аркасында яшь килеш сакланган Маһирә үзе. Алай ди-

сәң, кодрәт дигән нәрсә юк дибез бит инде без хәзер. Һәрхәлдә, язмыш шуклыгы бу, башка берни дә түгел.

Ничек кенә булмасын, минем алда дилемма тора. Яки Рөстәм алып кайтачак ул кыз белән бер өйдә калып, шуның аркасында узгандагы куркаклыгымны, кешегә сизелмичә тузан астында калган хыянәтемне, утка салсаң, ут тамагыннан үтмәслек гөнаһымны көн саен, сәгать саен искә төшереп, борчылып яшәргә? Яки импортный мебель белән җиһазланган өемне, узгандагы бөтен гөнаһларымны, чыны вә ясалмасы белән ирешелгән авторитетымны бер якка калдырып, Толстой бабайның «Тере мәет»е кебек, ялан аяклап кая булса да чыгып югалырга? Нишләргә? Нишләргә?

...Тукта, чү! Тагы бер акыл килеп төште бит әле башка. Дилеммасыз да мөмкин икән ләбаса! Нишләп өйне калдырырга да, нигә ялан аяклап чыгып китәргә? Бик әйбәт бер юл бар, мин уйлап тапкан түгел, башкалар шулай эшлиләр. Менә бик шәпләп докторскийны яклыйм, профессор җөббәсен иңемә салып алам, ул чагында инде минем улчәү икенче төрлерәк тартачак. Торак органнарына, югары оешмаларга мөрәҗәгать итәрмен: ишәйдек, фәнни иҗатка мөмкинлегем калмады, чарасын күрүегезне үтенәм, дип гариза бирермен. Андыйларның бусагасын таптау буенча тәҗрибәм юк түгел, кирәк булса, бусагаларын таптармын. Чарасын күрергә тиешләр һәм һичшиксез күрерләр дип уйлыйм. Иркенрәкне ала калсам, малайны бу квартирамда калдырып, үзем күчәрмен. Кечерәге эләксә, теге «гөнаһ шомлыгы» белән малайны күчерермен — менә сиңа узгандагы гөнаһларыннан качу юлы! Кара әле, ничек соң бу әлегрәк башыма килмәде икән?».

## XI

Өйгә кыз алып кайту мәсьәләсе турында атна-ун көн чамасы берсе дә сүз кузгатмыйча, берсе өчен икенчесе табышмакка әйләнеп, эчләреннән тынып йөрделәр. Гайшә ханым сүз кузгатмады, чөнки иренең гадәтен белә, үзе уйлар, үз вакыты белән сүзен әйтер дип көтә иде. Ризванов, хатыны кабаттан ул турыда сүз яңартмаганга, кузгатмады. Эченнән генә ул: «Бәлки эндәшмәүне бу эшне өнәмәү дип аңлаганнардыр... Әмма шулай гына була күрсен икән!» — дип йөрде. Рөстәм сүз кузгатмады, кабат-кабат олыларның исенә төшерүне яхшысынмый иде. Һәм бу эшнең ул дигәнчә булачагына, башкача булуы мөмкин дә түгел икәнлегенә яшьлек үҗәтлеге белән кирәгеннән артык нык ышана иде. Шулай да бу киеренке хәлнең озак дәвам итә алмаслыгы, семьяда үзара бер чарпалышу чыгачаклыгы көн узган саен ныграк сизелә бара иде. Һәм бу чарпалышу үзен озак көттермәде.

Бер көнне Рөстәм истә-оста юк чагында, ләкин гадәттәге шуклыгына һич бирелмичә, утә житди бер тон белән:

— Теге көнне кузгаткан мәсьәләгә карата мин сездән җавап көтәм, әни. Онытмадыгызмы нәрсә турында икәнлеген? — дип әнисенең исенә төшерде. Юк, Гайшә ханым ул сүзне онытмаган иде, ләкин Рөстәме кинәт болай өзеп куйгач, сүзеннән дә бигрәк малаеның кырыс тавышыннан аптырабрак калды.

— Онытылган булса да бер дә гаҗәп түгел, карт хәтер — тишек иләк, — дип, ничектер, уен-көлкегәрәк борырга тырышып җавап кайтарды ул. Шул ук вакытта: «Әнә әтиең суза ич... Мин үзем генә нәрсә эшли алам»,— дип ирен яманатлы итеп калдыруны да килештерми иде.

— Менә әтиең алда торган эшеннән бераз баш-күз алсын инде, сөйләшербез-киңәшербез, — дип, авыз эченнән ботка пешереп маташ-

ты. Болай икеле-микеле бирелгән җавап Рөстәмне, әлбәттә, канәгатьләндермәде. Киресенчә, ул аның егетлек горурлыгына гына тиде.

— Мин бала түгел, әнкәй, шуны белеп торыгыз, — дип кабынып китте ул, гомерендә беренче мәртәбә әнисенә каршы сүз кузгатып, — әгәр мина ошаган кеше сезгә ошамый икән, әйтеп сөйләшегез, без сезне борчымыйча да бу дөньяда үзебезгә почмак табарбыз.

Һәм ул, башка бер сүз дә өстәмичә һәм әнисенең нәрсә әйтүен дә көтмичә, чыгып китте. Әмма ишекне каты ябып түгел. Малайның сүзләрендә һәм хәрәкәтендә гадәттә күрелмәгән кискенлек күренсә дә, тупаслыкка ук барып җитәргә әле иртәрәк, әле аның тагы бераз көтәргә сабыры җитәрлек иде. Әни кеше чын-чынлап аптырауда дәвам итте. Ни генә булганда да бердәнбер малаен ул үз яныннан читкә җибәрергә һич кенә дә теләми иде. Шул ук вакытта, ире Хәнәфинең, бу мәсьәләгә карата ачык кына җавап бирмичә, һаман сузып килүе дә аны ике күлсыз итә, гәрчә үзе Рөстәм алып килеп йөри торган Мөнәвәрә атлы студенткадан — аз сүзле, тыйнак табигатьле күренгән ул мөлаем кызчыктан — бик тә риза булып, аны үз кызы итеп канаты астына алырга әзер торса да, иреннән башка өзеп кенә ни дә булса әйтергә кыймый иде.

Нәкъ әнә шундый каршылыклы уйларга күмелгән минутында, арып-талып һәм йөрәк авырулы кешеләргә хас рәвештә чак-чак кына мышкылдап, ире Хәнәфи кайтып керде. Ризванов өстен-башын чишенде, ләкин әйберләрен гадәттәге педантлыгы белән гардеробка элеп тормады, диванга атып кына бәрде һәм, хатынына ләм-мим сүз кушмыйча, көзге каршына барып, инде яртылаш пеләшләнгән чәчен-башын рәтләргә керешкән булды. Әшнең тикмә түгеллеге әллә кайдан сизелеп тора иде. Озак еллар бергә яшәп, иренең гадәтен-фигылен белеп бетергән Гайшә ханым шундук эченнән генә нәтиҗә ясап куйды: «Әшендә нәрсәдер килеп чыккан булса кирәк... Һәрхәлдә, минуты-секунды белән генә сүз башлап, кызган ташка су сибеп сикертергә ярамас». Ләкин малае белән ике арада булып алган сүзнең аңарга ясаган йогынтысы, ире көенә ипләнүгә караганда, көчлерәк иде. Эндәшми чыдарга никадәр генә тырышып караса да, чәй әзерләп йөрешли сүз башламыйча булдыра алмады:

— Юлына Рөстәм очрамадымы? Нәрсәдер, әтине күрәсем бар, дип йөри ул малай.

— Нәрсәгә мин кирәк булдым икән? — дип, бераз илтифатсызрак күренергә тырышып, әмма асылда сагая төшеп, җавап кайтарды Ризванов. Һәм шундук, тавышына усенчак ноткалар чыгарып, өстәде: — Гадәттә безнең ике арада дипломатлык миссиясен башкаручы кеше — ул бит син идең, анасы. Нишләп бу очракта гына мин кирәк булып чыктым икән?

Шаярткан булып әйтелгән бу сүзләрдән, аларның әйтелешеннән, аларны әйткәндә Ризвановның авыз чите белән генә сәер көлемсерәп куюыннан сизенергә бик мөмкин: әти кеше бу минутта ул турыда сүз ачарга бер дә теләми иде. Әммә Гайшә ханым бераздан тагы сүз башламыйча кала алмады.

— Без баласытып карасак та...— дип тотынды ул бу юлы, яхшы ук житди, хәтта чак кына үпкәләгән дә кебек итеп, — яшьләр, без күз алдына китергәнгә караганда, тизрәк өлгерә. Күрәсең, безгә дә итәкнеҗиңне җыеп, чынлабрак бер уйлап карарга вакыттыр.

— Миңа профессор Харитонов звонить итәргә булган иде, мин өйдә юк чагында кем дә булса шалтыратучы булмадымы? — дип, кинәт бик әшлекле кыяфәт белән, хатыны кабатлаган сүзне колагына да элмичә, сорашып куйды Хәнәфи. Сүзенең җилеме ябышмаганлыгы әллә кайдан күренеп тора, сизгер күңелле Гайшә ханым бу теманы хәзергә куеп торырга риза иде инде. Ләкин берме-икеме чынаяк чәй эчкәннән соң,

Ризванов баягы кырыслыгын һич югалтмыйча, киресенчә, тавышын күтәрә төшеп:

— Кайгысы юк — кайнанасының калын шәле турында кайгырткан, — дип, үзе сүз башлап җибәрде һәм, кызганнан-кыза барып, дәвам итте: — Синдә чүп кайгы, ә минә минем ун ел буена чиләнеп әзерләгән докторский диссертациям трубадан очарга тора. Куерак яса, ичмасам, чәенне.

Гайшә ханым ни дип эндәшергә дә белмәде. Чынлап та, монда, малай өйләндерү кайгысына караганда, зуррак кайгы ишек шакырга тора түгелме соң? Нә берсе, нә икенчесе сүзне яңартмыйча бераз тын утырганнан соң, Ризванов, бу юлы инде яхшы ук йомшый төшеп, хәтта чак кына мескенләнгән, хатыныннан хәлгә керүен үтенгән кыяфәт белән, актык сүзен әйтте:

— Авторефератны укыган өч кешенең өчесе дә бер фикер әйтә: икенче як чиккә ташлангансың, диләр. Әллә мине казыкка бәйләп куймакчы булдылар микән? Защита дигәне тагы берәр елга кичектерелер кебек. Әле аның белән генә җайлап булса?..

Ул моны, хатынына сөйләүдән дә бигрәк, үзенә үзе сөйли, бу минутта аңарга ничек тә булса бушанып, чак кына җиңеләеп калырга кирәк иде.

Чәйдән соң Ризванов, өстенә өйдә кия торган халатын аннан-моннан гына элеп, кабинетына кереп чумды. Дөресен генә әйткәндә, кабинеты — аның эш урыны гына түгел, кабинеты — дөнья ыгы-зыгысыннан, башка төшкән күңелсезлекләрдән, өйдәге вак-төяк сүзләрдән үзенә күрә бер качу урыны да иде. Аларда элек-электән шундый тәртип урнаша килде: укымышлы әти кабинетына кереп бикләндеме, аны нинди дә булса вак-төяк йомышлар белән бүлдерү катгый рәвештә тыелган иде.

— Тукта, чү! Шауламa! Әтиең эшләп утыра, әтиең шауламаска кушты.

Гайшә ханым малае Рөстәмне дә элек-электән гел шулай кисәтә килде. Әмма малай кеше малай булып кала: еш кына хәлләрдә шук малай, анисе ясаган кисәтүләрне онытып, атылып әтисенең эш кабинетына барып керә һәм еш кына «эшләп утыра торган әти»не, диванга кырын әйләнеп төшкән хәлдә, түшәмгә күзләрен текәп яткан яки хырлап йоклап киткән хәлендә очрата иде. Бу хәл малайда кече яшьтән ук әтисенә карата билгеле бер сагаю тудырды. Инде соңгы вакытларда, Мөнәвәрәне бу өйгә китерү, аңарга өйләнергә теләү ниятен белдергәннән соң, олылардан бу турыда ачык кына бер җавап ала алмагач, Рөстәмнең сагаюлары тагы да кискенләшкән, кабинетка искәрмәстән генә атылып керергә өйрәнгән шук малай белән «укымышлы әти» арасында зур бер сөйләшү булырга тиешлеге ачыктан-ачык сизелә иде.

Ә кабинетның тышында, зал һәм кухня тирәсендә, вак-төяк эшләр караган булып, асылда исә анысы да шул бер үк мәсьәләләр белән баш ватып, әле улы Рөстәм, әле булачак килене Ак маңгай турында уйланып, әле ире алып кайтып җиткезгән күңелсез хәбәр өчен пошынып Гайшә ханым йөри. Аның, Гайшә ханымның, һич кенә дә катлауландырасы килми, югыйсә. Катлауландырырлык сәбәпләр дә күрми. Бердәнбер малаеның үсеп җиткәнлеген күрү, аны вакытында башлы-күзле итү, аларның бәхетле тормышының шаһиты булу һәм, ниһаять, картайган көнендә аларның балаларын — оныкларыңны тезеңә утыртып назлау — әйтәсе дә юк, ана кеше өчен моннан да зуррак куанычның булуы мөмкинме соң! Ә бит моның өчен, бер караганда, әллә нәрсә дә кирәк түгел. Әнә аның, кабинетта бикләнеп утыручы укымышлы «дәү абый»ның, ачык йөз белән чыгып, бер-ике авыз сүз әйтүе генә кирәк.

— Яшьләр үзләре шуны телиләр икән, миннән фатиха. Әйдә, мине

бик борчымыйча гына туй чарасына керешегез! — дип әйтсә, шул бик житкән, югыйсә.

Кара әле, бөтенләй юктан гына терәлеп тора икән ләбаса!

Гайшә ханым әнә шундый каршылыклы уйларга күмелеп йөргән вакытта кабинет ишеге кинәт ачылып китте, аннан сөмсере коелган Ризванов килеп чыкты.

— Аңламыйм, ник шулай каты басып йөри торгансыңдыр? — дип, кырыс кына эндәшеп куйды ул. — Өйдә, әйтерсең, бер полк солдат йөри.

Кинәт һәм кабыну белән әйтелгән бу шелтәле кисәтүдән соң, Гайшә ханым бер мәл таркалыбрак калды һәм, бу таркалу минуты узгач, әкренләп акылын башына җыя барды. «Тукта инде, алай хәттин ашма син, Хәнәфи,— дип, күңеленнән үзе белән сөйләнергә тотынды ул, — докторскийны яклыйсыбыз булмагач та, әллә без адәм баласы түгелме? Әллә мин бердәнбер улымның язмышына күз йомып калыйммы? Юк инде, булмас инде анысы!»

Бу — моңарчы бервакытта да, беркайчан да иренә каршы килмәгән итагатьле хатынның, баласы язмышын яклап, иренә каршы баш күтәрергә ниятләве иде һәм, шунлыктан, бу өч кеше арасында күптән көтелә килгән әлеге зур сүзнең әйтелер көне менә-менә килеп житте, дип уйларга да мөмкин иде.

## XII

Кайбер чарпалышларга караганда, кузгаласы алдан ук билгеле булган «су асты дулкыннары» берьюлы өскә бәреп чыкты һәм моны инде Гайшә ханымның сабырлыгы, «Тукта, чү!» дип үзен тыя килүе белән генә тотып торырга мөмкин түгел иде. Бер көнне Рөстәм тыштан билбаулап, эчтән көзгеләр, әллә ниткән кесәләр куеп эшләнгән импортный чемодан күтәреп кайтты һәм, моны кайдан алганлыгы, нинди максат белән күтәреп йөрүе турында ләм-мим дәшмичә, әнисен мең төрле табышмак алдына куеп, чыгып китте. Малайның сүзсез генә каядыр, нәрсәгәдер җыенуы күз алдында иде. Күрәчәккә каршы, нәкъ шул хәерсез сәгатьтә, култыгына калын-калын өч папка кыстырып, төссез-чырайсыз өлкән Ризванов та кайтып керде. Юк, иске традицияләрне саклап торудан узган иде Гайшә ханым. Иренең өске киемнәрен салганны гына көтеп тора алды ул, хәтта тегенә, көзге каршына барып, пеләше читендә сакланып калган берничә бөртек чәче белән көязләнергә дә ирек куймады.

— Күрәсеңме әнә тегене? — дип гардероб башындагы чемоданга төртеп күрсәтте. Үз нәүбәтендә Хәнәфи Ризванов та табышмак алдында калды. Гомерендә болай күтәрелеп бәрелмәгән хатынының кинәт шулай кабынып эндәшүе аның тез астына суккандай итте.

Хәлбуки, аның тез астына, Гайшә ханым сукканга караганда күп мәртәбә катырак итеп, гыйльми совет утырышында ук сугып кайтарганнар: докторский диссертация дип, ничә еллар чалбар төбе шомартканы «чыш-пыш» булып чыккан. Хәтта аннан да яманрагы: доцент Хәнәфи Ризвановның, әлектә, Сталин исән чакта, аның итеген яларлык булып йөреп, шул исем белән турыдан-туры бәйланышлы темага кандидатлык диссертациясе яклап та, Сталинның вафатыннан соң, йөз сиксән градуска борылып, шәхес культын фаш итү маркасы астында, шул исемне ничек булдыра алса — шулай пычратып, бер уңайдан революциянең житдирәк бүтән казанышларына да тел-теш тидереп, фәннәр докторы, профессор булырга йөрүен чикылдап торган принципсызлык, уңны-сулны белмичә карьера артыннан чабу дип бәяләгәннәр һәм бичара пеләшбаш, диссертациясен култыгына кыстырып, кире алып кайтырга мәжбүр булган иде.

Булып узган шул удардан айнышып житмәгәннекеме, әллә йоклаган вөжданы уяна башлаудан, әмма бу юлы ул гадәттәге тәкәбберлеген җуйган, тавышы да бөердән чыкмый, хәтта сүзләрен дә көчкә-көчкә генә әйләндереп әйтә алды:

— Син эшнең ничек торганлыгын белмисең, Гайшә. Һай, барысы да син уйлаганча ансат кына булса икән...

Чынлап та, Ризвановның бу хәерсез сәгатьтә күтәреп кайткан фаҗигасен Гайшә ханым әлегә белми, чөнки ул турыда ишетмәгән һәм, булган хәлне ачыктан-ачык әйтеп сөйләшәсе бервакытта, Ризвановның, жеп очын тоттырмаска тырышып, гадәтенчә томанлы сүзләр кулланып маташуы әле һаман малае кайгысыннан арынмаган Гайшә ханымда берьюлы әллә ничә төрле шик-шөбһәләр кузгаткан иде.

— Шулай инде алайса, утыз ел бергә гомер иткән хатынын берни дә белми. Аның аяк басып йөрүләре дә солдатча. Син дәү абыйның анарга әйтергә ярамый торган серләре дә булып чыкты, — дип, үпкәсен һәм ярсуын бергә кушып, елый-елый тезәргә тотынды хатын. Ризванов моны шушы бер елау белән узып китәр дип уйлаган иде, ләкин узмады.

Кайда ул узу, инде узган, тузан астында калган, күмелгән, беткән дип йөргәннәре дә кинәт һәм сафура бураннары уйнатып калкып чыкты. Кирәк бит бөтен өермәләргә берьюлы кузгалырга!

Ирле-хатынлы икәүдән-икәү генә чакта да сүзнең очын таба алмый аптыраган бервакытта малайлары Рөстәм кайтып керде. Һәм бусагадан атлауга: аптырау катнаш таркалыбрак калган әтисен, бер читтә аркасы беләнрәк борылган әнисен, өйдәге тартынкы кырыслыкны, барыннан да бигрәк, әнисенең елаудан кызарып чыккан күзләрен — барысын-барысын берьюлы күреп алгандай итте.

— Нинди спектакль безнең монда? — дип, дуамал гына сорап куйды ул, озак уйлап тормастан. Әнисенең яшьле күзе аны кинәт тетрәтеп ташлады булса кирәк. Өстен дә салып тормастан, әтисенең каршына килеп басты.

— Беләм, син рәнжеткәнсең әнкәйне, — ул, үз тупаслыгыннан үзе үк уңайсызланып, күзләрен шундук аска алды, беравык сүзсез торды, аннан гафу үтенгән сыман йомшак тавыш белән, ләкин күңелендәгеен һич тыеп калдыра алмыйча ялгап алып китте: — Әгәр сүз минем аркада чыккан булса, гафу итегез, мин бүтән андый сәбәпләрне булдырмаска тырышырмын. Аннары тагы шуны да әйтим: Мөнәвәрә сез уйлаганча ук аңсыз кыз түгел, берничә килү белән ул безнең бу өйгә сыймаслыгыбызны сизеп алган.

— Юкны сөйләмә... Җибәрмим, беркая да җибәрмим. Сыярбыз. Малаем сыйган җиргә килене сыяр, — Гайшә ханым, кызып һәм, бер үк вакытта, болай кызганы өчен иреннән гафу үтенгәндәй, күзләрен яшь белән коендыра-коендыра тезде дә малае Рөстәмне кочып алды һәм аннары тагы тезәргә тотынды. Бу күренештән тәмам гаҗизләнгән өлкән Ризванов, ниһаять, кабыгыннан башын чыгармыйча булдыра алмады.

— Күрәм, монда иң яман кеше мин булып чыктым, ахрысы... — дип, гадәттәгечә, чолгабрак сүз башлады ул. — Нишләмәк кирәк, мин сезнең барыгызга караганда да картрак кеше, шулай булгач, күрәсең, бу буталчык дөньяда минем җыйган гөнаһларым да сезнекенә караганда күбрәктер.

— Әти! — дип, җитди рәвештә әтисен бүлдерде яшь Ризванов. — Давай фәлсәфә сатмыйча гына сөйләшик. Синең ул «гөнаһлар» дигәнең безгә бик билгеле: Мөнәвәрә миңа барысын да сөйләде... Сүз хәзергә ул турыда бармый, сүз хәзер безнең турыда: әгәр сез миңа минем яратып йөргән кызымны — Мөнәвәрәне алып кайтырга рөхсәт итә-

сез икән, мин моны һич сүзмыйча эшлим. Әгәр сез шуна рөхсәт бирмисез икән, ул чагында...

— Ник бүленеп калдың? Ул чагында... мин үзем чыгып качам дип тә куркыт.

— Куркыту түгел, — Рөстәмнең тавышы нык һәм ул башланган сүзне ярты юлда бүлеп калдырырга һич җыенмый иде. — шулай ук кайчандыр син качкан кебек, качып китәргә дә җыйналмыйм.

Ләкин әйтергә кирәкне ачык итеп һәм ахырынача әйтеп бетермәде ул. Чөнки ата белән малай арасында башланган бу җитди сөйләшүне, сүзнең үзеннән дә бигрәк, аның астында яшеренеп яткан ымлыкларны ничек аңларга, нәрсәгә юрарга белмичә, бер агарынып, бер күгәренеп басып торган кешегә — әнисенә күзе төште. Әйе, монда бит әле ул бар, бу йортта мона хәтле җыслып кылгән бөтен гөнаһларга карата үз сүзен — гафу сүзенме, ачу сүзенме — әйтергә тиешле Гайшә ханым бар иде.

XIII

## Эпилог

Малае ягыннан да, хатыны Гайшә тарафыннан да йомшаклык күренмәгәч, бигрәк тә эше-карьерасы буенча җөйләре сүтелә барганны күреп торганда, Хәнәфи Ризвановка кикрикләрне югары тотып кыланырга һич урын калмаган иде. Беренче чиратта, артык катлауландырып тормыйча, яшьләргә үз язмышларын үзләре белгәнчә, үзләре теләгәнчә корырга фатиха бирергә, аннары узгандагы «романы» турында өйләнгәндә дә, аннан соңгы утыз ел дәвамында да, ниһаять, Маһирәнең кызы аларның өйләренә килеп булып килергә йөри башлаганнан соң да никахлы хатынына ләм-мим эндәшмәгәне өчен бик нык дулаган Гайшәсен ничек тә тавышсыз-тынсыз гына җайларга һәм, шулар рәтеннән ук, квартира артыннан да чабарга — Хәнәфи Ризвановның якын ара өчен сызып куйган программа-минимумы әнә шулардан гыйбарәт иде.

Ләкин боларның барысы да диярлек «төерле» булып чыкты. Беренчедән, бик гади эшләрне дә катлауландырып, күзгә томан җибәреп һәм үзенең укымышлы кеше икәнлеген һәр даим сиздерергә тырышып эшләргә өйрәнгән Ризванов, бу очракта, улы Рөстәм белән дә кешечә гади итеп сөйләшә алмады.

— Әлбәттә, мин сезнең теләккә каршы килә алмыйм, — дип башлады ул, күңелендә ниндидер чишелмәгән төен калдырган кебек итеп,— хәтта мин әти-әнисеннән рөхсәт сорый белә торган малай үстергәнлегем өчен шөкрана кылырга тиешмендер әле... Хәзер бит аның, аллага шөкер, фактны кабыргасы белән китереп куя торганнары да җитәрлек. — Аннары ул мәгънәле генә итәргә тырышып пауза ясады, торып, аякларын язып килде, аннары тагы каршыга ук утырып, әлбәттә, борчылганлык күрсәтеп тирән сулап алганнан соң, гел шул бер тоньк тон белән тагын дәвам итте: — Үзара гына әйткәндә, сезнең яшьлек бәхетле чорга туры килде, балакай, сез моның кадерен белергә тиешсез. Безнең яшьлекнең аяк-кулын бәйләгән шартлылык тышауларын сез хәзер күз алдыгызга да китерә алмыйсыздыр. Белмим, синең безгә китерергә йөри торган ул кызың иң элек үзе ни дәрәҗәдә дөрес информировандыр һәм аннары сина ничек җиткергәндер, чынлап караганда, балакай гынам, бөтенесенә шул вакыттагы объектив сәбәпләр, культ чорының...

— Минем ашыгыч барып кайтасы җирем бар иде, әти, — дип кинәт урыныннан сикереп торды Рөстәм. Аның болай дуамал кузгалуында ук ниндидер бер каршылык, әтисе белән килешмәү ачыктан-ачык сизелеп тора иде, хәер, ул аны эчендә калдыруны кирәк дип тә тапмады.

— Кайчанга калэр без, бөтенесен объектив сәбәпләргә сылтап, үзебез сөттән ак, судан пакь булып калырбыз икән? Әйтеп тә торасы юк, рыцари без страха и без упрёка...

Малаеның дулкынлану һәм тирән үпкә белән әйткән шушы сүзләре житте. Ризванов әле хакыйкатьне төшенмәслек үк дәрәжәгә төшкән кеше түгел иде: димәк, чолгап-чолгап сөйләү белән генә бу замандагы яшьләрнең күзләрен томалап булмаячак.

Аннары хатыны Гайшә белән арасы бозылды. Юк, кычкырышу, талашуга үк барып житмәделәр, моны алар арасында элек-электән урнаша килгән нәзакәтле тәртип «рөхсәт итми», шуның өстенә, Ризванов, профессор үк булып житмәсә дә, доцент дигән исемне тагып калган һәм доцент башы белән кычкырышып-талашып яшәүне, әлбәттә, килештерми иде. Шул ук вакытта, Гайшә ханым да инде аның тыштан гына шулай ялтырый торган, ә эчендә әллә никадәр әйтелмәгән яшерен сер, ясалмалык һәм куркаклык йөртергә сәләтле бер кеше икәнлеген соңга калыбрак булса да төшенә башлаган, бигрәк тә ул Ризвановның үзенә яратмыйча өйләнүен һәм утыз ел буена чын-чынлап яратмыйча, бары тик көн үтсен дә сүзе булмасын дип кенә торганлыгын гафу итә алмый, шуның аркасында хәзер үтә вәсвәсәчән, юк-бар шикләргә бирелүчән, вак сүзле кешегә әверелеп бара иде. Ике арада ни генә булмасын, шулай да бер чиккә хәтле моны тышка чыгармыйча түзделәр. Ләкин бу «чик» дигәнебез әллә кайда булмаган икән, хәерсез. Бер үк вакытта туры килгән ике вакыйга бу «чикне» дуамал тизлек белән өскә калкытып чыгарды. Беренчедән, яшьләрнең, кушылып, бергә тора башлаулары белән генә эш бетмәгән, ана кеше бердәнбер улының түсен шаулатып итмичә ирена һәм малаена тынгы бирмәде. Туйга районнан Мөнәвәрә киленнең әнисен чакыртырга кирәк иде. Моңа хәтле бөтенесенә тешен кысып риза була килгән Хәнәфи Ризванов бусына менә һич риза түгел, утыз елдан соң Маһирә белән кода-кодагый булып йөзгә-йөз очрашуны ул күз алдына да китерә алмый иде. Бәхеткәме, бәхетсезлеккә каршымы, нәкъ шул көннәрдә икенче вакыйга да килеп өстәлде: Ризвановны шәһәр торак идарәсенә чакырып, яңа салынган йорттан, яшь семья өчен дип, бөтен җайлары житкерелеп эшләнгән аерым бер бүлмәгә ордер биреп җибәрделәр.

Башка берәү өчен әйтеп бетерә алмаслык шатлык китерәсе бу вакыйга өлкән Ризванов өчен янә дә бер башваткыч мәсьәлә булып чыкты. Чөнки иренә карата ышанычлары какшый башлаган Гайшә ханым бердәнбер малаен үз янынннан аерып чыгаруны хәтта ишетергә дә теләми, әгәр этиләре шуны бик нык куя калса, «Орлыгым кайда — мин шунда!» дип, үзе дә алар белән бергә җыенып чыгып китәргә катгый рәвештә әзер тора иде.

Нишләсен карт Ризванов, бичара пеләш баш! Кылган бөтен гөнаһларын һәм анадан тумыш кимчелекләрен искә алганда да, ул әлегә бөтенләй үк кешелексез кеше булмаган икән. Яшьләр аерылып чыгарга бик атлыгып торсалар да, хатыны Гайшәне, иске өйдә икәве генә калырга ничек тә ризалата алмагач, чемоданын күтәреп һәм башка бер нәрсәне дә дәгъва итмичә, яңа бүлмәгә ялгыз баш үзе чыгып китте. Әмма шунда да бер кабырынкы сүз кыстырмыйча китә алмады:

— Мина, бәлки, фәнни иҗатым өчен ялгызыма гына җайлырак та булмагае әле анда, — дигән булды. Нишләтәсең инде кешене, гадәте шундый булгач!

Гөрләгән шәһәр уртасында, бала-чагалы, мәшәкатьле, нужалы, ләкин шулары белән үк бәхетле дә булган бик күп һәм бик төрле семьялар урнашкан зур коммуналь йортта, шуның ялгыз бер бүлмәсендә менә хәзер ул — доцент Хәнәфи Ризванов яши. Керсә — ялгыз, чыкса —

ялгыз. Бүлмәсе икенче катта гына булганлыктан, тәрәзәдән әллә ни киң горизонт күренми. Каршы йортның яртылаш кырылган кирпеч стенасы, шул буйда күптән утыртылып та, кәрлә килеш картаеп калган сирень куагы, аннары тагы җәйге айларда кәрнизләрдә чуалып йөрүче биләмче песиләр... Көндез, нәкъ ике белән өч арасында, диета ашханәсенә барып ашап кайта, иртәсен-кичен өендә җайлаган, билгеле бер вакыттан биш минут элек түгел, биш минут соңга калмый. Аннары билгеләнгән сәгатьләрдә институтына барып укытып кайта, хәтта өй җыештыруга кадәр ныклы режимга көйләнгән: алдан сөйләшенү буенча, институт техничкаларыннан берсе шимбә көн, төштән соң, атнага бер мәртәбә килеп, аның бүлмәсен җыештырып китә. Ләкин бу да алдан сөйләшкәнгә карата гына эшләнә. Юкса, күп вакытта Ризвановның бүлмәсендә җыярлык чүп тә булмый, бөтен нәрсәне нәкъ үз урыныннан алып, нәкъ үз урынына куярга өйрәнгән һәм, гомумән, һәр яктан пөхтә Ризванов чүп белән һич дус түгел. Хәер, кешеләр белән дә бик алай дус дип әйтеп булмый хәзер Ризвановны. Бигрәк тә докторлык диссертациясе белән эше барып чыкмагач һәм өйдәгеләр белән дә конфликтка кергәннән соң, ул кешеләргә — яшьләренә дә, үзе белән бер чамадагы кордашларына да — ышанып җитмичәрәк карый башлады. Нәрсәдер бөтенесе аны читләтәләр, аның тирәсендә сиздермичә генә казыналар кебек тоела иде аңарга. Хәлбуки, якын итеп килеп керүчеләр булса, аның Мәскәүгә барган җирдән махсус алып кайткан иң яхшы винолары, аларга нәкъ килешеп кенә торучы деликатес закускалары да әзер иде, югыйсә. Тик менә әллә ни килүче генә күренми, хәтта телефоннан да хезмәте буенча институттан һәм тагы шуның ише рәсми учреждениеләрдән рәсми йомыш белән генә шалтыраталар иде...

Һәм әнә шул рәвешчә, гөрләгән шәһәр уртасында япа-ялгызы яши кеше. Җитмәсә тагы бүлмәсенең тәрәзәләре дә ахмакларча уелган. Кухня тәрәзәсе урамга карый, ә түр тәрәзә әлеге дә баягы кырылган стенага, чыккан да каткан сирень куагына. Бик аптырагач, болай үзе кухняда газ исе чыгып тору ихтималы бар дип бик шөбһәләнсә дә, шул почмак тәрәзә каршына килеп, тәрәзәне ачып, ләкин үзе бик үк тыгылмыйча, урамнан узучы кешеләрне күзәтеп тора ул. Озак-озак күзәтә. Күңеленнән мондыйрак нәтиҗә чыгарырга да өлгерә: кабаланалар инде болар кабалануын, ләкин бит кайчан булса да, барыбер, сгылып борыннарын канатачаклар. Әмма урамнан үтүчеләрнең берсе дә аның кухня тәрәзәсеннән ясаган философиясе белән исәпләшеп тормый: чабасы җирләренә чабалар, кайтасы җирләреннән кайталар, кычкырасы урында кычкыралар, көләселәре килсә — көләләр, җитмәсә эңгер төшәргә өлгерми, кайсыбер яшь-җилбәзәкләре, барасы җирләренә барып җитәргә өлгермәс кебек кыланып, әлеге теге кәрлә сирень төбенә ышыкланып, чап-чоп үбешеп тә китәләр. Кыскасы, урамда тормыш, тормыш, тормыш, ә менә Хәнәфи Ризвановның тузан кунмаган, тузан кунарга ярамый да торган чиста бүлмәсендә көннән-көн симерә баручы ялгызлык, ялгызлык, ялгызлык...

1966 ел

## Яшьләр иҗаты

# *РЕНАТ ХАРИСОВ*

*Сабый чакта рәсем ясарга ярата идем, ләкин рәссам була алмадым.*

*Гармун бармакларына саннар сугып, шул саннар ярдәмендә бер-ике көй дә язып карадым — композитор чыкмады.*

*Дымлы җиргә ике тимерчыбык батырып, электр тогы тапмакчы идем — җир бирмәде, физик та итмәде.*

*Әти-әнидән курмакче, укытучы булырга хыялланып йөрдем. Пединститут тәмамладым. Арча педагогия училищесында укытып карадым һәм... комсомолның Татарстан өлкә комитеты инструкторы булып киттем.*

*Хәзерге көндә мин — журналист һәм «Яшь ленинчы» газетасында эшлим. Бу газетага мин гашыйк.*

*Шигырьне шигырь итеп тоеп студент чакта яза башладым, ә шигырь язуның көй чыгарудан, электр тогы табудан, рәсем ясаудан, укытучы булудан җиңелрәк эш түгеллеген әле генә — 25 яшькә җиткәч кенә, аңлый башладым.*

*Туган ягым — Ульяновск өлкәсе.*



## Киту, көту, кайту

1

Китәләр, китәләр, китәләр...

Күзләргә пәрдә каплап,
Тузаннар уйнап кала.
Ана кулын алга суза —
«И, бала...»

Китәләр...

2

Көтәләр, көтәләр, көтәләр,

Кочып алырга сузылган
куллар көтә.
Үбәргә дип кайнарланган
Ирен үз-үзен өтә.

Ярата белгәннәр генә шул
көтә белә.
Исән булганнар гына шул
кайта ала.

. . .

Көтәләр.

Бары шатлык алып кайтыр кебек
бу юллар.

3

Кайталар...

Яратулары үлемнән көчле булганнары
кайталар.
Аларны кочалар,
аларга рәхмәтләр яудыралар,
исемнәрен догаларга куша карчыклар —
озак яшәсен, диләр.

Ә яратулары
яшәүдән дә көчлерәкләре...
Алар да кайталар,
кайталар да
берсүзсез
~~стеналардагы~~ буш рамнарга керәләр.
Алар да кайталар —
аларны көчлерәк сагыналар.

4

Унтугыз яшьлекләр
талдай буйларына котомкалар асып,
көлешә-көлешә,
ялык болгый-болгый киткәндә
әниләр елап калалар
«Китү, көтү һәм кайтуны»
кабат искә төшереп.

## Уйнамагыз!

Уйнамагыз бомба шартлатып,
    унар чакрым биеклеккә
    агулы тузан атып...
Су алырга,
су керергә
сылу кызлар төшеп килә.

Су коеп,
сулар алып,
сылу кызлар менеп килә.

Күкрәкләре турысында
ак күлмәкләре юпь-юеш.

Мөлдерәмә чиләкләренә
орыш серкәсе коела...

Уйнамагыз —
    унар чакрым биеклеккә
    агулы тузан атып.
Елгаларның,
чишмәләрнең,
күлләр,
океан, диңгезләрнең
    өстен япмаган.

## Авыл карты

Гомере буе күзгә яңгырларны сүккән
авыл карты асфальтта тора.
Ә яңгыр
Чиләкләп ора.

«Эх, яңгыры! —
Чиләк, чиләк.

Кырларга — мунча,
хатыннарга — иләк,
илгә — икмәк.
Эх, яңгыры! —
чиләк, чиләк.

Ә менә монда чәчәк үсәр дип
шатлана алмыйм.
Ә менә монда ашлык пешәр дип
шатлана алмыйм.
Монда яңгыр тузан гына баса,
монда яңгыр — күктән тамган су гына.
Ә бездә яңгырдан
аңкып тора сөт исе.

Эх, яңгыры! —
чиләк, чиләк,
илгә икмәк,
кулга иләк.

Ә монда шатланып булмый,
Җир өстендә асфальт зонтик —
Җирне яңгырдан яшергәннәр».

Гомерә буе җәйгә яңгырларны көткән
авыл карты асфальтта тора.
Ә яңгыр
ора да ора —
асфальтка.

●

Бөртек-бөртек
нәкъ сиксән сигез керфек.

Сиксән сигезәр кара кылыч
ике диңгез тирәсе.
Кылычлардан тишелә-киселә
килә шунда кирәсе.

Һәр яраны ерта-ерта
тулсын диңгез йөрәккә —
яшәү өчен
бу диңгезгә
батып үлү кирәк тә...

Бата алмый аптырыйм.

## Салкын яз

Язмыни бу —
бу бит кыш:
шытарга курка камыш.

Вяткадан суык ага —
кыш качкан шул Вяткага.

Яр буеннан кыз атлый,
күзләрен күзлек каплый.
Начар күрә дисезме —
күзен суыктан саклый.

Суык керсә күзенә,
суык үтсә сүзенә,
суык сеңсә үзенә
нишләр идем икән мин?..
Бар дөньясын Вяткага
алып ташлавым мөмкин.

Язмыни бу —
бу бит кыш:
шытарга курка камыш.

# ХАРРАС ӘЮПОВ



*Бишегем — Мөслим районының Түреш авылы. Бала чагымнан ук шигырьләр яратам. Урта мәктәптә укыганда үзем дә язып карау теләге уянды. Беренче тәҗрибәләремне шунда ясадым. Әлегә кадәр район газеталарында басылгаладым. Әдәбиятка мәхәббәтем университетка тартып китерде. Хәзер өченче курста укыйм. Быелгы яз — минем егерме беренче язым... Уйландырырлык итеп язасы, шигырьләрдә, матуррак итеп, гадирәк итеп, тормышның үзеннән сөйләттерәсе иде...*

## Күләгәләр

Яктылыктан качып барса кеше
Күләгәсе алдан сузыла,
Кайвакытта шулай җирнекедәй
Үз күләгән үзеңә төн була.

Икеләнми атлыйм, караңгылык
Сукмакларны яшереп тормаса.
Күләгәләр артка калсын өчен
Йөзем белән йөгерәм кояшка!

## Танышу

Җирдә сагыш бар, диделәр —
Миннән ерак иде.
Әле җирнең
Ваемсыз бер улы идем.
Җирдә сагыну бар, диделәр —
Көлдем, булмас, дидем:
Әле хисләр белән
Таныш түгел идем.
Җирдә сөю бар, диделәр —
Көттерсә дә килде:
Һәм мин
Барысы белән таныш инде!

## Вәгъдә

— Көтәрсеңме? — дидем.
Син баш идең.
Вәгъдәбезне шомырт ишеткән:
Күңелләр күк керсез булсын дипме
Ап-ак итеп чәчәк өлгерткән,
    Вәгъдәбезне шомырт ишеткән...

Еллар кичеп, бире килдем менә,
Сине көтеп инде кич җиткән.
Таныш аяк тавышларын түгел,
Ялгыз шомырт шавын ишетәм,
    Әллә инде үзем кичеккән?..

Шомырт тагын ап-ак чәчәк аткан,
Без килер дип исен тараткан,
Ә мин көн дә үзем генә килеп,
Яшьлек куйган вәгъдәм яңартам.
Шомырт тагын чәчәк агарткан...

●

Горур дисең, бәхәсләшмим, чөнки
Бу гадәтем үскән тирәннән:
Урманнардан киләм, яктыны мин
Баш очымнан эзләп өйрәнгән.

●

Киләчәгеn сагына алмый кеше,
Сагынулар карый үткәнгә.
Көтеп алып булмый кичәгене,
Киләчәкләр кала киткәнгә.

Сине генә сагынып китәм дисәм,
Гаҗәпләнмә, дөрес әйткәнем:
Син генә шул минем киләчәгем,
Синдә генә минем үткәнем.

## Билгесезлек

Ярый алда син бар,
Төпсез билгесезлек.
Рәхмәт! —
Әйтми тордың:
Ул бит сөйми, диеп.
Шатлыкларым булса,
Кинәт сөендерден.

Мондый гадәтеңне
Әле белми идем.
Билгесезлек!
Бераз
Сөенеп яшим әле.
Алда кайгым булса,
Яшереп тор, ярме!

●

Мәхәббәт аланнарында
Йөргәндә үзем генә
Зәп-зәңгәр чәчәкләр сайлап
Өздем дә өздем генә.

Сиңа да китердем әле
Күзләре йомылганчы.
Чыклары сиңа коелсын,
Җилләргә коелганчы.

## Хыял

Юлда йөреп, кеше күнеккән
Маякларга карап барырга.
Юлга чыгам — минем хыялым
Маяк булып баса алдыма.

Хыялыма җиттем дигәндә
Ул алгарак китеп өлгерә.
Гомере буе кеше туктамый
Хыялына карап йөгерә.

●

Ышанып та бетмим кешеләргә:
Сукыр, диләр сине, мәхәббәт!
Ә соң ничек бөтен гомерем буе
Син йөртәсең мине җитәкләп?!



# РИМ ИДИЯТУЛЛИН

•

*1940, Башкортстан, Чакмагыш районының Яңа Мортаза авылы; урта мәктәп, завод, университет. «Кызыл таң» газетасы редакциясе — биографиям.*

*... Кулда авторучка, алда ак кәгазь. Көн темасын тойсаң, яз да яз...*

*... Майлы ботка кебек туйдырган калыпларны, яшен яшәгән канунннарны шәхес булып күздән кичерәсе, форма һәм эчтәлек бердәмлегә дигән төшенчәнең биек түбәсен күрәсе, үз мәкканңне табасы, кешеләрне фәкать ачы дөреслек һәм буяусыз матурлык алласына табындырасы иде...*

*Туган телемне, Тукаемны, Такташымны яратуым мене мине Казанга тартты. Мәхәббәтле Казан! Мәрхәмәтле бул.*

•

## Үз йолдызым

Кайсы юллардан атлармын?
Кайдан беләсең алдан.
...Үз йолдызымны тапмыйча,
Күкләрдән күзем алмам.

Күптән күзәтә күкне
Күзләрем яшькә тулып.
...Арадан берсе атылды
Шигырь юллары булып.

•

Белмим, кеше нидән яралгандыр?
Берәү судан, берәү уттан, ди;
Ә берәүләр:
без тик тузан, ди.
Белмим, кеше нидән яралгандыр?
Су булып агабызмы,
Ут булып янабызмы,
Әллә инде тузан булып,
Туфракта калабызмы?
Белмим, кеше нидән яралгандыр?
Су булса, ул — ташкындыр;
Ут булса, ул — ялкындыр;
Җир булса, ул — алтындыр;
Юктыр, юктыр,
Кеше — һәм тузан, һәм су,
һәм уттыр.

## Наиләгә

Төн белән көн кавышканын
Карыйк әле —
Ничек икән?
Әйдә, йолдыз саныйк әле
Ничәү икән?
Әнә берсе күзен кыса —
Кемгә икән?
Карау белән ул атылды —
Нигә икән?

Күп карасаң, күз тия ди —
Тия икән.
Йолдызларны керфек каплый —
Нигә икән?
— Мин санадым:
Күктә йолдыз икәү генә —
Синең ничә?
...Төн белән көн кавыштылар —
Әллә бүген, әллә кичә...

## Кызлар көлә

Кызлар көлә...
Кыш та көлә, җәй дә көлә,
Яз да көлә, көз дә көлә;
Урамда ни, урманда ни,
Яңгырда ни, буранда ни,
Нәрсәдәндер кызык табып,
Кызлар көлә.
Җәен —
Су кергәндә су чәчрәтсәң,
Язын —
Кар йомарлап кар ыргытсаң,
Кышын —
Юл бирәм дип көрткә чумсаң,
Көзен...
Нинди кызык табалардыр,
Шайтан белсен.
Урманда ни —
Бүләгем дип чәчкә тоттырсаң,
Яңгырда ни —
Очрашырга сүз куешып
Бик чак кына көттерсәң,
Буранда ни —
Чәчләренә кар кунгачтын
Тының белән эретсәң,
Урамда ни, урамда ни —
Ялгыш кына каш сикертсәң,—
Кызлар көлә.
Кайгы килми, шатлык килми.
Юк, юк, килә.
Кайгыдан да, шатлыктан да
Кызык табып шашып көлә:
Шатланганда —
Чәче көлә,
Кайгырганда —
Яше көлә.
...Урамнарга шатлык чәчеп
Кызлар килә.
(Иркесездән елмаясың)
— Исәнмесез?!
Кызлар көлә-ә-ә...

## 9 нчы Май шигыре

Егерме ел сугыш беткәнгә;
Күптән инде күз-яшь кипкәнгә.
«Сау булыгыз, бер кайтырбыз» —
Күптән инде алар киткәнгә.
Егерме ел инде киткәнгә.
«Кайтырбыз»лар һаман кайтмаган.
Ә аналар көтә, ятмаган...
Кош теледәй кәгазь алучылар
Каберләрен һаман тапмаган.
«Кайтырбыз»лар һаман кайтмаган.
Сандыклар тулы хатлар,—
Аналар күпме саклар.
Иле барлар ләкин үлемсез;
Ана күңеле көтә түземсез:
«Кайтып җитәр бүген-иртәгә...»
Иле барлар, әйе, үлемсез.
Кайтыр алар, менә күрерсез!

●

Безнең авылны
күреп ярата алмаса да,
никтер бик еш урый иде
сукыр музыкант.

Йорт күләгәсендәге
ташка утырып,
скрипкасын —
иң-иң нечкә кылын,
йөрәк өзгеч моңлы көен
тарта иде.

Малайлар бик сак
үрелеп кенә
музыкантның йомык күзләреннән
чебен куа;
Әнкәйләр
җиргә текәлгән килеш
яшереп кенә
яулык читен уа...

## Музыка

Баш очымда
чәч кылыма кагылган җил
көй уйната.
Аяк аста
яфракларның шәүләләре шыбырдаша:
«Ул ярата! Ул ярата!»



# РӘШИТ ФАЗЛЫЕВ

*1930 елда Башкортстанның Илеш районы Зур Бишкурай авылында туганмын. Авыл мәктәбен һәм бухгалтерлар курсын тәмамлагач колхозда хисапчы, район башкарма комитетында төрле эшләрдә йөрдем һәм «Сталинчы» дигән район газетасында җаваплы секретарь булып эшләдем. 1956 елны Уфа заводларының берсенә эшкә кердем. Хәзер дә шунда токарь булып эшлим.*

*Яшем зурая килгәндә генә шигырь яза башлаган кебек, укуымны дәвам итүне дә соңлабрак башладым. Уфа электромеханика техникумының IV нче курсында укыйм.*

*Башкортстанда чыга торган татар газетасы — «Кызыл таң»да, күп кенә еллардан бирле, шигырьләрем басылып килә.*

## Уйлану

Кичә генә сабый бала идем,
Бүген инде бала атасы.
Кичә генә зурлар тарткан йөкне
Горурланып бүген тартасың.
Ә шулай да яшәү кызык нәрсә,
Чапкан аттай алга барасың.
«Фәлән көннәр тизрәк үтсен»,— дисең,
Ярты гомер үткән — карасаң.
«Бәйрәм арты бәйрәм җитсен», — дисең,
Ашыгасың, йөрәк җилкенә.
Тик сизмисең: бер көн үткән саен
Гомер дә бит кими бер көнгә...
Искеләрне яңа алмаштыра,
Мәңге яшәр җирдә берни юк!
Хәрәкәттә дөнья дигәннәре,
Үткән гомер гүя аткан ук...
Тик гомерен санлы еллар гына
Билгеләми үлгән кешенең.
Әйтә ала яшәү озынлыгын
Җимешләре кылган эшенең.

## Дүрт солдаты туган илемнең...

*(Илебез батырлары Җиһаншин, Поплавский, Крючков һәм Федотовларга багышлап)*

Батырларын беләм әкиятләрнең,
Диюләрнең башын кисканнәр.
Җиде башлы аждаһаны җиңеп,
Җиде диңгез аша кичкәннәр...

Дүрт солдатын беләм туган илнең —
Әкият батырына тиңнәрен;
Һәм мин беләм шушы батырларга
Кырык тугыз үлем килгәнен.

Дүрт батырның кырык тугыз тапкыр
Җиңгәнлеген беләм үлемне.
Мин аларны тиңлим туган илгә
Һәм аларга тиңлим илемне.

## Вьетнамга

Бүген монда көмеш Идел ага,
Алсу кояш белән нурланып.
Бүген анда җиргә бомба ява,
Сулар ага канга болганып.

Бүген монда көмеш Идел ага,
Бала уйный суга чыланып.
Бүген анда күпме авыл яна,
Көчле ялкын белән чолганып.

Бүген монда көмеш Идел ага,
Рәхәт, тыныч елга буйлары.
Карап торам шаян дулкыннарга,
Ә Вьетнамда йөри уйларым:

Вьетнам җире, әгәр мөмкин булса,
Көч итеп ал минем хисемне.
Минем хисем синең белән бергә
Вәхшиләрдән алсын үчемне!

## Көтеп яшәү бигрәк авыр икән...

Көтеп яшәү бигрәк авыр икән,
Ник белмәдем шуны элгәре.
Таңда килеп йөрәк кылын чиртә
Йомшак тынлы Идел җилләре.

Көтеп яшәү бигрәк авыр икән,
Кыска көннәр озын тоела.
Зәңгәр күктә кояш елмайса да,
Күңелемә яңгыр коела.

Көтеп яшәү бигрәк авыр икән,
Ләкин көтү — үзе батырлык!
Көтәм сине, әгәр булсаң гына
Син дә миңа сагынып кайтырлык,
Сагына белү — үзе матурлык!



# ДНЕПРНЫ КИЧҮ

*Г. Сафиуллин,*

Советлар Союзы Герое,
запастагы генерал-лейтенант.

**Ш**ул ук моментта 53 нче дивизиянең уң флангысында 12 нче һәм 223 нче полкларга каршы дошман «Бөек Германия» СС танк дивизиясен һәм 355 нче пехота дивизиясен сугышка кертте. Өстәвенә, гитлерчылар дивизиянең сугышчан сафлары өстенә өзлексез бомбалар яудырып тордылар. Кичкә таба дивизия командиры генерал Овсеенко:

— Дошман 223 нче гвардия полкы оборонасын өзде. Танкка каршы средстволар белән ярдәм итүегезне сорыйм, — дип шалтыратты.

Корпус өчен гаять кыен шартлар туды.

— Үзегездәге танкка каршы дивизионны бик тиз шунда күчерегез, — дидем мин аңа. — Ә мин ярдәмгә танк полкы җибәрәм.

Мин дошманның кичү урыннарына тудырган куркынычы турында уйлана башладым.

Әйтергә генә ансат, сугышның иң кызган моментында, дошманның ярсулы атакаларын кире кайтару өчен каты сугышлар алып барганда, танк полкын һәм танкка каршы дивизионны позицияләрдән алырга?.. Өстәвенә, тиз генә башкару да кыен аны: дошман артиллериядән ут, һавадан бомба яудырып тора, икенчедән, күчү һәм яңа позиция алу да шактый вакыт, күп мәшәкать таләп итә.

Күзәтү пунктында минем белән рәттән торган дусларыма күз йөртеп чыктым. Алар мине сүзсез дә аңладылар. Алексей Петрович Колесник, «Виллис»ка үзе белән бергә политбүлек инспекторлары майор Сурков һәм майор Астархановны утыртты да, тиз генә 223 нче полкка китеп барды.

Артиллерия командующие Василий Николаевич Журавлев 53 нче дивизиядәге танкка каршы дивизионны үз позициясендә калдыру тәкъдимен әйтте.

— Бәлки, мин бүтән участоктан бер-ике батарея таба алырмын,— диде ул.— Алгы сызыкны зәгыйфьләндермик.

Ул да, артиллерия штабы офицерлары белән машинага утырып, китеп барды. Полковник Журавлев, резервтан танкка каршы ике артиллерия батареясы алып, Барадаевкада позициягә куя. 20 минуттан ул батареялар дошман танкларына каршы сугышка да керешәләр.

Барадаевканың көнбатыш читендә хәлләр җайга салынгач, мин командующий күзәтү пунктына шалтыраттым. Телефон трубкасын фронт командующие И. С. Конев алды. Минем докладны тыңлаганнан соң:

— Корпусның уң флангысындагы хәлләрне мин яхшы күреп торам, — диде ул.— 53 нче дивизия командиры генерал Овсеенкога әйтегез: Барадаевканы кулда тоту өчен бөтен җаваплылыкны мин аңа йөклим. 15 нче гвардия дивизиясенең чигенүче подразделениеләрен туктатыгыз һәм 53 нче дивизиягә кушыгыз, анда тәртип урнаштырыгыз.

Барадаевкадан дошманны алып ташлау өчен күргән чараларны әйткәч, фронт командующие:

---

Ахыры. Башы 2, 3 саннарда.

— Корпуска нинди ярдәм кирәк? — дип сорады.

— Барадаевканың көнбатыш өлешенә, 147,4 биеклегенә армиянең туп-артиллерия бригадасының утын юнәлдерсәгез иде, — дидем мин.

Телефон трубкасын куйдым да запас күзәтү пунктына киттем. Артиллерия бригадасы 147,4 биеклегенә, Тарасовкага һәм Барадаевканың көнбатыш өлешенә ут яудырырга кереште дә инде.

Барадаевкада каты сугышлар дәвам итә иде. Дошман һаман һавадан бомба яудыра. Безнең танклар һәм артиллерия туры наводка белән дошман танкларына аталар. 223 нче полк батальоннары, йорт артыннан йортны, сарайларны, каралтыларны штурмлап, дошманны чокырга кысрыклыйлар. Үзәк урамда, чокыр аша салынган күпер янында, өч дошман танкы пыскып ята.

Киеренке сугыш кичке 9 га кадәр дәвам итте. Дошман чокыр аша Барадаевканың көнбатыш өлешенә алып ташланды. Корпус оборонасының уң яктагы өлеше, аның төп полосасы торгызылды. Сәгать 10 да бу турыда армия командующиена шалтыраттым.

М. С. Шумилов үзе килеп моны тикшерде дә:

— Барадаевка «капкаларын» көнбатыштан нык саклагыз, — диде, — бер генә дошман солдаты да үтәрлек булмасын. Танк полкын вакытлыча Барадаевкада калдырыгыз. 24 нче гвардия корпусыннан генерал Скворцовның 78 нче гвардия дивизиясен сезнең карамакка бирәм. Аны резервта тотыгыз, кирәк булганда гына сугышка кертерсез. Кисәтеп куям: дошманның плацдармны җимерү уеннан кире кайтканы юк, авиаразведка аның яңа резервлар китерүен хәбәр итте.

Командующийга ярдәме өчен рәхмәт әйттем дә аерылыштык. Мин үземнең күзәтү пунктына юнәлдем. Колесник белән Журавлев та бирелә иделәр.

Полковник Колесник корпусның политбүлек работникларь күрсәткән батырлыклар турында сөйләде. Майор Сурков белән майор Астарханов сугышның иң киеренке моментында, тәртипсез чигенүче подразделениеләрне туктатып, аларда тәртип урнаштырып, контратакалар оештыралар. Автоматлар алып үзләре дә дошман сафларына ташланалар. Аннары, яңа рубежларны сугышып алганнан соң, шунда оборона оештыралар.

Сугышчан приказны үрнәк төстә үтәгәннәре һәм батырлыклары өчен майор Астарханов «Кызыл Байрак», майор Сурков «Беренче дәрәҗә Ватан сугышы» ордены белән бүләкләнде.

Төн җитте, курганнар, биеклекләр, урманнар төнге караңгылыкка, сугыш төтененә һәм тузанга күмелеп, күздән югалды. Алгы сызыкның кайда икәнен пуля калдыртан якты сызыклар, автомат һәм пулемет очередьлары буенча гына шәйләргә мөмкин иде. Караңгылыкка карамастан, дошман «Хейнкель»ләре, парашютка асылган ракеталар белән Днепр өстен яктыртып, кечү урыннарын бомбага тотуны дәвам иттерделәр.

Дивизия һәм корпус карамагына бирелгән частьлар командирлары, минем урынбасарлар, армия штабыннан һәм күрше корпуслардан килгән элемтә офицерлары күзәтү пунктына җыелды.

Мин корпусның фронт сызыгын ачыкларга керештем. Командирларның доклады буенча, 3 октябрьның 22 сәгатенә фронт сызыгы түбәндәгечә иде: үзәк Барадаевканың көнбатыш чите, 182,3 биеклеге, Погребная, Одинец. Дивизияләр оборонасының икенче эшелоны юк һәм корпус резервлар белән тәэмин ителмәгән. Днепрдан сул флангка кадәр фронт киңлеге 16 километрдан артыграк.

Армия командующие белән килештем дә 78 нче гвардия дивизиясен 53 нче дивизиянең артына урнаштырырга булдым.

Киңәшмәгә катнашучыларга армиянең Хәрби Советы приказы һәм Дала фронты командующие генерал И. С. Конев күрсәтмәсе җиткерелде. Корпус сугышчыларыннан, ничек кенә булмасын, кан түгеп яулап алынган плацдармны саклап калу, бер адым да артка чигенмәү таләп ителә иде.

Мин 53 нче дивизия командиры генерал Овсеенконы нык кына кисәттем. Чөнки ул дивизия оборонасын тиешенчә оештыра һәм ныгыта алмады, үз кул астындагы гаскәрләргә карата таләпчәнлек күрсәтмәде. Шулар нәтиҗәсендә дошман Барадаевканың үзәгенә бәреп керде.

Командирларга корпус штабы күрсәтмәсе җиткерелде. Бу күрсәтмә буенча дивизия командирлары, штаб офицерлары һәм политработниклар иртәнгә кадәр частьларның сугышчан сафларын, көчләрнең һәм коралларның урнаштырылышын тикшерергә, сугыш кирәк-яраклары һәм азык белән тәэмин ителүгә контроль ясарга тиешләр иде.

Тылда да, алгы сызыкта да киеренке эш кайнады. Гвардиячеләр оборонаны ныгыттылар. Барлык дәрәҗәдәге офицерлар частьларда приказның үтәлешенә контроль ясадылар, сугышчыларга алда торган бурычларны, армия Хәрби Советы һәм фронт командующие таләпләрен аңлаттылар.

М. С. Шумилов эшләрнең барышы турында әледән-әле телефоннан сорашып торды.

— Үзегез һәм полковник Колесник белән полковник Журавлев 53 нче дивизиянең әзерлеген, 78 нче гвардия дивизиясенең оборонага урнашуын тикшерегез. Плацдармны саклап калу өчен барлык чараларны күрегез, — дип кисәтте ул.

78 нче гвардия дивизиясе 4 октябрь көнне иртәнгә 53 нче дивизия артына, Барадаевка — Домоткань юлын кисеп, бер полкын икенче эшелонга куеп, оборонага урнашты.

Шулай ук дошман да иртәнгә кадәр перегруппировка үткәрде, яңа резервлар китерде. Иртәнге сәгать 3 тә полковник А. Д. Овсянников белән корпусның разведка бүлеге начальнигы майор И. А. Воронцов төнге разведка мәгълүматлары турында доклад ясадылар.

Дошман төп көчләрен Барадаевканың көнбатыш читенә туплаган иде. Анда гитлерчыларның 70 танкысы, 72 нче һәм 81 нче дивизия арасына ике полк пехотасы, ә 24 нче гвардия корпусы белән 72 нче гвардия дивизиясенең сул флангы арасында 30 танкысы һәм ике полк пехотасы урнашкан иде.

Элекке көннәрдәге сугышта җиңелгән дошман төп ударны яр буйлап Барадаевка авылының көнчыгыш ягына, шул ук вакытта, корпусның сугышчан сафларын өзү өчен, 81 нче һәм 72 нче гвардия дивизияләре арасына һөҗүм итәргә теләп һәм көньяктан кечү урыннарына чыгарга маташа иде. Разведчиклар алып кайткан әсирләр безнең корпуска каршы ике танк, өч пехота дивизиясе тупланганлыгы турында сөйләделәр. Дошманның алдагы сугышларда нык кына таушалган 39 нчы пехота дивизиясе тулыландыру өчен тылга чыгарылган, ә аның урынына резервтан тулы канлы 306 нчы пехота дивизиясе китерелгән иде.

## Плацдармны бирмәскә!

Иртәнге биш. Укчы полклар оборона рубежларына ныгып урнашкан. Танкка каршы артиллерия — частьларның сугышчан сафлары арасындагы позицияләрдә. Командирлар үзләренең күзәтү пунктларында. Плацдармда бер генә дә хәрәкәт сизелми.

Минем күзәтү пункты алгы сызыктан сигез йөз метрдагы +1,5 билгесе белән йөртелә торган биеклеккә күчерелгән иде. Минем янда — корпусның оператив бүлеге офицерлары, ординарец Сидор Новгородов һәм элемтәчеләр.

Полковник Колесник төнне 53 нче дивизиядә уздырды да көндез дә шул дивизиядә калырга рөхсәт сорады. Чөнки бу дивизия оборонасы барысына карата да мөһимрәк иде.

Мине блиндажга, телефонга чакырдылар. Армия командующие икән. Дошман һөҗүмен кире кайтарырга әзерлекне белдерергә генә керешкән идем, командующий:

— Дошман атакасын көтмәгез, — дип сүземне бүлде. — Ун минутлык артиллерия налеты ясагыз да барлык көчләр белән һөҗүмгә күчегез. Тиздән бу турыда сугышчан приказ алырсыз.

Унбиш минуттан сугышчан приказ килеп җитте. Корпус алдына яңа, тагы да җаваплырак бурыч килеп басты: плацдармны саклап калу гына түгел, аны киңәйтергә, өстәвенә, үз көчләребез белән күрше 49 нчы корпусның дошман кулына күчкән позицияләрен дә кире кайтарырга тиеш идек. Атака башланганчы кабат перегруппировка ясарга кирәк булды. Дивизия командирлары һәм минем урынбасарлар бик тиз генә күзәтү пунктына чакырылды. Ун минут эчендә күрсәтмәләр алып, алар үз урыннарына киттеләр.

Корпус частьлары перегруппировка ясаган арада, без борчылып дошман ягын күзәттек. Күк йөзе аяз булып, тирә-як яхшы күренеп торса да, дошман әллә ни активлык күрсәтми, безнең сафларны миномётлардан һәм артиллериядән методик рәвештә утка тоту белән генә чикләнә иде.

Менә Лиховка ягыннан дошманның утыз бомбардировщигы күренде. Димәк, дошман атаканы бездән алдарак башлады, хәзер җир өсте көчләре дә хәрәкәткә киләчәк... Юк, бомбардировщиклар безнең сафлар өстеннән узып киттеләр. Днепрның сул ягын — Яңа Орлик, Иске Орлик тирәләрен бомбага тотарга керештеләр.

Дошман самолетларының икенче группасын безнең истребительләр алгы сызыкка кадәр үк таркатып бетерделәр.

Армия командующие М. С. Шумилов әледән-әле дошман гаскәрләренең үз-үзләрен тотышы турында сорашып торды. Сәгать 10 да армиянең штаб начальнигы генерал Г. С. Лукин шалтыратты.

— 78 нче гвардия дивизиясен ашыктырыгыз, тизрәк әзерлек хәленә килсен, — диде ул. — Сезнеңчә ничек, нигә дошман ягы тын?

— Минемчә, дошман хәйләләмәкче була. Мөгаен, ул безнең фикерне белә торгандыр. Безнең һөҗүм башлангач, контрудар ясап, Барадаевкага бәреп керергә уйлыйдыр.

— Атака 11 сәгатькә билгеләнде. Армия бригадасы һәм фронт авиациясе бөтенләе белән сезгә хезмәт күрсәтәчәк. Билгеләнгән срокка барысы да әзер булсын!

Нәкъ 11 сәгать 15 минутта, куәтле артиллерия һәм авиация налетыннан соң, корпус һөҗүмгә күтәрелде. Безнең фикер дөрес булып чыкты: дошман тактикасын үзгәртте. Бүгенгә кадәр, без Днепрны кичкәннән башлап, һәрвакыт, ул һөҗүмне беренче булып башлый иде. Ләкин, сугышка үзенең күп санлы резервларын кертсә дә, ул уңышка ирешә алмады, зур югалтуларга дучар булды. Хәзер гитлерчылар безнең гаскәрләрне ачык урында, һөҗүм вакытында кырырга, дивизияләрнең сугышчан сафларын контратакалар белән өзеп, камап алырга һәм юк итәргә теләде.

Полклар атакага күтәрелү белән, дошман да һәр яклап атакага күчте. Минем күзәтү пунктыннан яхшы күренә: 147,4 биеклеге районыннан 78 нче гвардия дивизиясе полкларына каршы аның 40 танкы, ике полк пехотасы чыкты. 53 нче дивизиянең 223 нче полкына каршы 172,2 биеклеге районында 30 танк һәм ике полк пехота контратака ясады. Һавада дошман самолетлары мыжгып тора, безнең гаскәрләргә бомба яудыра иде. 81 нче гвардия дивизиясенә каршы бер полк пехота белән 35 танк, 72 нче гвардия дивизиясе белән 24 нче гвардия корпусы арасына 40 танк һәм ике полк пехота һөҗүм итте.

Корпус фронтының барлык участокларында каты сугышлар башланып китте. Дивизия командирлары көньяк-көнбатыштан дошманның яңа резервлар тарттыруын хәбәр иттеләр. Гитлерчыларның һавадан бомба ударлары сизелерлек көчәйде. Сугышның бер сәгате эчендә генә дә дошман самолетлары корпусның сугышчан сафлары өстенә 280 самолет-очыш ясадылар.

78 нче гвардия дивизиясе поклары дошманның барлык контратакаларын кире кактылар. 53 нче дивизия частьлары 182,3 биеклеген һәм Погребной хуторын алдылар. Шулай ук сул флангта да дошманның барлык атакалары кире кайтарылды.

Плацдармны саклау өчен сугышлар 9 октябрьга кадәр көнен дә, төнен дә дәвам итте. Кайбер көннәрне дошман унсигезәр тапкыр атакага күтәрелде. Сугышларда сирәгәйгән дивизияләрен тулыландырып торды, йөзләрчә танклар, бронетранспортерларга утырган марш батальоннары белән көчәйтте. Әсирләр дошманның яңа килгән резервлары Пятихатка, Верховцово станцияләрендә вагоннардан бушатылуларын һәм аннары туп-туры сугышка кертелүләрен әйттеләр.

24 нче гвардия корпусы фронтында да сугышлар көчәйгәннән көчәйде. Аның сул флангы дошман танклары басымы астында Дөмотканьь ягына чигенде. Элек 15 нче гвардия дивизиясе яулап алган плацдарм яңадан дошман кулына күчте. Хәзер 15 нче гвардия дивизиясен безнең корпуска кушу турында сүз дә булуы мөмкин түгел, чөнки ул бернечә өлешкә бүлгәләнгән иде.

Дошман самолетлары корпус гаскәрләрен төннәрен дә бомбага тотарга керештеләр. Гитлерчыларның авиациясе тәүлеккә 1300 әр самолет-очыш ясыйлар иде. Бигрәк тә алар Барадаевка авылын, курганнарны күбрәк бомбага тоттылар. Чөнки курганнарга күзәтү пунктлары, танкка каршы артиллерия урнашкан һәм ул рубеж безнен өчен уңай иде.

Плацдармны саклаучылар өчен авыр моментлар күп булды. Дошман танклары һәм бронетранспортерларга утырган аның пехотасы корпусның сугышчан сафларына бәреп керде, аны бернечә өлешкә бүлгәләде. Танклар безнең окопларны һәм траншеяларны изеп йөрде. Днепр буендагы калкулыклар, курганнар, чокырлар көнгә бернечә тапкыр кулдан-кулга күчтеләр. Гвардиячеләр арасында героизм, фидакарьлек көндәлек эш нормасына әверелде.

Шулай 7 октябрьда дошман, 72 нче гвардия дивизиясенең 222 нче полкы оборонасын өзеп, Погребной хуторын саклаучы батальонны камап алды һәм полкның флангысына чыкты. Икенче батальон да камалу алдында калды. Мин ул вакытта генерал Лосев дивизиясенең күзәтү пунктында идем. Полк командиры подполковник Уласовец, дивизия командирына донесение җибәреп, батальонны камалыштан чыгару өчен, контратакага күтәрелергә рөхсәт сорады. Донесениедә контратака белән Уласовец үзе җитәкчелек итәчәге әйтелгән иде.

— Нишләргә? — диде миңа карап генерал Лосев. — Ике батальон моны булдыра алырмы икән?

Мин полк командиры А. И. Уласовецны яхшы белә идем. Ул батыр, акыллы командир булып, һәрвакытта да кыен хәлдән чыга белә иде. Аның полкы корпуста иң яхшы полкларның берсе иде.

— Рөхсәт итегез, — дидем мин. — Уласовец үзе җитәкчелек итә икән, булдырырлар.

Һәм ул булдырды да.

Кичен без шул контратакага катнашкан полк командиры урынбасары майор Князевнең донесениесен укыдык.

«...Полкның сугышчылары һәм офицерлары «Ура» кычкырып дошманга ташланды, — дип язган иде ул. — Дошман, сугыш кырында йөзләрчә мәетләрен һәм яралыларын калдырып, Погребной хуторыннан чигенде. Беренче батальон камалыштан азат ителде.

Погребной хуторында безнең алга фашистларның коточкыч ерткычлыгы картинасы килеп басты. Дошман, хутордан чигенер алдыннан, корпусның яраланып әсир төшкән сугышчыларын һәм офицерларын явызларча җәзалап үтергән иде. Дошман бомбаларыннан җимерелгән йортлар һәм каралтылар арасында янып күмерләнгән хатыннар, картлар, балалар гәүдәләре ята иде».

Корпус өчен гаҗәеп авыр бу шартларда полкларның сугышчан сафлары арасына танкка каршы пушкалардан тыш, артиллерия полклары орудиеләрен һәм 5 нче зенит дивизиясе пушкаларының бер өлешен дә туры наводка белән позицияләргә урнаштырдык. Бу чара плацдармны саклауда, дошман атакаларын кайтаруда зур роль уйнады.

Ләкин дошман танкларына каршы каты сугыш алып барган бер вакытта, минем күзәтү пунктына армиянең артиллерия штабы начальнигы полковник З. М. Санфа-

ров килде. Ул, минем янга килешли, алгы сызыкта куаклыклар арасыннан туры наводка белән атып торган 122 миллиметрлы ике гаубицаны күргән икән.

— Мин андый орудиеләрне алгы сызыкка куярга рөхсәт итмим,— диде ул.— Алыгыз. Алар бары тик яшерен позициядән генә атарга тиешләр.

Мин аның сүзен тыңламадым. Ул, армиянең артиллерия командующие генерал Петровка шалтыратып, эре калибрлы орудиеләрне алгы сызыктан алырга приказ бирдертте.

Мин дә, үз чиратымда, бу турыда армия командующиена хәбәр иттем. Минем белән армиянең Хәрби Советы члены генерал А. В. Мухин сөйләште.

— Полковникка минем приказны җиткерегез: сугыш белән җитәкчелек итүдә сезгә комачаулап йөрмәсен,— диде ул.

Шуның белән сүз бетте, сугыш барышында бүтән андый формаль мәсьәләләр белән борчучы булмады. Әмма бу урында шунысын да әйтергә кирәк: плацдармда бер ай дәвамындагы сугышларда алгы сызыкка урнаштырылган артиллерия полклары ни барысы егермеләп орудие югалттылар. Алары да авиобомбалар тиюеннән генә булды...

Төн уртасында мин Барадаевка авылына киттем. Авыл уртасында исән калган бер хата бар иде, без, корпус командованиесе, сугыш тынган арада фикерләрне уртаклашырга, киңәшергә, капкалап алырга шунда җыела торган идек.

Минем урынбасарларым: Колесник, Журавлев, Овсянников һәм Смоляков мине көтәләр иде инде.

Штаб начальнигы дивизия һәм безнең карамакка бирелгән часть командирлары биргән бүләкләү кәгазьләре папкасын өстәлгә салды. Днепрны кичкәннән соң, бу әле беренче бүләкләүләр иде. Мин йөздән артык кәгазьгә кул куйдым. Бүләкләүгә тәкъдим ителгәннәр арасында укчылар да, артиллеристлар да, саперлар да, элемтәчеләр дә, танкистлар да бар иде.

Корпусның элемтә начальнигы майор Д. Ф. Токарев элемтәчеләрнең фидакарьлеге турында сөйләде.

Днепр ярына тоташа торган чокырларның берсенә корпусның элемтә узелы урнашкан иде. Анда Днепрны беренчеләрдән булып кичкән Шура Жукова белән Мария Коновалова искиткеч киеренке сугыш шартларында көнен дә, төнен дә сменасыз дежур тордылар.

6 октябрьда дошман самолетлары бу тирәне өзлексез бомбага тотты. Бомбаларның берсе чокыр кырыена төшә дә коммутаторны да, андагы кызларны да калын туфрак катламы белән күмә. Аларны казып алырга да өлгермиләр, якында гына тагын бомба шартлый. Мария белән Шура үз гәүдәләре белән коммутаторны каплыйлар. Алар икесе дә «Икенче дәрәҗә Ватан сугышы» орденына тәкъдим ителгән иде.

Плацдармдагы сугышлар вакытында элемтә эше гаять зур әһәмияткә ия иде. Элемтә линияләре өзелсә — пулялар өзлексез сызгырып торганда, берсе артыннан берсе снарядлар, миналар, бомбалар шартлаганда алар бик еш өзелә иде — һәрберебез дә тиз генә аны ялгауны таләп итә идек. Шуңа күрә элемтәчеләр пулялар яңгыры астында һәрвакыт эштә булды. Бик еш кына аларга дошман белән турыдан-туры сугышка керергә дә туры килә иде.

Шул ук 6 октябрь көнне лейтенант Сварчевский белән лейтенант Юров, 133 нче батальонның бер төркем элемтәчеләре белән, ярдәм килгәнче, тәүлек буена 170,1 биеклеген дошманнан саклыйлар.

Элемтәче Иванищев Днепрны беренче авангард составында кичеп чыга. Сугыш вакытында ут астында ул ун тапкыр Днепр аша сузылган элемтә чыбыкларын ялгый. Иванищев Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән иде.

Миңа 72 нче гвардия дивизиясе элемтәчеләре: Букреев, Лебедев, Киб, Белинин, Таганьязов, Деревянов һ. б. ларны бүләкләүгә тәкъдим иткән кәгазьләр. Барысы да алар Днепрны Баталов полкы белән бергә кичтеләр һәм плацдармны киңәйтү өчен сугышка керештеләр. Одинец авылы янында, дошман элемтә линиясенә якынлашкач, дүрт тапкыр контратакага күтәрелеп, аны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Рядовой Таганьязов — милләте буенча казакъ — бу сугышта, карабиннан атып, биш фашистны дөмектерде.

* * *

Төн. Плацдармда сугыш һаман дәвам итә. Гитлерчылар фронтның әле бер участогына, әле икенчесенә атака ясап торалар, оборона сызыгын үтәргә телиләр. Дивизия командирлары дошман атакалары, аларның кире кагылуы, немецларның сугыш кырында мәетләрен һәм яралыларын калдырып чигенүләре турында донесениеләр җибәреп торалар.

Миңа төнге уннар тирәсендә 53 нче дивизиядән шалтыраттылар. Телефонда генерал Овсеенко иде.

— Иптәш генерал,— диде ул, калтыранган тавыш белән,— 223 нче гвардия полкының уң флангысына дошманның 15 танкы белән бер полк пехотасы һөҗүм итте. Фашистлар, оборонаны өзеп, Барадаевка үзәгенә якынлашалар. Ярдәм кирәк.

Бу турыда армия штабы офицерлары командующийга хәбәр итеп өлгергәннәр иде булса кирәк, озак та үтмәде, фронт командующие шалтыратты:

— Барадаевкадагы хәлне яхшырту чарасын күрегез,— диде И. С. Конев. таләпчән тавыш белән.— Генерал Овсеенкога белдерегез: әгәр 53 нче дивизия югалткан позицияләрен кайтармый икән, ул дивизия белән командалык итмәячәк.

Биш минуттан соң 81 нче гвардия дивизиясе командиры С. Г. Николаев хәбәр итте:

— Дошман утыз танк һәм бер полк пехота белән 235 нче гвардия полкының уң флангысына һөҗүм итте. Кире кайтару чарасын күрәм.

Артиллерия канонадасы һәм пулеметлар тыкылдавы Барадаевский хуторлары тирәсеннән һәм 24 нче гвардия корпусы ягыннан да ишетелә иде. Хәл бик катлауланды. Полковник А. Д. Овсянниковка уң як күршенең хәлен ачыкларга приказ биреп, үзебез дивизияләргә таралыштык. 53 нче дивизиягә полковник А. П. Колесник, 78 нче гвардия дивизиясенә полковник Журавлев китте, ә мин 81 нче дивизиягә, полковник Николаев янына, юнәлдем.

Гитлерчылар корпусның бөтен фронты буйлап һөҗүмгә күчкән иде. Дошман көндезге сугышларда бик күп югалтуларга дучар булуына карамастан, хәзер төнге сугыш тактикасын кулланырга уйлады, безне көтмәгәндә юк итәргә исәпләп, һөҗүмне артиллерия әзерлегеннән тыш кына башлады. Николаев дивизиясенә килгәч, мин танкка каршы артиллерия полкының 115 нче батареясын, позициядән алып, 53 нче дивизиягә җибәрдем. 78 нче гвардия дивизиясенең икенче эшелондагы бер полкы да аларга ярдәмгә җибәрелде.

Менә төнге ике җитте. Гитлерчылар, югалтулар белән исәпләшмәстән, үзләренең танкларын һәм пехотасын һаман бер-бер артлы атакага җибәрәләр.

81 нче гвардия дивизиясе командиры сугышка резервны кертергә һәм 238 нче гвардия полкы белән Погребной хуторына яңадан бәреп кергән дошманның флангысына удар ясарга рөхсәт сорады.

Мин рөхсәт бирдем һәм танк полкы командирына аларга ярдәм итәргә куштым. Маневр уңышлы чыкты, дошман аннан алып ташланды.

Сәгать өчтә Колесник телефон аша шатлыклы хәбәр җиткерде.

— Барадаевкадан дошман алып ташланды, — диде ул. — Алты танк һәм өч бронетранспортер кулга төшердек. Безнең югалтулар күп түгел. 78 нче дивизия гвардиячеләре бик яхшы сугышты.

24 нче гвардия корпусы командиры генерал Васильев та дошман атакаларының кире кагылганлыгын, безнең сул флангка куркыныч бетканлеген хәбәр итте.

Днепр ярлары таң алдыннан тынып калды. Һәр ике як та гаскәрләрне һәм кораларны тәртипкә китерә, яңа сугышларга әзерләнә иде.

Мин 78 нче гвардия дивизиясе командиры янына киттем. Генерал А. В. Скворцов, полковник Колесник һәм корпус штабы офицерлары көнбатыш Барадаевка чиркәве каршысында, тирән чокырның көньяк ярында, дошман ягын күзәтәләр иде.

Төнге сугыш барышында 53 нче һәм 78 нче дивизия частьлары үзара аралашып беткән — кая карама, анда команда тавышлары ишетелә иде. Менә генерал Овсеенко да килеп җитте.

— Командующийга позицияләрнең кайтарылуы турында хәбәр итегез, — дидем мин аңа.

— Сез әйткәнсездер дип уйлаган идем мин.

— Юк, фронт командующие сезгә дивизиянең оборонасын элеккеге хәлгә кайтарырга һәм моның нәтиҗәләре турында үзегезгә хәбәр итәргә приказ биргән иде бит.

Фронт командующие да, армия командующие да үз күзәтү пунктларында иде әле.

— Дошманның барлык атакалары кире кагылды, дивизиянең оборонасын элеккеге хәленә кайтардык, — дип, Овсеенко командующийга кыска гына сөйләп бирде.

— 78 нче гвардия дивизиясе белән берлектә, дип өстәргә кирәк,— диде аңа полковник Колесник.

Таң беленә башлагач, дошман ягында хәрәкәт көчәйде. Гитлерчылар танкларын, үзйөрешле орудиеләрен һөҗүмгә әзерләделәр. Көньяктан һәм көньяк-көнбатыштан дошманның тагын танклары һәм мотопехотасы килгәне күренде.

Сәгать тугызга безнең корпус перегруппировканы тәмамлады. 78 нче гвардия дивизиясенең ике полкы Днепр яры һәм +2,0 биеклегенең төньяк итәге полосасына ныгып урнашты. Өченче полк икенче эшелонда калды. 53 нче дивизия 78 нче гвардия дивизиясеннән көньяктарак оборона билpoints. Корпусның башка частьлары элеккеге урыннарда калдылар.

Личный составка төнге сугыштан соң тагын ял итәргә туры килмәде. Ләкин гвардиячеләр хәлне яхшы аңлыйлар иде, беркем дә ял итү турында уйламады. Алар иртәнге ашны ашадылар да сугыш кирәк-яракларын тулыландырдылар, позицияләрен яхшырттылар. Бүген аларны тагын киеренке сугышлар көтә иде.

Сәгать 9 да фашистлар авиациясе корпусның сугышчан сафларын тагын бомбага тотарга керешә. Аннары снарядлар ява башлады. Ун минутлык артиллерия әзерлегеннән соң, дошман атакага күтәрелде. Ул көнне фашистлар аеруча шашынып сугыштылар, һичнинди югалтуларга карамастан, яңадан-яңа көчләр белән һөҗүмне дәвам иттерделәр. Кичкә таба, каты сугышлардан соң, дошман танклары, 24 нче гвардия корпусы оборонасын өзеп, Барадаевский хуторлары янына чыктылар. Көнбатыш-

тан фашистлар 40 танк ярдәмендә Одинец хуторын алдылар. Куәтле артиллерия һәм авиация ударлары ярдәмендә дошман танклары һөҗүмнәрен дәвам иттерделәр, 81 нче һәм 72 нче гвардия дивизияләрен камап алырга омтылдылар. Ике яктан да һөҗүм итеп килүче танкларның һәм пехотаның тоташуы өчен бары 800 метрлап ара калды — безнең полклар ярым камалыш хәлендә иде.

Шул ук вакытта 24 нче гвардия корпусының 73 нче дивизиясе дә дошманның бер дивизия пехотасы һәм 50 танкы басымы астында Домотканьга чигенде.

Дошманның Днепрга чыгу һәм корпус частьларын камап алу куркынычы көчәйде.

Мин урынбасарларымны һәм корпус белән идарә итү офицерларын күзәтү пунктына чакырдым. Алар барысы да арыганнар, тузанлы йөзләре суырылган иде.

Аларга мин үземнең карарымны әйттем:

— Дошман 81 нче һәм 72 нче гвардия дивизияләрен камап бетермәс борын, полкларны алдан әзерләнгән яңа рубежларга күчерегез, — дидем һәм яңа оборона сызыгын күрсәттем. — Корпус һәм дивизия штабы офицерларына, полк командирларына бу бурычны үтәүдә ярдәм итәргә. Бу карарны дивизия командирларына җиткерегез!

Шул вакыт армия командующие мине телефонга чакырды. Ул бездәге хәлләр белән таныш иде, минем карарымны сорады. Мин сөйләп бирдем.

— Исегездә тотыгыз, — диде М. С. Шумилов, — бу инде соңгы рубеж. Корпусның плацдармда бүтән бер карыш та җир калдырырга хакы юк. Ничек кенә булмасын, плацдармны сакларга кирәк. Частьларны күчергәндә тәртипне яхшы саклагыз, дошман артыгыздан биеклекләргә бәреп кермәсен!

Аннары, бераз тын торганнан соң, командующий өстәп куйды:

— Дошманның резервлары бетеп бара. Ике көннән плацдармның тулы хуҗалары булырсыз. Нык торыгыз! Бүген төнлә сезнең карамакка 41 нче гвардия дивизиясенең 122 нче гвардия полкы килер. Кичү урынында каршы алыгыз һәм полкны икенче эшелонга урнаштырыгыз.

Командующийның бу хәбәре офицерларны дәртләндереп җибәрде. Алар күтәренке күңел белән дивизияләргә таралдылар.

Дошман төне буе һөҗүмен дәвам итте, безнең дивизияләрне бәжра эчендә калдырырга теләде. Ләкин ул моңа ирешә алмады, дивизия командирлары, резервларны һәм икенче эшелонны уңышлы кулланып, гитлерчыларның омтылышын туктаттылар; дивизияләр камалыштан чыкты һәм уңайлы рубежларга урнашты.

Таң алдыннан 122 нче гвардия полкы килде. Аны дивизия командиры — тәбәнәк буйлы, кырыс йөзле, урта яшьләрдәге генерал Цветков үзе алып килгән иде.

— 41 нче гвардия дивизиясенең 122 нче полкы сезнең карамакка килде, кайда урнашырга боерасыз? — диде ул.

Цветковка мин хәлне аңлаттым, карта буенча оборона полосасын күрсәттем.

Корпусның яңа рубежы траншеялар, ДЗОТлар, артиллерия позицияләре белән ныгытылган һәм аннан дошман ягы уннарча километрга ачык күренеп тора иде.

11 октябрьдә полклар Днепрның сул ягында азат ителгән районнардан чакырылган хәрби хезмәткә яраклы кешеләр белән тулыландырылды.

Гитлерчылар, плацдармны юк итәргә теләп, бернинди югалтуларга карамастан, атакаларны һаман бер-бер артлы ясап тордылар. Дошман самолетлары безнең өскә туктаусыз бомба яудырдылар. Алар көненә меңгә якын самолет-очыш ясыйлар иде.

13 октябрьдә, төн уртасында, генерал Лосев:

— 229 нчы полкка дошманның 40 танкысы белән бер полк пехотасы һөҗүмгә ташланды. Ярдәмгә артиллерия һәм танклар җибәрсәгез иде, — дип шалтыратты.

Минем резервта бары ун танк калган иде. Аларны мин сугышка кертә алмыйм, соңгы чиктә генә файдалану өчен тота идем. Лосевка мин, армиянең танкка каршы артиллерия полкыннан алып, ике батарея җибәрдем.

— Дошман атакасы кире кагылды, — дип шалтыратты Лосев, шатлыклы тавыш белән, бер сәгатьтән соң. — Орудие расчетларын хөкүмәт бүләкләренә тәкъдим итәм. Артиллеристлар — молодецлар, дошманның унике танкысын яндырдылар. Өчесе — «Тигр».

Бу сугышта әсир төшкән немец офицеры:

— Роталарда ике, өч танк кына калды, — дип сөйләде. — Атака алдыннан алар группаларга берләшәләр. Солдатларның һәм офицерларның мораль торышы төшенке. Алар хәзер уңышка ышанмыйлар. Бөтен ышаныч авиациядә. Аның да соңгы вакытларда очышлары сирәгәйде.

Шулай да фашист командованиесе плацдармны юк итү максатыннан кире кайтмаган иде әле. Дошман киң фронт буйлап һөҗүмнән ваз кичсә дә, танкларын, артиллериясен һәм пехотасын бер үзәккә туплап, тар участокларда бик еш атакалар ясап торды, сугышка яңа резервларын кертте.

Шундый бер эпизод хәтердә калган. Кояш баер алдыннан алтмыш дошман самолеты 79 нчы, 81 нче гвардия дивизияләре командирларының һәм минем күзәтү пункты урнашкан биеклекләрне бомбага тотарга кереште. Авиация налетыннан соң, ун минутлык артиллерия әзерлеге үткәрде. 72 нче гвардия дивизиясе командиры генерал А. Н. Лосев команда пункты юнәлешендә дошманның десантлы 15 танкысы һөҗүм башлады. Танклар артыннан бер батальон пехота килә иде. Дошман иң кыска юлдан плацдармга бәреп керергә уйлый иде.

Күзәтү пунктындагы дивизия командиры, офицерлар һәм солдатлар, 150 метрлап артка чигенеп, уңайлы позицияләр алдылар да танкка каршы гранаталар, мылтыклар белән дошман танкларының юлын бүлделәр, пулеметлардан һәм автоматлардан атып, пехотаны ятарга мәҗбүр иттеләр. Шулай да уңайлы биеклек дошман кулында калды.

Шул ук вакытта дошман танклары минем күзәтү пункты каршындагы куаклыкларга урнашкан 81 нче гвардия дивизиясе батальонын да атакаладылар. Батальонның 80 проценты Днепрның сул ягындагы азат ителгән районнардан чакырылган һәм яңа гына сугышка кертелгән солдатлардан тора иде. Менә батальон танклар басымы астында чигенә башлады. Уңайлы булган биеклекләрне дошманга калдыру куркынычы туды.

Корпусның идарә итү офицерлары, полковник Колесник һәм мин күзәтү пунктында идек. Без хәзер алгы сызыктан да алдарак калдык. Безгә каршы дошман танклары килә, алар туры наводка белән пушкалардан һәм пулеметлардан ут яудыралар. Ничек кирәк алай йөз метрлар артка йөгердек, чигенүчеләрне куып җиттек һәм туктаттык.

Минем күзәтү пунктыннан уңдарак куаклар арасына, югарыда әйткәнемчә, ике 122 миллиметрлы гаубица урнашкан иде. Алар үтеп кергән дошман танкларының флангысында калдылар һәм туры наводка белән тәрәп атып дошманның дүрт танкысын, пехота төялгән өч бронетранспортерын юк иттеләр. Шулай итеп хәл яхшырды.

72 нче гвардия дивизиясе командирының күзәтү пункты районында, дошман танклары тукталган урынга, гитлерчыларның пехотасы туплана башлады.

Караңгы төшкәч, 78 нче гвардия дивизиясенең 225 нче полкы һәм 41 нче гвардия дивизиясенең 122 нче полкы, контратакага күчеп, 72 нче гвардия дивизиясенең сугышчан сафларына бәреп кергән дошманны алып ташлады. Аннан соң да гитлерчылар бу биеклекләрне кулга төшерергә күп тапкырлар тырышып карадылар, ләкин уңышка ирешә алмадылар. Биеклекләрне без танклар һәм артиллерия белән ныгыткан идек инде.

Бу сугышларны үз күзәтү пунктыннан карап торган армия командующие:

— Плацдарм хәзер Днепрның сул ягыннан да яхшы күренә, — дип, штабны һәм минем күзәтү пунктын көнчыгыш ярга яки утрауга күчерергә тәкъдим ясады.

— Биредә генә калырга рөхсәт итегез. Минемчә, дошман бүтән биеклекләргә тыкшына алмас. Ул инде хәлдән тайды, — дип җавап бирдем аңа.

Чыннан да гитлерчыларның атакалары зәгыйфьләнде. Резервлар килгәне дә күренми башлады. Самолетларның бомбага тотулары да сирәгәйде.

16 октябрь иртәсендә мин Домотканьга, 24 нче гвардия корпусының 73 нче дивизиясе командиры генерал Козак күзәтү пунктына киттем. Биредә дивизия авылга бәреп кергән гитлерчылар белән сугыша иде әле. Тиздән сугыш тына башлады, шартлау тавышлары сирәгәйде. Данлыклы 73 нче Сталинград дивизиясе гвардиячеләре дошманны авылдан тәмам кудылар.

— Иптәш генерал! Дивизия гвардиячеләре бүген дошманның унике атакасын кире кактылар, аны Домотканьнан алып ташладылар, — диде генерал Козак, горур елмаеп. — Инде бүтән борынын тыгарга хәле җитмәс!

— Котлыйм, иптәш Козак, уңыш белән котлыйм. Үзегезгә һәм дивизиянең сугышчыларына яңа уңышлар телим!

Шул вакыт күзәтү пунктына дивизия командирының урынбасары, минем күптәнге дустым П. С. Молчанов килеп керде. Без кочаклашып үбештек.

Без аның белән 1942 елда Харьков астыннан Донга кадәр чигенү ачысын бергә татыдык, Сталинградны бергә сакладык, Идел буенда, 25 нче гвардия корпусы оешканчы, Төньяк Донец аша бәреп кергән дошманга каршы дивизияне бергәләп контратакага алып бардык. Бер-беребезне шактый вакыт күргәнебез юк иде. Бу очрашуга икебез дә бик шат идек.

Мин телефоннан 24 нче гвардия корпусы командиры генерал Васильевка шалтыраттым, корпусның бүтән участокларындагы хәлләрне сораштым.

— Плацдармны саклап калдык, — диде ул, ышанычлы тавыш белән. — Дошман атакалары бүтән кабатланмас!

— Шулаймы икән?

— Бу аның үз-үзен тотышыннан ук күренеп тора. Гитлерчылар хәлдән тайдылар. Көт, тиздән яңа һөҗүмгә приказ алырбыз!

Васильев 25 нче гвардия корпусы сугышчыларына һәм командирларына сәлам һәм котлау тапшыруымны үтенде.

7 нче гвардия армиясенең плацдармын саклап калу өчен өч атнага сузылган бу каты сугышларда дошманның бик күп җанлы көче һәм техникасы юк ителде. 25 нче гвардия корпусы оборонасы полосасында якынча исәпләү буенча гына да гитлерчыларның 210 танкы һәм үзйөрешле установкалары яндырылды, йөздән артык самолетлары бәреп төшерелде.

Әйе, Днепрны борынгы славяннар юкка гына «Славутич» — «Дан улы» дип атамаганнар. Гитлерчы илбасарлардан азат итү өчен барган сугышларда бу данлы елганың даны тагы да күп тапкырларга үсте. Днепрдагы 1943 елгы сугышлар туктаусыз алга, гитлер фашизмын юк итәргә омтылган гаскәрләргә яңа җиңүләр китерде.

* * *

7 нче гвардия армиясе командованиесе, Днепрны киң фронтта кичүне оештырып, дошманны үз көчләрен бүлгәләргә мәҗбүр итте һәм безнең гаскәрләрнең хәрәкәт инициативасын, резервлар белән маневр ясау мөмкинлеген саклап калды.

Безнең корпусның Днепрның уң ягындагы дошманга каршы сугышы яулап алынган плацдармдагы көчләрне бик тиз арттыру, төп юнәлештәге уңышны үз вакытында файдалану, гаскәрләргә җитәкчелек итүдәге оешканлык белән характерланды.

Корпус сугышчыларының һәм командирларының героизмы, югары мораль-сугышчан сыйфатлары, Сталинград, Курск дугасы, Харьков тирәсендәге сугышларда тупланган тәҗрибәләре Днепрны уңышлы кичүдә зур роль уйнадылар. Командирлар, политработниклар, коммунистлар һәм комсомолецлар катлаулы шартларда үзләренең шәхси үрнәкләре белән барлык сугышчыларны батырлыкларга рухландырдылар. Дивизия, полк, батальон командирлары, аларның урынбасарлары, елганы алдынгы отрядлар белән кичеп, сугышларда батырлык һәм фидакарьлек үрнәкләре күрсәттеләр, үзләренең хәрби белемнәрен, сәләтләрен, коралларын һәм техниканы файдалы итеп, дөрес куллана белделәр. Болар барысы да кыен хәлләрдән җиңүче булып чыгуга мөмкинлек тудырды.

Днепрны уңышлы кичеп чыгу һәм плацдармны саклау сугышларында күрсәткән батырлыклары өчен корпус сугышчыларыннан, офицерларыннан һәм генералларыннан 74 кешегә (шулар исәбеннән миңа да) илебезнең иң югары бүләге — Советлар Союзы Герое исеме бирелде, ун меңнән артык сугышчылар һәм офицерлар орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде. Ә корпуска Верховный Башкомандование тарафыннан дүртенче тапкыр рәхмәт белдерелде..

---

## КАЗАКЪ ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕ

1. Үнәрле үргә менәр.
2. Ят сыйлашырга,
   якын елашырга яхшы.
3. Тоздай ачы булма,
   балдай татлы булма.
4. Күп куркыта, тирән батыра.
5. Башта ми булса,
   ике кулга көч төшәр.
6. Олы булсаң — кече бул! .
7. Алган ярың — җаның.
8. Мәкальсез сүз сакалсыз ияк белән бер.
9. Белемле — үлеп гүрдә мең ел ятсын,
   шунда да чыкмыйдыр кеше саннан.
10. Заман азмас — ил азар,
    ил нидән азар? — Сүздән азар,
    ир картайса, күзе азар,
    күп тик яткан җир азар,
    хатынсыз ир азар,
    якыннары яман хан да азар.
11. Берәүгә берәү ошый, баганага терәү ошый.
12. Кыз чагында кызыл чук,
    хатын булгач, хакы юк.
13. Кайгы — кыз чагында ясмык кадәр,
    хатын булгач, ястык кадәр.
14. Үксезгә киңәш бирүче күп — ризык бирүче аз.

Совет властенең 50 еллыгына

*Гайнулла Курчаков,*
*Галимҗан Насыйров*

# КЕМ ИДЕК ҺӘМ КЕМ БУЛДЫК

«Ульяновск губернасының бернича авылында зур янгыннар булып, алты йөзгә якын өй, бик күп терлек янды.

Шулар эчендә Зирекле күлдә (Кәшәдә) 278 хуҗалык каккан казыксыз да калган» [1].

Ике-өч юлдан торган бу кыска хәбәрнең никадәр күп кайгы-зарны эченә алуын бары тик шул янгын бәласенә дучар булган кешеләр генә бөтен тирәнлеге белән аңлаганнардыр. Әйе, хәсрәт чыннан да зур иде.

1927 елның язы бик коры килде. Игенче агайлар ни турында гәп кузгатмасыннар, әңгәмә шул корылыкка килеп тоташа иде.

Менә шундый көннәрнең берсендә, июнь башларында, йөрәк өзгеч тавыш белән «Янгын!» дигән аваз салдылар. Ул да булмады, Зирекле күл авылының нәкъ үзәгеннән кызыл телле ялкын аралаш кара төтен күтәрелде һәм, абайларга өлгергәнче, салам түбәле бүтән каралтыларны да ут чорнап алды.

Җил көчлерәк иса башлады. Өстендә чагында сүндереп булмасмы, дип маташкан халык, бертөрле дә нәтиҗә булмаганны күреп, үз хуҗалыкларын коткарырга таралып бетте.

Авыл урамнары ярдәм сорап кычкырган авазлар, терлек-туар мөгрәве, балаларның йөрәк өзгеч елау тавышлары белән тулды. Берәү актык өмете булган атын абзардан чыгармакчы булып иза чигә. Ә ат тезген башына асылынган хуҗасын өстерәп артка чигенә. Ут инде салам башлы абзарга якынаеп килә. Хуҗа өстерәвендә дәвам итә. Ләкин ат чыкмый, уттан куркып ут эчендә кала...

Күл кырыенда янгыннан саклап калу өчен өеп куелган йорт җиһазлары яна.

Менә кичке эңгер-меңгер җитә. Урамнарда пыскып яткан утлы күмер өемнәре тезелеп киткән. Кемнәрдер йөгерә-йөгерә бала-чагаларын эзли. Икенче берәүләр, ышыкланырга урын таба алмыйча, әле кичә генә гөрләп торган өе урынына, нигез туфрагына ятып уйга калган.

Әйтергә генә җиңел, ярты көн эчендә 278 йорт кара күмергә әйләнде. Аның өстенә күпме мал-туар юкка чыкты.

Зирекле күл (Кәшә) халкы шушы дәһшәтле вакыйгадан соң кайсы кая таралып бетәр, шулай итеп авылның гомере киселер кебек иде.

Авылның тарихын белгән картрак кешеләр:

— Зирекле күлнең 278 ел гомер итеп мондый ук бәлагә тарганы юк иде әле,— дип сөйләделәр шул вакытта.

---

[1] «Правда» газетасы, № 3670 (22/VI-1927 ел).

Авылның яшәгән яше белән янып киткән йортлар санының туры килүе төрле уйдырмаларга сәбәпче булды. Берәүләр моны яхшыга юрадылар, бүтәннәре — яманга...

«Совет хөкүмәте бәлагә дучар булган кешеләр турында онытмады. Ульяновск губернасына җибәрелгән махсус комиссия тикшергәннән соң, янучыларга ярдәм кулын сузды».

(«Правда» газетасы. 25/VI-1927 ел).

Авыл әкренләп аякка баса башлады. Халыкның бер өлеше, җир аздыктан, гомер буе иза чигүдән котылып булмасмы дип, Ульяновск губернасы Павлов районына урман кырыена күчеп утырды.

Урамнар бераз гына киңәйтелеп, яңа авыл, яңа Зирекле күл калыкты.

Хәйләкәррәк хуҗалыклар кибет ачып сәүдә итәргә керештө, атсызлар атлы булу ягын юнәттеләр. Ләкин... тормыш әкренләп юлга салына башлаганда, 1930 елда яңадан зур янгын булып, өлгертеп кенә кергән яңа өйләрнең йөзләбе тагын янып китте.

Нәкъ шушы елда аерым хуҗалык булып яшәү яхшыга алып бармаганын аңлатып, коллектив хуҗалык төзүгә өндәп, авылга агитаторлар килде.

НЭП дәверендә төрле юллар белән «баеп» киткән кайбер игенчеләр колхоз төзү турындагы бу киңәшләргә салкын карасалар да, ярлы халык, аерым торудан күңеле кайткан халык, «Ни күрсәк тә ил белән күрербез» дип, колхозга язылырга ашыктылар.

Һәм алар ялгышмадылар...

Ульяновск шәһәреннән Буага таба илле километр төньякта, Зөя буе үзәненә урнашкан бик зур татар авылы ул хәзер. Авылның көнчыгышында очтан очка Зирекле күл сузылып ята. Өянке, тал белән каймаланган күл тирәсендә тезелеп киткән калай, шифер түбәле яңа өйләр, авылның көньяк очына, колхозның алма бакчасына барып тоташалар.

Авылның үзәгендә электростанция, радиоузел, больница, сельпо, яшелчә киптерү заводы, клуб, аның күршесендә шәһәр тибында салынган ике катлы культура сарае, урта мәктәп, ике китапханә, биш магазин, политик агарту йорты, коммутаторлы элемтә бүлеге, саклык кассасы, колхоз правлениесе бар. Көнбатыш ягында — шлакбетоннан корылган биналар, анда — терлекчелек фермалары. Аннары гараж, машиналар паркы...

Кичләрен авылда электр утлары кабына. Аның алтын нурлары Зирекле күлдә чагылып, тылсымлы күренеш хасил итәләр. Урамда җыр, гармун тавышлары яңгырый. Авылдан бер-ике чакрым гына арырак Казаннан Волгоградка узучы поезд дөбердәве ишетелә.

Бай авыл диләр үзгынчылар безнең авыл турында. Әйе, бай. Ләкин каян килгән соң ул байлык?

Бу сорауга җавап бирүдән элек, әйдәгез, аның борынгы үткәненә экскурсия ясыйк.

XVII йөзнең беренче яртысында урта Иделдә бер-бер артлы яңа шәһәрләр калкып чыга. Көньяк далалардан килеп һөҗүм итүче калмыклар һәм башка күчмә халыклардан саклану өчен, Чирмешән буенда 1626 елда Мәләкәс бистәсе төзелә. Озак та үтми (1647 ел), Сура үзәнендә Карсун каласы барлыкка килә. 1648 елда, рус патшасы Алексей Михайловичның 10 февральдә чыгарылган указы буенча, Идел белән Зөя елгалары арасына Сембер шәһәре салына башлый.

Бу шәһәрне төзү эшенә руслардан биш йорттан бер, ә ясак түләүчеләрдән (рус булмаган милләтләр) өч йорттан бер кеше төзеләчәк Сембер тирәсенә китерелә.

1649 елда Зөя өязе авылларыннан ясак түләүче берничә татар семьясы, патшага хезмәт итү өчен, Елховка бистәсенә мәңгелеккә күчерелә.

«...Государству конную службу по городу Синбирску в слободу Елховку»[1], — дип язылә рәсми кәгазьләр.

---

[1] П. Мартынов. Селения Синбирского уезда. 1903 ел. Синбирск. 307 бит.

Бу якка үзләре теләп күчеп килүчеләр дә шактый табыла.

Шулай итеп Елховка бистәсенә китерелгән дүрт семья 1649 елда Зирекле күл (Елхсво, озерное) авылы тарихын башлап җибәрәләр.

Бу якларда Тархан, Тимерчән, Алгаш, Муклавыш, Кадыш, Вожжи, Бессоново авыллары инде моңа кадәр үк булганнар. Ә Елховка бистәсендә, шушы Зирекле күл урнашкан тирәдә, авыл булуы мәгълүм түгел. Тик сакланып килгән риваятьләр генә монда Болгар дәүләте вакытында утрак тормыш булуы турында сөйлиләр.

Шундый риваять бар. Хәзерге колхозның алма бакчасы кырында, «Монда изгеләр зираты» дип, озак вакытлар кешеләр гыйбадәт кылганнар. Һәм бу гадәт безнең заманга кадәр сакланып килгән. Моңа таянып бу урында кемнәрдер яшәп-үлгәннәр, биредә торганнар дип фараз итеп була. Чокырлар казыганда тимер кораллар белән кеше сөякләре чыгу да бу фикерне куәтли.

Сембер шәһәрен төзи башлагач, Татештән, Уржум, Карлы, Тиньки, Арча һәм башка яклардан бирегә күп кенә кешеләр күчерелә. Бу яңа килгән кешеләр үзләре күчеп килгән авылларның исемнәрен алып киләләр. Шулай итеп бер үк авыллар ике исемле авылга әверелә: Казан ягындагы Тиньки, икенче Тиньки булып, Сембер тирәсенә дә күчә.

Сембер тирәләрендә җирнең мул булуы Мәскәү боярларын кызыктыра. Хәйлә өчен малайларын алар Сембер тирәсенә эшкә җибәрәләр. Монда килеп исемлеккә «Синбирьянин» булып кергәч, күз төшәрлек җирләр аларга беркетелә. Әлеге яңа алпавытлар исә үз крестьяннарының бер өлешен бу якларга күчереп, яңа утарлар-авыллар салалар һәм бу авылларга үз исем-фамилияләрен тагалар.

Безнең колхозның дүртенче бригадасы — Кашинка авылы — алпавыт Борис Кашин исеменнән алынган.

Өченче төр күченеп килүчеләр авылларына елга, тау, күл исемнәрен биргәннәр. Елхово, озерное дигән исемнең Ольховой сүзеннән үзгәрүен; Ольховой булганчы әле ул Елховка дип аталып йөргәнен исбат иткән документлар әле дә саклана.

Елховка бистәсенә күчерелгән берничә семья ясак түләүче татарлар янына, бай җир эзләп, дүрт гаилә йомышлы татарлар килә. 1664 елдан башлап алар Зирекле күлгә нигез салучылар янында яши башлыйлар.

«Припустили в свой обод», дип языла борынгы документларда. «В свой обод» дигән сүздән авылның коймалар белән яки киртә-читәннәр белән әйләндереп алынуы аңлашыла.

1667 елның керем-чыгым кенәгәсендә: «Ольховой авылында, шулай ук Озерная да 12 бәтен, 3 парсыз һәм 9 ярым йорт санала, ясак 19 ярым хуҗалыктан алына»,— дип язылган. Шуңа таянып бу авылның «Елховозерное» дигән рәсми исеме нәкъ менә шушы елларда формалашкан дип әйтә алабыз.

Авылның Кәшә дигән исеме Кайсардан күчеп килгән Кәшәевтән алынуы бик мөмкин.

Писцовая кенәгәдә стольник Михаил Пушкин һәм язып торучы Матвей Бармин кулы куелган җир бүлү кәгазе барлыкка килә. Моның нигезендә христиан динендә торучыларга һәм көчләп чукындырылган ясак түләүче татарларга, йомышлыларга караганда бер ярым өлеш җир артыграк бирелә.

Йомышлы татарларга, Юеш Бакырлы елгасыннан коры Бакырлыга кадәр, авылның көньяк өлеше тия.

Авыл барлыкка килгән 1649 елда «Соборное уложение» дигән закон кабул ителә. Шушы уложение нигезендә крепостной бәйлелек тәмам ныгый, крестьяннарның хәле тагын да начарая.

Мәскәү боярлары һаман яңа җирләр басып алалар, төрле юллар белән үз биләмәләрен киңәйтеп, ясак түләүче крестьяннарны «кулга төшерәләр». Шуның өстенә рус патшасы Павел I нче йөз меңләп дәүләт крестьяннарын алпавытларга өләшә яки удельга тапшыра. Шулай итеп Зирекле күлнең ясак түләүче чувашлары һәм татарлары да көннәрдән бер көнне удельга әйләндереләләр.

1797 елның 5 апрелендә, Павел I нченең тәхеткә утыру көнендә, 6 бүлек, 207 параграфтан торган «Учреждение об императорской фамилий» дигән закон кабул ителә. Бу «Учреждение» император нәсел-нәсәбәсен асрау өчен удель имениеләрен

һәм дәүләт казнасының керемнәрен билгели. Шулай итеп патшалык үзен һәм населнәсәбәсен асрау өчен удель крестьяннарын барлыкка китерә. Шуннан бирле Зирекле күл игенчеләре күп төрле җәфалар чигәргә мәҗбүр ителәләр.

Удельга әйләндерелгән крестьяннарның тормышы крепостнойлардан артык булмаган.

Ул чагында ук Зирекле күл бай табигатьле авылларның берсе булган. Авылның һәр өч ягыннан урман чорнап алган. Авыл кырыенда ук — мул печәнле болыннар, төрле кош-кортка бай әрәмәлекләр, балыклы күлләр... Көнбатыш якта исә — кара туфраклы чәчү мәйданы. Менә шундый матур, гаять бай табигать тә шатлык китермәгән кешеләргә. Күп кенә елларда уңыш чәчелгән орлыгын да кайтармаган.

Казан губернаторы 1847 елгы отчетында крестьяннарның морҗасыз өйләрдә торуы, җәй көннәрендә куышларда яшәве, татарларның исә үзләре яшәгән өйләрдә терлек асравы һ. б. шундый хәлләр турында яза.

Патша Россиясенең милли политикасы да (чукындыру, халыкларны берсенә берсен өстерү һ. б.) крестьяннарның тормышын авырайтучы сәбәпләрнең берсе була. Зирекле күлдә крепостнойлыкның соңгы елларында керәшен татарларга (ә алар соңыннан христиан диненнән ваз кичәләр) һәм чуашларга 410 җанга (131 йорт) 3959 дисәтинә җир бүленеп бирелсә, мөселман татарларга 564 җанга (197 йорт) 2966 дисәтинә генә җир бирелгән.

Шунысы характерлы: XVII йөздә үк чукындырылган удель татарлары, өйләренә поп йөрүгә карамастан, һаман мөселман диненә кайту турында уйлыйлар. Гасырлар буена «керәшен булып яшәү», әле поп, әле мулла китереп иза чигү аларны туйдыра.

1870 елда алар, прошение язып, Сәйтур Әйделвәлиен Петербургка җибәрәләр. Ул, ислам динен тотарга рөхсәт алып, 1875 елда илгә әйләнеп кайта. Ләкин рәсми кәгазьне Сембердә алып калалар һәм ул 1879 елда гына халыкка мәгълүм ителә.

Яңадан ислам диненә кайткан удель татарларына бу хәлдән соң, чираттагы бүлү вакытында, җир йомышлы татарлар белән бертигез итеп бүленә.

Авыл крестьяннарының сыйнфый катлауларга бүленү процессы һаман көчәя. Хәллерәк йортлар барлыкка килә. Алар башлыча сәүдә белән шөгыльләнәләр. Ярлылардан арышның потын 30 тиенгә сатып алалар да аны 40 тиенгә сәүдәгәрләргә саталар. Ә сәүдәгәрләр исә шул ук бер потны дәүләткә 50 тиенгә «бирәләр». Шул рәвеш алыш-биреш итү һ. б. төрле «кәсепләр» мал табарга юл ачалар.

Идарә итү эшләре удель крестьяннары өчен удель приказы аша үткәрелә. Дәүләт крестьяннары староста сайлап куялар. Старостаның кулында таяк, күкрәгендә — кәнди төбе зурлыгында медаль. Аңа тәртип саклау, халыктан салым җыю, дәүләт эшләрен игълан итү, җыен җыю кебек җәмәгать эшләре йөкләтелә. Җыенда исә мәсьәләне байрак кешеләр хәл итә. Аларны «куштаннар» дип йөриләр. Авыл картлары җыенда үз фикерләрен әйтергә хокуклы. Яшьләр инде җыенга тамаша кылу өчен генә киләләр һәм аргта гына ышкылып йөриләр.

Йорт башына җир бүлү эше унике елга бер үткәрелә. Җир ир балаларга гына бүленә. Җир бүлгәндә, иң элек, уңдырышлы кырларны муллага кисеп калдыралар. Аннары гадәттәге шау-шу башлана. Сугыш-талашсыз гына үткәрелгән җир бүлүне Зирекле күл кырлары белмиләр. Үзенең өлешенә чыккан җиргә игенче үз тамгасын куя. Тамгалар исә шундыйлар: өзәңге, каз аягы, мөгаҗә, катлама, алка һ. б. лар.

Бер карыш җир өчен талашлар үтерешкә кадәр барып җитәләр. Фәтхулла карт, белепме, ялгышмы, бер көнне күршесе Әхмәт Шакиры җиренә үз тамгасын салып китә. Бу хәлгә Шакирның ачуы чыга. Фәтхулладан, тамгасын бозып, үз җиренә генә хуҗа булуын таләп итә. һәм ызгыш-талаш кына низагны хәл итмәгәч, Шакир дүрт кадаклы гер белән Фәтхулланың маңгаена суга. Фәтхулла егыла.

Җир башына салган тамга янына кан агып кала...

Бу турыда авылның бәетчеләре кайгы-сагышлы бәет чыгаралар. Бәет су буйларында берничә ел җырлана да онытыла. Ызгышлар, икенче мәртәбә җир бүлгәнче, беразга тынып торалар.

* * *

Борынгы Зирекле кулдән, әле Чынлы волостена кергәндә ук, кешеләр лашман хезмәтенә дә йөриләр. Берәр авыр эш эшләп аргач, «лашман хезмәте иттем» дигән сөйләмнәрнең безнең заманга кадәр сакланып килүе урман эшләренең нинди булганын бик яхшы аңлатсалар кирәк.

XIX йөз урталарында Зирекле кул Сөендек (хәзер Татарстанның Тәтеш районындагы авыл) волостена күчерелгәч, лашман хезмәте бетерелә.

Дәүләт йөкләмәләре борынгы Зирекле кулдән ясак тәртибендә алына. Аның урамнары ясак җыйганда түгелгән бик күп күз яшенә шаһит. Вакытында түли алмаса яки биш тиен бурычы калса, мескен крестьян тән җәзасына кадәр дучар ителгән.

Салымны ул вакытта хәтта морҗа яки тәрәзә исәбеннән дә салганнар. Салымнардан котылу өчен кешеләр морҗасыз өйдә яшәгәннәр. Тәрәзәләр саны өй саны белән тигез булган диярлек. Салымнарны шул тәртип белән салу бетерелгәч тә, гадәткә кереп китеп, өйләрне бер-ике генә тәрәзәле итеп өлгерткәннәр һәм тәрәзәсез «кара өйләр» ясаганнар.

Салымнарны староста, дәүләт кешеләре һәм пунәтәйләр җыйган. «Бурычы» булган хуҗалыклардан, ай-вайларына карамыйча, йорт җиһазларын тартып ала торган булганнар. Крестьяннар бу бәлаләрдән ничек котылырга белмәгәннәр. Кайберәүләр хәтта салымнардан котылу өчен җинаять кылудан да тартынып тормаганнар. Шундыйларның берсе — Хисаметдин, үз ишләрен җыеп, кеше үтерүгә кадәр барып җиткән. Хәсән Марш дигән берәү йорт тирәсен сипләү өчен атын саткан була. Шул акчаны кулга төшерү һәм аны түләп салымнан котылу өчен әлеге Хисаметдин һәм аның иптәшләре, Хәсән Маршны үтереп, читән артына ыргыталар. Бу җинаять бик тиз ачылып, үтерүчеләр Себергә озатыла. Хисаметдин балаларына «Чебер (Себер сузеннән) ыланнары» дигән кушамат тагыла.

1875 елда авылда яза белүче беренче һәм бердәнбер кеше писарь Сәйпи Хәсәне була. 1895 елда күрше Кайсар авылында «Школа грамоты» ачыла, 1900 елда Зирекле кулда ике мәчет һәм шул мәчетләр каршында ике «мәптәк» барлыкка килә. Мәптәктә ир балалар гына укый.

Күңел ачу өчен авылда бер төрле урын да булмый. Шулай да халык арасында ачы моңны, аһ-зарны сәнгать аша белдерергә омтылыш туа. Авылда скрипка, кубыз, курай уйнаучылар күренә башлый. Иң каты хорафатлары белән халыкны гасырлар буе буып килгән дин бу уеннарны да тыя. Мәхәллә мулласы дин буенча гына түгел, дәүләт эшләре белән дә идарә итә. Мулла сүзе закон сүзе дип кабул ителә.

Бөек Октябрь революциясенә кадәр авылда бернинди дәвалау эше алып барылмый. Кешеләр кырык тартмачыларга, ырымчыларга, өшкерүчеләргә йөриләр. Үлемкитем бик күп була. Менә шул елларның митрика дәфтәреннән (ул әле дә авыл Советында саклана) алынган бернича сан: 1845 елда 38 бала туып, аларның 26 сы чәчәк авыруыннан үлә. 1850 елда 52 бала туа, 35 е чәчәктән үлә.

Йогышлы авыруларга каршы көрәш турында беркем дә уйламый. Ә авырулар таралу өчен исә бөтен шартлар була: мәдрәсәдә 40—50 бала бергә йоклый, семьяда аш-су бер табактан ашала, теләнчеләр бер йорттан икенчесенә кереп хәер эстәп йөри һ. б. Өстәвенә, ачлык елларның әледән-әле кабатланып торуы да төрле авырулар таралуга сәбәп була. 1891 елгы ачлыкны гына алыйк. Бу елдагы ачлык вакытында авылга үләт (холера) тарала. Зират мәетләр белән тула. Яңа зират ачарга мәҗбүр булалар.

Өй тулы бала-чага. Кичләрен аларны «дөмек» дип йокларга яткыралар да чыра яндырып җеп эрлиләр, чабата туныйлар. Тамаклары кипсә, казанда су кайнатып, чәй эчеп җибәрәләр. Сәлам түшәлгән идәнгә төрлесе төрле якка сузылып яткан агай-эне, тирә-күрше җен-парилар, патша кызлары, хәйләкәр таз малай турында озын-озын әкиятләр тыңлыйлар. Булмаса, тормышның авырлыгыннан зарланалар. Кабыктан ясалган сандыкка аркасын терәгән берәү, агачтан киселгән бүкәндә утыручыга кушылып, җырлап җибәрә:

Янар да гына янмас балавыз шәмнән
Якты яна каен чырасы.

Арслан да кебек егетләрне
Баса икән дөнья нужасы.

Инде йокларга вакыт җитә. Ишекне, убыр-фәлән кермәсен өчен, бисмилла әйтеп иплап ябалар. Бете бетсен өчен мунчага эленеп куырылган тунга төренеп салам түшәк өстенә йокларга яталар...

Ара-тирә авылга аю биетүчеләр килеп чыга. Алар һәр кешедән бер чиләк арыш бәрабәренә мичкә өстендә аю биетәләр.

Җәйләрен тузан, ә кышларын кар көртләре белән томаланган авылның гадәттән тыш тар урамнарында: «Барлык яраштыра, юклык талаштыра»,— диган мәкаль йөри. Зирекле күллеләр аны безнең авылдан чыккан дип сөйлиләр. Моның да үз хикәяте бар:

Зирекле күл кешесе Фазлый төрек сугышында (1877—78) катнаша. Яулап алынган җирдә ул бер төрек кызы белән таныша. Авылдагы өч катлы өе, байлыгы белән мактанып, төрек кызын үзенә карата һәм хатын итеп алып кайта. «Кая соң өч катлы өең?» — дип сораган хатынына ул үзләре кайтып төшкән өйнең идән астын, түр өйне һәм түшәм өстен (чорманы) күрсәтеп: «Өч кат ләбаса»,— дип җавап кайтара. Шул көннән башланып киткән ризасызлык болар гаиләсендә гомер буена бетми. Төрек кызына өйләнгәнә өчен «Төрек Фазлый» кушаматы йөрткән бу абзый ике сүзнең берендә: «Барлык яраштыра, юклык талаштыра», — диган мәкаль кыстыра икән.

* * *

Еллар үтү белән Зирекле күлнең табигате ярлылана бара. Кырларында соры туфраклы уйдыклар күбәя. Алар, мәдрәсәдә укучы шәкерт башында ишаеп киткән кутырлар кебек, бөтен басуны тазга әйләндерәләр. Зәя буе әрәмәлекләре арасына сибелгән йөзләгән балыклы күлләр бер-бер артлы батканлыкларга әверелә. Кәшә кырларыннан боргаланып ага торган мул сулы Бакырлы инеше саега; ат йөздерерлек елга кибә, аны таллыклар каплап китә.

Авылның сул ягындагы Зирекле күл белән Зәя арасында сузылып яткан Займище урманын һәм андагы болынны ачлык елларның берсендә куштаннар бик арзан бәягә Васильевка алпавыты Рудольфка саталар. Рудольф, немецка хас тәгәллек белән, анда үз тәртипләрен урнаштыра. Кәшә халкына җиләккә йөрү, коры-сары җыю тыела. Буйсынмаган кешеләргә карата ул иң әшәке җәзалар куллана. Үзенең махсус тәрбияләнгән этләрен өстерә, подвалында ябып асрый, кыйный.

Васильевка белән Зирекле күл авылын Зәя елгасы аерып тора. Бу ике авыл, тигез мая белән салышып, елга кичү өчен сал ясыйлар. Бу хәлдән дә алпавыт Рудольф файдалана. Сал ясау эшен үз өстенә ала һәм әлеге салга бәйләнеше булганга «салаузы» дип йөртелгән болынның печәнен үзенә чаптыра.

Үзара бик талашып яшәсәләр дә, авыл байлары: Хәсни Чатан (малае Чәнки бай), Митәй (малае Шәмши глава) Гафурбай (малае Әхмәтҗан бай) барысы да Рудольфны дус күрәләр. Аңа еш баралар, ничек баю (дәресрәге, ничек халыкны изү) юлларын өйрәнәләр.

Шау-шуга сыныш та сылтау була, диләр.

Көннәрдән бер көнне көтүдән Идрис Юнысының сарыклары югала. Көтүче: «Сарыкларның бары тик Васильевка авылында гына булуы мөмкин»,— ди. Йөзләгән Зирекле күл ирләре, кусәклар, балталар белән коралланып, Васильевкага таба китәләр. Төрле янаулар белән сарык таптыралар. Бер йортта суелган сарык эчәгеләре табып, йорт хуҗасына «самосуд» ясарга карар бирәләр. Килеп өлгергән урядник та талашны баса алмый.

Рус авылының бөтен ир-аты ерак урманга кача. Көтүче килеп, сарыкларның табылуын хәбәр иткәч кенә, канлы кыйнаш булмый кала.

Күрше Кайсар чувашларының әйберләрен, терлекләрен урлап тәңкәләренә тиган Шаһи карт, ниһаять, бер эләгә. Чувашлар аңа җәзаны шунда ук бирәләр: кыйнап үтерәләр. Бу хәбәр Зирекле күл татарларының ачуын чыгара. Бу юлы да бөтен авыл татары җыелып Кайсарга һөҗүм ясый. Качып котылырга өлгермәгән Кайсар кешеләрен кыйнап ташлыйлар. Ул көнне Кайсар авылы кешеләренең берсе дә өйдә калмый. Алар Бузак дип аталган әрәмәлек арасында чатырлар ясап куналар.

Мулла-мутагайлар мондый талашларны хуплый. «Кяферләргә шул кирәк, кара йөрәкләрне үтергән өчен безгә, мөселманнарга, савап кына була»,— диләр.

Моның белән тормыш, билгеле, яхшырмый.

Хәерчелек күп кешене авылдан — кендек каны тамган җирдән — бер кисәк икмәк эзләп, ягага (читкә) китәргә мәҗбүр итә. Уралга, Бакуга, Астраханьга кадәр барып җитәләр.

Зимагурның чалбары
Ямаулыдыр аллары.
Тәмәкегә, аракыга
Бетә тапкан маллары.

* * *

Рус-япон сугышы болай да ачуы ташыган халык массасына дары мичкәсенә ташланган шырпы тәэсирен ясый.

Зирекле күлгә каяндыр бер студент кайта. Ул Мөхитов Имамнарда яши. Бу студентны авылдан авылга Сабирҗан Хөсәенов озатып йөри. Студентның халыкка сөйләгән сүзләре кешеләрнең күңеленә тирән кереп урнаша.

Патша кадәр патшага тел тидерү закон буенча да, дин буенча да олуг гөнаһ итеп саналуга карамастан, әлеге студентның сүзләре телдән телгә йөри: «Патша алпавытлар, байлар яклы гына икән, безне санга да тыкмый икән. Ут капсын патшасына, алпавытына, баена, бикәсенә!» Ахыр чиктә сөйләнеп кенә калмыйлар: «Ичмасам, үзебезнең гомер гомердән изге саналган Займище урманын гына булса да Рудольфтан тартып алыйк»,— дип, җыелышалар да урман кисәргә керешәләр.

Казанда укытучылык иткән Галәлетдин Габбасов та бу елларда туган авылы Зиреклегә кайткан була. Үзенең революцион карашларын ул турыдан-туры халыкка белдерә. Революциянең сәбәпләрен төшендерә.

Ләкин беренче рус революциясе бастырыла, Зирекле күл халкы, эшнең кая барасын сизеп, алпавыт урманыннан кисеп кайткан агачларны яшерә: Зөягә агыза, сазга чыгарып ташлый.

Шулай да авылга берничә дистә атлы казаклар китерелә. Яшереп өлгермәгән Займище иманнәре табылган йорт хуҗалары каты тән җәзасына тартылалар. Рудольф: «Икенче сабак булыр»,— дия-дия, этләрен ияртеп, җигүле тарантаска аркасын терәп, экзекуция вакытында казаклар белән авыл буйлап йөри.

Куропаткинны каргап, мең төрле бәддогалар кылып япон сугышыннан гарипләнеп кайткан солдатлар да үз фикерләрен кычкырып әйтүдән курка башлыйлар. Аның каравы авыл кулаклары тагы да баш күтәрәләр. Авылның үзәк урамында яшел, зәңгәр калай түбәле бай өйләре арта бара. Шәмси глава, Гыймади колак, Әхмәтҗан бай һәм башка тагын берничә кулак, берсеннән-берсе уздырып, яңа яхшы йортлар сала. Аларның көтүләрендә терлекләр саны да бермә-бер арта. Ялчылар да күбәя.

Сембер өязендә җир биләүчеләр исемлегенә Әхмәтҗан Насыйров та кергән. Бу кулак 1901 елда Сембер губернаторы Еремеевның Тарханнан 9 чакрым читтәрәк булган утарыннан 464 гектар җир сатып ала. Шулай итеп ул алпавытлар исемлегенә керү дәрәҗәсенә ирешә һәм авылда поташ заводы ача. Аңа управляющий итеп кулак Җәли Хөсәеновны билгели.

Удель татарлары арасыннан чыккан Гыймади колак та үз байлыгын ишәйтү буенча күп эшли. Арендага җир ала, ростовщиклык белән шөгыльләнә, «очсыз бәягә» ялчылар яллый.

Байлык грамоталы булуны таләп иткәнгә, кулаклар үз балаларын укытырга тырышалар. Алардан мулла-мутагай да калышмый. Авылда газета алдыручылар күренә башлый.

Мәдрәсәдә яңача уку — җәдит кертелә. Байлар тарафыннан кайтарылган Хәбибулла шәкертнең мәдрәсәдә фән укытуы, география буенча җирнең түгәрәк булуы һ. б. турында өйрәтүе иске карашлы муллалар тарафыннан шау-шу чыгаруга сәбәп булса да, Сәлах хаҗиның дәрәҗәсе, аның байлар белән бергә эш итүе һәм җәдитне мактавы бу төр укытуга зыян китерә алмый.

Торган саен, авылда сыйнфый каршылыклар көчәя бара.

Тауасты һәм Бузак болынын алдап үз кулына төшергән һәм аның печәне белән әллә ничә еллар файдаланган Әхмәтҗан бай Насыйров империалистик сугыш алдыннан нәфесен тагын да сузып, башкаларга шобагага чыккан болыннарга да чалгычылар төшерә. Шуңа ачуы килгән халык Тауасты һәм Бузак болыннары печәнен чабып ала. «Дөягә өмет итеп куянсыз да калган» Әхмәтҗан бай бу каруны ничек кайтарырга белми. Байкот ясап тегермәнен туктата, кибетләрен яба, арыкны бүлдерә. Бөтен тау астын су баса. Ярлылар төнлә буаны ерып, суны агызалар. Менә нәкъ шуның өчен авылдан 40 кеше Сембергә озатыла. Алар 10 ар тәүлек төрмәдә утырып кайталар.

Аяз көнне күк күкрәгәндәй булып, авылга сугыш башлану турында хәбәр килеп җитә. Бу хәбәрне ишеткән кешеләр кем ат белән, кем җәяүләп газиз тамгалары салынган, изге тирләре тамган межалы басуларын ташлап, авылга ашыгалар.

Беренче көннән үк 75 кеше, ипи салынган киндер капчыклар күтәреп, сугышка китеп бара. Авылда эшкә яраклы ир-ат бик аз кала. Аты-сыеры булмаган хуҗалыклар саны арта, ә икмәккә туйган гаиләләр саны кими бара. Шуның өстенә бер-бер артлы «кара пичәтле» кәгазьләр килә тора. Сугышта үлгәннәрнең «40 ахшамнарын» уздырып, тыгынып йөрүче муллалар:

— Падишаһ әгъзам хәзрәтләренең боерыгына баш иярга кирәк, аллаһе тәгаләнең тәкъдиренә тел тидермәскә кирәк. Сугышта үлмиләр, шәһит киталәр, урыннары җәннәттә була аларның,— дип вәгазь укыйлар.

— Бу хәлдә яшәп булмый, нидер эшләргә кирәк. Халык күтәрелмичә, сугыш бетмәс ахры,— дигән сүзләр баштарак ышын-пышын, соңрак ачыктан-ачык ишетелә башлый.

Электән дә бик авыр яшәгән авыл сугыш елларында тәмам биртелә. Сугышка алынган 280 кешенең өч ел эчендә 50 сеннән «кара пичәт» килә. Йөзләгәне имгәнеп кайта.

Урамнарда озын моңлы көйләргә кайгы-сагышлы җырлар яңгырый:

«Ай-һай ла гына дигән әй тавышка
Кыр казлары кача камышка;
Тавышларым чыга сөрем булып
Эчемдәге кайгы-сагышка.

Утырма вагон читенә
Җилләр тияр битенә;
Бу сагышның авырлыгы
Үтте йөрәк итемә».

Кышкы көннәрнең берсендә Каюм мулла җыенда: «Инде яңа кояш чыкты, патша төшерелде, җәмәгать»,— дип, февраль революциясенең нәтиҗәләрен әйтә. Халык башта: «Николайны яратмаганнар, инде яңа патша куйганнар»,— дип каршы ала бу хәбәрне. Вакытлы хөкүмәтнең һаман сугышны дәвам итүен күргәч кенә: «Килен кайниш туфрагыннан икән»,— дигән сүзләр тарала.

Беренче мәртәбә Зирекле күл кешеләренә ярлы халыкларның бөек юлбашчысы Ленин исемен Камалетдин Халиков җиткерә, юлбашчы турында солдатта ишеткәннәрен сөйли, аның хезмәт ияләре яклы булуын, сугышка каршы көрәшүен аңлата. Ленин исеме зур ихтирам белән телдән телгә күчеп йөри:

«Ленин дөньяны хезмәт кешеләре кулына тапшыра ала торган бик зур акыллы кеше икән».

«Ленин ул безнең якта туып-үскән, агасын аның патша үз кулы белән аскан икән».

«Ленин бер селтәнүдә тугыз пот йөк күтәрә ала, кешенең күзенә карап нәрсә уйлаганын белә, ди».

«Ленинны Сембердә Мөбин бабайлар күргәннәр. Үзе сөйләгән!»

«Питырбурда патшаның үзе янына кереп котын алган, имеш».

Ниһаять, Россиядә чын-чыннан яңа кояш чыга. Октябрь революциясенең җиңеп чыгуын ишеткәч, барлык тирә-юнь авыллар җир мәсьәләсе белән ыгы-зыгы килергә керешәләр. Алпавыт Рудольф кача. Кәшә халкына, барына өстәп, Займище һәм Банырлы кырларыннан 210 гектар җир бирелә.

Гасырларның астын өскә китергән революцион ташкын шаулары Зирекле күл ярлыларына җир, матур тормышка өмет алып килә. Ләкин бу өметнең тормышка ашуы, тыныч тормышны саклап калу өчен кулга корал алырга кирәк була әле. Гражданнар сугышы кабынып китә. Хәснетдин Биккиниев гражданнар сугышында күрсәткән батырлыклары өчен «Кызыл Байрак» ордены белән бүләкләнә, Гатаулла Самарханов, Ибраһим Измайлов (хәзер персональ пенсионер), Галәлетдин Сөләйманов һәм башкалар Кызыл Гвардия отрядларына үзләре теләп язылалар. Камалетдин Халиков 1918 елда большевиклар партиясе сафына керә. Ул — безнең авылдан беренче коммунист...

* * *

...1930 елның 1 февралендә колхозчы булырга теләп гариза биргән кешеләрнең гомуми җыелышы билгеләнде. Бу җыелыш колхозчыларның тәүге җыелышы саналып, монда эреләндерелгән авыл хуҗалыгы артеле уставы кабул ителде. Правление составы, ревизия комиссиясе сайланды һәм колхозга «Волга» исеме бирелде.

Беренче колхоз язы бик авыр шартларда башланып китте. Кырык җиде йортны берләштергән кумәк хуҗалыкта нибары ун ат, ике сабан, өч тырма һәм 20 пот чәчүлек орлык бар иде. Ләкин дәүләт, бу хәлне белеп, ярдәм кулын сузды: 10 мең сум ссуда бирде. Бу акчага артель тагын җиде ат һәм җитмеш центнер солы сатып алды.

19 апрельдә колхозчылар, кызыл байраклар күтәреп, революцион җырлар җырлап, кырга чыктылар. Өч гасыр буена ызгыш сәбәпчесе булган ызаннар мәңгегә бетерелде. Язгы чәчүгә чыгучылар арасында укытучылар да бар иде. Алар язгы каникулларны махсус шуңа туры китерделәр. 47 хуҗалыкның җидесе укытучылар гаиләсе булганга, оештыру, агит-масса эшләрен алар киң колач белән алып бардылар.

Тырыш хезмәт нәтиҗәсендә 129 гектар чәчүлек мәйданы тиз арада эшкәртелеп, чәчелеп бетте.

Колхозчыларның эштән кайтканын көтеп торучы байрак хәлле аерым хуҗалыклар:

— Менә сатып алыгыз, колхозга ярый ул,— дип, төпсез капчыклар тәкъдим итteләр. Янәсе, колхозчылар эшкәрткән җирләрдә шайтан таягы да үсмәячәк. Янәсе, уртак малны эт ашасын...

Эш белән җәй үткәне сизелми дә калды. Җир-ана куйган хезмәт, кайнар тир хакына гектарыннан йөзәр пот иген уңышы бирде. Бөтен салымнар белән тиененә кадәр санашканнан соң, колхозчылар калган икмәкне җан башыннан гаилә саен бүлеп, кызыл олаулар белән өләшеп йөрделәр. Чын-чынлап күргәзмәле агитация булды бу, төпсез капчык тәкъдим иткән «аерым»нарны муенны кашып куярга мәҗбүр итте.

— Әллә, карчык, тәвәккәллибезме? — диючеләр күбәйде.

«Тәвәккәлләүчеләр» колхозлашуның икенче елында 266 хуҗалыкка җитте. Атлар саны да инде ун мәртәбә артты, чәчү мәйданы да 780 гектарга үсте.

«Волга» колхозының уңышлары авыл кулакларына тынгы бирми иде. Алар халык арасына төрле гайбәтләр тараттылар. Янәсе, колхозның гомере озын түгел, бер-берсе белән сугышып бетәрләр әле... Кулак малайлары урам тутырып колхозга каршы җырлар җырлап йөрделәр.

Коллективлашу башлану елларында авылда мәгариф эшләре киң җәелдерелде.

Уку яшендәге балалар барысы да мәктәпкә тартылды. Җидееллык гомуми мәҗбүри уку тәртибе кертелде. Шушы елларда ук наданлыкны бетерү эше дә башланды. 30—40—45 яшендәге укый белмәгән ирләр, хатыннар, алифба тотып, мәктәпкә йөрделәр. Йорт эшләре, бала-чагалар белән бик мәшгуль хатыннарга өйләргә кереп дәрес бирәләр иде.

Кичләрен мәктәп бинасында, соңрак клубта, еш кына концертлар, спектакльләр үткәрелә иде. «Укытучы Мостафа Фәезовның моңлы җырын ишетеп кайтыйм әле бер, ичмасам»,— дип, апалар, агайлар бу концертларга, спектакльләргә бик яратып йөрергә керештеләр.

Күп кенә халык талантлары да кутәрелеп чыкты. Имам Гафаровның, Мостафа Фаезовның җырларын, Һади Шәмсетдиновның, Нурмый Хәснетдиновның шигырь сөйләүләрен, гармунчыларның, скрипкачыларның уеннарын халык бик ярата иде. Шуңа күрә тирә-як авылларның диндар кешеләре арасында «Зирекле күл — динсез авыл ул» дигән сүзләр дә йөри иде. Дөреслек юк түгел иде ул сүзләрдә. Дин белән бәйләнеш чыннан да бик кимеде. Җитмәсә, «Сугышчан алласызлар түгәрәге» дә оешып китте. Бу түгәрәкне укытучылар оештырдылар. Фән һәм дөнья хәлләре турында алар сөйләгәнне тыңларга халык бик яратып йөри торган булып китте.

Кичләрен урамнарда гармунга кушылып җыр яңгырый, җырларның да хәзер мәгънәсе яңа, аларда моң-зар түгел, кешеләр күңелендәге патриотик хисләр чагыла:

«Ак чәчәк ата чия,
Күк чәчәк ата чия,
Җиңүләрдән җиңүләргә
Алып бара партия».

Бу җыр Кәшә урамнарында елына ничә мәртәбә яңгырамый икән?!

Шул ук урамнарда хат ташучылар Кәшәнең үз басма газетасын өләшеп йөриләр. Әйе, басма газета. Биш меңгә бер чыгарыла торган, тиражы 600 данә булган авылның үз басма газетасы 1934 елда чыга башлады. Исеме «Большевистик колхоз өчен». Редакторы — Галимҗан Хәсәенов, җаваплы секретаре — Фатих Гафаров. Басма газетаны бик яратып укыйлар. Аңа колхозчылар бик актив язылалар. Партия оешмасы хәзер инде үз газетасы аркылы да колхозчылар арасында тәрбия эшләре алып бара. Анда тырыш кешеләр мактап языла, ялкаулар тәнкыйть уты астына алына.

1937 елга инде «Волга» колхозы күп тармаклы хуҗалыгы булган нечле артель булып әверелгән иде. Грозный шәһәреннән кайткан егерме биш меңче Таҗи Котбетдиновны председатель итеп сайладык. Киң күңелле, тырыш һәм тугры Таҗи, эшче булса да, игенчеләрнең кайнар мәхәббәтен бик тиз казанды. Колхозда төзү эшләре киң колач алды. Менә дигән сыер абзарлары, амбарлар салынды. Исхак Хәсәенов җитәкчелегендәге махсус бригада, күп кенә сазларны киптереп, колхоз басуларына менә дигән чәчү мәйданнарын өстәде. Тырыш эшләр нәтиҗәсез калмады, уңыш елдан-ел арта барды. Көннәрдән бер көнне колхозчы Садри Сәйфетдинов, алма бакчасы үстерү хакында сүз кузгатып, бу эшне үз өстенә алды.

Революциягә кадәр ничек кенә тырышып карамады Садри, барыбер үз хуҗалыгын рәткә сала алмый аптырады. Әтисе Сәгъди бабай аңа әйтеп калдырган икән: «Бәхетне, улым, бик иртә өләшәләр, элэктерергә уйласаң, йоклама!» — диген. Садри һәр көн кояш белән берга тора. Йокларга да кояш баеганнан соң гына ята. Иртә таңнан төнгә караңгыга кадәр туктамый эшли, ләкин, ир уртасы булгач кына, үзенә ат юната ала. Бу елларда, кайдандыр килеп, Зирекле күлдән ат урлап китәләр икән. Артыннан барсаң, кыйнап җибәрәләр. Атны авылдан берәрсе озатып тора булса кирәк, дип уйлый авыл халкы. Һәм бу эштә әлеге дә шул һич тә атка тиенә алмаган Садридан шикләнәләр. Исмәгыйль такъва аты югалгач, җыен җыеп Садрины шунда өстерәп китерәләр.

— Син озаттыңмы?

— Нәрсәне?

— Белмәгәнгә салынамы, сал авызына!

— Ни өчен?

— Әле ни өченме?!

Котырынган кешеләр Садрины үтергәнче кыйныйлар һәм нигезләренә китереп ыргыталар.

Озак авырый Садри. Күп төрле уйлар уйлый ул түшәктә. Тормышны, язмышны каргый. Терелгәч тә озак еллар нужалана. Күмәк хуҗалык оешкач, беренчеләрдән булып колхозга керә.

Ул утырткан бакча авылга ямь өстәп елдан-ел матурая. Садри абзый аны 41—42 елгы кечле салкыннардан да саклап калды. Бу бакчада хәзер 3 меңнән артык төп алмагач кына бар. Шуның өстенә анда 10 гектар чамасы төрле җиләкләр үсә.

Авылда бер-бер артлы алдынгы кешеләр, хезмәт батырлары үсеп чыкты. Сарык караучы Кәрим Забировның уңышларын өйрәнергә тирә-як колхозлардан делегация-

лар кила. Уңыш чыннан да зур. Сарыклар фермасы мөдире Җамалетдин Шакмиев белән берлектә Кәрим ага, ясалма орлыкландыру кертеп, 100 баш сарыктан 185 бәрән алуга, һәр сарыктан 2,8 кг йон алуга иреште. Бу уңышлар өчен ферма коллективы Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашты, Мактау китабына кертелде.

Яшелчә бакчасында да уңышлар яхшы. Тирә-юньдә кавын-карбызны әлек бар дип тә белмәгәннәр. Хәзер Зөя буенда, көзге айлар кергәндә, бу көньяк җимешләре тау-тау булып өелә. Помидор, кыяр, кәбестә һәм башка яшелчәләр алырга шәһәрдән, тирә-як авыллардан халык килә. Яшелчә бакчасы җитәкчеләре Салихҗан Хәсәнов, Әкрәм Ураев 1939 елда ук Күргәзмәгә катнашу хокукын яулап алдылар.

Фәнгә, алдынгы тәҗрибәләргә таянып эшләү һәм тырышлык нәтиҗәсендә, «Волга» колхозы басуларында һәр елны мул иген уңышы җитешә.

1940 елның кышкы көннәреннән берсе бик зур шатлык китерде: колхозның ышанычлы вәкиле итеп җибәрелгән Әхмәтҗан Хәсәенов, Кәрим Биктимиров иптәшләр Мәскәүдән кайттылар. Аларга Михаил Иванович Калинин үз кулы белән СССР Верховный Советы Президиумының Грамотасын һәм «Почет билгесе» орденын тапшырган иде.

Грамотага болай язылган: «Авыл хуҗалыгын күтәрүдә күренекле уңышлары һәм Авыл хуҗалыгы күргәзмәсе күрсәткечләрен 1937, 1938 елда үтәве һәм арттырып үтәве өчен Кәшә (Зирекле күл) авылы Советы, «Волга» колхозын СССР Верховный Советы Президиумы «Почет билгесе» ордены белән бүләкли».

Тантаналы җыелышта колхозчылар артель хуҗалыгын, туган илебезне ныгытуда фидакарь хезмәтләрен кызганмаска сүз бирделәр.

Икенче елда яңа төр уңышлар өчен өлкә тарафыннан бирелгән 10 мең сум акчага колхозчылар бөтен авылны радиолаштырырга булдылар. Колхозчы өйләрендә, әйе, әкиятләр һәм төрле мәзәкләрдән, авыр тормыштан зарланудан башканы ишетмәгән авыл өйләрендә, Казан, Мәскәү тавышы яңгырый башлады.

Гасырлар буе татлы хыял булып кына килгән мул, матур тормышта яшиләр иде инде колхозчылар. Авыл өйләрендә радио гына түгел, Ильич лампалары нур чәчә иде. Өстәллардән сый төшми иде.

Ләкин радио бәгырьләрне өзгеч хәбәр китерде:

— Германия фашистлары безнең илгә каршы сугыш башлаган...

Дошманга каршы сугышка авылдан 426 кеше китте. Бөтен эш картларга, хатынкызга, яшүсмерләргә калды. Хасан күле янында япон самурайларына каршы сугышта катнашып, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән Гәрәй Әхметов, немец фашистларына каршы сугышка киткәндә, авылда калган апалардан: «Ирешелгән уңышларны юкка чыгармагыз инде, авыр булса да яхшы эшләгез!» — дип үтенде. Госман Ильясов, Хәмидуллов Вәли, Мортаза Ильясов сугыш хәбәрен ишетүгә, райвоенкоматка барып: «Безнең урын анда, фронтта»,— диделәр.

Бу елларда: «Менә бу яхшы эшләде», — дип, кемне дә булса аерып күрсәтү башкаларны кимсетү кебек тоелыр иде, чөнки бөтен авыл, бал корты иле кебек, җиңү тәэмин итү өчен җан аямый эшләде.

Шуның өчен авыл материаль яктан артык ук аяктан егылмады. Ләкин 4 ел сугыш, авылдан 69 кешенең гарипләнеп кайтуы, 206 кешенең бөтенләй югалуы эзсез каламыни?

Әйе, фашистлар китергән шундый зур бәхетсезлекләр тормышны бик нык авырайтты.

Бөтенесен яңадан башларга кирәк иде. Авылның күп кенә ирләре салмакланып, тормышны тагын да артыграк яратып, күкрәкләренә күп кенә орден-медальләр тагып илгә әйләнеп кайттылар.

Партия оешмасы, авыл Советы, колхоз правлениесе колхозчыларны сугыш вакытында туган авырлыклардан арыну өчен хезмәткә, хуҗалыктагы артталыкны бетерүгә тупланды. Җаваплы урыннарга тәҗрибәле кешеләр, коммунистлар билгеләнде.

«Волга» яңадан аякка баса башлады.

Авырлыклар әкрен генә артка чигенде.

Ниһаять, менә колхоз үзенең утыз еллык юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнә.

Шифер, калай түбәле өйләр өстендә ал байраклар җилферди. Февраль аеның кич-

ле бураннардан соң урнашкан тыныч көне. Иртән иртүк инде тәҗрибәле радистлар — Мөстәкыйм Ильясов һәм Фәрит Ибраһимов — колхозның өченче бригадасы өчен Чабаксарны, калганнары өчен Казанны тоташтырганнар. Авыл урамнарында музыка яңгырый. Чувашлар, татарлар клубка, үзләренә бәхетле тормыш тәэмин иткән колхоз бәйрәменә агылалар. Тиздән мена үзәк утардан җиде чакрымга урнашкан дүртенче бригада кешеләре килер. Анда руслар яши. Күп милләтле интернациональ колхоз тантаналы утырышны ачар.

Шәп чабышкыларга утырып, дугаларны ал тасмалар белән бизәп, күрше авыллардан кунаклар килә. Әнә, чана артына нәселле айгыр тагып, «Победа» колхозы председателе килеп чыкты. «Волга» белән ярышучы бу колхоз безгә иң яхшы айгырларының берсен бүләк итәргә булган.

Ульяновск шәһәрендә ясала торган «УАЗ» маркалы җитез машиналарга утырып, район җитәкчеләре килде. Өлкә партия комитетыннан авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире иптәш Давыдов, мишәрчәләп:

— Бөген тышта суык булса да, сездә елы икән. Бәйрәм елысы белән котлыйм, егетләр,— дип, аксакаллар белән килеп күреште.

Клуб тирәсендә, рәшәткәләр буйлап, транспарантлар тезелгән. Анда колхозның утыз елда нинди уңышларга ирешүе күрсәтелгән.

Клубның тәрәзәсез ягында зур итеп эшләнгән колхоз картасы. Шунда ук бер плакат бар. Ул колхозда 5827 гектар сөрүле җир, аны эшкәртү өчен 23 трактор, 12 комбайн, 16 автомашина һәм, иң мөһиме, 1220 хезмәткә яраклы кеше булу турында сөйли.

Күршесендә ук —1552 баш эре мөгезле терлек, 2510 баш сарык, 1350 баш дуңгыз булган фермалардагы уңышлар, ит җитештерү планының тулуы, һәр сыердан 2510 кг сөт савып алыну турында аңлаткан плакат.

Клубның бөтен стенасы буена «Алга — коммунизмның җиңүенә» дигән зур һәм матур итеп язылган лозунг эленгән.

Менә клуб залы. Тантаналы җыелыш ачылырга тора.

Сәхнәдә — кызыл комач эскәтер җәйгән өстәл, өстәл артында кунаклар, колхоз ветераннары, колхоз җитәкчеләре, хезмәт алдынгылары утырган...

Кемнәр генә юк залда. Әнә шикәр чөгендере үстерү осталары: чуваш Васильев Август белән татар Тимерша Бәлтиев утыра. Алар бөтен бригада күләмендә һәр гектардан 250 центнер чөгендер алуга ирештеләр. Икәү кызып-кызып ни турындадыр сөйләшәләр. Алар янына комбайнчылардан Василий Дементьев белән Нуретдин Сәйфетдинов, алдынгы сыер савучылар Фәридә Фәтхуллина белән Мария Белова, терлекчеләрдән Володя Грушин, Галимҗан Сәйфетдинов, Василий Дементьев, көтүче Әхәт Мөхитов, укытучы Корбан Кадыйров утырганнар.

Тантаналы җыелыш ачыла.

Партия комитеты секретаре Заһит Ибраһимов, колхоз ветераннарын, хезмәт алдынгыларын, бөтен колхозчыларны тәбрикләп, 9 елдан бирле председатель булып эшләүче Харис Газизовка сүз бирә.

...30 ел. Чал тарих өчен бу утыз ел бик кечкенә бер өзек булса да, кеше гомере өчен байтак вакыт. Өч гасырда ирешелмәгән уңышлар менә шушы өч дистә елда яулап алындылар.

Җыелыш озак барды. Бик күп кешеләр партиянең өлкә комитеты, өлкә башкарма комитеты Мактау грамоталары, кыйммәтле әйберләр белән бүләкләнделәр.

Менә трибунага Әсхәт Хәбибуллин күтәрелде.

— Мин яшь кеше әле, иптәшләр. Урта мәктәпне бетергәнемә ярты гына ел. Шәһәргә китәргә ниятләп тора идем, бүген башка карарга килдем. Үзебезнең туган колхозыбызда эшкә калам. Нинди генә эш бирсәләр дә риза,— диде ул.

Моны хуплап, көчле кул чабулар яңгырады.

Колхоз ветераны, элекке колхоз председателе, биш орден һәм бик күп медальләр кавалеры Галимҗан Хөсәенов сүз алды.

— Безнең фидакарь хезмәтебез, иптәшләр, гади генә итеп әйткәндә, әнә, барысы да алтын белән язылганнар,— дип ул стенага тезелеп эленгән күп сандагы грамота-

ларга, дипломнарга тертеп курсәттс. Әйе, яулап алынган уңышлар берсе дә онытылмаган. Алар барысы да билгеләнеп үтхәннәр.

Кырчылык буенча өлкәдә беренче урын алган «Волга» колхозына:

— Һәр гектардан 20 центнер тары уңышы алган өчен;

— Чәчүле пар җиренең һәр гектарыннан 15 центнер арыш уңышы алган өчен;

— Яшелчә бакчасында мул итеп яшелчә орлыклары җитештергән өчен;

— Алма бакчасында мул итеп җимеш-җиләк үстергән өчен;

— Нәселле яхшы айгырлар ярышында беренче урынны алган өчен;

— Сарык фермасында югары күрсәткечләр өчен;

— Колхозда спорт җәмгыятенең яхшы эшләве өчен;

— Умартачылык буенча күп итеп товарлыклы бал җитештергән һ. б. лар өчен бирелгән алар.

— Бу уңышларның һәрберсе турында китап язарлык, — диде оратор, сүзен тәмамлап.

Җыелышка күп санда килгән котлау телеграммалары укылды.

Подполковниклар Гадельша Измайлов белән Нургали Фәезов, башкалабызда завод директоры булып эшләүче Яхъя Фәезов, Волгоградтан РСФСРның атказанган укытучысы Миннур Юмаева, Урта Азиядән банк управляющие Нурми Насыйров, Карагандадан шахтер Әхәт Идрисов, Казаннан пилот Рәшит Ибраһимов, башка бик күп авылдашлар, укытучылар, врачлар, эшчеләр җибәргән ул котлауларны.

Җыелыш беткәч тә, зиреклe күллеләр кайсарлыларны, кашинлеләрне кунакка алып киттеләр. Татар өендә рус, чуваш халкы вәкилләре — революциягә кадәр гомер буе талашып килгән кешеләр — бер-берсен тәмле азыклар белән сыйладылар. Бу инде күптән гадәткә кергән кунакка йөрешү. Утыз-ныры елдан бирле шулай ул.

Күп милләтле күмәк хуҗалыкның дуслык белән ныгытылган мул тормышы күңелле дә, шатлыклы да...

—✦—

# Язучының иҗат портреты

*Гариф Ахунов*

## Җир һәм күңел җылысы

### 1

Сабый чакта укыган китап белән сабый чакта күргән төш онытылмый, ахрысы. Әле бик бәләкәй чакта ук безнең болынга ай төшеп, аның аппак зур көмеш тәселе тәгәрәп йөргәнен төштә күргән идем. Бүгенгә чаклы ул минем иң якты, иң матур төшем булып хәтеремдә саклана. Хәреф таный башлагач, китапханәдән алып укыган беренче китапларым — «Соңгы сугышу», «Ике дус», «Ана хикәясе» дә шулай ук исемнән чыкканы юк. Мин әле ул чакта аларның өчесен өч язучы язгандыр дип тә башыма китерми идем. Гомәр Разин, Ибрай Гази, Фатих Хөсни нигәдер өчесе бер автор булып күңелгә кереп калганнар.

Бераз үсә төшеп, инде бишенче класста укыганда бугай, безнең әдәбият укытучыбыз Хәнифә апа Абдуллина, мәктәптә дәресләр беткәч, теләге булган балаларга кычкырып китап уку, язучылар турында сөйләшү сәгатьләре оештыра башлады. Беркөнне ул бездән, «китап чире йоккан» малайлардан, кемнең кайсы язучыны белүе турында сорады. Мин уйлап-нитеп тормастан:

— Гомәр Разинны беләм! — дип әйтеп салдым.

Малайлар, бик сәерсенеп, борылып карадылар. Алар минем сүземне, язучының үзен күреп белү дип аңладылар бугай, ахрысы. Бездә әле тере язучыны күреп белүче юк иде ул чакта. Мин иптәшләремнең сәер карашларыннан уңайсызланып, югалып калдым.

Бу бәладән укытучым Хәнифә апа коткарды.

— Ә нигә? Гариф бик дөрес әйтә. Ул Гомәр Разинны хикәяләре буенча белә. Язучының үзен бер мәртәбә күреп калуга караганда, аның язган әсәрләрен укып белү, һичшиксез, әйбәтрәк, — диде.

һай, алтын сүзләр!

Чыннан да, язучы бөтенләе белән әсәрләрендә бит ул. Анда аның тойгылары, анда аның күңел җылысы, ашкындыргыч хыяллары, дөньяны үзенчә тануы һәм үзенчә бәяли белүе. Шуңа күрә кайберәүләрнең: «Мин ул язучыны күреп беләм», дип мактануына караганда, «Мин ул язучының фәлән әсәрен укып чыктым», дигән сүзе миңа күбрәк ошый.

Әйе, Гомәр Баширов (Разин) әсәрләре белән бик күптән, утызынчы елларда ук танышкан идем. Авыл халкын укырга-язарга өйрәткән заманнар. Ун өенең берендә, сукыр лампа яктысында, агайлар, карандашны төкереклэп, бик тырышып дөнья гыйлеменә өйрәнәләр иде. Безнең өйдә дә сакаллы сабыйлар сабак укыйлар, каядыр шунда бер почмакка сыенып, мин дә китаплар дөньясына чумам. «Соңгы сугышу» да, «Һашим каны» да Гомәр Башировның беренче каләм тирбәтүләредер дип ул чакта башыма да китермәдем. Аларның сабый күңеленә тәэсирләре шулкадәр зур булган, күрәсең.

Хәзер инде мин Гомәр Башировны якыннан беләм. Татарстанның өлкән язучыларыннан берсе, зур такыр башлы, бик юаш, хәтта оялчан табигатьле, ләкин әдәбият мәсьәләсенә килгәндә бик үз сүзле, принципиаль карашлы бу агай миңа (юк, бер миңа гына да түгел!) аякка басарга, әдәбиятта үз сукмагымны табарга булышты. Утыз ел вакыт эчендә ул язган барлык әсәрләрне — аның беренче хикәяләрен дә, повестьларын да, бөтен илгә танылган «Намус» романын да кат-кат укыдым. Барысын беләм, барысы таныш, аның әсәрләре турында җиде төн уртасында уятып сорасалар, шатырдатып әйтеп бирә алырмын кебек. Ләкин мин әле аның әсәрләрендәге нәрсәнедер белмим, әнә шул «нәрсәдер» серле булып, менә гел дулкынландырып тора. Нигә шулай? Ник дулкынландырып тора? Әнә шул тойгыларымны укучылар белән уртаклашасым килә.

## 2

Кайсыдыр бер съезд трибунасыннан мәрхүм Мәхмүт Максуд болай дип сөйләгән иде:

— Мин, иптәшләр, үз гомеремдә иң югары, иң башлангыч мәдрәсә белеме алган язучы...

Юк, ул моны кылтаеп, яки мактанырга теләп әйтмәде, ул чорда белем алуның, димәк, әдәбиятка килүнең дә никадәр авыр булганын бүгенге яшьләргә аңлатырга теләп әйтте. Чынлап та, өлкән буын әдипләребезнең иҗат юлы җиңел булмаган. Үзлегеңнән белем ал, үзлегеңнән язарга өйрән, сәнгатьнең тылсымлы көченә төшен. Шуның өстәвенә син әле, кулыңа корал тотып, яшь советлар республикасын дошманнардан сакларга һәм моңарчы күрелмәгән өр-яңа дөнья төзергә тиешсең. Боларның барысын башкарып чыгу, бигрәк тә, кешелек җәмгыяте гасырлар буена тудырган сәнгать җәүһәрләрен аңлау, аларны өйрәнү өчен вакыт та, тырышлык та бик күп кирәк бит. Нәфис сүзнең кешеләрне сихерли ала белү хасиятенә төшенмәсәң, күңел түреңдә йөрткән иң изге, иң мөкатдәс уйларың белән саубуллашырга туры килә. Үз сүзеңне әйтерлек, кешеләрне кайнар сүзең белән канатландырып, тергезеп җибәрерлек булмагач, язучы булам дип йөрүең кемгә хаҗәт!

Гомәр Башировның тормышы ил язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Фрунзе гаскәрләре сафында ул Перекопны сугышып ала. Беренче колхозларны оештыруда катнаша. Беренче буын совет балаларын гыйлемгә өйрәтә. Һәм әнә шул үз халкының язмышындагы борылыш моментларын романтик күтәренке, ялкынлы әсәрләрендә, үсмер чактагы күңел хыяллары белән үреп, сурәтләп бирә. Аның иҗатында елдан-ел тормышның яңа катламнары, яңа күренешләре ачыла бара.

«Һашим каны» белән «Соңгы сугышу» — язучының утызынчы еллардагы кумәк хуҗалык кору вакыйгаларыннан алган, беренче мәртәбә каушап һәм дулкынланып каләм тибрәтүе булса, «Әни» — үткәндәге авыр һәм караңгы елларның хатирәсен бөтен ачылыгы белән күңелдән үткәрү.

«Минем үземә язачак әсәрләремнең идеясен беркайчан да «түшәмнән» әзләп утырырга туры килмәде шикелле, — ди язучы «Тормыш сукмаклары» исемле очеркында. — Аларның һәммәсенең дә беренче яралгылары тормыштан «борынлап» чыга иде. «Әни» дигән хикәямне язу теләге көз көне урман буеннан узып барганда уянды. Каты җилдә карт агачлар шыгырдый, шулар арасында яңгыр астында утынга килгән начар гына киемле бер хатын-кыз йөри иде. Бу күренеш менә нигәдер дулкынландырды, уйларымны бала чакка алып китте, авыл ярлыларының урманнан күтәреп утын ташулары, аларның кызганыч тормышы күз алдыма килде. Бераздан шул уйларга, кичереннүләргә бүтәннәре кушылды, барысы бергә куера торгач, шуннан хикәя килеп туды.»

Без бик күп язучыларның, шул исәптән дөнья әдәбиятында үлмәс гәүһәрләр тудырып калдырган язучыларның иҗат итүләре хакында язганнарын укып беләбез. Язучылык эше — гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган, әллә нинди бер сихри хезмәт. Кайберәүләр беркайчан да кесә дәфтәре йөртмәүләрен, барлык язганнары хәтер җимеше булуын әйтәләр. Икенче берәүләр феноменаль хәтерле булу өстенә, туктаусыз куен дәфтәре кулланалар, зур романнарын язганчы барысын күңелдән кичереп, хыял белән баетып кына калмыйлар, аның геройларын, шахмат тактасына тезгән кебек, башта бик җентекләп кәгазьгә язып, планын корып чыгалар.

Гомәр ага белән аерым әңгәмәләр вакытында да, иҗаты хакында үзенең язганнарын укып та мин бер нәрсәгә төшендем: Башировның эшләү алымы — тулысынча тормышка таяну. Күңелне кузгатып, җәрәхәтләп яки сөендереп узган вакыйгалар аны күбрәк дулкынландыралар. Әнә шул вакыйгалардан, аннары — тышкы бер котелмәгән этәрештән дип әйтимме — язылачак яңа әсәрнең очкыны туа.

Аның иҗат биографиясендә әһәмиятле урын тоткан «Сиваш» повесте бар. Әсәрнең вакыйгасы — гражданнар сугышы: солдат Гомәрнең үз башыннан узган чын хәлләр, кызыл солдатларның туганлык, дуслык хисләре, ил өчен утка керүләре.

Бу әсәрнең безнең әдәбияттагы урыны турында озын-озак сөйләп торырга кирәкми. Мирсәй Әмирнең «Агыйдел»е, Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы утызынчы еллар әдәбиятында нинди урын тоткан булсалар, «Сиваш» та һич икеләнүсез шул сафта атлап бара. Повестьның, заман сынавы үтеп, кат-кат басыла алуы, соңгы елларда Мәскәүдә русча да чыгу факты безнең фикерне тагын бер мәртәбә раслый.

Ләкин минем әйтәсе килгән сүзем ул түгел әле. Ни өчен «Сиваш» 1930 елларның башында ук язылмаган, 1938 елда гына чыга алган? Нигә повесть укучыларны шушы көннәргә тикле дулкынландыра ала?

Бая әйткәнемчә, Баширов — артык салмак, артык юаш табигатьле. Ул үзе вакыйгалар тудырып, үзе бик хотәр сюжетлар оештырып, шаулап яши белми. Аңа ниндидер тышкы бер этәргеч, «толчок» кирәк. Гәрчә гражданнар сугышын ул бик яхшы белсә дә, аның турында зуррак әсәр язу уе күптән инде күңелендә бөреләнеп йөрсә дә, никтер һаман башлап китә алмый. Рәхмәт төшкересе, юк бит әлеге этәргеч!

Шәриф Камал да, Кави Нәҗми дә аңа гражданнар сугышы турында зуррак әсәр язарга киңәш итәләр. Ниндидер бер йомыш белән авылларга чыккан чакта Фатих Кәрим дә шул хакта сүз кузгата. Юк, язылмый китап. Салкын тимерне кып-кызыл итеп кыздыру өчен аны утлы күмер өстендә тотарга, өстәвенә әле тимерче күрүгеннән бик нык өрдереп торырга кирәк. Язучы унбиш-уналты еллар элек башыннан кичергәннәрнең инде салкыная, сүрелә төшүен тоя. Шуңа күрә 1936 елда махсус командировка алып, Украинага, Кырымга барып чыга. Анда ул үзләренең Сиваш дивизиясе узган тарихи урыннарны тагын бер мәртәбә әйләнә. Теге чакта, гражданнар сугышы барган көннәрдә, аларның дивизиясен төнлә белән Сиваш диңгезе аша алып чыккан Оленчук дигән партизан картны эзләп таба... Алар икәүләп тагын бер тапкыр Сивашны кичеп чыгалар. Үткәннең дәһшәтле көннәре әкренләп күңелдә терелә, кабатланып, яңара башлый. Шуның өстәвенә язучы Кырымның өлкә архивында утырып, дивизиянең элекке командирлары, комиссарлары язган истәлекләр белән таныша. Кеше күңеле бик сизгер бит ул. Менә синең элекке командирыңның бер имзасы, менә аның бер боерыгы — син шунда аның тесен-битен, тавышын, аяк атлауларын исеңә төшерәсең! Шул кирәк бит инде язучыга! Менә кайчан салкын тимер ут кебек кыза һәм үзеннән кайнарлык бөрки башлый. Бер сүз белән әйткәндә, яшь язучы уналты ел элек булып узган тарихи вакыйгаларны, гражданнар сугышының кайнар сулышын тагын бер тапкыр бөтен җаны белән хис итә.

«Сиваш» повесте әнә шулай язылы.

Инде бу повестьның, гомуман әдәби әсәрнең, безне дулкынландыра алу ягына килик. Нигә бер ише әсәрне тоташ бер сулыш белән укыйсың? Ә икенчесе сине тамчы да мавыктыра алмый. Баксаң — икенчесендә тормышның зуррак, катлаулырак яклары күтәрелгән. Бу хакта мин күптән уйланам, ләкин төп сәбәбен үзем өчен ачыклап җиткергәнем юк иде әле. Моны миңа бик гади һәм кыска итеп, Әмирхан Еники аңлатып бирде. Ниндидер бер хан үзенең өч улыннан бүләк сораган. Туган көне-мазары була бугай, ахрысы. Ханның олы улы агачтан юнып, әтисенә күгәрчен ясап

алып кила. Бик матур, бик пөхтә ясалган бу күгәрчен. Ләкин ханны канәгатьләндерми. Икенче улы абыйсыннан да уздыра, ул инде күгәрченне чын каурыйлар белән бизи, хәтта томшык та ябыштыра. Хан барыбер канәгать түгел. Өченче улы да күгәрчен ясый, тик ул аны ясап бетергәч, әтисенә бирер алдыннан, хаят суына манып ала. Күгәрченгә җан иңә һәм ул канат кагып очып китә. «Безнең күп кенә әсәрләребезнең җаны юк, алар хаят суына манып алынмаганнар», — дип аңлатты миңа Әмирхан Еники. Әйе шул, җансыз әсәр, никадәрле генә зур проблемалар күтәрмәсен, никадәрле генә күп һәм олы геройларны бирергә тырышмасын, безне җылытмый.

«Сиваш»та данлы полководец Фрунзе бар, уңышлы язылган командирлар, политруклар бар. Ләкин алардан бигрәк мине, укучы буларак, гади кызылармеец Шәмси күбрәк җылыта, күбрәк мавыктыра.

«Ул хәзер ялгыз, ул хәзер әллә кайларда, аның туган яклары бик ерак калган иде инде...

Шәмси бара торган көенә башын чайкый-чайкый, күңеленә килгән җырны көйләп җибәрде:

Йөгереп китәрдәй булам,
Кайтып җитәрдәй булам,
Кечке салкын җилләрдә,
Туган-үскән илләргә шул,
Туган-үскән илләргә.

Их! Ничек итептер менә, күз ачып йомган арада, авылга кайтырга иде дә, Киек тавы башыннан торып, җырлап җибәрергә иде. Судан кайтучы кызлар бер аягын баскач, икенчесен атларга онытып, яшь киленнәр сыер савуларын бүлеп, карт-корылар кулларын колакларына куеп рәхәтләнеп тыңласыннар иде. Ишетсеннәр иде дә, моңланып, җырлаучының тавышын танып, хәйран калсыннар иде. «Әнкәем, Шәмси кайткан! Шәмси тавышы бит бу!» — дип Нәсимә йөгереп чыксын иде...»

Монда мин үземне таныйм, ерак юлларга чыкканда кичергән сагышларымны табам. Бик күбебез өчен уртак сагыш, уртак моң бар монда. Бу өзектә әле Шәмсинең тесе-бите дә, кыяфәте дә әйтелми, әмма аның уйлау рәвеше, аның сагышлану, фикер йөртү рәвеше минем күз алдыма хыялымда үзем тудырган кешене җанлы итеп күрергә җитә кала. Инде хәзер аерым бер кешенең, әдәби персонажның типик образга әйләнү мәсьәләсенә кайтып карыйк. Язучы хыялында, язучы аңында туган татар егетенең, гомумиләштереп әйткәндә, татар халкының уй-фикер йөртү рәвеше түгелмени бу? Бик урынлы килеп кергән халык җыры да, «әллә кайларда» кебек ераклык үлчәве дә, судан кайтучы кызларның бер аягын баскач, икенчесен атларга онытып җыр тыңлавы да, егетнең сөйгән кызы Нәсимәнең «Әнкәем, Шәмси кайткан!» дип дәшүләре дә — барысы да чын һәм үзенчәлекле-милли. Ә бит сагынып яши белү тойгысы, туган илләргә карата олылык, ихтирам тойгысы — бар халыклар өчен дә уртак тойгы. Шуңа күрә дә ул үзенчәлекле-милли халәтендә бүтән халыклар күңеленә дә кереп урнаша ала.

Димәк, әдәби әсәргә «җан өрү», аны хаят суына манып алу ул — язучының үз әсәренә күңел җылысы салуы, аны иң изге, мөкатдәс тойгылары белән җылытуы, ул аның үз халкы тормышы белән яшәве дигән сүз булып чыга түгелме?

## 3

Мин гомерем буе җирне һәм Ватанны олылап яза белгән әдипләрдән көнләшеп яшим. «Нигә, ул сыйфат язучыларның һәммәсендә дә юкмыни?» — дип сораулары мөмкин. Ул сыйфат барлык язучыларда да бар, шуннан башка язучының булуы да мөмкин түгел, әмма кайбер язучыларда әнә шул хис аерата үткен, аерата көчле була. Мәрхүм Фатих Кәрим шундый булган. Аның кайсы гына шигырен алып карама — илгә турылык, җирне ярату, болыннарны, чишмәләрне, шомырт чәчәкләрен ярату күздән яшь китерер дәрәҗәдә чын һәм тирән. Тойгылар тирәнлеге ягыннан, минемчә, ул татар совет шагыйрьләренең күбесеннән өстен.

Гомәр Бәширов нәкъ менә туган-үскән җирне олылаучы язучылар рәтенә керә. Тик аның әсәрләрендә илгә булган мәхәббәт, җирне олылау хисе күзгә ташланып,

чекерәеп тормый. Әйтик, тукымага буяу ничек сеңган булса, Баширов әсәрләрендә дә илне, җирне ярату хисе әсәрнең тукымасыннан аерып алып булмастай дәрәҗәдә табигый булып, бер бәтен булып яши. «Намус»ны укыган чакта үзеңне гел хуш исле үләннәр арасында, болын тугайларында итеп тоясың, язның шыпырт сулышын һәм башаклар кыштырдавын ишетәсең; сине гаҗәеп тыйнак һәм эчкерсез кешеләр, хәтта беренче карашка басынкырак, тоныграк кешеләр мөхите уратып ала. Сиңа рәхәт. Болар синең якыннарың, боларга син ышанасың, алар сине уңайсыз хәлдә калдырмаячаклар. Алар кеше җилкәсенә ышыкланып яшәргә өйрәнмәгәннәр. Авыр сынау сәгате суккач, шушы басынкы гына, күзгә әллә ни бәрелеп тормый торган кешеләр үз җилкәләренә көч җитмәстәй авыр йөкне, сугыш йөген күтәреп алалар. Айһай лабаса, кыен бит безгә, дип әйтмиләр, сыкранмыйча-ыңгырашмыйча, тешләрен кысып бара бирәләр. Һәм син аларның батырлыгына таң каласың. Фронтта газиз ирен югалту, кайбер вак җанлы кешеләрнең гайбәт сүзләрен ишетеп тору, җитмәсә, фронт өчен дип үстергән бодаеның кулак Сәйфи тарафыннан урлануы — болар берсе дә Нәфисәнә рухи сүндереп-сүрелдереп кала алмыйлар. Гаҗәеп тирән һәм фидакарь бер ярату белән ярата белүче, үз бригадасының кызларына мөгамәләдә үтә сизгер һәм нечкә күңелле, мәрхәмәтле Нәфисә — тормышның кискен борылмаларында нык куллы кырыс бригадир, туган колхозының чын хуҗасы булып әверелә.

Татар әдәбияты хатын-кыз образларына ярлы түгел. Әле революциягә кадәрле үк Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал һәм Мәҗит Гафури күңел тойгыларына бай, рухлары белән бөек, тик кара көчләр басып торганга гына күтәрелеп китә алмаучы татар хатын-кызларының истә калырдай образларын иҗат иткәннәр иде. Инде совет чорында Афзал Шамов, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов һәм башка күренекле язучыларыбыз үзләренең әсәрләрендә ирек алган, шул ирекнең кадерен белеп, гел алга, яктыга омтылучы хатын-кызларны сурәтләп бирделәр. Әмма, миңа калса, Нәфисә алардан бераз әскәрәк күтәрелде кебек.

Нәфисәнең югарырак күтәрелүен мин менә ничек аңлыйм.

Әйтик, Баширов «Намус»ның төп герое итеп хатын-кызны түгел, ир-атны сайлый алган булыр иде. Ләкин бу нәкъ үз урынындагы герой булыр идеме? Ваныйгә бит тылда бара. Күңелдә шундук сорау туар иде: нигә ул ир фронтка бармаган? Димәк, ул я гарип, я шкурник дип уйлар идек. Төп әхлак нормаларында кимчелекле герой укучыга тулы эстетик ләззәт бирә алмый.

Бөек Ватан сугышында Совет тылының иң күп авырлыгы хатын-кызлар өстенә төште. Бу хәл үзе үк Нәфисәне бердәнбер дөрес табылган төп герой итә һәм типик образ дәрәҗәсенә күтәрә. Икенче хәлне алыйк: Нәфисәнең ире фронтта һәлак була. Бу исә меңләгән укучының йөрәгендә теләктәшлек таба. Чөнки меңләгән хатын-кыз укучының ире фронтта сугышты, яки ир-ат укучының хатыны тылда икмәк үстерде, балаларын карады. Шулай булгач, үзеннән-үзе табигый, солдат хатыны Нәфисә күзгә күренмәс җепләр белән халык йөрәгенә, укучы йөрәгенә тоташа. Ягъни әйтергә теләгәнем — Нәфисә һичбер тартып китерүгә, автор тарафыннан өстәмә аңлатуларга мохтаҗ түгел, ул — халыкның үз баласы, үз каны, үз хәсрәте. Ә бу — халыкчанлыкның төп билгесе бит инде. Өченчедән, татар хатын-кызының патша заманасында бик күп җәбер-золым күреп, хокуксыз яшәвен беләбез. Шул хокуксызлыкның шаукымы безнең чорга да калмаган дисезме? Кайнана белән килен мөнәсәбәтләрен кая куябыз? Ирсез хатынга бик тиз гайбәт тагылу — тегә шаукымнан түгелмени?

Болар Нәфисәне тагын бер мәртәбә авыр сынау алдына китереп бастыралар. Ул аларны я җимереп чыгарга, яки кызганыч бер елак хатын булып калырга тиеш. Нәфисә ирекле заман хокукларыннан файдалана белүче, төпле акыллы хатын. Үз халкының язмышын, ул иптәш кызларыннан тирәнрәк аңлый, тирәнрәк тоя, һәм шуңа күрә дә аларның бригадиры булып күтәрелә. Ягъни ул автор теләгәнгә генә бригадир түгел, без аның җитәкчелек сыйфатларын — иң элек эш яратуын, бурычларны аңлата белүен, кешелекле һәм зирәк булуын адым саен тоеп торабыз.

Әнә шул сыйфатлар гармоник рәвештә бергә кушылгач, Нәфисәне күтәрәләр, моңарчы тудырылган хатын-кыз образларыннан тулырак, калкурак итеп таныталар. Мөлаемлеге, сүзгә тапкырлыгы һәм чын күңелдәнлеге белән ул безнең рухи дөньябызны баета, күңелләрне сафландырып, омтылышлы, канатлы итә. Матур кешеләр

янында мин үзем дә матуррак булып китәм, дип Толстой әйткән бугай. Матур әдәбиятның тәрбияви игы әнә шулдыр инде ул...

Нәфисә романда ялгыз-ярым түгел. Аны чолгап алган мөхит бар, аның бригадасының тырыш һәм эшчән кызлары: Сөмбелләр, Карлыгачлар, Гөлзәбәрләр, барысының әнисе кебек Мәүлиха түтиләр, бер караганда бик сабыр да, икенче караганда арсландай ярсулы да Тимри картлар, фронттан яраланып кайткан командир, элекке укытучы Хәйдәрләр Нәфисәне тагын да ачып, балкытыбрак җибәрәләр. Көмеш, постауга ышкыгач, ялтыраган кебек, Нәфисә дә шушы киң күңелле, олы җанлы кешеләр белән мөнәсәбәттә тулырак ачыла.

«Намус»ның укучыларны җәлеп итә торган иң көчле ягы — аның сәнгатьчә теле. Халык күңелендәге моң-сагышны да, шатлык-сөенечләрне дә, тапкырлык-зирәклекне дә һәм җиңелчә юмор белән үтергеч сатираны да тел аркылы гына белдереп була. Болар романда барысы да бар. Язгы кыр эшләрен, май кояшы астында күпереп яткан басу өсләрен тасвирлаган чакта автор күкрәкне киергән тантаналыкны, җир уянуын, мәңгелек табигатьнең кешеләр күңелен яңарта торган гаҗәеп бер хасиятен укучыга да күчерердәй образлы төгәл сүзләр тапкан. Урам киңлеге араны иңләп кереп киткән тырмалар, төчкелтем җир исен иснәп, бөтен саннарын тетрәтеп кешнәп җибәргән атлар, яки Тимри агайның үзе беренче башлап тубалны муенына асып, вакарь белән генә чәчү чәчеп баруы — болар рәссам күңелендә картина тудырырдай күренешләр бит. Ә вакыйгалар өермәдәй өерелеп барган төштә җөмләләр кыска, мускуллы, күбесенчә хәрәкәт-фигыльләрдән генә тора. Шулар янына тагын герой-персонажларның төрле кәефкә, төрле тавышка, төрле үткенлектә сөйләнелә торган үз сүзләрен китереп ялгагыз. Оста тукучы төрле-төрле җепләрдән матур һәм нык келәм тукыган кебек, язучы да үз әсәренең төрле төсле, аһәңле һәм образлы тукымасын тудыра. Бер мәлне, үзара сөйләшеп утырганда, әдәби әсәрләребезнең теле турында сүз кузгалгач, Гамил Афзал болай дигән иде: «Намус» романының теле җанлы татар теленең үткенлеген, моңын һәм афоризмын шулкадәр үзендә җыйган, аның һәрбер җөмләсен кара тактага язып, укучы балаларга берәмләп аңлатып чыксаң да зыян итмәс иде». Моның белән кушылырга кирәк.

Гомәр Баширов халык авыз иҗатындагы образларны, сурәтләү чараларын, әсәрнең гомуми эстетик максатына туры килгәндә, турыдан-туры ала, туры килмәсә үзгәртеп ала яки тагын да үстеребрәк җибәрә һәм хәтта халыкның эстетик нормаларына ятышлы рәвештә үзе дә иҗат итә, дөресрәге халыкның тел иҗаты процессында потенциаль рәвештә сакланган байлыкны ачып, аның үзенә кайтарып бирә. Кыскасы, язучы үзенең романында телнең халык авыз иҗатындагы кебек йөгерек, үткен, вакыт-вакыт салмак-тантаналы агучы образлы, аһәңле, сәнгатьчә бизәкле асыл бер тукымасын барлыкка китерә.

Үзеннән-үзе: язучы моңа ничек ирешкән, дигән сорау туа. Иң әүвәл телнең төп чыганагыннан — халык авыз иҗатыннан өйрәнү нәтиҗәсе бу. Без Гомәр Бәшировның гомер буена телгә карата битараф кала алмавын, фольклорны җыйнавын беләбез, телгә казенный килүче кайбер салкын җанлы галимнәр белән бәхәскә керүен беләбез. Ул, хикәяләр, повестьлар, романнар язу белән бергә, татар халык җырларын, әкиятләрен, бәетләрен һәм мәзәкләрен туплап, дистәләгән китап бастырып чыгарды. Димәк, алар эзсез калмаганнар, язучыны тел остасы итеп тәрбияләгәннәр.

Әдәбиятка яңарак кына аяк баскан яшьләрдә әдәби телгә карата зәвык тәрбияләгәндә, тел осталыгына ирешкән бүгенге күренекле әдипләребезнең — шагыйрьләр, прозаиклар, драматургларның — тәҗрибәсенә таяну бик файдалы булыр иде. Ләкин үкенечле хәл — тел гыйлеменең бу өлкәсендә хәзергә кадәр ныклап шөгыльләнүче юк. Тел безнең җанлы практикабыздан аерым өйрәнелә, язылган хезмәтләрнең дә күбесе, тузан җыйнап, киштәләрдә ятып калырга мәҗбүр булалар.

4

«Намус», хәтерем ялгышмаса, аерым китап булып 1948 елда чыккан иде шикелле. Укучылар, хаклы рәвештә, автордан яңа әсәр көтә башладылар. Конференцияләрдә булсын, журнал редакциясенә яки язучылар союзына җибәрелгән хатларда булсын — укучы дигәнең Нәфисәне талап итә, аның бүгенге тормышын, хәзер ничек

яшәвен, бәхетлеме-бәхетсезме булуын белергә тели. Моннан бер генә нәтиҗә ясап була: укучы автордан китапның дәвамын сорый иде.

«Намус» — тәмамланган бер бөтен әсәр. Монда инде язмышлар ачыкланган, образлар ачылган, шулай булгач, Нәфисәне сугыш чорыннан тыныч чорга күчереп, бер табылган характерны икенче мәртәбә эксплуатацияләүнең алла ни иҗат шатлыгы китермәячәген язучы яхшы аңлый иде. Монысын мин ышанып әйтәм, ник дисәң — беренче очрашуда Гомәр аганың үзенең үк ул хакта укучыларга әйткәнен ишеткәнем булды. Шулай булгач, үзеннән-үзе билгеле, Нәфисәне әсәрдән-әсәргә күчереп йөртү варианты төшеп кала.

Димәк, яңа геройны, «үзең генә белгән яңа җырны» икенче бер тарафтан, икенче бер мөхиттән эзләп карарга кирәк. Үзенә дә, каләмдәш иптәшләренә карата да бик таләпчән килүче Гомәр Бәширов, Дәүләт премиясе лауреаты дигән бик җаваплы исемгә дә лаек булгач, «Намус»тан ким әсәр язарга теләми һәм иҗат газаплары кичереп яши иде. Ул Татарстанның Ык буйларына да килеп чыга, табигате ямьле булган бүтән урыннарга да барып кайта, күңелендә йөрткән өеткысын ул якын дуслары белән дә уртаклашып карый. Аны хуплыйлар, әйбәт була бу, уңыш телибез, диләр. Тик әсәр дөньяга тумый азаплана. Хикмәт нидә икән соң?

Илдә шәхескә табынуны фаш итеп йөргән заманнар иде бу. Эстетик категорияләр дә, әдәби кыйммәтләр дә алышынган, әнә шул шаукым әдәбият-сәнгать дөньясына да килеп кергән иде. Язучының республикабызны яшел урманнарга бизәүче кешеләр турындагы беренче замыселы юкка чыга. Ул уйлардан авторның үзенең үк күңеле кайта. Яңасын табарга кирәк. Нәкъ шул заманда, Татарстанның көнчыгыш районнарында ике чакрым тирәнлектән нефть фонтаннары бәрә башлый. Кичәге авыллар шәһәргә, кичәге игенчеләр эшчегә әйләнә. Безне тудырган, үстергән, икмәк биргән җир өстендә әнә нинди хикмәтләр бара. Әле моңарчы әдәбиятта бераү дә кузгатмаган өр-яңа дөньяны ачып, сурәтләп бирергә уйлый язучы: эшче белән игенченең бер үк җиргә булган мөнәсәбәтен сәнгать чаралары белән ачып бирергә кирәк. Һәм менә без байтак еллардан соң «Совет әдәбияты» журналында «Таң беленгәч» романының беренче кисәген кулга алып укый башлыйбыз.

Укыйбыз — шул ук Бәширов: теле үткен, образлы, халыкчан, элекке романнарындагыга караганда бераз гадирәк тә дип әйтимме әле. Конфликты да әсәрнең беренче битләреннән үк башлана. Аяз, әсәрнең баш герое, институтка керә алмыйча, имтиханнан «җимерелеп» төшә. Тагын бер кайгысы бар икән егетнең: әтисе белән әнисе нигәдер уртак тел таба алмыйча аерылганнар. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, ятимлек янына менә тагын институт кайгысы да килеп кушылды бит әле. Күренеп тора, ашның тозы бар, суганы-борычы бар, һәммәкәе дә җиренә җиткерелгән кебек, шулай да «Таң беленгәч»не укучылар тыенкырак каршыладылар. Дөрес, язылып бетмәгән әсәр турында алдан ук хөкем чыгарып кую гаделсезлек булыр иде. Шулай да күңелдәгесен яшермичә әйтсәң, «Таң беленгәч»тә нидер җитми. Нәрсә җитми һәм аны каян эзләргә? Башкалар ничек карый торганнардыр, белмим, әмма мин үзем әлеге «чүт-чүт» кенә җитенкерәмәгән нәрсәне, әлеге дә баягы, хаят суы тирәсеннән эзләү ягындарак торам.

«Әни» белән «Кунак егет» хикәясе дә, «Сиваш» белән «Намус» та — язучының җаны аша узган әсәрләр. Аларның геройлары авторның тәмам үзенеке булып, үз шатлыгы, үз кайгысы булып әверелгәннәр. «Таң беленгәч»тә, күрәсең, әверелеп җитмәгәннәр әле. Өстәвенә романда шул замандагы шаукымга, модага бирелү дә юк микән? Имтиханнан дөбердәп «җимерелеп» төшүче герой 1955—60 елларда бик модага кереп киткән иде бит. Кыскасы, «Таң беленгәч»нең төп герое, «Намус»ның төп герое кебек, бердәнбер үз урынындагы төп героймы? Бәшировның язу алымы — җәмгыятьнең әйдәүче көчләрен күреп алып, шуны беркадәр романтик күтәренкелектә тасвирлау. Яңа романда исә «хакыйкать эзләү», вак-төяк «шпилькалар да» сизелә, минемчә.

Бу әсәрен язган дәвердә Гомәр ага Бәширов Татарстан һәм РСФСР язучылар союзында байтак еллар җитәкчелек эшендә эшләде. СССР Верховный Советы депутаты буларак, парламент делегациясе составында чит илләрдә дә йөреп кайтты. Ягъни бу чорда ул җитәкче абзыйлар даирәсендәрәк яшәгәнлектән, җирдән һәм җирне уңды-

рышлы иткән кешеләрдән беркадәр аерылыбрак торды. Күрәсең, шушы объектив сәбәп, тормышның корыч логикасы буенча, аның яңа әсәрләрендә үзен сиздерми калмаган.

5

Гомәр Бәшировның халык тарафыннан кабул ителгән уңышлы әсәрләре, башка зур язучыларның әсәрләре кебек, укучыларда матурлык тойгысы үяту, хезмәткә, туган-үскән җиргә мәхәббәт тәрбияләү белән генә чикләнмиләр, яшь язучыларны үстерүдә дә ярдәм итәләр. Бүген азмы-күпме уңышлы иҗат итеп килгән яшь прозаикларның кайсысын гына алма, Гомәр Бәширов йогынтысы булмаган берсе дә юктыр. Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев, аеруча Рафаил Төхфәтуллин аңардан тел осталыгына өйрәнделәр. Бигрәк тә Рафаил Төхфәтуллинның эчке интонацияләре, тирбәнешләре, лирикасы Бәширов иҗаты белән аваздаш. Аваздаш, ләкин тәңгәл түгел. Укытучысыннан алган беренче сабак аның дөньяга караштагы үз үзенчәлекләре булган, укучылар арасында танылган Төхфәтуллин алымын тудырды.

Бу урында бер нәрсәне ачыклап узарга кирәк. Кайбер иптәшләрнең: ә нигә Бәширов йогынтысы турында сөйлисең әле син, нигә Галимҗан Ибраһимов йогынтысы турында сөйләмисең, дип әйтүләре мөмкин. Һәм алар хаклы булачаклар. Мирас һәм традицияләр — татар прозасында иң катлаулы мәсьәлә. Безгә, әлбәттә, иң әүвәл Галимҗан Ибраһимов традициясе турында сөйләргә кирәк иде. Ләкин объектив сәбәпләр аркасында без, бүгенге көннең кырык яшьтәге прозаиклары, Галимҗан агайны укый алмадык. Ул безгә бик сабый чакта эләкте, анда да «Кызыл чәчәкләр», «Алмачуар», «Яз башы» кебек, балалар дөньясына якынрак әсәрләре генә эләкте. Ә иҗатыбыз формалашкан дәвердә, эстетик зәвыкларыбыз уянып, дөньяга карашыбыз ныгыган чорда, ул безнең өчен бикле иде. Безнең бердәнбер классигыбыз Шәриф Камал иде прозада, аннары инде без Кави Нәҗмидән, Гомәр Бәшировтан, Ибраһим Газидан һәм Фатих Хөснидән өйрәнә ала идек. Соңгы дүртесе безнең иҗади формалашуыбызда зур урын алып торалар. Кави Нәҗминең зур мазоклар белән эшләүче рәссамлый, саллы һәм бераз дорфарак теле, И. Газиның чеметтереп-чеметтереп ала торган усаллыгы, кыска-җыйнак җөмләләре, Ф. Хөснинең дөньяга сыймас шаянлыгы — безгә теге-бу дәрәҗәдә көчми калмагандыр. Әмма җитдирәк килеп, гыйльми нигездә анализ ясап карасаң, иң зур йогынты Гомәр Бәшировтан килә. Нурихан Фәттахның да, Аяз Гыйләҗевнең дә Бәшировтан өйрәнәбез дип әйткәннәре юк, әмма портрет пластикасы, табигать бизәкләрен, эчке монолог һәм моң-сагышны бирү, эпиклык белән лиризмны бергә үрү, ягъни Бәширов алымына хас сыйфатлар бүгенге урта буын прозаикларда бик нык сизелә. Шундый гармонияле стильне без иң башлап Гомәр Бәшировта күрдек. Ләкин татар прозасында зур колач белән сурәтләү башлап Галимҗан Ибраһимовта, Шәриф Камалда туа. Аннары аны, минемчә, яңа шартларда яңачарак, үзенчәлеклерәк итеп, тагын да үстереп һәм баетып, Гомәр Бәширов алып китә. Димәк, Галимҗан Ибраһимов безгә Бәширов иҗаты аша күчә. Тагын да җыйнабрак әйткәндә, Гомәр Бәширов татар әдәбиятының классикларына булган ихтирамын, үз иҗаты аша, бүгенге яшьләргә дә китереп тапшырды.

Монысы объектив йогынты.

Моннан тыш Гомәр Бәширов яшьләрнең иҗаты белән үзе турыдан-туры кызыксына. Язучылар союзы председателе буларак та, өлкән язучы буларак та, ул яшьләргә булышуны үзенең төп эше дип санап килде. Рафаилның беренче хикәяләре аның кулыннан уздылар. Журналда эшләгән чагымнан хәтерлим, Рафаил ул чакта авылда, Яңа Кенәрдә яши иде. Хикәяләренең бер данәсен ул журнал редакциясенә җибәрсә, бер данәсен үзен шефка алган өлкән язучыга җибәреп тора иде. Гомәр ага аның беренче җыентыгына кергән хикәяләрен дә, икенче җыентыгындагы хикәяләрен дә барысын да үзе карап, кайбер ялгыш бәя бирүчеләр белән бәхәсләшеп, үзе барлап торды, соңыннан журналда «Яңа танышларыбыз» дигән зур гына мәкалә язып чыкты. Төхфәтуллин инде Язучылар союзы члены булып алынганнан һәм танылып өлгергәннән соң да ул аның иҗаты белән кызыксынудан һаман туктамады. «Йолдызым» повесте буенча аның тирән бер кайгыртучанлык һәм ихтирам белән авторның үзенә язып җибәргән зур хаты моңа мисал була ала. Яшь язучы Рәкыйп Шәйхетдиновның беренче әсәрләре шулай ук аның кулыннан уздылар. Газетада басылган «Кәтүчә»

исемле бәләкәй генә парчасына карата Гомәр ага «Үсү юлы» альманахында унбиш битлек мәкалә язып чыкты. Бу мәкалә язучылык хезмәтенә җаваплы карарга, халыкның тел байлыгыннан туктаусыз өйрәнергә чакырган иде. Бер Ракыйп өчен генә түгел, безнең барыбыз өчен дә кирәкле мәкалә иде бу.

Өлкән әдип безнең уңышларга сөенә, чатаклыкларыбызга көенә белә. Ул һәм шагыйрь Сибгат Хәким Татарстан язучылары союзының Әлмәттә бүлекчәсе ачылуга сәбәпче булдылар. Нефтьчеләр ягына күчәргә, халык белән бергә яшәргә алар безне үгетләделәр. Алар безгә, Әлмәт язучыларына, рухландыргыч хатлар язып торалар, алар безнең әсәрләребезне беренче булып укыйлар, камиллаштерергә ярдәм итәләр.

## 6

Гомәр Бәширов күптән түгел зур күләмле «Туган ягым — яшел бишек» дигән әсәр тәмамлады. Әле матбугатта басылып чыкмаганлыктан, ул повесть хакында зур итеп сүз сөйләү бәлки кирәк тә түгелдер. Ләкин мин бер нәрсәне укучыларга әйтми булдыра алмыйм. «Туган ягым — яшел бишек» автобиографик әсәр булса да, тик ул авторның үз эчке дөньясы белән генә чикләнми, халыкның борын-борыннан килә торган матур йолаларын, гореф-гадәтләрен үз авылының кешеләренә, тормышларына бәйләп сурәтли. Үткән заман гел начар гына булган, хәзерге заман гел яхшы гына диган, инде шаблонга әйләнгән карашны алга сөрми автор. Халыкның зурлыгын, бөеклеген, аның күңел байлыгын һәм шигърилеген ача. Кышын тәрәзәгә төшкән бизәкләрне Ай кызы ясап киткәндер төсле тоела авыл малаена. Язын бәбкә чыгарырга утырган ана казның кыланышларын бәләкәй Гомәрнең әнисе бик матур итеп, эчке бер җылылык белән аңлатып бирә. Булачак язучының күңеленә сеңеп калган Арча ягы урманнары, Арча ягы сулары, Яңа Сала буйларының болын-тугайлары, кояш бату, кояш чыгулары, кырлар өстендә тибрәнгән рәшә дулкыннары — кыскасы, кеше күңелен нечкәртә, матур һәм җылы итә торган табигать дөньясы кабатланмас бизәкләре белән ачыла. Әнә каян килә икән Гомәр Бәширов әсәрләрендәге игенчеләргә булган мәхәббәт, туган җирне олылау — повестьны укыгач, шуларны да аңлыйсың.

Үзара сөйләшкән чакта, сүздән-сүз чыгып, мин Гомәр агайдан: бу автобиографик повестьны язарга сезне нәрсә мәҗбүр итте, дип сорадым.

Гадәтенчә, сабыр гына елмаеп, ул болай диде: безне тудырган туган-туфрак бар бит әле. Тукай белән Такташны, Җәлил белән Фатих Кәримне, Сәйдәшевне һәм Яруллинны тудырган җир бит ул. Бөек Ватан сугышының йөзләгән геройларын, бүгенге тыныч тормышның фидакарь кешеләрен тудырган җир. Мин әнә шул җирнең нинди икәнен үзем өчен, шул нәүбәттән укучы өчен дә күңел күзеннән үткәреп карарга теләдем. Җиде юл чатында, тарихның усал җилләре астында гасырлар кичергән, ике катлы изү-җәберләүгә дучар булган халык ничек соң исән калган? Ниһаять, ул үзенең күп гасырлык культурасын нинди могҗиза белән саклап кала алган?

Моң-зарлы халыкның иреккә булган омтылышын, иң изге тойгыларын үзендә туплап, үзенең гаять тәэсирле, эмоциональ җаны аша үткәреп, халыкка кайтарып бирә алмаган булса, табигать нинди генә зур талант бирсә дә, Тукай Тукай була алмас иде бит, — диде язучы.

Күп мәхрүмлекләр кичергән халыкның бүгенге бәхетле тормышы бар. «Намус»тагы Нәфисәләр заманыннан соң да егерме елдан артык вакыт узды инде. Бөек Октябрьга илле ел тулган, бөтен ил канатланып, зур җиңү бәйрәмен, хезмәт һәм азатлык бәйрәмен иткән чакта татар халкының үткәне һәм аның тугандаш халыклар семьясындагы бүгенгесе турында уйлый язучы, шуны күңел күзеннән үткәреп яши.

—✦—

# *Гази Кашшафка 60 яшь*

## ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ

Әдәбиятыбызның күренекле вәкилләреннән берсе Гази Кашшафка 60 яшь тулды. Гази Кашшаф (хәер, бер ул гына түгел, ә бүгенге «алтмыштагылар» барыбыз да) әдәбиятка утызынчы елларда килде.

Бәләбәй педтехникумы фатихасын алып Казанга ашкынган мыексыз һәм кәләшсез яшь егет, педагогия институтында укыган көннәрендә үк, әдәби хәрәкәткә бай тормышка беренче адымнарын ясый...



Шул көннәрдән алып узган вакыт эчендә Гази Кашшаф үзенең бик күп хезмәтләре белән әдәбиятыбызны тагы да үстерү, данын күп милләтле Ватаныбыз чикләреннән ары — башка илләргә дә җиткерү эшенә билгеле бер өлеш керткән әдип.

Әдәбият кешесенең эш-хезмәт юлы шундый бит ул! Язасың, иҗат итәсең, яңадан-яңа әсәрләр тудырасың, тудыру газабының ләззәтен һәм газабын кичерәсең, янасың-көясең. Шуның өстенә тагы, бәхетле язмыш буенча, җәмәгатьчелек эшенең ару-талу белмәс тырышчанына әйләнәсең, яшь буынны тәрбияләү кебек гаять гүзәл бер миссияне үтәү бәхетенә дә ирешәсең. Еллар уза тора. Узган елларның юллары маңгай өстендә үз буразналарын сыза тора, чигә төпләрең кырау суккандай көмешләнә һәм, ниһаять, шундый көн килеп җитә: туган халкың хезмәтеңне зурлап, хөрмәт белән исемеңне телгә ала, рәхмәтен әйтә.

Менә шундый дулкынландыргыч тантана көннәрендә синең үзеңә генә билгеле, үзең генә кичергән эчке хисең — канәгатьләнүгә дә, горурлыкка да охшый язган хисең — кинәт синдә сагаюга охшаш икенче бер хисне дә уята. Әнә шул чагында синең үзеңә генә: «Халык хөрмәтенә, халык рәхмәтенә лаек булырлык хезмәт күрсәтә алдыммы соң мин?» кебегрәк эчке борчылу авазы ишетелеп уза.

Мин моны үз башымнан гына түгел, ә халык зурлавын күргән замандашларымның барысы да үз башларыннан кичерүенә бик нык ышанудан әйтәм. Чөнки бу безнең ише Октябрьда туып, Октябрьда күтәрелеп чыккан совет кешеләренең барысы өчен дә уртак сыйфат.

Һәм менә шундый эчке борчылулы минутларында эшләгән эшләрең, башкарган хезмәтләрең, күңел экранында кино тизлеге белән уза башлый һәм, уза торгач, кинәт күңелең яктырып китә синең. Баксаң, чын мәгънәсендә халык хөрмәтенә лаек булган әйбәт кенә эшләр башкарып та куйгансың икән. Әйе, дисең син күңелең яктырган бу минутларында, мин үземнең халкыма шушы, бары тик шушы хезмәтемне күрсәтер өчен генә дә әдәбиятка килергә риза булыр идем... Әле генә сине борчыган теге эчке тавышның кайтавазы шунда ук юк була.

Гази Кашшафның кырык еллык әдәби, педагогик һәм җәмәгатьчелек эшчәнлегенең соңгы ун елында Муса Җәлил васыятен үтәү буенча күч куйган иҗади эше әнә шундый хезмәтләргә керә. Укучыларга мәгълүм булганча, бу күпкырлы хезмәт әдәбиятыбызны «Муса Җәлил» исемле дүрт йөз илле битле монографик очерк белән баетты. Бу китап бүгенге яшь буынны коммунизм рухында, Ватаныбызга Муса Җәлилчә бирелгәнлек сафлыгында тәрбияләүдә бик кирәкле хезмәтне үти һәм киләчәктә дә үтәр. Шушы үзе генә дә күренекле әдибебезне алдагы эшләргә тагы да дәртләндермәс тә, тагы да илһамландырмасмыни?!

Әллә инде без «алтмыштагылар» шундый бер бәхетле буын булдык димме, бик тиз генә тынарга чамаламыйбыз, Туфан әйткәнчә:

Бездә әле дәрман,
Бездә әле җегәр житәрлек,
Әле тагын берәр ярты гасыр
Әһ тә итми гомер итәрлек!

Гази Кашшаф та әнә шундый «алтмыштагылар»ның берсе. Филология фәннәре кандидаты буларак, ул гыйльми институт эшләрендә катнашырга да, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының өлкән укытучысы сыйфатында лекцияләр укырга да, «Казан утлары» редколлегиясе члены тәртибендә калын-калын роман, повесть кульязмалары белән танышырга да, тәнкыйтьче, язучы буларак, үз иҗат эшләрен дәвам иттерергә дә, партия члены буларак, партия тапшыруларын үтәргә дә, кыскасы, өстери алганча төягән йөкне өстерәргә дә әзер торган, ару-талу белмәс кеше ул.

Гази Кашшафның әлеге шул санап киткән гражданлык сыйфатларының нигезендә бик кешелекле бер сыйфат ята. Бу — тыйнаклык.

Минем дуслыгыбызга кырык елдан артык гомер узды инде, моның ише сабыр, тыйнак кешене бик сирәк очраттым дисәм һич тә арттырып әйтү булмас.

Шундый деталь истә калган. Гази Кашшафның 50 еллык юбилее уңаеннан уздырылган аш мәҗлесендә, мәрхүм Әхмәт Фәйзи, берсеннән-берсе күнелле һәм тапкыр тостлар әйтә торгач, Гази Кашшафка карата:

— Син, дускай, үзең бик әйбәт кенә кеше болай, тик бер житешмәгән ягың бар — артык тыйнак! — дигән иде.

Әйе, Гази Кашшаф тыйнак кешеләрдән ул. Мин моны тагы бер кат шушы мәкаләне язганда күрдем. Миңа Муса Җәлилнең авыр сугыш уты эчендә рус телендә язып калдырган васыятен кабат карап чыгу кирәк иде. Кулыма Гази Кашшафның әлеге китабын алдым.

Васыятьнең өченче абзацында менә болай язылган:

«В случае моей смерти сбор всех моих рукописей, стихов, песен, поэм, рассказов, пьес, эпиграмм, критических статей, дневников, писем, как в черновом виде, так и в виде беловиков, завещаю и доверяю моему лучшему другу, критику и писателю, члену ССП тов. Кашшафу Гази (астына мин сыздым).

Гази Кашшаф исә үз китабында бу васыятьнең шушы өченчесен алмыйча, кабатланганга күрә беркадәр гади әйтелгән бишенче абзацын тәрҗемә итеп бирә:

«Әгәр дә мин үлә калсам, минем барлык кульязмаларымны җыюны һәм үз карамагында чыгаруны... иптәш Гази Кашшафка тапшырам...»

Әле бу абзацта да Мусаның: «Үземнең барлык иҗатымны һәм әдәби мирасымны үзе каравынча, үз комментарийлары белән матбугатта чыгаруны аңа тапшырам», кебек тирән ышаныч тудырган сүзләренә кыскартулар ясый.

Гарәпләрдә бер мәкаль бар: «Дустыңның кем булуын әйт, мин синең үзеңнең кем булуыңны әйтеп бирермен».

Әгәр дә бу юлы да юбиляр белән бер табында очрашырга туры килсә, өлешемә төшкән тостны болай әйтер идем мин:

— Гази дус! Алдагы иҗат юлыңны да халкыңа хезмәт итү бәхетен кичереп яшә. Иртәгә дә бүгенгедәй хезмәт сөйгән тыйнак замандашларыбызның берсе бул! Артык тыйнак булуың да зарарсыз. Шундый әйбәт сыйфатның кешедә аз булуына карагенда артык булуы әйбәтрәк, чөнки, тыйнаклык ул кеше күрке, диләр иң.

*ГАБДРАХМАН МИНСКИЙ.*

# ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

*Дамир Вагыйзов*

## ПРИНЦИП[1]

Нургаяз бүген башка көннәрдәгегә караганда да арыбрак кайтты. Сәгать уникеләргә кадәр медпунктта авырулар кабул итте, аннан соң өйләрендә ятучы сырхаулар янына барып килде. Кайтып төшке ашка гына утырган иде, «Киттекме, Нургаяз абый!» — дип, күршесе Гыйлаҗ килеп керде. Шулай итеп, аш артыннан хатыны кайнаткан кофены авыз итәргә дә өлгермичә, күршесе белән китеп барды. Ә фермага килдеңме, тиз генә кайтам димә инде. Сүз иярә сүз чыга, бер сорауга икенчесе ялгана. Ни өчен аларда дуңгызларның тәүлеклек артымы 400—450 грамм гына, ә менә газетада язганнар: Алексеевск районының «Красный Восток» совхозында дуңгызларның көнлек артымы 600 граммга якын икән. Ашатулары бер үк югыйсә. Нургаяз алар тәҗрибәсен өйрәнә тора. Шулай эшләмәгәндә, җавап бирә алмыйча, бик тиз топ башына утыруың мөмкин. Күзенә тагын бер җитенкерәмәгән як чагылды. Икенче көн инде күрсәткеч такталары тутырылмаган икән. Нургаяз шуларны җайга салды. Моның өчен җаваплы агитаторны чакыртып, бергәләп «Молния» чыгарып куйдылар. Стена газетасының алдагы санының макетын төзеделәр.

Соңыннан совхоз конторасына кереп, һәрвакыт үзе белән йөртә торган коңгырт тышлы блокнотының соңгы битләрен саннар белән чуарлады. Алары терлекчелектәге эшкә анализ ясау өчен кирәк иде. Утыра-утыра вакытның узганы сизелми дә калды. Өенә кайтканда авылда күбесе йокларга яткан, бары тик электр баганаларындагы лампалар гына көчле буранда «моңнанрак атла» дигән сыман үзләренең очкын күзләрен чекрәйтеп яналар иде.

Улы белән кызы бүген дә, аны көтә-көтә көт булгач, йокыга киткәннәр. Ул аларга бүген ниндидер әкият сөйләмәкче иде. Вәгъдәсендә тора алмады. «Эти сүзендә тормады», дигәннәрдер инде.

— Көттеләр, көттеләр дә, ярты сәгать чамасы бардыр, күзләрен йомдылар, — диде хатыны, пышылдап. — Булырлык булмагач, сөйләп тә торасың юк. Аннан үзләре дә шуңа өйрәнәләр алар.

— Күрәсең ич, әле тегендә, әле монда чабам. — Нургаяз, хатыны алдында акланган сымак, кулларын җәйде. Аннары ул тамагына капкалады, чишенде, бүген килгән газетаны кулына алып, кроватька менеп ятты. Бер-ике хәбәр дә укып чыга алмады, йокыга талды.

Нургаязның хатыны каты итеп тәрәзә шакуга уянып китте. Ул, пәрдәне күтәреп, урамга карады. Ләкин берни дә шәйләмәде. Ут кабызды. Чыгарга да, чыкмаска да белмичә, беравык басып торды. Олы юл өсте булганлыктан, җиде төн уртасында үзе генә чыгып капканы ачарга һәрвакыт шикләнә иде ул. Төнлә ашыгыч ярдәм сорап килсәләр, тиз-тиз ирен уятырга кереша. Хәер, авылда андый-мондый хәлләрнең күпме заманнардан бирле инде ишетелгәне юк... Ул иренә карады. Нургаяз кулын баш астына куеп тәмле генә йоклый иде. Бүген аны уятырга базмады. Кулына эләккән беренче пальтоны чөйдән алып киде һәм, яланаякка галошлар сөйрәп, әкрен генә өй алдына чыкты. Ишекне аз гына ачып, кыяр-кыймас кына:

— Кем бар анда! — дип сорады.

— Мин бу, сеңелем, Әхмәтҗан бабаң, — дип, карлыккан тавыш белән җавап бирде урамдагы кеше. Таныш авазны ишеткәч, ул баскычтан тиз-тиз төшеп капканы ачты. Өстенә кара тун кигән, билен кызыл эзәр белән буган карт керде. Ул, чакырганны да көтеп тормыйча, тун якасына сарган карны кага-кага өйгә үтте.

— Мин кантурга каравылга килгәндә, тып-тын тора ие, алланың рәхмәте, ә хәзер күзне ачар хәл юк. Ишә прәме. Йоклыймы! — ул, тавышын әкренәйтә төшеп, кулы белән Нургаязга күрсәтте.

— Бу вакытта йокламыйча ни! — хатын, мич белән стена арасын каплаган чуар чар-

---

[1] Очеркта кайбер геройларның исемнәре үзгәртеп алынды (автор).

шау артына кереп, пальтосын озын халатка алыштырып чыкты. — Сәгать өч бит инде, Әхмәтҗан бабай. Аның фельдшерлык эше генә булса иде икән...

— Һм, алай да уят инде син аны, сеңелем, — карт, электр утыннан күзләрен чекрәйтеп, хатынга ялварулы караш ташлады.— Ялландагы теге безнең Гайфетдин үлем хәлендә, ди. Белә дә торгансыңдыр, калхуз вакытында беравык персидәтел булып эшләде бездә. Вәт шул инде, ие. Прәме тәки үләргә ята, ди. Имән грәжедәй йөри иде, ие. Алган да сәлгән, алланың рәхмәте...

— Ялан — Нургаяз участогы түгел бит, Әхмәтҗан бабай, боларны миңа ни дип сөйлисең син!

— Беләм, сеңелем, беләм, ие. Баштан телефон шалтыраттылар. Мәйтәм шулай бит, аның тәртибе бар. Нургаяз участогы түгел, бармас, дим, ие. Үзебезнең фершыл өйдә юк. Әхмәтҗан абзый, зинһар, юллый күр инде, диләр. Аннан соң ул белә дә төшә, диләр, ие. Шалтыраттылар, шалтыраттылар да инде хәзер ат җибәргәннәр. Тизрәк ие инде, ни, сеңелем, Яланныкы теге Хисами малае шунда капка тур янында көтә калды.

Хатыны әкрен генә кровать буена килеп, Нургаязны уятты. Нургаяз тору белән, карт тиз арада булган хәлне сөйләп бирде.

— Тәрәте юк, ди, ие. Бөгәрләнеп идән тырный, ди...

«Гайфетдин Вәлиевич, — дип башын чайкап уйлап куйды Нургаяз. — Үзе беләме икән ул кем артыннан җибәргәннәрен. Әгәр белә икән, димәк, үз тормышының принциплары белән хисаплашмый. Нургаяз да аның кебек принциптан чыгып эш итсә! Юк, ул аны һич тә булдыра алмаячак...»

* * *

Татар Сарсазы авылына эшкә Нургаяз моннан тугыз ел элек, Чистай фельдшер-акушерлык мәктәбен тәмамлап, Хәрби Диңгез Флотында хезмәт итеп кайтканнан соң килде. Җәй көне иде. Бөтен байлыгы салынган бер чемоданын белешләренә кертеп куйды да авыл Советына китеп барды. Председатель белән секретарь ниндидер исемлекләр тикшереп утыралар иде. Нургаяз исәнләшеп өстәл янына үтте һәм район сәламәтлек саклау бүлегеннән алган кәгазьне председатель каршысына куйды.

— Оһо, күрәсеңме, сеңелем, безгә фельдшер җибәргәннәр. Яхшы, яхшы! — ул сүзгә генә ышанмас диган сымак, кәгазьне секретарьга да укырга бирде. — Халык, понимаешь, кайсы чит авылга, кайсы Чистайга йөри-йөри тинтерәп бетте. Тәк, бу иптәшне кемгә урнаштырсак яхшы булыр икән, сеңелем! Семьялымы!

— Әлегә мин урнаштым, белешләрдә,— диде Нургаяз, аны бүлеп. — Анысын соңынрак уйлашырбыз. Ә хәзер, мөмкин булса, медпунктны күрсәтсәгез икән!

Авылны урталай ярып үткән олы юл буйлап беразбаргач, кара айгыр җиккән тарантас аларны тузан белән бөркеп узды. Председатель: «Исәнмесез, Гайфетдин Вәлиевич», — дип аның артыннан башын иеп исәнләшеп калды. Атка утырган юан кеше Нургаязларны әллә бөтенләй үк күрмәде, әллә муенын борырга иренде, дилбегәсен каккалый-тарткалый, дәшми-тынмый гына китеп борды.

— Безнең колхоз председателе, — диде авыл Советы җитәкчесе. Беравык дәшми барганнан соң, өстәп куйды:

— Бик своеобразный кеше.

Бераздан алар урамның очына килеп җиттеләр. Авыл Советы председателе, олы яшьтә булса да, юл кырыендагы канауны җитез генә сикереп чыкты да түбәсе салам белән ябылган искерәк кенә бер өй янына килеп туктады.

— Медпункт белән мактанырлыгыбыз юк, Хәйретдинов иптәш. — Башы белән ул каршыдагы өйгә ымлады. — Менә шушында була инде.

Анда авыруларны кабул итү өчен берниндн мөмкинлек юк иде.

— Элек шушында эшлиләр иде инде, болай жаловаться иткән кеше булмады, — диде председатель.

Килүенең өченче көнендә Нургаяз, кешеләрнең сәламәтлеген тикшерү нияте белән, өй борынча чыгып китте.

Аны һәр өйдә ачык йөз белән каршыладылар. Башта үзләренең сәламәтлекләре турында сөйләделәр, аннан соң сүз иярә сүз чыгып, колхоз тормышына кереп киттеләр. Тормышлары бик шәптән түгел икән. Колхозлары районда койрыкта сөйрәлүчеләрдән санала. Эшнең уң булуы күп яктан хуҗага бәйле шул... Бар белгәне кычкыру икән. Хайван да бит йонны бераз җайга сыпырганны ярата.

Иртәгесен Нургаяз, үпкәсенә салкын тидергән бер колхозчы хатынны район больницасына озату өчен атмы, машинамы сорарга дип, идарәгә керде. Гайфетдин Вәлиевич наряд бирә иде. Нургаязның үтенечен ишетү белән, өстәл артыннан сикереп торды һәм:

— Чираттагы симулянт, больше бернәрсә дә түгел, — дип, сугышырга әзерләнгән кеше сымак, итләч кулларын бер-берсенә ышкып алды. Аннары, Нургаяз белән эшне тәмамлаган кебек, бригадирларга ниндидер кәгазьләр өләште. Кемнәр беләндер байтак сөйләшкәч кенә әле һаман каршысында басып торган егеткә карады.

— Беләләр алар ике көннән уракка төшәргә икәнен. Транспорт юк, — дип мыгырданды ул. — Дәүләт күзлегеннән карап эш итәргә кирәк. Алда ни чаклы эш, ә мин транспортны тегендә-монда җибәрим дә ваттырып, ике кулсыз калыйм, имеш.

— Сүз колхоз члены турында, аның гомере турында бара, иптәш председатель, — диде Нургаяз, ачуын яшерә алмыйча һәм тыелырга да теләмичә.

— Син һаман үз каланчаңнан карап кына сөйлисең. Мин мең кеше турында кайгыртам. Ашлыкны вакытында чыгара алмадыңмы, әрәм-шәрәм иттеңме, димәк, меңләгән кешене ач калдырдың. Хөкүмәт аның өчен рәхмәт әйтми. Канца да конец, сезнең үз участогыгыз, минем үземнеке. Эш прин-

ципта да монда. Мин сезгә: «Фәләнне эшләгез», дип бармыйм бит. Раз сезгә кешеләрнең сәламәтлеген саклауны йөкләгәннәр икән, саклагыз. Мин причем! — ул өстәл өстеннән яшел фуражкасын алды да, берәүгә дә күтәрелеп карамыйча, зур-зур атлап идарәдән чыгып китте.

Гайфетдин Вәлиевич белән сөйләшүдән соң, бик каты кәефе кырылып, Нургаяз авыл Советына керде. Булган хәлне башкарма комитет председателенә сөйләп бирде.

— Син аны, Хәйретдинов иптәш, бүген генә күрдең, ә без күптәннән беләбез инде, — диде ул, Нургаяз сөйләгәннәргә аз гына да гаҗәпләнмичә. — Озатырбыз, узгынчы машиналар белән. Бүген генә шулай иту түгел...

— Ләкин ул андый вакытта машина бирергә тиеш, — диде Нургаяз. — Аңа карата ничек либерал булып яшисез әле!

— Ә син, Хәйретдинов иптәш, аның турында сүз булмады дисеңмени! Һи, сессиядә тәнкыйтьләү кирәкме, партоешмада тикшерү дисеңме — берсе дә калмады. Үз туксаны туксан аның. Туры әйтсәң, үчегә башлый. Соңгы тикшерүдән файдасы шул булды: бөтен учреждениеләрне утынсыз калдыра язды. Райкомнан шалтыраткач кына ташыта башлады.

Нургаязның Гайфетдин Вәлиевич белән икенче бәрелешүе көзге якта булды. Бу юлы ул аның янына колхоздагы буш өйне медпункт өчен бирүләрен сорап кергән иде.

— Мин сиңа бер әйткән идем, һәр эшнең үз принцибы бәр дип, — идарә председателе кулы белән һаваны ягргандай хәрәкәт ясады. — Кеше ашына катык катып йөрмәсәгез икән... Миңа да күп нәрсә җитешми, сезнең каршыга гозерләп барганым юк бит. Хотя, сездән алырга да юк.

Гайфетдин Вәлиевичның һәрвакыт сөзгәк үгез кебек каршы килүе Нургаязны чыгырыннан чыгарды. Кешеләр алдында ул аны бюрократлыкта, эгоизмда гаепләп сүгеп ташлады.

Шул көннән соң озак та үтмәде, аны авыл Советына чакырттылар. Өстәл артында утыручы участок милиционеры хулиганлыкта гаепләп, аның өстеннән жалоба булуын әйтте. Нургаяз моңа башта бөтенләй ышанмады. Шулай да:

— Гаепләүләре дә бар, иптәш участковой, көнгә әллә ничә кешенең тәнен инә белән тишеп, җанга бик үк рәхәт булмаган дарулар җибәрергә туры килә, эчергән даруларым да ширбәт түгел, — диде, шаярып. Ә инде жалобаның Гайфетдин Вәлиевич белән булган вакыйга турында икәнлеген белгәч, йөзе кырысланып калды.

— Бу очракта кайсыбыз сезнең каршыда утырырга тиеш икән, шунысын уйлап карагыз, — диде ул һәм булган хәлне чәчмитүкми сөйләп бирде. Ахырдан Нургаяз, тавышын акрынайта төшеп, болай дип өстәде:

— Сез ничек карарсыз ул эшкә, ләкин мин кеше белән исәпләшмәгән, сәлам бирергә дә теләмәгән бюрократларга каршы һәрвакыт көрәшәчәкмен. Кычкырышудан тартынып тормыйм. Ник дисәгез, сүз кеше гомере хакында бара. Барыбыз да бит дөньяга яшәү өчен киләбез. Тормыштан да кадерле ни бар!

— Без һәр жалобаны тикшерергә тиешбез, сез гафу итегез, — диде участковой, Нургаязның сүзләрен азаккача тыңлагач...

Бу вакыйгадан соң Нургаяз Гайфетдин Вәлиевич белән уртак тел таба алмаячагына тәмам ышанды. Алар бер-берсе белән бик сирәк очраштылар, очрашканда да күрмәмешкә салышырга тырыштылар.

Нургаяз кешеләр сәламәтлеге өчен, үзүзен аямыйча, тырышып йөрде. Урында хәл ителмәслекләре булганда, район Советы башкарма комитетына барды, арырак узды, әмма үз дигәнен эшләде. Күп тә үтмәде, медпункт өчен аерым бина бирделәр. Беренче чиратта зарур булган медицина җиһазлары кайтардылар. Гайфетдин Вәлиевичның бина өчен ачуы кабарган иде кабаруын. Алай да сер бирмәскә тырышты бугай. Хәтта бервакыт үтеп барышлый:

— Шулай, медик, һәр нәрсәнең үз принцибы була, бина өчен рәхмәт әйтерлегең бәр, — дип кычкырды. Бу сүзләрнең теш арасыннан ничек чыгуын Нургаяз сизенде. «Югарыдан кысмасалар, бирер идең син», дип уйлап алды.

Январь азагында колхозның отчет-сайлау җыелышы булып узды. Авыл халкы клубка җыелды. Гайфетдин Вәлиевичның һәм ревкомиссия председателе докладларын тыңлагач, колхозчылар берәм-берәм трибунага күтәрелделәр. Дүртме-бишме кеше сөйләгәннән соң, Нургаяз да, урыныннан торып, сүз сорады.

— Производствода эшләүчеләр нигә тынып калды, давагыз, иптәшләр, давагыз. Җитешмәгән яклар бар икән, тәнкыйтьләгез. Шулай итсәгез, аларны бергәләшеп бетерүе дә җиңелрәк булыр, — диде, әлегә кадәр кызарынып-бүртенеп утырган Гайфетдин Вәлиевич. Тик халыкны болай гына күндерә алмады.

— Хәйретдинов сүз сорый бит. Нигә аңа бирмисез! — дигән тавышлар яңгырады. Нургаяз, үзенә сүз бирүләрен дә көтеп тормыйча, сәхнәгә, трибунага юнәлде. Аның әле мондый зур җыелышларда бер тапкыр да чыгыш ясаганы юк иде. Халык алдына чыккач, ул башта каушап калды. Залда утыргандагы фикерләре кайсы-кая чуалып беттеләр. Халык гөжләп торган арада ул аларны тупларга тырышты. Бу очракта үз юлында очраган каршылыклар турында гына сөйләү җитешеп бетмәс кебек тоелды аңа. Беразык уйлап торганнан соң, ул коллективта бердәмлек булмау, кайбер җитәкчеләрнең, аерым алганда Гайфетдин Вәлиевичның, кешеләр һәм оешмаларны, хәтта авыл Советын да санга сукмавы, моның эшкә ничек зарар итүе турында дәлилләр китереп сөйли башлады. Аны әледәнәле: «Дөрес әйтә», «Күптәннән сүзне шуннан башларга иде», — дигән сүзләр белән бүлдерә тордылар.

— Иптәшләр, хәзер безнең эштә командада гына җитешми. Дөрес, вакытында кирәк булгандыр ул, ә хәзер заман икенче.

Партия җитәкчеләрдән халык арасында тәрбия эше алып баруны, кешеләргә йөз белән борылуны да таләп итә. — Нургаяз минем бетте дигән сымак башын селкеде дә сәхнәдән түбән таба атлады.

— Мин халыкка артым белән торам што ли! — дип кычкырып калды аның артыннан Гайфетдин Вәлиевич. Аның сүзләрен президиумдагылардан кала берәү дә ишетмәде. Халык кул чаба иде.

Бу җыелышта Гайфетдин Вәлиевичны председатель итеп сайламадылар. Атна чамасы вакыт узгач, ул, семьясын төяп, туган авылына күчеп китте. Гайфетдин Вәлиевич әкренләп халык теленнән чыга барды. Ә бер ел дигәндә, бөтенләй онытылды. Нургаязның да аны беркайчан искә алганы булмады. Һәркем үз эше белән мәшгуль иде.

Авыл кешеләре Нургаязны үзләренең ихтирамга лаеклы кешеләренең берсе итеп саный башладылар. Аның терлекчелек фермаларында, кыр станнарында агитатор буларак җиң сызганып эшләп йөрүен күреп:

— Һай, дускай, монда йөреп доктор эшеңә зыян килмәгәе, — дип тә әйткәләделәр. Ләкин алар ялгыштылар: хәзер авылда авырулар сирәк, балалар үлү кебек фаҗигале хәлләрнең бөтенләй булганы юк иде. 1962 елда аңа «Медицина отличнигы» дигән мактаулы исем бирделәр. Ә бер ел узгач, аның фамилиясе беренче категория медицина работниклары исемлегенә кертелде.

Кешеләр бигрәк кызык! Үзләре Нургаяз өчен борчылалар, ә нинди генә җаваплы эш булмасын, «Безнең доктордан да шәбрәк үтәүче табылмас», — дип, аңа йөкли торалар. Үткән сайлауларда аны авыл Советына депутат итеп сайлаганнар иде. Ә узган ел партоешма секретаре вазифаларын да аңа тапшырдылар. Әйе, халык аның эшеннән бик канәгать...

Кинәттән генә Гайфетдин Вәлиевичның исемен ишетеп, Нургаяз бүген тагын үткәннәрен исенә төшерде. Әлегә кадәр ул турыда уйларга ничектер вакыты юк иде. Ә артыңа әйләнеп карау, мөгаен, кирәктер дә ул. Кешеләрне шулай яхшырак аңлыйсыңдыр.

* * *

...Авылдан чыгып, өч чакрымнар үтү белән, ат өстеннән пар күтәрелде. Ә ул, хайван, алда ашыгыч эш көткәнне аңлаган кебек, юлны әзли-әзли һаман алга йөгерде. Чана табаннары, мамык өстендә баргандай, бер йомшак кар өстеннән шудылар, бер, каты юлга чыгып, кетердәп алдылар да тагын тавыш-тынсыз гына көртләр өстеннән үттеләр.

Олаучы, егерме-егерме биш яшьләр тирәсендәге егет, дипбегәсен әледән-әле каккалап барды:

— На, малкай! Озакламый җитәбез, чыда.

Ул Нургаязның толып чабуын җил үтмәслек итеп кыстырып куйды, ә аннан соң аның борчулы йөзенә карады.

— Фельдшер бу[illegible] эшләве авырдыр, абый, ә!

— Төрле вакыт була, авыры да, җиңеле дә, — диде Нургаяз.

— Кешеләр менә хәзер рәхәтләнеп йоклый, ял итә. Ә сезне йокыгыздан уяталар. Төнлә буранда менә чит авылга барасыз, — ул беравык тын гына барды да тагын сөйли башлады. — Мин дә, унны бетергәч, врач булырга уйлаган идем.

— Ә нигә, барып чыкмадымыни! — Нургаяз, кызыксынып егеткә табанрак борылып ятты һәм игътибар белән аның йөзенә карады. Ул тулы битле, кысынкырак күзләре, буранга каршы юлны шәйләп барганлыктан, ярык булып кына күренә иде.

— Барып чыкмады шул, — егет авыр сулап куйды. — Керү имтиханнарында немец теленнән биреп булмады. Бүлмәгә килеп керүем булды, миңа немецча сораулар яудыра башладылар. Мин берни аңламый карап торам. Алар да бер-берләренә карашалар. Шуннан соң русчалап: «Билет ал», — диләр. Ну, беттем болай булгач, дим. Тәки шулай булды. Нәрсә, без соң авылда күп укыдыкмени аны! Ике ел укытучысы булмады, аннары...

— Икенче елны әзерләнеп барырга кирәк иде.

— Кирәк иде дә, ярәр инде. Колхозга кайтып эшли башладым. Быел кердем менә авыл хуҗалыгы институтына. Читтән торып укыйм. Ә шулай да врач булу ошыйрак төшә иде.

— Син Гайфетдин Вәлиевич малае буласыңмы!

— Юк, алар каршысында торам. Авырый, диделәр, барып кайтмассыңмы, дип ялынып керделәр. Нәрсә ялындырып торырга, «Барам хәзер», — дидем...

Нургаяз кергәндә, Гайфетдин Вәлиевич бөгәрләнеп кроватьта ята иде. Аның кызгылт битенә, тар гына маңгаена борчак зурлыгында тир бөртекләре бәреп чыккан. Аксыл-зәңгәр күзләре калайланып калганнар иде.

— Агуланган, — диде Нургаяз. Гайфетдин Вәлиевичның хатынын икенче бүлмәгә чакырып. — Гадәттә, без андыйларны больницага алып барабыз. Мондыйда кая чыгасың, кайчан барып җитәсең. Чыдамавы да мөмкин. Тиз генә җылы су әзерләгез! — ул хуҗа хатынга тагын кайбер күрсәтмәләр бирде дә Гайфетдин Вәлиевич яткан бүлмәгә кереп китте.

Вакыт үтте. Төнлә балкып торган электр лампалары көн яктысында тоныкланып калдылар. Нургаяз, бүлмәдән чыгып, кульяулыгы белән битендәге тирне сөртеп алды.

— Булды, — диде ул, куркудан ни әйтергә белми аптырап басып торган хатынны күреп. Шул ук минутта бүлмә ишеге тагын ачылды. Анда, еш-еш сулап, эчке киемнән генә Гайфетдин Вәлиевич басып тора иде.

— Карале, иптәш Хәертдинович, син бездәме әллә хәзер!

— Юк, Гайфетдин Вәлиевич, болай, принципны бозып кына, — диде Нургаяз һәм, пальтосын киеп, сумкасын кулына алды да мыек астыннан гына көлеп чыгып китте.

*Эдуард Касыймов*

# КАРТ РӘССАМ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Байтак вакытлар буровойларда булганым юк иде. Август азакларында бер иртәне, хәзер текә Кама ярында урман эчендә бораулыйлар икән, тукта, хәлләрен белешеп, бер әйләнеп кайтыйм әле дип, җилкәмә җәйге пальтомны элдем дә вахта автобуслары тукталышына чыктым.

Тукталышка шактый кеше җыелган иде инде: менә-менә вахта автобуслары килеп җитәргә тиеш. Көн сүрән, салкынча, күктәге күе соры болытларны Урал ягына таба куып, салмак җил исә иде. Ләкин бораулаучыларның күбесе, үткән көннәрнең коры-кызу булуына алданып ахры, бик җиңелдән киенгәннәр, арада тик ике-өч кешенең генә өстендә брезент спецовка күренә иде.

Бораулаучылардан таныш-белеш аз түгел микем, шуларның бер-икесе белән хәләхвәл сорашып, әңгәмә куертып җибәрергә торганда, ни күрим, безнең каршыда гына, урам уртасындарак, озын, чал сакаллы бер карт йөренеп тора. Өстендә җиңел соры плащ, башына, шактый ук батырып, хәтта кашларын каплый язып, соргылт кепка кигән, аякларында исә, әле җәй булуга карамастан, җылы ботылар. Карт нечкә баулар белән бәйләнгән озынча тартма сыман бер нәрсәне һәм ныклап төреп алынган галәмәт зур зонтны кулына тоткан көе, автобус көтүчеләренең әле бер төркеме, әле икенчесе янына килә, ләкин аларга сүз катарга базмыйча, янәдән читкә, асфальт юл кырыена китеп бара.

— Тукта, бу теге кем түгелме соң!

Янымда басып торган бораулау мастеры Әсгат Абдуллин:

— Ә кем булыр дисең син аны! — дип кызыксынды.

Аны-моны аңлатып тормастан, мин мастерның беләгеннән тотып алдым:

— Әйдәле, барып сорашыйк-белешик әле! Әмма карт янына килгәч, ничектер каушап куйдым, кыяр-кыймас тавыш белән аңардан:

— Ялгышмасам, сез художник Максимов буласыз... Шулаймы! — дип сорадым.

Картның куе сакал-мыеклары арасында чак кына елмаю балкып алды.

— Әйе, нәкъ үзе: Кондрат Максимов.

— Бик шәп, бик әйбәт, — дидек без Абдуллин белән һәм, үзебезнең дә исем-фамилияләрне әйтеп, картның сөякчел кулын кыстык. — Сез каядыр барырга җыенгансыз шикелле...

— Җыенган идем шул: Кама ярына, Богатый Логка бармакчы идем... Белә торгансыздыр, ул төштә Кама аша электр линиясе атлап үтә... Бик тә матур җирләр! Тик аптырашта калдым әле: Богатый Лог янындагы буровойга нинди автобуста, кемнәргә ияреп барыйм икән, ә!

Мин Абдуллинның кырыс йөзенә текәлдем. Ул чак кына уйланып торды да:

— Шайморатов буровое... Ләкин өченче көнме, кичәме аның бригадасы икенче буровойга күчкән булырга тиешле, — дип куйды.

Безне бүтән бораулаучылар да әйләндереп алган иде инде, алар арасыннан берничә кеше:

— Кичәгенәк күчтеләр...

— Хәзер анда безнең автобуслар керми инде, — дип, мастерның сүзен куәтләделәр.

— Моннан дүрт-биш көн элек кенә ул буровойда дөбер-шатыр эшләп яталар иде, инде бетереп тә куйганнар, кара син, ә! — дип гаҗәпләнде карт рәссам, һәм аның эчкә баткан күзләре янәдән аптыраган-каушаган төс алды.

Абдуллин әйләнә-тирәбездә басып торган бораулаучыларга күз йөртеп чыкты.

— Егетләр, ничек уйлыйсыз, Богатый Логка кем буровое якынрак: безнекеме, әллә Гайнуллинныкымы!

Шундук төрле яктан көр тавышлар яңгырады:

— Безнеке! Безнең белән барсын!

— Юк, Гайнуллинныкылар автобусына утырсын!

Әсгат бәхәснең куерып китүенә ирек куймыйча:

— Булды, аңлашылды, — дип кырт кисте һәм олы, таза гәүдәсен карт рәссамга таба борды. — Пожалуй, сезгә Гайнуллинныкылар белән бару уңайлырак булыр: юл Богатый Логтан әллә ни ерак үтми... Кирәк җирдә төшереп калдырырлар.

— Бергә барырбыз: минем дә юл шул якка, — дидем мин, сүзгә катышып. — Кая, Кондрат Евдокимович, әйберләрегезне күтәрешим әле...

— Юк-юк, хафаланмагыз: бик җиңел ул, — дип, әйберләрен бирергә теләмичә, артка таба чигенде юлдашым һәм, югарыдан, промысел, бораулау конторалары ягыннан, бер-бер артлы тезелеп килгән автобусларны күреп, кинәт кабалана башлады. — Әнә киләләр дә инде... Кайсына утырырбыз икән!

Автобуска кергәч, бораулаучылар Кондрат Евдокимовичка иң алдагы урынны бирделәр, ә мин арткарак үтеп утырдым. Машинабыз нефтьчеләр поселогыннан түбәнгә, шәһәргә таба җай гына кузгалып киткәндә, юл читендә, бик зур эш башкарган кеше кебек, авызын колагына тикле ерып, мастер Әсгат Абдуллин гына кул селтәп басып калды. Ул ялда иде.

Мин карт рәссамны күзәтеп барам. Баштарак ул бер нигә исе китмәгәндәй,

ваемсыз бер кыяфәт саклап, тыныч кына утыра бирде, әмма бер кадәр юл үткәч, түзмәде ахры, якындагы бораулаучы егет белән ни турындадыр гәп корып җибәрде.

Барасы юлыбыз әллә ни озын түгел иде: унбиш-егерме минуттан мондагы халык тарафыннан Олы Бор дип йөртелгән урман борынын кисеп үткәннән соң, асфальттан уңга төшеп, басу юлы белән киттек. Тагы да бераздан хәрәкәтсез-җансыз торган бер буровой каршысына җиткәч, автобусыбыз шып туктады.

— Рәхим итегез! Богатый Лог дигәннәре шушы була инде, — диде шофер, елмаеп. — Юлда ничек итеп калдырып китим ди мин сезне! Ә без өлгербез әле: әйләнечтән юл туры, диләр бит.

Без мондый хәлне көтмәгән идек, сөенеп:

— Рәхмәт инде сезгә, бик рәхмәт! Юлларыгыз уң булсын! — диештек.

Ишек ябылган чагында бораулаучылардан кемдер:

— Тынычлап эшләгез: кайтканда кереп алырбыз! — дип кычкырды.

Кондрат Евдокимович автобус артыннан беравык карап торды да тирән сулап:

— Яратам мин алар арасында йөрергә... Гаҗәеп кешеләр: әйтсәләр, турыдан ярып әйтәләр, эшләсәләр, янып эшлиләр... Безнең интеллигентларның күбесе алар янында чүпкә дә тормый... Каян килде икән аларга шундый күркәм сыйфатлар, ә! — диде һәм шундук үзенә-үзе җавап та бирде: — Мөгаен, хезмәтләре авыр булгангадыр...

Мин янәдән аның әйберләрен күтәрешергә теләгем барын белдердем. Ул, кинәт айнып киткәндәй, миңа сәерсенеп карап алгач:

— Туктагыз әле, сез нишләп монда төшеп калдыгыз! Үз йомышыгызны онытгыгызмы әллә! Кем булып эшлисез! — дип бер-бер артлы сораулар тезеп китте.

— Сезнең кебек үк мин дә матурлык эзлим, — дидем мин һәм үземнең кемлегемне әйттем.

— О, алай булгач, күтәрегез... Сез хәтта күтәрешергә тиешле дә, — дип, ул миңа бер кулындагы әйберләрен тоттырды.

Без үр өстеннән түбәнгәрәк, Каманың биек ярына таба атладык. Бу тирәләрдә минем беренче тапкыр булуым иде, һәм сокланып, гаҗәпләнеп әйләнә-тирәмә күз салдым. Якында гына, могезен соры күккә төбәп, буровой вышкасы утыра, аның артында гына ерак-еракларда гигант адымнар ясап килгән югары вольтлы электр линиясе Кама аша сикереп үтә, түбәндә, дугайланып аккан киң елга битендә, дисталәгән суднолар узыша, ә монда, үр өстендә, бездән ук атарлык җирдә, сирәк куаклар арасында салам түбәле бернечә йорт күренә... Нинди контраст! Карт рәссамны күңеле тикмәгә бу тирәгә тартмагандыр...

Ә ул, минем матур әдәбиятка кагылышым барлыгын белгәч, шул хакта сүз кузгатып җибәрде һәм «кыска язарга кирәк, кыска, тормыш хәзер шулай куша», дип өледән-өле кабатлый торды, сүз уңаенда хәтта зур бүләккә лаек булган калын бер романны туздырып та ташлады. Әмма аның матур әдәбиятны тәнкыйтьләве озакка сузылмады, текә яр ягыннан куе куаклар белән уралган түгәрәк бер алангa җиткәч, ярым пышылдауга күчеп:

— Карагызчы, зинһар: нинди киңлек, нинди хозурлык, нинди төсләр! — дип кулларын күкрәгендә кушырды.

Дөресен әйткәндә, минем әллә ни ис китмәде, чөнки Кама аръягының иксез-чиксез киңлекләре соры томан эчендә югала, еракгагы урманга тикле күгелҗемләнеп тору урынына, шул ук соргылт төсләргә манчылган елга да, моңсу, шадра җыерчыклар белән капланып, күңелсез генә агып ята, ә без басып торган түгәрәк аланчыкка сибелгән кыр чәчәкләре берөзлексез сибәләгән яңгыр астында боегып башларын түбән игәннәр.

— Яңгыр туктап, аязып китсә, тагын да матуррак булыр иде, — дидем мин.

— Миңа табигатьнең теләсә кайсы вакыты матур... Бигрәк тә алтын көз, — диде Кондрат Евдокимович, һәр сүзенә басым ясап. — Ә яңгыр дисәң... иртән башланса, тиз туктый ул, куркасы юк... Әйдәгез әле, арырак барып карыйк әле...

Яр буйлап ары атладык. Хәзер картның үз-үзен тотышында, хәрәкәтләрендә зур гына үзгәреш тойдым мин: ул әледән-әле як-ягына карангалый, аз сөйләшә, сөйләшсә дә, сүзләрне ничектер әкрен, беркадәр калтыранган эчке тавыш белән әйтә иде. Ары барып әллә ни чыкмады: анда яр читендәге агачлар калкурак та, куерак та булып, елга ягына күренешне томалыйлар иде. Картым баягы түгәрәк аланга кире кайтырга теләде һәм һич уйламаганда миннән әйберләрен алды.

— Минем монда шушылай озак кына буталып йөрүем ихтимал... Сез инде, зинһар, үз эшегез белән барыгыз, вакытыгызны юкка сарыф итмәгез, — диде ул.

— Юк-юк, вакыт санаулы түгел минем, — дип, мин баш селкедем.

Шул чак капылт кына минемә: «Ах, җүләрнең җүләре... Соң картның табигать кочагында, үз стихиясендә япа-ялгызы каласы килә — шуны да сизмисең, җитмәсә, үзең дә иҗат кешесе», дигән уй килеп, үз-үземне әрләп алдым һәм:

— Ярый, Кондрат Евдокимыч, уңышлар телим сезгә! Без әле очрашырбыз, — дип карт рәссамга кулымны суздым.

Ул, әйберләрен кочаклап, яр буйлап кирегә таба китте, ә мин еракта урман өстендә калкып торган буровойга карап атладым.

...Карт рәссам ялгышкан икән: иртән башланган яңгыр төш тирәләренә туктамады гына түгел, киресенчә, торган саен көчәя барды. һәм мин диспетчерлык станциясенең ачык кузовлы машинасында бер буровойдан икенчесенә йөри-йөри, кичкырын Алабугага мәнмә булып кайтып кердем. Менә картның хәле борчый иде. Кайткач, тиз генә өс-башны алмаштырдым да күршедә яшәгән бораулаучыга кереп белештем: картны вахта автобусында исән-имин алып кайтканнар икән.

— Соң ничек, бик чыланмаганмы!— дип сорадым мин күршемнән.

— Чыланмаган кая!.. Шулай да сынатасы килми, һаман да шаярткан була... Боевой карт! — диде ул, тел шартлатып.

* * *

Икенче көнне мин нефтьчеләр гостиницасына бардым. Дежурный апа:

— Уникенче бүлмәгә, үзебезнең люкска урнаштырдык без художник бабайны... Ләкин өйдә юк бит әле ул, — диде.

— Нигә, ул шулай соң кайтамыни!

— Бүтән көннәрдә бу вакытта өйдә була торган иде, ә бүген иртән киткән иде, әле һаман юк... Әнә тегендә аны ике пенсионер баядан бирле көтеп утыра инде...

Фойедагы диванда тын гына утырган шактый олы яшьләрдәге ике агай янына килдем. Икесе дә чип-чиста итеп кырынган, ләкин җыерчыклы йөзләрендә, озак котүдән ахры, арганлык аермачык беленә иде. Күрештем, таныштым. Берсе, киңрәк җилкәле, тазарак гәүдәлесе — Илья Григорьевич Краснов, икенчесе, гәүдәгә дә җыйнаграк, йөз-кыяфәткә дә картрак күренгәне — Яков Степанович Колпаков икән.

— Икәүләп килгәнсез... Сезнең йомыш зурдан, ахрысы! — дидем мин, алар янына диванга утыргач.

— Зурдан дип... әллә ни түгел, — дип, утырган җирендә авыр гына кузгалып алды Илья Григорьевич. — Минем кыз Мәскәүдә художественный училищеда укый бит. Ялга кайткач, Максимов белән бергә сурәт төшереп йөрде ул. Шулай йөргән чагында, бер көнне теге әйткән минем кызга: үнсигезенче елда үлем баржасы торган җир белән кызыл гвардеецларны аклар аткан яр буен төп-төгәл күрсәтүчеләрне каян табыйм икән дип... Менә шул хакта килгән идек.

— Ә сез ул җирләрне төгәл беләсезмени!

— Белмәскә, без икебез дә үнсигезенче елда да, унтугызынчыда да үзебезнең Алабуга тирәсендәге сугышларда катнашып йөргән кешеләр... Азин дивизиясендә, — диде Яков Степанович, сүзгә кушылып. — Партиягә дә шул заманда ук кердек без...

— Оһо, сез ул елларның җанлы шаһитлары икәнсез әле!

Алабуга тирәсендә булган сугышлар турында минем беркадәр ишеткәнем бар иде инде, әмма моңарчы ул сугышларда турыдан-туры катнашкан кешене очратканым юк иде. Форсаттан файдаланып, җайлап-иплэп сораштыра башладым.

Гражданнар сугышының Кама — Вятка буйларында барган өлешеннән байтак кына кызыклы хәлләр турында ишеттем. Сөйләшеп утыра торгач, вакытның үткәнен сизми дә калганбыз. Бер заман сәгатькә күз салсам, инде тугыз тулып килә. Шунда гына үземне дә өйдә кеше көтеп утырырга тиешлеге исемә төште. Кайтмыйча булмый. Бу ике ветеран белән икенче бер вакытта иркенләбрәк утырырга сүз куешып, адресларын язып алдым да урынымнан кузгалдым.

— Кондрат Евдокимычны көтәсе булсагыз, минем килүем турында әйтмәсәгез дә ярый. Аның бүлмәсендә телефон бар, үзем шалтыратырмын әле, — дидем мин алар белән саубуллашканда.

Картлар художникның кайтуын көтәргә булып калдылар...

* * *

Карап торырга сабыр һәм тыныч холыклы күренгән бу карт эшкә килгәндә бик тә бимазалы кеше икән.

Иртәгә нефтьчеләр бәйрәме дигән көн иде. Без Кама буе нефть промыселлары идарәсенең парткомында сөйләшеп утыра идек. Кинәт ишек ачылып китеп, аннан Кондрат Евдокимыч атылып килеп керде.

— Иптәш кем... энекәш! — диде ул, партком секретаре Малышкин каршысында туктап. — Нишлибез, күргәзмәне клубта бүген ук, менә хәзер ук куя башларга кирәк бит.

— Әле вакыт бар... Мастерскойда рамнарны эшләп бетерсеннәр инде... Сез борчылмагыз, барысы да вакытында эшләнер, — диде теге, бер дә исе китмәгән тонда.

— Борчылмаска, ул күргәзмәне мин оештырам лабаса... Кичен тантаналы утырыш башлаганда, оятка калмыйк тагы.

— Сез, Кондрат Евдокимыч, һич тә хафаланмыйча, гостиницага кайтып, ял итеп ятыгыз. Кирәк чагында без сезне дәшеп алырбыз. Күргәзмәнең әйбәт оештырылуында без, нефтьчеләр, сездән дә күбрәк кызыксынабыз бит, — дип сүзгә кушылды идарәнең профсоюз җитәкчесе Маслов.

— Сез алай дисез дә бит... Моңдый көнне сез үзегез дә тыныч кына ята алмас идегез әле, — диде карт калтыранган тавыш белән һәм, башын түбән иеп, ишеккә таба юнәлде.

Мин дә аның артыннан чыктым.

— Алар әйткән сүзләрендә тормастай кешеләр түгел, сез юкка пошынасыз, — дидем мин, аны коридорда туктатып. — Соң, эшләр ничегрәк, әйбәт барамы!

— Бара да, бармый да...

— Нишләп тагы! Әллә бер-бер хәл булдымы!

— Мин һаваны әйтәм әле. Кичә Кама буена төшкән идем. Үлем баржасы торган җирне язып алырга ният бар иде. Аз гына утырган идем, и култы җил, и тотынды Кама үкерергә... Эскиз ящигымны куя гына алмыйм... Табигатьнең авыр җәрәхәтенә тидем, ахрысы... Шуннан, кайтып китәргә булып, әйберләремне күтәрдем дә тауга менеп киттем.

— Менгәнем бар, хәтәр текә, хәтәр биек бит ул.

— Шулай икән. Аз гына менәм дә туктыйм, аз гына менәм дә тын алам. Бер заман йөрәгем бугазыма килеп терәлде, инде шунда егылырмын, бетәрмен дип торганда, әллә тау үзе булышты инде, җиңә алдым тагы үзен... Күрәсез, тәндә җан бар бит әле, — диде карт рәссам, күзләрендә шаян очкыннар уйнатып, һәм ки-

сәк, очып китәргә җыенган коштай, типпе-неп алды. — Туктагыз, сезнең белән сөйлә-шеп дөньямны онытмыйм инде мин: ба-рыйм әле мастерскойларына...

Әлбәттә, нефтьчеләр үз сүзләрендә тордылар: тантаналы җыелыш башланган-чы, күргәзмә әзер булды. Клубның шак-тый зур фойесында бөтен стеналар дияр-лек Максимовның рәсемнәре һәм этюдла-ры белән тулган иде. Ул аларның күбесен бу җәй азакларында Алабугада яшәп эш-ләгән икән. Нефтьчеләр төркем-төркем бу-лып та, ялгызлап та, стенадагы гүзәллек-тән күзләрен аерып алалмыйча, җәй гына йөренәләр. Кама буйларыннан, урман-күл-ләрдән үзләренә бик күптәннән таныш бул-ган күренешләр алдында озаграк басып торалар, кай арада бәхәсләр дә кубып-ку-бып куя. Карт рәссам үзе дә шунда. Ул хәзер тынып, хәтта нәүмиз булып калган кебек тоела: кулларын артка куеп, чак кына бөкрәя төшеп, бер кырыйда мыштым гына йөренә...

Аны идарәнең иң алдынгы кешеләре белән бергә президиумга дәшеп, алдагы рәткә, кызыл комачлы өстәл янына, утырт-тылар. Доклад тәмамлангач, хезмәт батыр-ларын бүләкләүләр булды. Идарә башлыгы Борис Львович Сапгир, үз кешеләренең исемнәрен әйтмәс борын ук, әле тынып калган залга, әле янәшәсендә нигәдер бө-решебрәк утырган чал сакаллы картка ка-рап, болай диде:

— Дуслар, безнең бүгенге олы бәйрә-мебезгә, нур өстенә нур булып, зур шат-лык өстәлде: безгә кунакка Татарстанның халык художнигы хөрмәтле Кондрат Евдо-кимович Максимов килде. Залда сез аның рәсемнәрен күреп, зур ләззәтләр кичер-гәнсездер, дип уйлыйм... Былтыр әлмәтле-ләр Кондрат Евдокимовичны шушындый ук тантаналы бер җыелышларында үз арала-рына «Почетлы нефтьче» итеп алганнар иде. Ул безнең дә кадерле дустыбыз, без-нең дә сөекле кешебез... Иптәшләр, без-нең хисләребезне баетып, күңелләребез-не үстереп җибәргәне өчен барыбызның исеменнән рәхмәт әйтеп, Кондрат Евдоки-мовичка «Почет Грамотасы» тапшырырга рөхсәт итегез!

Моны залдагылар дәррәү алкышлар бе-лән каршы алдылар. «Почет Грамотасы» карт рәссам кулына күчкәч, дер-дер кал-тыранып-тирбәлеп торды. Әйе, бу хәлне ул көтмәгән иде булса кирәк, тәмам каушау-дан җавап сүзен дә бик әкрен, бик азап-ланып әйтте, аның сүзләре куе сакал-мыек-лары арасында буталып, адашып калгандай булды...

* * *

Берничә көннән соң миңа, Алабугадан китеп, ике атнадан артыкка сузылган сә-фәрдә йөреп кайтырга туры килде. Киткән чагымда ул: «Мин монда сентябрь беткән-че торам әле, без очрашмый калмабыз», дигән иде. Кайткач та аның янына бардым. Барсам, аңарда Кама буе нефть промысел-лары идарәсе башлыгы Сапгир белән аның хатыны Нина Петровна утыра. Минем кебек үк хәл белешергә килгәннәр.

Тышта тәнне куырып, зәһәр җил исә, монда да, идәндә кирпечләр өстендә электр плитәсе яныл торуына карамастан, баз салкыннары хөкем сөрә иде. Кондрат Евдокимович өстенә калын сырма, аякла-рына җылы туфлиләр киеп алган.

— Зыян юк, болай гына... — диде ул, минем белән җылы гына күрешкәч. — Бо-рынга томау төшеп, бераз баш авыртып торды.

Нина Петровна врач кеше, ул карт рәс-самга яндырып карап алды да:

— Җил дими, яңгыр дими, урман-кыр-ларда йөрсен дә кеше, салкын тимәсен, ди... Саклана белмәгәнсез, — дип куйды һәм картка тегеләй дип, болай дип киңәш-ләр бирергә тотынды. Азактан, картның кул селтәнүләренә игътибар итмәстән: — Иртәгә җылы бирә башлаячаклар, ди әнә... Өйдә утырырсыз, ике-өч көн үтмичә, сезгә урамга чыгарга рөхсәт юк, — дип кырт кис-те.

— Сез нәрсә, мине монда бикләнеп ятарга килгән дип беләсезме әллә... Юк инде, акыллым, булмас андый хәл, — диде рәссам.

Алар шулай бәхәсләшеп торган арада, Борис Львович миңа:

— Сырхауласа да, диванда кул кушы-рып ята торганнардан түгел шул, — дип пышылдады һәм өстәлдә аерым-аерым тә-линкә-табакларда өелеп торган күгелҗем йөзем белән эре-эре аксыл-кызыл алма-ларга күрсәтте. — Менә бу аңа ашар өчен китерелгән нәрсәләр... Ә ул аларның мыс-калына да тимичә, сурәткә төшереп яткан... Кондрат Евдокимович, теге натюрмортла-рыгызны күрсәтегезче безгә...

Кондрат Евдокимович, врач белән бә-хәстән аеруларына куанып, әллә никадәр картиналар арасыннан кирәклеләрен бик тиз табып алды. Натюрмортлар соклангыч төстә гаҗәеп бер нечкәлек һәм нәфислек белән эшләнгәннәр иде. Аерата йөзем... Бәрәм-бәрәм авызга кабып җибәрәсе ки-лә...

— Алмаларны Чаллыдан горком секре-таре җибәргән... Ә болары, йөзем, монда Алабуганың комлы тау битендә Борис Львович бакчасында үскән җимешләр. Тәм-ләп карагыз, чын йөзем тәмнәре бар, — дип елмайды рәссам. — Тартынмагыз, аша-гыз! Хәзер ашарга ярый инде аларны.

Сапгирлар, картның тизрәк савыгуын теләп, кайтып киткәч, Кондрат Евдокимо-вич чал башын селкә-селкә бүлмәдә йөре-неп алды.

— Урамга чыкма, имеш... Ә күргәзмәгә рәсемнәрне кем әзерләр! Уен эш түгел, күргәзмә юбилейный... Бөек Октябрьгә ип-ле ел...

Бер мәл тын торгач, күкрәгеннән яңа-дән ялкын бәреп чыкты:

— Русның бөек художнигы Шишкин як-лары бу. Мин үземне аның эзләренә басып йөргәндәй хис итәм: шул ук Богатый Лог, шул ук Афанасьево урманы... «Корабельная роща»ны хәтерли торгансыздыр! О, юк, мондагы һава, мондагы табигать үзе миңа тик торырга кушмый...

Картым беркадәр тынычлана төшкәч, мин югында ясаган рәсемнәрен күрсәтүен үтендем. Ул стена буена идәнгә иң башта өч портрет тезеп куйды. Аларның икесен мин шундук таныдым: Краснов белән Колпаков. Өченчесе, шундый ук олы яшьләрдә, әмма кара озын мыеклы, үткен карашлысы миңа таныш түгел иде.

— Танайка авылыннан. Кызыл партизан Парков, — дип аңлатты Кондрат Евдокимович. — Авырып киткән булсам да, авылына барып төшердем. Ул бит аклар тарафыннан атылып та, ничектер әҗәлгә бирешмичә, исән калган һәм соңыннан тагын сафка басып Азин дивизиясендә сугышып йөргән кеше...

— Бик тә гайрәтле күренә шул, — дип җупләдем мин.

— Мин үзем портретчы түгел. Шулай да ясадым инде: мондый кешеләрне ничек калдырып китәсең, ди! — Беравык тын торгач, авыр сулап куйды ул.

— Шәп портретчы булмавыма уфтанам... Нигәме! Соң Казанның үзендә генә дә тарихка кереп калырдай кешеләр әзмени! Бүгенге көндә танылган язучыларны гына алыйк — бөтен бер плеяда бит алар... Эх, үзләре исән чагында, сурәтләрен буяуга төшереп алсаң иде... Югыйсә без, алар дөнья куйгач кына, фотоларына карап, нидер ясап чыгарабыз... Халык сөйгән язучыларының чын йөзен күрергә теләмимени!

— Соң алар, безнең сурәтне ясагыз әле дип, ялынып йөри алмыйлар бит инде... Тыйнаксызлык булыр иде ул, — дидем мин.

— Әлбәттә. Инициатива монда художниклар кулында. Җитәкче оешмаларның берәрсе кузгатып та җибәрсә, тагын дә әйбәтрәк булыр иде.

Портретларны табигать күренешләре алыштырды. Арадан берсе минем күңелгә аерата сеңеп калды: көзнең кояшлы, матур бер көне. Бар дөнья алтын нурларга күмелгән. Зәңгәрсу Кама өсте тынып калган. Яр читеннән алтын яфраклы агач араларына тар гына сукмак кереп югала — билләһи, менә шундук кулыма кармак чыбыклары тотып, көзге яфраклар мул булып сибелгән бу таныш сукмактан, салкынча саф һаваны күкрәк тутырып сулый-сулый, атлап китәсем килде...

Иң азактан ул бөтенләй бүтән төсләргә бизәлгән пейзажны күрсәтте. Текә Кама яры, түбәндә су, ләкин елга кара-кучкыл төскә кереп дулап ята... Ярсулы җил яр өстендәге нәзек наратларның ябалдашларын түбәнгә бөккән, күктә бик түбәннән соры болытлар агыла, тик кайдадыр еракта, Кама арьягында, күк чите тар гына тасма булып, аязып килә... Ак чехлар кызылармеецларны җәзалап үтергән яр өсте иде бу...

— Авыр картина, — дидем мин.

— Әйе, монысы йөрәккә ял бирмәс... Кешене халыкның көрәшеп үткән юлы хакында уйландырырга тиешле ул...

...Сентябрьнең ахыргы көне иде, бүлмәсенә барып керсәм, Кондрат Евдокимович әлеге картинаның түбәнге өлешенә, яр читендәге бәләкәй генә сырт буйлата тимгел-тимгел итеп куе-кызыл буяу салып утыра.

— Беләсезме нәрсә, бүген мин үзем өчен зур ачыш ясадым әле, — диде ул, бик дулкынланган кыяфәт белән. — Тагын бер карап кайтыйм әле дип барсам, ни күрим, менә бу сырт өстен, нәкъ кызыллар атылган төшне, алсу-кызыл үлән басып алган... Яран үләне дип атала шикелле. Көзен әнә шулай кан төсенә кереп, янып утыра ул... Кызылларны да көз көне атканнар бит... Шаккаттым...

— Искитмәле хәл бит бу, — дидем мин, аның сүзенә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

— Әйе. Октябрьның илле еллыгына анда обелиск куймакчылар, ди... Баксаң, ул төштә әллә кайчаннан инде җанлы һәйкәл үсеп утыра икән... Менә бит табигать нишли, ә!

(Соңрак, үз күзләрем белән күрим әле дип, мин анда бардым һәм, карт рәссам сүзләренең дәреслегенә ышанып, хәйран булып кайттым...)

Кондрат Евдокимович, канәгатьләнү аша елмаеп, беравык кулларын угалап, рәсемгә карап торганнан соң:

— Казанга кайткач, мин моны зур картина итеп эшлим әле. Этюд хәлендә калдырырга ярамас, — дип куйды. — Шулай итеп, туганкаем, эшләр тәмамланып килә. Тик ни... Нефтьчеләрдән мастер Гобәйдуллинның портретын гына ясыйсым калды... Аны әле күптән түгел генә Ленин ордены белән бүләкләгәннәр икән.

— Казан качмас иде әле. Хәзер булмагез дә җылы...

— О юк, монда инде ике айдан артык ятам... Тегендә карчык та үпкәли башлаган. Шалтыраткан саен: «Киттең дә баттың, әллә берәрсенә йортка кердеңме», — ди... Хе-хе...

...Миңа янәдән бер-ике көнгә Алабугадан китеп торырга туры килде. Дүшәмбе көнне, өченче октябрьда, юлдан кайтып төшү белән үк, җилкенеп гостиницага бардым. Ләкин ул анда юк иде инде: машинага төяләп, көндезге самолетка китеп барган... Кызганыч, озатып җибәрә дә алмадым...

Гостиницадагы таныш апа:

— Булышучылары байтак иде аның... Сурәтләре ярты самолет булгандыр, — диде.

Ярты самолет сурәт... Меңләгән кешеләргә өләшү өчен ярты самолет гүзәллек, ләззәтле тойгылар һәм якты уйланулар төяп алып киткән...

Алабугада аның күргәзмәсен бик яратып карадылар.

Мин аның рәсемнәре хакында тәгәл һәм матур итеп сөйли дә алмадым. Хәер, моңа әллә ни әчем дә пошмый. Мин аның үзе турында уйлыйм. Аңа хәзер җитмеш ике яшь. Без ул үткән гомер юлының яртысына гына җиткән буын... Ләкин без, бик күпкә яшьрәк булсак та, аңардагыдай җитезлеккә, дәрт һәм якты омтылышка ия түгелбез, күбрәк илһам килгәнен көтеп, аз селкенеп, сүлпәнләнеп ятабыз... Менә шул мине еш кына уйланырга мәҗбүр итә.

**КОНКУРСКА КИЛГӘН ӘСӘРЛӘР**

*Туфан Миңнуллин*

# БӘХЕТЛЕ КИЯҮ

*Комедия бер пәрдә, ике күренештә*

**КАТНАШАЛАР:**

Харис — авыл карты.
Нәфига — аның карчыгы.
Мөнирә — кызлары.
Нури — кияүләре.
Гөлбикә — авыл карчыгы.
Исмәгыйль — бригадир.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Харис карт өенең ишек алды. Сәхнәдә берәү дә юк. Бераздан капка ачыла. Аннан шәһәрчә матур, зәвыклы итеп киенгән Мөнирә керә. Керә дә капка артындагы Нурины чакыра.

Мөнирә. Рәхим итегез, кияү. Төкле аякларыгыз белән. Гафу итегез, тун җәеп куя алмадык. Тунныбыз юк.

Нури керә. Ул да бик ыспай киенгән. Башында — салам эшләпә. Бер кулында — чемодан, икенчесендә — кармак саплары.

Мөнирә. Түрдән узыгыз, кадерле кияү.

Нури. Тукта әле син, Мөнирә. Бабай белән әби күрсә, яхшы түгел.

Мөнирә. Әһә, курка да башладыңмы? Казанда бик батырайган идең бит. Карап карыйк, нишләрсең икән? *(Тәрәзә янына барып.)* Әти!.. Әни!.. *(Җавап юк.)* Әллә өйдә юклар инде? *(Болдырга йөгереп менә. Ишектән кереп югала. Нури, чемоданын да куймыйча, ишек алды уртасында таптанып тора. Тирә-ягына карана. Мөнирә өйдән чыга.)*

Мөнирә. Менә сиңа мә! Исәнмесез, кияү. Берәү дә юк.

Нури *(чемоданны җиргә, кармак сапларын болдырга сөяп куя)*. Бай яшиләр, ахрысы.

Мөнирә. Менә, иптәш Маннуров, бәхетле кияү, сизденме инде кем кызына өйләнгәнеңне?! Кадерен бел. Борыныңны бик күтәрмә.

Нури. Да, монда кунак булырга ярый.

Мөнирә. Кая киттеләр икән?

Нури. Миңа әйтмәделәр.

Мөнирә. Әйдә, өйгә керик булмаса.

Нури. Шушы кояшны ташлап өйгә керәмме соң. Казанга кайтканда негр кебек булып кайтам, дип сүз бирдем. *(Күлмәген, майкасын салып болдыр тактасына элеп куя.)*

Мөнирә. Әни кайтса, шулай каршыларсыңмы? Килешмәс.

Нури. Мин киенгәнне күрми дә кала ул. *(Сыртын кояшка таба борып.)* Пешерә. Шәп. Эх, эчәргә су да булса. Елгагызны бик мактаган идең, әллә коенып кайтабызмы?

Мөнирә. Өлгерербез. Кайтсыннар. Әллә кая китмәгәннәрдер. Беләсеңме, Нури, нәрсә эшлибез? Баздан салкын катык алып чыгам.

Нури. Әзерләп куйганнар, ди.

Мөнирә. Курыкма, безгә җитәрлек бардыр. *(Өйгә кереп савыт алып чыга да бакча ягына китә. Нури, юынгычны күреп, шуның янына килә, сыртына юынгычтан су агыза. Капка ачылган тавышны ишетеп, тиз генә күлмәге янына ташлана, күлмәкне киеп куя. Исмәгыйль керә. Бер-берсенә карашып торалар. Нури, Исмәгыйль каршына барып, кулын суза.)*

Нури. Исәнмесез... бабай.

Исмәгыйль. Исәнме. Харис абый өйдә юк мәллә?

Нури *(Исмәгыйльгә текәлеп карап)*. Ә... ә... юк шул, абый кеше.

Исмәгыйль. Кирәк иде бит. Син кем буласың соң, танымыйм?

Нури. Мин — кияү... кияүләре.

Исмәгыйль *(күз карашы белән Нурины тикшереп)*. Кунаккамыни?

Нури. Әйе.

Исмәгыйль *(ишек алдында аунап яткан букәнне күләгәгә алып килеп утыра. Кесәсеннән кулъяулык чыгарып сөртенә. Аның йөрешендә, хәрәкәтләрендә, сөйләшүендә ниндидер сулпәнлек, эленке-салынкылык сизелә. Йөзендә нәрсәдәндер канәгать булмау билгесе ярылып ята)*. Кыздыра. Радиодан егерме биш градус дигән булалар, кая монда егерме биш, кырык бардыр.

Нури. Шәп.

Исмәгыйль. Нәрсә шәп?

Нури. Кояшны әйтәм. *(Күлмәк изүеннән күренеп торган ялангач күкрәген чәбәкләп куя.)*

Исмәгыйль *(Нурига мәгънәле карап ала)*. Үзең генәме?

Нури. Мөнирә белән.

Исмәгыйль. «Беломор»ың бармы?

Нури. Тартмыйм бит, абый.

Исмәгыйль. Шәп. *(Кармак сапларына күрсәтеп.)* Синекеләрме?

Нури. Әһе. Мөнирә әйтә, безнең елгада балык мыжлап тора, ди. Бер салганда икешәр эләгә, ди. Дөресме?

Исмәгыйль. Белмим... Кая китте соң бу Харис абый! Нәфига апа да юкмы?

Нури. Юк.

Исмәгыйль *(күккә карап)*. Бер үзе бит, каһәр. Яндыра да яндыра. Шәһәрдә сез күтеп ала алмыйсыздыр әле.

Нури. Быел яздан бирле рәтләп кызынган юк. Монда рәхәтләнәм инде. Казанга кайткач, танымаслар да.

Исмәгыйль. Берәр ракета тиеп, бәреп төшерми, ичмасам. Тәк, ярый. Харис абый кайтса, әйт әле, мине тапсын. Исмәгыйль минем исемем, бригадир. *(Нурига карап.)* Да, кияү диген. Кунакка кайткан, имеш... Тәмәке тартырга өйрән! *(Чыгып китә.)*

Нури *(аптырап)*. Нинди кеше соң бу?

Катык тутырылган савыт күтәреп Мөнирә керә.

Мөнирә. Менә рәхәтләп, кияү. Тешеңне сындырырлык.

Нури. Мин монда бер кешегез белән таныштым. Бөтенесе дә шундыйлармы сездә?

Мөнирә. Нинди?

Нури. Чырае җимерек. Сөйләшүенең рәте-чираты юк. Миндә үче бар кеше шикелле. Авылыгызның бөтен кешеләре шулай булса, аллам сакласын.

Мөнирә. Кем соң ул?

Нури. Исмәгыйль ди, бригадир ди.

Мөнирә. Исмәгыйль абыймы? Исмәгыйль абый кебек ачык йөзле, яхшы кешене син бөтен Казаннан эзләп табалмассың.

Нури. Табылмавы яхшы. Мин аңа бабай дип дәштем, җитмәсә. Әле, карточкасын бир әле бабайның, тагын бер карыйм. Бөтенесе бертөсле.

Мөнирә *(ридикюленнән карточка чыгарып биреп)*. Кайтып төшәргә өлгермәдең, ошамый да башлады.

Нури *(үз-үзенә)*. Авыл кешесе авыл кешесе инде. Мәгънә җитеп бетми.

Мөнирә. Шул авыл кызына өйләндең ич.

Нури. Синең авыллыгың... Тәмәке тартырга өйрән, ди.

Мөнирә. Я, ярый. Киткәндә икенче төрле сөйләрсең әле. Мә салкын катык, кызуыңны басар. *(Болдырга менеп, чиләк-көянтә алып төшә.)*

Нури. Кая барасың?

Мөнирә. Салкын чишмә суы алып кайтып куйыйм. Әйдә минем белән.

Нури. Да ну, кәефем бозылды.

Мөнирә. Чебен тимәс чер итәр. Бигрәк тиз бозыла кәефең. *(Көлеп чыгып китә. Нури көлмәгән салып әлә дә катык ашый башлый. Гөлбикәнең тышта Нәфига, Нәфига дигән тавышы ишетелә. Нури тиз генә көлмәген киеп куя.)*

Гөлбикә *(керә)*. Нәфига! Нәфига күрше! *(Җавап ала алмагач, болдырга бара. Нурины күрә.)* Абау җаным, кем бу? *(Гөлбикәнең үзүзен тотышында да Исмәгыйльгә хас сүлпәнлек, чырае да шулай ук караңгы.)*

Нури. Исәнмесез.

Гөлбикә. Шөкер әле. Нәфига күрше өйдә юк мәллә?

Нури. Юк шул.

Гөлбикә. Менәтерә, ә. Кирәк иде. Син кем соң?

Нури. Кияүләре.

Гөлбикә. Шулаймыни... Кирәк иде бит, ә. *(Чыгарга таба борыла. Алгы белән бәрелеп кармак сапларын аудара)*. Хәерсез. *(Кармак сапларын алгы белән этәреп җибәрә дә чыгып китә.)*

Нури *(тәмам аптыраган)*. Әллә нинди кешеләр. *(Мөнирә кайта.)*

Мөнирә. Ни сөйләштегез Гөлбикә әби белән? Әкәмәт карчык ул. Бер сөйләшә башласа, качып котылып булмый. Әнәсеннән алып җебенә кадәр җентекли-җентекли сораша. Без кайтканны белеп, кунакка чакырырга кергәндер әле. Чакырдымы?

Нури. Чакырды. Әйдә, җыена башла. Син нәрсә, мине үртәр өчен мактыйсыңмы авылың кешеләрен. Дөресен әйт инде, исең китмәсен, безнең авыл кешеләре шулай томана инде, диген.

Мөнирә. Юкны сөйләмә.

Нури. Болары чепуха. Әби белән бабай шундый булса, нишләрсең. *(Капкадан Харис белән Нәфига керәләр. Аларның хәл-халәте дә Исмә-*

*гыйль белән Гөлбикәнеке кебек. Мөнирә, әтисе белән әнисен күрүгә, аларга ташлана, икесен дә кочып үбә.)*

Мөнирә. Без инде үпкәләп китәргә җыенган идек. Кайтып төштек, сез юк. *(Нурины күрсәтеп.)* Әти, әнә, киявегез.

Харис *(Нури янына килеп салкын гына күрешә).* Саумы, кияү. *(Нәфига да Нури белән кул биреп күрешә, ләкин «Саумы кияү»дән башка сүз әйтми. Шатлыклы очрашуны көткән Нурига бу чөй өстенә тукмак кебек тәэсир итә. Ул бөтенләй коелып төшә).*

Нәфига. Нигә өйгә кермәдегез?

Мөнирә *(шат).* Киявегез сездән башка өйгә керергә ашыкмасын әле, дидем.

Нәфига *(болдырга таба атлап).* Әйдәгез.

Нури *(үзен-үзе кулга алып, шат булырга тырышып).* Ә без сынатмадык, салкын катык белән сыйландык.

Нәфига *(исе китмичә генә).* Әйбәт булган.

Мөнирә. Ә мин салкын чишмә суы алып кайтып куйдым.

Харис. Шулаймы... Ярар... Нәфига, самоварыңны куй. Сусап кайтканнардыр. Мин озакламый кайтырмын.

Мөнирә. Әти, кая барасың?

Харис. Исмәгыйльне күрәсе иде. Барыгыз керә торыгыз. Бар, кияү, ятсынма. *(Ишектән кереп киткән Нәфига артыннан Мөнирә белән Нури иярә. Нуриның атлавы атлау түгел, әйтерсең лә аны бауга бәйләп сөйриләр. Ишек алдында бер ялгызы калган Харис әрле-бирле йөренә, Нуриларның чемоданын, гамьсез генә, җирдән алып болдырга меңгерә. Кармак сапларын сөяп куя. Аннан капка ягына сүлпән генә атлый. Өйдән Нәфига чыга.)*

Нәфига. Сиңа әйтәм, кер инде. Барырсың... Бергәләп чәй эчеп алыйк.

Харис туктап уйланып тора да теләр-теләмәс кенә өйгә керә. Пауза. Өйдән Мөнирә чыгып чиләк белән су алып кереп китә. Бераздан ишектә Нури күренә. Йөзе ачулы.

Нури. Ял ит, күңел ач, Нури, рәхәтлән!

Мөнирә чыга.

Мөнирә. Нигә чыгып киттең?

Нури. Нишләргә кирәк иде соң миңа? Авыз йомыш уйнап утырыргамы?

Мөнирә. Сиңа ошап булмас инде.

Нури. Ә сиңа ошыймы? Кунак каршылауның нәрсә икәнен беләм мин.

Мөнирә. Кунак дип биеп йөрмәсләр инде.

Нури. Алар миңа килсә, мин биер дә идем, бишкә ярылыр идем. Юк, монда нәрсәдер бар. Бөтенесе бергә сүз куешкан кебек.

Мөнирә. Арыганнардыр. Яшьләр түгел ич.

Нури. Эш аруда түгел. Аларның минем белән сөйләшәселәре килми. Минем кайтуым ошамый аларга. Бәлки, башка кияү көткәннәрдер. Сиңа кияүне үзләре сайлап куйганнардыр.

Мөнирә. Әллә ниләр уйлап чыгарма. Язган хатларын үзең укый идең.

Нури. Хатта нәрсә язмаслар.

Мөнирә *(пауза).* Нигә миңа ачуланасың? Әйт соң үзләренә.

Нури. Шул гына җитмәгән. Кыйнап чыгарырга да күп сорамаслар.

Мөнирә. Җүләрләнмә. Әйдә, ал чемоданны. Чәй кайнагандыр.

Нури. Чәй кирәкми миңа, ачык чырай кирәк.

Мөнирә. Ачык чырайны бүтәннәрдән генә таләп итмә. Үзең дә бит әле турсаеп йөрисең.

Н у р и. Әллә бер үзем дурак кеше шикелле шаркылдап көлеп утырыйммы? Минем нинди икәнне беләсең. Берәүнең дә зарланганы юк.

М ө н и р ә. Акрын, кемдер чыгып килә.

Х а р и с *(өйдән чыга)*. Нигә монда торасыз? Барыгыз, чәй өлгергән. Гаеп итмә, кияү, мин барып кайтыйм әле. *(Капкадан чыгып китә.)*

Н у р и. Я?

М ө н и р ә *(ул да уйга калган)*. Ни булган соң, чыннан да. Минем әти болай түгел иде. Үзләре моннан бер ай элек кунакка чакырып яздылар. Әллә берәр кайгылары бармы?

Н у р и. Булса әйтсеннәр, мин бит алар кайгысыннан көләргә кайтмадым.

М ө н и р ә. Әйттем мин сиңа, телеграмма сугыйк, дидем. *(Нәфига чыга)*.

Н ә ф и г а. Нигә кермисез? Әйдә, кияү.

М ө н и р ә. Әни...

Н ә ф и г а. Нәрсә, кызым?

Капкадан Г ө л б и к ә керә.

Г ө л б и к ә. Нәфига! Син кирәк иең.

Н ә ф и г а. Нәрсә, Гөлбикә апа?

Г ө л б и к ә. Сүзем бар ие. *(Нәфига Гөлбикә янына бара. Гөлбикә аны капканың теге ягына алып чыгып китә. Нури аптыраганнан көлеп җибәрә.)*

М ө н и р ә. Нигә көләсең?

Н у р и. Юк, мин бернәрсә дә аңламыйм. Кайда соң без? Кешеләр арасындамы? Сөйләсәң, ышанмаслар. *(Көлеп.)* И, Казанда йөргән булдык. Әбигә ефәк күлмәк, бабайга костюм эзләдек. Бүләк, янәсе. Рәхим ит, Нури, бир бүләкләреңне. Тик кемгә бирергә? Кеше юк ич бу өйдә. Китик булмаса, Мөнирә.

М ө н и р ә. Кая?

Н у р и. Казаныбызга.

М ө н и р ә. Нури!.. Нигә син...

Н у р и. Я, кирәкми. Синең дә кәефең бозылса, аннан бөтенләй түгәрәкләнә. Нәрсәгә шулай борчылырга соң? Гомер яшисеме? Ун көнгә түзәрбез, шулай бит. Курыкма, сиздермәм. Янымда син булгач, миңа шул житкән. Көндезләрен кызынырбыз, балык чирттерербез. Кайтып йоклар өчен урыннарын бирсәләр...

М ө н и р ә. Алай түгелләр иде бит алар, алай түгелләр иде. Әгәр бердәнбер кызлары аларга артык икән...

Н у р и. Ачуланыша күрмә тагын. Үзләре беләләрдер. Син мине яратасың, мин сине яратам. Иң кирәклесе шул... Әйдә, ясаган чәйләрне эчик. Без андыйлар түгел. Без кунак та була беләбез, кунак та итә беләбез.

П ә р д ә

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шул ук урында бара. Бер көн узган. Вакыт иртә. Кояш яңа гына чыгып килә. Пәрдә ачылганда Н ә ф и г а, тыз-быз чабып, әле өйгә керә, әле чыга. Иртәнге аш әзерләп йөрүедер, күрәсең. Менә ишектә М ө н и р ә күренә. А н а б е л ә н к ы з болдырда очрашалар.

Н ә ф и г а *(шат. Әйтерсең алыштырып куйганнар)*. Тордыңмы, кызым, бәләкәчем? *(Кочагына алып сөя.)* Бердәнберем минем. Кияү йоклыймы?

М ө н и р ә. Йоклый.

Н ә ф и г а. Йокласын, тимә. Йокысы туйганчы йокласын. Атаң белән сөйләштек әле. Бигрәк килмәгән җире юк инде. Холкы да төсе-бите, буе сынына тартса, дөнья күрке инде, дөнья күрке. *(Мөнирәгә сокланып*

*карап.)* Кызыбыз да шул безнең былбылга тиң. Юынып ал, кызым, умывальниккә яңгыр суы тутырып куйдым. Хәзер сөлге алып чыгам. *(Мөнирәнең аркасыннан сөеп кереп китә. Мөнирә әнисенең кинәт үзгәрүенә аптырап калган.)*

Нәфига *(әйләнеп чыгып)*. Кызым, иртән нәрсә ашарга ярата кияү?

Мөнирә. Белмим тагын. Ни булса, шуны ашый иде.

Нәфига. Син ир хатыны, кызым, белергә кирәк... *(Мөнирәнең кәефе юклыгын күреп.)* Нигә син алай күңелсез, кызым. Кичә дә үпкәләгән сыман нәрсәдер әйттең бугай.

Мөнирә. Әйттем дә, ишетмәдегез бит.

Нәфига. Әллә куйган ризыкларым ошамадымы?

Капкадан Харис керә.

Харис. Бәй, кунак кызы торган да. Нихәл, кызым? Нигә алай иртә? Кияү кайда?

Нәфига. Шул кадәр кычкырмасаң. Әкрен. Йоклый.

Харис *(әкрен тавыш белән)*. Уятырга кирәк. Йоклап ята торган көнме?

Нәфига. Тик кенә тор. Кайчан уянасын үзе белер.

Харис. Йокласын алайса, тимәгез. *(Ашыгып капкадан чыга башлый.)*

Нәфига. Кая китәсең тагын?

Харис. Марзияны әйтәм, кибетен һаман ачмый.

Нәфига. Ачмаса, сиңа нигә?

Харис. Сабыр, анасы. *(Чыгып китә.)*

Нәфига *(кинәт исенә килеп)*. И, ходаем, мичем нишли икән? *(Ашыгып кереп китә. Мөнирә юына. Нури чыга.)*

Нури. Хәерле иртә, Мөнирә. *(Кояшка карап)*. Соңга калганмын балык чирттерергә.

Мөнирә. Син әнине күрдеңме?

Нури. Юк. Кухняда нишләптер йөри иде. Күренмәскә тырышып чыгып шылдым. Ә нигә?

Мөнирә. Болай гына.

Нури. Ну, кызык иттем үзем дә. Сез дәшмәсәгез, мин дә дәшмим, дидем дә авызга су кабып тик утырдым. Мин йоклагач та шулай сөйләшми утырдыгызмы?

Мөнирә. Сөйләштек.

Нури. Рәтләрәк кияү таба алмадынмыни, диләрме?

Мөнирә. Аларның синең белән миндә эшләре юк иде. Бүген күрсәң үзләрен.

Нури. Нишләгәннәр?

Мөнирә. Телләрендә кияү дә кияү.

Нури. Хәерлегә булсын. *(Тирә-якка карап.)* Әллә янгыр яуган инде.

Мөнирә. Төн озын дөбер-шатыр килеп яуды. Сизмәдең дә, йокладың.

Нури. Димәк нервылар нык. *(Зарядка ясый.)* Үзгәргәннәр, дисеңмени?

Мөнирә. Үзгәрмәгәннәр. Элеккечә.

Нури. Яхшы. Үрдәкләренә каз куя беләбез без. Болай эш чыкмас, ошамаса да, булганына риза булыйк дигәннәрдер.

Ишектә Нәфига күренә. Күренә дә яңадан кереп китеп, кулына кружка тотып чыга.

Нәфига. Кияү дә торган икән. Әйбәт йокладыңмы, кияү! *(Кружканы Нурига биреп.)* Мә, кияү, шуны эчеп җибәр, иртән сауган сөт бик файдалы була ул. *(Нури кружканы ала.)*

Нәфига. Тынычлап йоклый да алмагансың инде. Без авылда шулай иртә торабыз шул. Әйдә тынчу да. Печәнлеккә урын әзерләргә кушармын бабаңа. Кайнар коймак чыгармыйммы, кияү?

Нури *(гаҗәпләнгән)*. Рәхмәт, әби. *(Әби сүзен кияве теленнән ишеткәч, Нәфиганың йөзе тагын да ачыла. Куанудыннанмы, оялуыннанмы йөгереп диярлек кереп китә.)*

Нури. Әкәмәт!.. Әкәмәтище!.. Үзгәргәннәр. *(Юына. Капкадан Гөлбикә керә. Йөзе шат, йөрүендә җиңеллек, яшәреп киткән кебек.)*

Гөлбикә. Торгансыз да икән. Йокыгыздан бүлмим дип, керергә базмыйча йөрдем. Кул биреп күрешеп чыгыйм, дидем. *(Күрешә. Нуриның аркасыннан кагып сөя.)* Бәхетле кияү. Авылыбызның бәхете гел бәхетле кияүләрдән. Кайсын гына алып карама, бөтенесе шул. Сания кызы Әлмирәнең Исламы дисеңме, Хәйруллалар кияве Саматны әйтәсеңме, үзебезнең Фәритебез тагын... Кызларыбыз әйбәт шул. Әйбәткә әйбәтне насыйп итә. Әле бер көн Хәмдебану ахирәт белән сөйләшеп утырдык. *(Мөнирәгә.)* Сине искә төшердек. Кияүгә чыкканыңны ишеттек тә, без карт-корының шул бит инде аның, бик сөенештек. Теләк теләдек. Ишеттек, Нәфига белән Харис күршеләрне туегызга чакырганыгызны да ишеттек. Бара алмадылар шул. Йорт жирегезгә үзем күз-колак булырмын, дип тә әйтеп караган идем. Мин карчыкка ышанмадылар, ахрысы. Менә шулай яшәп ятабыз инде без, Мөнирә кызым. Көн туса, көнем күршеләремдә үтә. Үзең эшкә ярамый башлагач, кешеләр эшләгәнгә куанып шөкер кылып йөрисең инде. Кияүнең исеме ничек?

Нури. Нури.

Гөлбикә. Абау, бигрәк килешле исем. Нурисламмы, Нуриәхмәтме?.. Юкса, безнең авылда кайберәүләр балаларына аллә ниткән исемнәр тагып бетерәләр. Әлбирт, Мәлбирт. Әйтә дә торган түгел. Үзебезнең кияү Миңнефәрит тә баласына Ирек дип кушкан. Хатлары килде. *(Нәфига чыга.)*

Нәфига. Нихәлләрең бар, Гөлбикә апа?

Гөлбикә. Бүген аллага шөкер, диген, Нәфига күрше. Менә мин тагын кереп җиттем әле.

Нәфига. Әйдә, әйдә үт.

Гөлбикә. Юк, үтеп тормыйм, Нәфига күрше. Менә кияү белән Мөнирәне алмага кергән идем.

Нәфига. Иртә таңнанмы? Әле аларның ашаган-эчкәннәре дә юк.

Гөлбикә. Аллага шөкер, ашарга да, эчәргә дә хәстәрләдем.

Нәфига. Юк, юк!.. Әле үзебезнең дә күреп туйганыбыз юк.

Гөлбикә. Күреп туймадык дип. Үзегез дә керегез. Бездә рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз. Бәхетле кияүнең аягын бусагама бастырасым килә ләбаса.

Нәфига. Кыстама да, Гөлбикә апа. Кайнар коймагым өстәл өстендә. Әйдә, үзең кер. Әйдә, кияү, суынганчы ашап алыгыз. Кая китеп югалды инде бу Харис?

Гөлбикә. Башта безгә кермәсеннәр дисеңмени инде, Нәфига?

Нәфига. Керерләр. Сезгә дә керерләр.

Гөлбикә *(Нәфига өстендәге ефәк күлмәкне күреп)*. Абау, нинди затлы күлмәк кигәнсең, Нәфига.

Нәфига. Киявем бүләге, Гөлбикә апа.

Гөлбикә. И-и-и!.. Кайлардан гына таптыгыз бу чама затлы әйберне? Сөбханалла!

Нәфига. Хариска — кәчтүн-чалбар.

Гөлбикә. И-и-и! Менәтерә. Вәт бит, ә! Ала белеп алуларын әйт әле син!

Капкадан атылып Исмәгыйль килеп керә.

Исмәгыйль. О-о! Менә бу миңа ошый. Мин килгәнне көтеп то•

ралар. Шулай, бригадирны аягүрә каршыларга кирәк. Я, саумы, кияү? Әби белән бабай мунча ягып чабындырдылармы әле?

Нафига. Синең шул. рәтле сүзең булмас.

Исмәгыйль. Нигә, ялгыш әйттем мәллә? Нәфигә апа, барыгыз әле, өйгә керегез. Бар син дә, Гөлбикә әби. Мөнирә син дә.

Гөлбикә. Нигә куасың әле, син кем?..

Исмәгыйль. Барыгыз инде, начальство әйткәнне тыңлагыз. Ашыгам, эшем күп.

Нәфига, Гөлбикә, Мөнирә кереп китәләр.

Исмәгыйль. Я, нихәл соң, кияү?

Нури *(ни булганын һаман аңлап бетермичә)*. Яхшы.

Исмәгыйль. Молодец! Исемең ничек дидең әле? Хәтердән чыккан.

Нури. Мин әле сезгә аны әйткәнем дә юк. Нури.

Исмәгыйль. Нури? Молодец!.. Кара әле, Нури кияү, мин ашыгам, әйеме. Син ничек болай, ниме?

Нури. Нәрсә?

Исмәгыйль *(кесәсеннән аракы шешәсенең башын күрсәтеп)*. Аз гына, очрашу хөрмәтенә димме.

Нури. Без кичә очраштык бугай ич.

Исмәгыйль. Аны искә алма әле син. Әйдә, Нафига апа сизгәнче... Хатын-кызның күрмәве хәерле. Бәхетле син, Нури туган. Шуңа хөрмәтем. Кунакка чакырып сыйлау икенче булыр, бусы бераз гына, аяк өстән генә. Закуска әйбәт, каклаган каз боты. *(Кесәсеннән кәгазьгә төргән каз боты чыгара.)* Күп түгел, икебезгә бер чөлли. Әллә син андыйны авызга алмыйсыңмы? Алай булса, гафу ит.

Нури. Юк, эш анда түгел. Уңайсыз.

Исмәгыйль. Син миннән тарсынма, туган. *(Кесәсеннән рюмка чыгара.)* Менә Марзиядан городской стакан да ала килдем. *(Рюмкага салып)*. Тот әле. Юк, син әллә ни уйлама. Мин дә монын белән артык шаярмыйм. Бүген көне шул. Я!.. *(Нури эчә.)*

Исмәгыйль. Молодец! *(Каз ботын Нурига тоттырып, үзенә салып эчә. Нури каз ботын кире кайтара.)*

Исмәгыйль. Юк. Миңа кирәкми. *(Һава иснәп.)* Вуздыхы әйбәт, закускаң бер читтә торсын. Тагын бернеме?

Нури. Җитәр.

Исмәгыйль. Ну, анысын үзеңә кара. Мин тагын берне эмәллим дә, шабаш. *(Салып эчә дә шешә белән рюмканы болдыр астына яшереп куя.)* Калганы торсын. Алай-болай кирәк булса, карарсың. Мыскыл итә дип уйлама, Харис абый аракы белән дус түгел, аракы эчкән кешеләрне җене сөйми. Ә син яшь кеше.

Тәрәзә ачыла. Анда — Нәфига.

Нәфига. Кияү, Исмәгыйль, өйгә керегез.

Исмәгыйль. Булды. Кем, Нәфига апа, бетте, хәзер керә. *(Тәрәзә ябыла.)* Нури туган, бүген кич безгә килеп чыгарга вакыт табарсыз бит? Кәнишне! Молодец!

Нури. Кичә мин сезне бабай дип торам.

Исмәгыйль. Ә, чепуха. Була ул. Унбиш көн кырынмаган идем. Бүген менә унсигез яшь. Ярамый, туган, кырынмый йөрергә. Бригадир гына булсаң да, командир, синнән үрнәк алалар. *(Кармак сапларына күрсәтеп.)* Синекеләрме? Әйбәт. Ну, мин сиңа күрсәтәм балыкның кәттәләрен. Салган саен кызылканат. Мотоциклда йөри беләсеңме?

Нури. Беләм.

Исмәгыйль. Молодец! Кирәк булганда оялма, Исмәгыйль абый, бир диген, вәссәлам. *(Болдыр астына ишарәләп.)* Тагын бергә нәфесең юкмы?

Нури. Юк, юк. Рәхмәт.

Исмәгыйль. Кичәге өчен мина ачуланмыйсыңмы?

Нури. Нигә?

Исмәгыйль. Рәтләп сөйләшеп булмады ич. Ачуланма, туган, дөнья бит.

Нури. Кичә чыннан да икенче төрле идегез шул. Сез генә түгел, Гөлбикә әби дә, бабайлар да. Бүген бөтенесе үзгәргән.

Исмәгыйль. Булгандыр, булгандыр. Син үзең шәһәрдә туып үскәнме?

Нури. Әйе.

Исмәгыйль. Сиңа аңлавы читенрәк шул алай булгач. Болай бит ул, туган...

Харис кайтып керә.

Исмәгыйль. О-о! Әнә хуҗа да кайтты. Саумы, Харис абзый.

Харис. Ничәнче тапкыр исәнләшәсең инде. Кияү, нихәл, әйбәт йокладыңмы?

Нури. Рәхмәт, бабай.

Харис. Я, Исмәгыйль, ни әйтерсең безнең кияү турында?

Исмәгыйль. Молодец!

Харис. Бабасына охшаган. Нәкъ менә шундыйдыр дип уйлаган идем.

Нури. Иртә мактыйсың түгелме, бабай?

Харис. Алай димә, кияү, синең хатларыңны укыйбыз без. *(Нури кулындагы каз ботын күреп ала да мәгънәле итеп Исмәгыйльгә карый.)* Син нәрсә?

Исмәгыйль *(Нурига күз кысып алып)*. Юк инде, что син, Харис абый, Гөлбикә әби күчтәнәче ул. *(Үзе аягы белән болдыр астындагы шешәне эчкәрәк этәргә тырыша. Шешә ауган тавыш ишетелә.)*

Харис. Тукта әле, тукта. *(Иелеп болдыр астына карый. Шул вакыт чалбар кесәсеннән шешә төшә.)*

Исмәгыйль *(көлеп)*. Эләктең бит, Харис абый.

Харис. Әкрен, Нәфига апаң ишетмәсен. *(Шешәне кесәсенә салып куя.)* Айга-елга бер аракы эчәсең, шуны да әдәм рәтле итеп эчмисең. Нәрсә, безнең өйдә урын беткәнмени?

Исмәгыйль. Ашыга идем, Харис абый. Аннан соң өйдә Нәфига апа, Гөлбикә әби дигәндәй.

Харис. Шулай дисәң инде. *(Кесәсендәге шешәгә ымлап Нурига.)* Кияү, син гаепкә алма инде. Мин үзем болай да... Бердәнбер кияү кайткач...

Исмәгыйль. Ярый, мин тайыйм әле, Нури кияү.

Харис. Кая ашыгасың? Әнә болыт та килә. Кияүгә дә күңеллерәк булыр. *(Нәфига чыга.)*

Нәфига. Уф алла. Кайткансың икән. Әйдәгез инде. Кияүне ачтан үтерәсез ләбаса.

Көчле күк күкрәү ишетелә. Харис, Исмәгыйль, Нури күкрәү тавышы ишетелгән якка карыйлар. Болдырдан Нәфига төшә. Өйдән Гөлбикә белән Мөнирә дә чыгалар.

Харис. Килә, тагын килә.

Гөлбикә. Рәхмәтең белән, хәерең белән кил.

Исмәгыйль. Бүген төнлә уянып китсәм, Харис абый, ява бит ява. Урамга йөгереп чыгып бөтен авылны уятырдай булдым.

Харис. Ә кем йоклаган дисең син. Җаны булган кеше шундый чакта йоклап ятамы? Тагын бер-ике көн генә яумаса да, барысы янып-көеп бетә иде бит.

Гөлбикә. Киявебез, Харис күрше, киявебез алып килде яңгырны. Бәхетле кияү. Рәхмәт төшкересе. Гомере озын булсын.

Нури. Мин?.. Ничек?

Харис. Син кияү. Мөнирә кызым белән икәүләп. Игеннәр генә түгел, үзебез дә кара көя башлаган идек. Яшәүнең кызыгы бетә башлаган иде. Хәтта сез дә күзгә күренмәдегез кичә. Кайгыбыз бик зур иде шул.

Нури. Без кайтмасак, яумас идеме?

Нәфига. Анысын кем белә инде, кияү. Тик сез кайткач явуы хак.

Мөнирә *(көлеп)*. Кичә куркуга төшердегез...

Гөлбикә. Шул яңгыр булмау галәмәте. Игеннәр тишелеп чыкканнан бирле тамып та караганы юк иде бит. Аптырагач, кичә әллә алладан сорап карыйкмы, дип, карт-корыны җыярга уйлаган иек. Нәфига күрше риза булмады. Кеше көлдереп йөрмәгез дип әйтте.

Исмәгыйль *(көлеп)*. Алладан сораганны Нури кияү алып кайтты диген, Гөлбикә әби.

Нури. Безнең заманда яумаса да куркыныч түгел. Монда булмаса башка җирдә ява.

Мөнирә. Икмәкне башка җирдән китерерләр иде.

Харис. Хикмәт андамыни, балалар. Ачтан үлүдән курыкмыйбыз. Тик җир кысыр кала иде бит. Янган-көйгән басуларыбызга карап, читтән килгән икмәкне ашаудан да авыр нәрсә бармы соң? Үзебезнең кулыбыз белән иккән бер телем икмәкне кулда тотып торуга ни җитә. Сөенечебез дә, көенечебез дә шул җир безнең. Шәһәр кешесе булгач, син моны аңлап та бетермисеңдер, кияү. Рәнҗемә. Рәхмәт сиңа. Бәхет алып кайттыгыз, куаныч алып кайттыгыз.

Исмәгыйль. Әнә ышна җиренә сибә дә башлады.

Гөлбикә. Җир тәмам туена, алла боерса.

Исмәгыйль. *(Сикеренгәләп такмаклый.)*

> Яңгыр яу, яңгыр яу!
> Майлы ботка казанда,
> Тәти кашык базарда.

Эх, малай чак искә төшеп китте.

Харис. Тәти кашык, майлы ботка киявем белән кызыма. Кара, кияү, синең яңгырың бу! *(Харисның сүзен җөпләгәндәй күк күкри.)*

Пәрдә.

*Шәукәт Галиев*

## Ислемай

Абыем минем Исмай,
Өстәлендә ислемай,
Учына тортә-тортә,
Өз-әзләп кенә сертә.
Мин дә исен ошаттым,
Селкеп-селкеп бушаттым.
Абый эштә, белмәде —
Коенганны күрмәде.
Манчылып бер хуш искә
Мактаныймчы дус-ишкә!

Әнисәләр, Хөснијләр,
Әй иснииләр, иснииләр,
Йөгерсәм дә калмыйлар,
Борыннарын алмыйлар.
Арттан кычкыра Хисмәт:
— Зинһар, тагын бер иснәт!

Шактый шулай йөгергәч,
Хуш ис аңкытып йөргәч,
Кайтыйм дисәм төшке ашка,
Бәла булды бит башка —
Адаштырып та булмый,
Алмаштырып та булмый,
Бетми генә ислемай —
Киемдә дә ислемай,
Иренемдә дә ислемай,
Кулымда да ислемай,
Борынымда да ислемай,
Сизәр абыем Исмай.
Кирәк бераз көтәргә,
Җилдә җилләп үтәргә.

Кайтсам да утлар сүнгәч,
Истән белделәр кергәч...
Бер орышты да бетте —
Абыем гафу итте.
Малайлар учеклиләр:
— Исемең ничек? — диләр,
Абыең Исмай, диләр,
Үзең Ислемай, диләр...
Ах, бу малайларны!





## Актүш һәм велосипед

Чирәмгә егып салып,
Кулыма ачкыч алып,
Велосипед төзәтәм.
Актүш читтән күзәтә,
Борганны карап тора,
Әйтерсең, аңлап тора.
Аягыма сьрыша,
Булышырга тырыша.
Төзәтешим, ди ахры,
Тизләтешим, ди ахры.
Велосипед Актүшкә
Кирәк димсең ни эшкә?
Бик кирәк ул аңарга —
Арттан җәяү чабарга!

## Басмалар саный Әсма

Бер басма да ике басма,
Өч басма да дүрт басма...
Мена еска, төшә аска
Басмалар саный Әсма.
Биш басма да җиде басма...
Тукта, Әсма, ялгышмаска,
Бу басмага басма, Әсма,
Яңадан саный башла!

Бер, ике, өч, дүрт, биш басма,
Баскычта йөри Әсма,
Басмалар саный Әсма.

Сезгә нәрсә, кызык кына
Читтән кызга каравы.
Белмисез лә, һай авыр ла,
Һай читен лә бу дөньяда
Унга хәтле санавы!



## Шакир һәм шикәр

Шак-шок сугып, шакмаклап,
Шикәрне ваклап-ваклап,
Әби-бабай чәй эчә.
Ә Шакир киресенчә —
Шикәрен генә ала,
Урамга чыгып чаба.
Бабай шелтәләп кала:
— Чәен эчми, хәйләкәр,
Кимерә генә шикәр!
Тешләрең синең нишләр?

Шакир шикәрне ашый,
Чабып чыгып барышлый
Сарбаена да ташлый.

Сарбай каба сикереп.
Шакир әйтә Сарбайга
Бабасы күк иттереп:
— Чәен эчми, хәйләкәр,
Кимерә генә шикәр!
Тешләрең синең нишләр?



## Колмак

Куакка колмак чорналган,
Кадакка колмак чолганган,
Колмакка колмак чорналган,
Колакка колмак чолганган,
Колгага колмак чорналган,
Кулга да колмак чолганган,
Чолганып шундый чуалган,
Чуалып шундый чорналган —
Колмакның очы югалган!


## Кыяр-кыймас

Койма кырында кыяр,
Кыям карый кыяр-кыймас.
Кыям кочагына куяр,
Кыям комга кыяр коймас!

## Багана

Кайтып килә Дәлфәт урманнан,
Шундый арыган, шундый арыган —
Кайта торгач өстерәлеп,
Туктый баганага бәрелеп,
Маңгае белән терәлеп.
Малайның бик ачуы чыга,
Киерелеп торып бер суга:
— Син багана арымаган,
Урманга да бармаган,
Көне буе тик торган,
Төне буе тик торган,
Гомер буе тик торган!
Кит юлдан!!


Тора-тора да багана тыңлап,
Җавап бирә малайга зыңлап:
— Кара, башыңны күтәребрәк,
Кәпәчеңне артка этәребрәк —
Бер дә утырмыйча басып торам,
Иңемә чыбыклар асып торам!
Кемгә дә сиздермибез без
арыганны,
Күрәләр бары үлеп ауганны...



ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

# ТУКАЙ АСТРАХАНЬДА

«Тукай турында замандашлары» исемле китапка Г. Утабалиев, Х. Гайфетдинов һәм В. Алиевлар язып калдырган истәлекләр кертелгән. Сүз дә юк, ул истәлекләрдә шагыйрьнең Астраханьга сәяхәте хакында байтак мәгълүмат бар. Ләкин Габдулла Тукайны күреп калган яки аның белән очрашып сөйләшкән астраханьлылар шушы өч исем белән генә чикләнмиме, билгеле.



Шагыйрьне күреп белгән һәм аның бу сәяхәтенә башлап сукмак салышкан өлкән буын астраханьлыларның тагын берсе — Н. Шабанов. Үзенең сөйләвенә караганда, 1910 елда ул Казанга килә һәм, Г. Камал ярдәмендә, Габдулла Тукай белән таныша. «Казанга килгәннең икенче көнендә иртән, — дип сөйли Н. Шабанов, — мин тукталган номерның ишеген какты лар. Ишекне ачсам, Г. Камал белән миңа таныш булмаган бер егет басып тора. Ул егет Г. Тукай булып чыкты...». Аның сүзләренә караганда, әнә шул көннәрдә үк Тукай Астраханьга барырга вәгъдә бирә.

1911 елның язы килеп житә. Сәламәтлеге нык какшаган булуга да карамастан, пароходлар йөри башлау белән, шагыйрь юлга чыга. Г. Тукай үзе болай яза: «Быел апрель ахырында Казаннан «Самолет» ширкәтенең «Тургенев» нам пароходына утырып, Әстерханга сәфәр иттем»[1]

Астрахань пристанендә Тукайны танышлары, дуслары каршы ала. Алар арасында С. Рәмиев, Ш. Гайфетдинов, З. Солтанов һәм башкалар була. Мәгълүм булганча, Астраханьда берничә көн торганнан соң, Г. Тукай, Идел аръягына чыгып, укытучы Ш. Гайфетдиновта тора. Анда ул кымыз эчә, яхшылап ял итә. Ике атнадан соң шагыйрь янадан Астраханьга кайта, көннәрен күбрәк «Идел» газетасы редакциясендә уздыра, берничә көн Н. Шабановта да кунак була.

Габдулла Тукайны күреп калган астраханьлылардан Нуржиһан апа Ваһапова болай сөйли: «Тукай буйга тәбәнәк, ябык, ак йөзле. Өстендә кыек якалы кызыл төстәге күлмәк, кара чуклы пута белән билен буган иде. Кара чалбар, аягында штиблет, башында фуражка, жилкәсенә накидка салган иде...».

Санаулы вакыт тиз үтә. Ниһаять, китәр көннәр дә якынлаша. 1911 елның 6 июнендә, «Василий Лапшин» исемле пароходка утырып, Г. Тукай Казанга кайтырга чыга. Һәм шагыйрь китеп берничә көн узуга, «Астраханский край» газетасында (1911, 10 июнь) түбәндәге мәкалә басыла:

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. 4 том. Казан. 1956 ел, 95 бит.

## «АСТРАХАНЬ ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫННАН

6 июнь кичэ Астрахань татарлары өчен үтә тантаналы бер кич санала алган булыр иде, чөнки бу кичне яшь татар шагыйре Г. Тукаев Астраханьнан китте. Бирелә ул бер ай чамасы булды. Ләкин шагыйрьне шактый ямьсез кыяфәттә рәсемгә төшергән бер карикатурчыны санамаганда, Астрахань татар интеллигентларыннан берсе дә шагыйрь белән кызыксынмады.

Шигырьләренең көче, мәгънәви тирәнлеге һәм киң колачлы булуы ягыннан Тукаевны даһи шагыйрь дип әйтергә мөмкин. Моннан берничә ел элек аның кайбер шигырьләре хәтта рус әдәбиятында да тикшерелде, аның шигырьләре Пушкин һәм Лермонтов әсәрләре белән тиңләштерелделәр. Моннан, әлбәттә, татарлар өчен Тукаев Пушкин һәм Лермонтов дәрәҗәсендәге шагыйрь, дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин булыр иде. Әмма безнең Астрахань татарлары, күрәсең, даһиларның талантына бәя бирерлек дәрәҗәгә үсеп җитмәгәннәр, һәм 6 июнь көнне кичен туры килгән очрактан тиешенчә файдалана алмадылар.

Шагыйрьне якын дусларыннан һәм аны ихтирам белән укучылардан торган бер кечкенә төркем кеше озатты. Ә шунда булган бик күп татарлар, пароходчылык дебаркадерында буталып йөреп, авыз ачып калды, алар үз милләтләренең даһие һәм киләчәк буыннарының горурлыгы булган кешенең бу вакытта шунда булуын белмәделәр дә.

А. Р.»

Хәзергә бу мәкаләнең авторын ачыклый алмадык. Әмма бернәрсә бәхәссез: инде шул елларда ук алдынгы рус матбугаты Габдулла Тукайның шигъри талантына гаять югары бәя биргән.

Р. МИҢНУЛЛИН.



*Уфада Г. Тукай туктаган йорт.*

# АРХИВ КИШТӘЛӘРЕННӘН

Әкияттәге серле йомгак булып
Җырым калды сүтелеп юлымда.
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Минем соңгы йөрәк җырымда.

*Муса Җәлил.*

*Шагыйрь үзе шулай язган иде. Нәкъ ул язганча булды да: Мусаның үлемсез җырлары безгә Моабитның салкын базларында җәфа чиккән халык улының куркy белмәс кайнар йөрәгеннән аңларга ярдәм иттеләр, ул җырлар безгә Мусаның үзен, аның намуслы исемен алып кайттылар, ул җырлар шагыйрьгә үлемсезлек алып килделәр...*

*Мәгълүм булганча, Муса беркайчан да профессиональ әдәбиятчы гына булмаган. Ул гомер буе кайда да булса хезмәт иткән, шуның өстенә күп төрле җәмәгать эшләре башкарган. Үзе әйтмешли, ул «әлмисактан» бирле туктаусыз хезмәт итеп килгән. Шуңа күрә, Муса узган юлда, гүзәл җырларыннан тыш, бик күп истәлекләр, хатлар, төрле документлар калган. Алар безгә моңарчы билгесез булган сәхифәләрне ачарга, герой-шагыйрь тормышын теге яки бу яктан ачыкларга, Муса образын тагын да тулырак итеп күз алдына бастырырга ярдәм итәчәкләр.*

*Муса Җәлилнең иҗат һәм тормыш юлына караган шундый документларның байтагы Татарстан Үзәк дәүләт архивында саклана.*

*Мәскәү шәһәрендә чыгып килгән «Коммунист» газетасы ябылгач, 1935 елның 1 январенда Муса Җәлил Татарстан язучылар союзы идарәсенең ул вакыттагы председателе Кави Нәҗмигә хат яза. Татарстан язучылар союзы идарәсеннән Иҗат йортына урнашырга ярдәм сорап язылган бу хат безгә шагыйрьнең гаять зур иҗат планнары белән яшәве турында сөйли.*

*Документларның икенче зур төркеме Муса Җәлил Татарстан язучылар союзы идарәсендә эшләгән чорга карый. Аларның күбесе рәсми эш кәгазьләре: төрле белешмәләр, партия-дәүләт оешмаларына язган хатлар, гаризалар, Муса кул куйган таныклык язулары...*

*Хәтта шул рәсми характердагы документларда да без тере, җанлы Мусаны күрәбез. Безнең күз алдына ул булдыклы җитәкче, кечелекле, ярдәмчел, әйбәт күңелле кеше булып килеп баса.*

*Журналның бу санында Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлына караган шул документларның кайберләрен укучыларга тәкъдим итәбез.*

**В. СКВОРЦОВ,**

Казан дәүләт университетының
КПСС тарихы кафедрасы
аспиранты.

1

*1 январь, 1935 ел, Мәскәү.*

Кави дус!

Сиңа күптән билгеледер инде, «Коммунист»[1] газетасы бетте. Аның партияле эшчеләре — без хәзер партия Үзәк Комитеты ихтыярында торып торабыз.

Мин бу хатны сиңа шушы уңай белән килеп чыккан бик ашыгыч йомышым турында язам.

Үзенә мәгълүм, мин инде «әлмисактан» бирле һаман туктаусыз хезмәт итеп (служить итеп) киләм. 1923 — 25 ел рабфактә укыганда да хезмәт иттем. Аннан соң 2 ел тоташ хезмәт иттем. 1927—1931 елларда МГУда укыган чакта да хезмәт иттем. Әле менә «Коммунист» редакциясендә төгәл ике ел инде һичбер төрле чираттагы отпускы белән файдаланмыйча хезмәт иттем. (1932 елның маеннан бирле бер көн дә отпускы алганым юк.)

Болай гел хезмәт итү иҗат эшенә бик тыгызлый. Бөтен игътибарны, вакытны хезмәт алып бетерә дә, әсәрең өстендә онытылып, тирәнәеп, җентекләп, озаклап эшләргә туры килми. Менә шуның аркасында мин соңгы елларда бер дә ныклап бер әсәр эшли алганым юк. Әйберләр бик ашыгыч — кабаланып эшләнәләр, зур әйбер язып булмый.

Үзең беләсең, мин һәр елны язгы чәчү һәм урып-җыюда колхоз-совхозларда 3 әр — 4 шәр ай газета чыгарып, эшләп кайттым. Шул аркада бик күп яңа әйберләргә материал җыйнадым. Ләкин буш ара тапмаганга берсен дә эшли алганым юк. Мәсәлән, минем соңгы 3 елда языла башлап та, ташланган (бетмәгән) күп әйберләр бар: пьеса — «Күселәр»[2], поэмалар — «Шахмат»[3], «Директор һәм кояш»[4], «Домна № 7», шигырь белән роман — «Җир» һ. б. Бик яхшы әйберләр буласылар иде. Ләкин өстендә ныклап эшләргә кирәк.

Менә мин хәзер «Коммунист»ның бетеп, үземнең бушауны файдаланып, шушы иҗат эшемә тирәнрәк — ныклабрак тотынмакчы булам.

Ләкин ҮК мине Чиләбегә редактор итеп җибәрергә уйлый. Димәк, тагын өзлексез һәм авыр, нервалы хезмәт. Димәк, тагын яза алмыйм һәм язмаларымны бетерә алмыйм.

Менә шунлыктан мин ССП правлениесенә гариза яздым: «ҮК тан мине сорап алып калыгыз да, бушатыгыз һәм миңа бер 3—4 ай иҗат эше белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирегез», дидем. Алар шул гариза буенча сиңа хат яздылар. Мин хатны сиңа җибәрәм. Алар, хатта әйтелгәнчә, минем танылган язучы булуым турында һәм миңа хәзер язарга кирәклек турында сезнең фикерегезне сорыйлар.

Мин үзем дә бушап 1—2 ай язгач, сезгә яңа әйберләрем белән барам һәм сездә үк калырмын да. Тик хәзер миңа хәзергә бушап, иҗат йортында язып ятарга кирәк.

Синнән бик ышанып көтәм: син бик ашыгыч ССП правлениесе җаваплы секретареның хатына ашыгыч җавап язарсың. Миңа язарга мөмкинлек бирү кирәклеген, Татарстан союзы исеменнән, нык кына әйтерсең. Әйе бит, бик ышанам. Ләкин җавап бик ашыгыч кирәк. Юкса мине шушы 5—10 көн эчендә Чиләбегә җибәреп куярлар. Көтәм. Көтәм. Хатны я туры ССПга яз, я минем аркылы яз. Һәрхәлдә, минем үземне җавапсыз калдырма. Көтәм. Хуш. Башка сүзләрне икенче хатта язармын. Хуш.

**МУСА ҖӘЛИЛ.**

---

Латин алфавитында язылган бу хатның төп нөсхәсе ТАССРның Үзәк дәүләт архивында (7083 фонд. 1 опись. 54 эш. 30 бит) саклана.

Бу хат язылып бер атна вакыт узгач, 1935 елның 8 январенда Татарстан язучылар союзы идарәсенә, Кави Нәҗми исеменә, Муса Җәлилдән ашыгыч телеграмма килгән. Муса анда «иҗат ялы бирү мәсьәләсе буенча җавап көткәнлеген» әйтә. Кемдер әлеге телеграмма кәгазенә: «1935 елның 9 январенда җавап бирелде», дип язган. Хәзергә Мусага нинди җавап язылганын ачыклап булмады. Әмма шул кадәресе мәгълүм: Муса Казанга күчеп килми.

[1] «Коммунист» — (1933—1935) СССР Үзәк Башкарма Комитетының милләтләр Советы органы буларак, Мәскәүдә татар телендә чыккан газета.

[2] «Күсежамал» пьесасы беркайда да басылмаган, караламасы шагыйрьнең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтындагы архивында саклана.

[3] Әсәрнең язмышын ачыклап булмады.

[4] «Директор һәм кояш» поэмасы матбугатта Муса Җәлил үлгәннән соң гына чыкты.

Муса Жәлилне Иҗат йортына җибәрү мәсьәләсе буенча Мәскәүдән Кави Нәҗми исеменә җибәрелгән хат СССР язучылар союзы идарәсенең бланкысына кулдан язылган:

**«Союз Советских Писателей СССР**

*Москва, ул. Воровского, № 52.*

Тел. 1-16-81,
8-36-32.

**Правление**

№ ... *«1» январь, 1935 ел.*

**Татарстан Совет Язучылар Союзы председателе**

**иптәш Кави Нәҗмигә**

Безгә, үзәк «Коммунист» газетасының ябылуы уңае белән, ҮКның Культпропында иҗат эше өчен үзенә отпуск алырга ярдәм итүебезне сорап, үзәк «Коммунист» газетасы эшчесе, татар язучысы ип. Муса Жәлил мөрәҗәгать итте.

Бу мәсьәләне ҮК каршында кую һәм аннары ип. Муса Жәлилне башлаган эшләрен тәмамларга бернинчә айга Иҗат йортына җибәрү өчен, безгә Татарстан Союзы Идарәсенең бу мәсьәлә буенча белдерүе кирәк, ул, әгәр иҗат мөмкинлекләре ягыннан шуңа лаеклы кеше дип санаса, Жәлилнең үтенечен якларга яки, дәлилләр китереп, кире кагарга тиеш.

Мәсьәлә һич кичектерми ачыклауны таләп иткәнгә күрә, аны тизрәк хәл кылуыгызны һәм безгә хәбәр итүегезне сорыйбыз.

**Совет Язучылар Союзының**
**җаваплы секретаре ярдәмчесе**

(Имза танылмый. ред.)»

Хат русча язылган. Төп нөсхәсе ТАССРның Үзәк дәүләт архивында (7083 фонд. 1 опись. 54 эш. 29 бит) саклана. Хатның өске өлешендә сул почмакта: «Гомәр! Бу турыда ашыгыч җавап җибәрүегезне үтенәм. Кави. 5/I—35», дигән сүзләр бар. Инде бер тапкыр әйтелгәнчә, Муса Жәлилгә җавап 1935 елның 9 январенда язылган.

## II


### 50 номерлы йортлар идарәсенә

Дзержинский урамындагы 1/29 номерлы йортта яшәүче ип. М. С. Бубеннов талантлы совет язучысы, ул Совет Язучылар Союзы члены, Татарстан Язучылар Союзы Идарәсенең әгъзасы. Язучы һәм Татарстан Язучылар Союзы каршындагы рус секциясенең житәкчесе буларак, ип. М. С. Бубеннов зур күләмдә әдәби һәм җәмәгать эшләре алып бара. Ләкин аның язучы кеше өчен зарури булган нормаль торак шартлары юк. Үзенең гаиләсе белән ул ванна бүлмәсеннән генә үзгәртеп эшләнгән, беркайчан да кояш нурлары төшми торган, юеш һәм салкын кечкенә бер бүлмәдә яши. Шуңа күрә Татарстан Язучылар Союзы Идарәсе, бик үтенеп, язучы М. Бубенновның торак шартларын яхшыртуны сорый. Хөкүмәт карарлары буенча, аның 20 кв. метр күләмендә өстәмә торак мәйданы алырга хакы бар. Әгәр аңа зур күләмле квартира бирергә мөмкинлек юк икән, ул чагында һич югында тагын бер аерым бүлмә бирүегезне сорыйбыз.

**Совет Язучылар Союзы**
**идарәсенең җаваплы секретаре:**

**(Жәлилов)**

Рус телендә язылып, машинкада басылган бу хатның икенче нөсхәсе Татарстан Үзәк дәүләт архивыннан (7083 фонд. 1 опись. 130 эш. 3 бит) табылды. Хатның өске сул як почмагында: «№ 7 8/I-1940 г», дигән тамгалар бар. Аларны, күрәсең, Язучылар союзы идарәсенең техник-секретаре салгандыр.



Управляющему Таттосиздата

тов. АРСЛАНОВУ

На основе решения правительственной комиссии по подготовке к декаде татарского искусства тов. ЗАЛИЛОВ /Джалиль/ М.М. правлением ССП ТАССР временно освобождается от должности ответ секретаря и направляется в распоряжение Управления по делам искусств при СНК ТАССР.

В связи с этим правление ССП утвердило врид ответ. секретарем, члена правления тов. Шамова А. за период с 15/X по 15/XI-1940г.

Правление ССП ТАССР просит временно освободить тов. Шамова А. с 15/X по 15/XI-40г. от должности редактора в Таттосиздате и направ[ить] в распоряжение Союза писателей.

Ответ. секр. правления ССП ТАССР: [подпись] /ЗАЛИЛОВ/

*Татарстан китап нәшриятына җибәрелгән хат.*

**ВКП(б)ның Арча райкомына**
**Арча район Советына**
**ВЛКСМның Арча райкомына**

ТАССР Совнаркомының карары буенча, 1940 елның март ахырында язучылар җәмәгатьчелеге һәм Татарстанның барлык хезмәт ияләре күренекле татар язучысы Шәриф Камалның 30 еллык юбилей бәйрәмен уздыралар. Шул уңай белән хөкүмәт юбилей комиссиясе һәм Татарстан Совет Язучылар Союзы районнарга язучылардан төзелгән бригадалар чыгаралар һәм язучыларның укучылар белән очрашу кичәләрен уздыралар. Шул максат белән 22 мартта бер бригада Арчага бара.

Без Сезгә үтенеч белән мөрәҗәгать итәбез:

1) Язучылар бригадасының Сезнең район укучылары белән тиешле дәрәҗәдә очрашуын тәэмин итүне;

2) Бригадага эшләү өчен кирәкле шартлар тудыруны; аларны бина белән тәэмин итүне һ. б.

3) Әдәби кичәләр оештыруда ярдәм итүне; юбилей кичәсен яхшы үткәрү өчен район клубын бирүне, клубны тиешенчә бизәүне һәм җирле үзешчән сәнгать көчләрен тартуны;

4) Ш. Камал юбилеен үткәрү буенча (кичәләр, күргәзмә һ. б. ш.) җирле оешмаларга — клубларга, китапханәләргә, мәктәпләргә һ. б. ш. күрсәтмәләр бирүне.

Бу әһәмиятле политик-культура чарасын үткәрүдә Сезнең конкрет ярдәмегезгә ышанабыз.

[Очрашуларны] үткәрүнең конкрет планнарын ТАССР Совет Язучылар Союзы идарәсе члены ип. Халитов белән ачыклагыз.

Сәлам белән,

**Язучылар Союзы идарәсенең җаваплы секретаре**
**һәм хөкүмәт комиссиясенең җаваплы секретаре**

**(Җәлилов)**

---

Хат рус телендә язылган һәм машинкада басылган. Бу хатның да өске сул як почмагында: «№ 70 9/III-40 г.», дигән тамгалар бар.

—✦—

# ГАБДЕЛРӘҮФ НИЯЗБАЕВ

(1881—1920)

Рәсеменә игътибар итегез! Калын кашлар, очлары тырпаеп-күтәрелеп киткән күе, кара мыек, кискен, хәтта артык кырыс караучан күзләр... Эчке бер сизенү белән әйтергә мөмкин: тормышта ул үтә тәвәккәл һәм принципиаль кешеләрдән исәпләнгәндер. Бу кеше — күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм драматург Габделрәүф Ниязбаев. Төрле сәбәпләр аркасында, аның исеме озак вакытлар онытылып торды.



Габделрәүф Ниязбаев Оренбург өлкәсенең Сәет бистәсендә (Оренбург Каргалысы) Хәкимбай Ниязбаев исемле крестьян гаиләсендә 1881 елның 3 декабрендә туа. Авыл мәктәбендә берничә ел укыганнан соң, Казанга килеп, «Татарская учительская школа»га керә. Г. Ниязбаевның, бу мәктәпнең алдынгы укучылары белән бергә, революцион хәрәкәткә катнашуы билгеле. Ул күренекле большевик Хөсәен Ямашев белән якын мөнәсәбәттә була [1].

Беренче рус революциясе бастырылганнан соң, Г. Ниязбаев Урта Азиядә укытучылык итә. Ә Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәч, мәгариф органнарына эшкә күчә, байтак вакытлар Башкортстан мәгариф комиссариатында укыту эшләре буенча инспектор булып эшли.


Шул ук вакытта Ниязбаев әдәби иҗат эше белән дә шөгыльләнә. Аның «Беренче таң», «Борадәран Галимовлар» («Көчле вә көчсезләр»), «Кызыл истигъбаль өчен көрәш», «Гөлбостан» һәм «Кара көннәр» исемле драмалар язуы мәгълүм. «Кызыл истигъбаль өчен көрәш» драмасы 1919—1920 елларда артистка Анненкова-Бернар тарафыннан русчага да тәрҗемә ителә.

Г. Ниязбаевның «Бораләран Галимовлар» исемле дүрт пәрдәле драмасы сәхнәгә беренче кат 1918 елның маенда «Кариев идарәсендәге татар театры» тарафыннан куела [2]. «Кояш» газетасы спектакльдә җырчы һәм биючеләр тарафыннан авыл җырлары һәм биюләре башкарылачагы турында яза. Бу — «Бораләран Галимовлар» драмасында музыкаль номерлар байтак булган дигән сүз. Хәбәр өлкән буын артистларының истәлекләре белән дә раслана.


Бездә Г. Ниязбаевның «Беренче таң» исемле драмасының кулдан күчерелгән нөсхәсе бар. Тышлыгына «Уральск шәһәренең гублиты тарафыннан 1924 елның 9 маенда сәхнәгә куярга рөхсәт бирелде», дигән печать сугылган.

«Беренче таң» драмасы 1905—1907 еллар хәрәкәтендә актив катнашкан татар революционерлары тормышына багышланган. Драмада революционер Гариф Алмаев исеме белән Г. Коләхметов образы сурәтләнә дип әйтергә була. Хикмәт Гариф белән

[1] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Рус телендә. Казан. 1964 ел. 34 бит.
[2] «Кояш» газетасы. 1918 ел. 23 май.


1881 г 3 декабря


Ниязбаевның туу турында таныклыгы.


Копія съ метрики № 42, хранящейся въ приходѣ Оренбургскаго уѣзда Сеитовскаго посада мечети № 7 за 1881 годъ записанным значится въ отдѣлѣ о родившихся рожденіе

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19 | Габдрауфъ | 3 декабря | Отецъ Хакимъ-бай Ниязбаевъ | Родился въ Сеитовскомъ посадѣ |

Я Оренбургскаго уѣзда Сеитовскаго посада № 7 соборной мечети имамъ и ахундъ Хайрулла Галикеевъ вѣрно списалъ копію и приложилъ именную печать. 1901 года 7 августа [illegible]

Танылыкның русча тексты.


ОРЕНБУРГСКОЕ ОБЩЕСТВО ПОПЕЧЕНІЯ ОБЪ УЧАЩИХСЯ МУСУЛЬМАНАХЪ

ОРЕНБУРГЪ.

дня 191 г.

№

Удостовѣреніе.

Ниязбаев Абдрауф Хакимдаевич действительно состоит учителем 2го мусульманского женского училища, что удостоверяется приложением печати школы.

Заведующий школой:

Ниязбаевка укытучылык итү турында бирелгән таныклыкның копиясе.

Г. Коләхметов биографияләрендә охшаш моментлар булуда гына да түгел. Гарифның бик күп сыйфатлары (үткен фикере, революцион рухы, пафосы, якты киләчәккә зур ышанычы) Г. Коләхметовны нык хәтерләтә, Г. Коләхметов характерына туры килә. Үзенең темасы, социаль тирәнлеге, героик пафосы белән «Беренче таң» драмасы революциянең беренче елларында язылган әсәрләрнең яхшыларыннан санала. Бу пьесасы белән Г. Ниязбаев татар совет драматургиясенә революцион романтика пафосын алып килде. Композицион яктан йомшаграк эшләнүенә, кайбер образларының схематиграк булуына карамастан, бу пьеса революцион театр репертуарында зур роль уйнады, тамашачылар тарафыннан яратылып каралды.

Ниязбаевның бу әсәренә бәя биреп, шагыйрь Мирзанов болай дигән иде:

«Беренче таң» пьесасы Рәүф иптәш Ниязбаевның иң матур, иң нәфис вә иң көчле әсәрләргә дә мөхәррирнең көчле бер талантка малик икәне ялтырап ята. Шулай ук мөхәррирнең һәр әсәрендә тормышның якты һәм ямьсез, караңгы якларын күрәсең, һәр әсәрендә музыка, җыр, нәфәсәт, шигъри моназараларда, шуның белән бәрабәр хәятның коточкыч упкыннарын вәкаһкәһә ватык арган тавышларын ишетәсең дә, мөхәррир хыял күгенең бер ягында ал, кызыл нур бәйләме уйнаганда, икенче ягында күк күкрәп яшен яшьнәгәнен күрәсең...».

1 нче Армиянең сәяси бүлегенә Г. Ниязбаев тарафыннан бирелгән йөкләмәгә караганда, автор беренче рус революциясе темасына «Кызыл истигъбаль өчен көрәш» исемле биш пәрдәлек һәм эшчеләр тормышыннан «Кара көннәр» исемле дүрт пәрдәлек драмалар язып тапшырган. Моның өчен сәяси бүлек Ниязбаевка алты мең сум акча да биргән.

Г. Ниязбаевның тормыш һәм иҗатына карата материалларны барлыйсы һәм тикшерәсе бар әле. Ләкин материалларның табылган кадәресеннән дә Ниязбаевның Октябрь социалистик революциясеннән соң татар совет драматургиясенә нигез ташы салучыларның берсе булганлыгы ачык күренә.

ХӘСӘН ГОБӘЙДУЛЛИН,
сәнгать фәннәре кандидаты.

## Төрлесеннән

*Җәүдәт Фәйзи*

# ЧӘЧКАП АЛЬБОМЫ

Архивымны актарганда күземә ноталар альбомы чагылды. Аның таушалган битләрендәге Гадел Кутуй һәм Гамир Насрый кулы белән язылган шигырьләргә, поэмага, газеталардан кисеп ябыштырылган материалларга, хатларга, җыр текстларына берәм-берәм күз йөртеп чыктым. Күз алдыма моннан 25 ел элек булган истәлекле көннәр килеп басты.

1941 елның шомлы көзе иде. Гитлерчылар Мәскәүгә ыргылалар. Оборона корылмалары булдыру өчен хезмәт фронты ачылды. Институтларда, учреждениеләрдә оештырылган аерым бригадалар төзелешкә — Кайбыч, Буа районнарына җибәрелделәр.

Без дә, Татарстан радиокомитетында эшләүчеләрдән 14 кешелек бригада, Кайбыч районындагы Чәчкап авылына барып, җир казу эшенә кереште. Безнең бригадада бухгалтерлар да, машинисткалар да, дикторлар да бар иде. Алар арасында: әдәби редакциядән — Гадел Кутуй, Идрис Туктар, Гамир Насрый, музыкаль редакциядән — Рөстәм Яхин һәм мин.

Безне хуҗалары ташлап киткән, тәрәзәләре такталар белән кагылган бер өйгә урнаштырдылар. Үзебез ашарга әзерлибез, үзебез, утын тапсак, ягабыз. Шуның өчен чиратлап дежур торабыз.

Дежур көннәрендә Г. Кутуй да, Г. Насрый да, И. Туктар да, үзара дусларча шаярып, эпиграмма-парчалар язалар.

Әнә шул экспромтларның кайберләре минем ноталар альбомында сакланганнар.

Бөек Ватан сугышының авыр көннәрендә дә елмая белгән Гамир Насрыйның һәм Гадел Кутуйның бригаданың күңелен күтәрү теләге белән шул вакытта шаярып язылган әсәрләре белән укучыларыбызны таныштыруны үземнең бурычым итеп саныйм.

I

Гамир Насрый, әле Чәчкапта эшләгән чакта ук, бик тиз арада, «Ундүрт юлчы турында» дигән әкият-поэма язган иде. Казанга кайткач, ул аның бер нөсхәсен миңа бүләк итте. Анда авторның кулы белән язылган шундый сүзләр бар:

*«Җәүдәт иптәшкә!*
*Хезмәт фронтында бергә эшләгән көннәрнең истәлеге булсын!*
*Гамир Насрый. 6.II.42. Казан. Радио».*

Менә ул әсәр:

## УНДҮРТ ЮЛЧЫ ТУРЫНДА ӘКИЯТ

*I бүлек*

### Юлда күргән хикмәтләр

Мең тугыз йөз ничәнче
ел булгандыр, оныттык...
14 кеше капчык асып,
Бик еракка юл тоттык.

Килеп җиттек вокзалга,
Вагоннарга урнаштык.
Акырдык та бакырдык,
Көлештек тә җырлаштык.

Әкиятләр сөйләштек,
Гәпләштек тә серләштек,
Талаштык та дуслаштык,
Икешәр булып парлаштык.

Чөнки ирләр — яртыбыз,
Ә җидебез — хатын-кыз.
Һәркем парын сайлады,
Ятим булып калмады.

Кинәт поезд сызгырды,
Алга таба ыргылды,
Кич булды да ай чыкты,
Әй, капшыйбыз капчыкны...

Прянниклар, конфетлар,
Кыздырылган тавыклар,
Мае да һәм ите дә,
Калмады бөртеге дә...

— Барасы җир бик ерак,
Булыйк без җыйнаграк...—
Дип үзара сөйләштек,
Сак булырга киңәштек.
Ләкин инде бу вакыт
Шып-шыр иде һәр капчык.

Таң вакыты булганда,
Килеп җиттек Ормарга,
Капчыкларны астык та,
Сафка чыгып бастык та
Юналдек тагын юлга —
Чәчкап дигән авылга.

Әй, барабыз, барабыз,
Тиздән пычрак ярабыз;
Мусерма дигән авылдан
Ерак калмый арабыз.

Караңгы төшкәч кенә,
Тирләшеп пешкәч кенә,
Алда йортлар күренде...
— Мусерма шул түгелме?

Ничек фатир тапканны,
Тезелешеп ятканны,
Язып тормыйм һәркайсын,
Анысы сер булып калсын.

Иртән сәгать тугызда
Кузгалып чыктык юлга...
Мамадышка килгәндә,
Хәлдән тайдык дигәндә,

Ике кәбестә таптык,
Бүлгәләдек тә каптык.

Ләкин тамак туймады,
Эчләрдә җил уйнады,
Ә капчыкта юк икмәк,
Бер җай табарга кирәк.

Арабыздан беребез
Уйлап тапты бит рәтен,
Коткарды ул бәладән
Язам шуның хикмәтен.

— Җәмәгать,— ди ул безгә,—
Обойдем иписез дә,
Давай ашыйбыз кишер,
Пожалый ул килешер [1].

Кул чаптык, бүрек чөйдек,
— Гаҗәп шәп фикер,— дидек.
Ярты капчык кишерне
Тын да алмый кимердек.
Көч керде бит, дүрт чакрымны
Ял да итми элдердек.

Кояш баеп килгәндә,
Салтыганга җиттек без.
Кишер «зур файда бирде»,
Тәмам арып беттек без.

Юлчыларның берсе дә:
— Кишер ашыйк,— димәде.
Чөнки барыбыз диярлек
Понос белән чирләдек.

Ашамыйча йокладык,
Иртәгесен дә капмадык,
Ләкин һич сынатмадык,
Һаман алга атладык.

Тау өстеннән — ерактан
Күренде авыл — Чәчкап.
Арып-талып, янып-пешеп,
Килеп җиттек чак-чак-чак...

Нигә монда килгәнне,
Авылда ни күргәнне,
Ниләр эшләп йөргәнне,
Ишеткәнне-белгәнне,

Ничек тормыш корганны,
Нинди өйдә торганны,
Юлчылар кем булганны,
Һич тә кертми ялганны,
Язармын киләчәктә
Моннан соңгы бүлектә.

## *II бүлек*

# Без кемнәр

Унҗүрт юлчы турындагы әкиятемне,
Әгәр сезне ялкытмаса, дәвам итәм,
Һәрберсенең исемен һәм гадәтләрен
Берәм-берәм иренмичә язып үтәм.

---

Юлчыларның арасында бар бер кеше [2]
Тел остасы, тапкырлы һәм үткен кеше,
Ялкауланмый һәрбер эшкә әзер кеше,
Мулла кушкан исеме белән Гадел кеше.

---

[1] Идрис Туктар иде бу. Ж. Ф.
[2] Сүз Гадел Кутуй турында бара. Ж. Ф.

Аңа хөрмәт белән карый һәрберебез,
Аның белән рәхәт таба күңелебез.
Берсебезне дә рәнҗетми ул, кимсетми ул,
Уйламыйча беркайчан да эш итми ул.

Тик кайчакта гаделлеген ул югалта,
«Җайсыз яткан» утыннарны өйгә алып кайта [3].
Яки икмәк булган чакта шыпырт кына
Өстәл астында аягын кыймылдата [4].

---

Арабызда түгәрәк йөзле, зәңгәр күзле,
Йөрәкләрне эретә торган татлы сүзле,
Нурлы Маһи дип аталган кызыбыз бар [5].
Күңелләргә рәхәт биргән моңлыбыз бар.

Ул озын да һәм кыска да түгел болай,
Тик аз гына юанлыкка юан бугай;
Төс белән дә ул кадәрле чибәр түгел,
Ә шулай да аны сөя безнең күңел.

Бөтен кеше белән уртак фикер таба,
Ни кирәксә, шуны күршеләрдән ала.
Чиләккә дә, чүлмәккә дә аптыратмый,
Ләкин инде үзен дә ул һич алдатмый.

Дөрес булса, кичен күршеләргә кереп,
Чыга диләр бер стакан сөт чүмереп.
Имеш-мимеш аның исәбе бар икән
Кайтырга Казанга тәмам симереп.

---

Арабызда бар бер кеше — ябык кеше,
Ач янаклы, гүяки ул арык кеше.
Һәркем уйлар бу көчсез һәм хәлсез диеп,
Ләкин кан күплеге белән мәшһүр егет.

Бик юмарт ул, һәр вакытны кан алдыра,
Авыруларны үлемнән саклап калдыра [6].
Чөнки йөрәгендә бихисап каны бар.
Карт булса да, дәртлек чәчкән яшь җаны бар.

Кешеләрне хөрмәт итә — илтифатлы,
Эчкерсез һәм гади йомшак табигатьле.
Кайберәүләр шуны аңламый йөриләр,
Гаепсезгә «шөреп» исемен бирделәр.

Сүлпән, ләкин һәрбер эшнең җаен белә,
Әкрен йөри, аз сөйләшә, сирәк көлә.
Әрәм итми, ул байлыкның кадерен белә,
Акчага баш итеп куйдык шуңа күрә.

Үзе болай сүлпән булып күренсә дә,
Расходка акчаны кызганып бирсә дә,
Кулына кашык эләксә, кимен куймый,
Күпме генә ашамасын, барыбер туймый.

---

Һәр кешенең моңы була үзенә күрә,
Көй чыкса да, чыкмаса да җырлый бирә,
Ә безнең арабызда бар бер кеше,
Аның моңын бөтен татар халкы белә.

Ул җырчы да, гармунчы да түгел-түгелен,
Тик музыка агулаган аның күңелен.
Аның моңын көйләп ләззәт таба һәркем.
Әйтеп тормыйм инде исемен һәм кемлеген [7].

---

[3] Ягулык табуны, күбесенчә, Г. Кутуй оештыра иде. Җ. Ф.

[4] Идрис Туктар арабызда өлкән һәм бик ябык булганга, ипинең дә зуррак өлешен аңа бирү өчен Г. Кутуй шулай аяк белән ымлый иде. Җ. Ф.

[5] Диктор Маһинур Хәбибуллина. Җ. Ф.

[6] Сүз Идрис Туктар турында бара. Ул — донор иде. Җ. Ф.

[7] Бусы миндер инде. Җ. Ф.

Үзе болай ыктымат һәм пөхтә кеше,
Әкрен ашый, әйтерсеңлә үтми теше,
Кайнар чәйнең суынганын көтә-көтә,
Иң кимендә 3—4 сәгать вакыт үтә.

Игътибарлы, ләкин бик тиз кәефе китә,
Аның кәефен бозу өчен бер сүз җитә.
Шунысы яхшы: эчендә ачу сакламый,
Барыбызны да якын күрә, туган итә.

Я тын гына, моңсу гына утыра ул,
Эш дигәндә җиң сызганып тотына ул,
Тик кай эшкә бөгелми аның бармагы,
Нишлисең бит, дәрт булса да, юк дәрманы.

---

Зифа буйлы, нәкъ сум камышы шикелле,
Аппак йөзле, мәхәббәтле һәм сөйкемле,
Арабызда безнең яшь илһам кызы [8],
Аңа баксаң, искә төшә таң йолдызы.

Ярата ул уйланырга караңгыда,
Көлеп куя бик сирәк һәм саран гына.
Күп вакытны тын утыра, сөйләшми ул,
Сүз кушмасаң, үзе башлап эндәшми ул.

Йөргән чакны әле уңга, әле сулга
Сынар төсле булып аның биле сыгыла.
Баскан җирем ишелмәсен дигән сыман,
Атлап китә сакланып кына, шом гына.

Никадәр уй булмасын күңелендә,
Сөйләмәскә тырыша ул бәртеген дә;
Тик хәтерен уйлар чуалта кай чакта:
Адашып йөри, кайта белмичә Чачкапка.

Бер сер чишәм, зинһар, үзенә әйтмәгез,
Нигә алай икән, диеп йөдәтмәгез.
Аның күңеле егетләргә бик тиз төшә,
Мәхәббәте чиядәй кызарып пешә.

Ләкин ул йөрәк назын сайлый белми,
Үзе өчен мәгъкуль чәчәкләрне күрми.
Аның һәрбер мәхәббәте, шуна күрә,
Бүген янса, иртәгесен инде сүнә.

---

Салмак атлап, ашыкмый гына йөрүче,
Иң карт кеше һәм дөньяны күп күрүче,
Җирән сакаллы бабай бар арабызда [9],
Аңа хөрмәт белән карый барыбыз да.

Яшьләрдән дә уздырып башкара үз эшен,
Башыннан һич төшермәс ул кәләпүшен.
Ашауда да, эшләүдә дә сынатмый ул,
Картлар кебек ыңгырашып һич ятмый ул.

Көязлекне һәммәбездән дә уздырды,
Түгәрәк сакалын төптән кырдырды.
Ләкин әйтмим, сәбәбен яхшы белсәм дә,
Ни булганын үз күзем белән күрсәм дә.

---

Кем яратмый шатланырга һәм көләргә,
Эч пошыргыч кызыклы хәлләр сөйләргә.
Ләкин безнең арабызда бар көләч кыз
Шаркылдап көлә һаман бертуктаусыз [10].

---

[8] Машинистка Илһамия Нигъмәтҗанова. Җ. Ф.
[9] Анысы каравылчы Галиев абзый иде. Җ. Ф.
[10] Җирле тапшырулар инспекторы Тәзкирә Сәмигуллина. Җ. Ф.

Гаҗәп кеше, һәрнәрсәдән кызык таба,
Ул көлгәндә тетрәп тора җир һәм һава.
Ләкин инде ачуланса — табып булмый,
Аның кәефен ачу өчен һичбер дәва.

Ифрат чыдам, авырлыкка һич бирешми,
Күңеле төшми хәсрәткә дә һәм уйга да.
Ахры, шуңа күрә һәркөн симерә ул,
Арта бара аркылыга да, буйга да.

---

Арабызда картлар да һәм яшьләр дә бар.
Тар маңгайлы һәм кечкенә башлар да бар.
Мәгънәсезгә акыл чәчеп, вакчылланып,
Тыз-быз килеп йөри торган кешеләр дә бар.

Бер ханым бар, һич өзлексез махра төрә,
Эшен онытып, ләззәтләнеп төтен өрә [11].
Бер кеше бар, картлар кебек бик аз сүзле,
Күп белсә дә, тотнаклы бер егет үзе [12].

Әкиятемне вакытлыча тәмам итәм.
Чөнки бүген Чәчкаптан чыгып китәм [13].
Вакытым барда язуымны туктатмаска,
Укучылар, барыгызга да вәгъдә итәм [14].

* * *

1942 нче елның язында Гамир Насрый, запастагы офицер буларак, фронтка китте. Шул сәбәпле әкиятнең дәвамы язылмый калган булырга тиеш.

## II

Гадел Кутуй безнең бригадир иде. Аның үпкәләре дә сау түгел. Җитмәсә, ишиас авыруы белән җәфалана. Төннәр буе мич башында ыңгырашып чыга, ә иртәгесен инде берни булмаган кебек, безне эшкә рухландырыр өчен, көлке сүзләр сөйли, дежурныйларга күрсәтмәләр бирә, артыннан ияртеп кырга җир казырга алып китә. Эш нормасын үтәүгә килгәндә, безнең арада аннан да яхшы эшләүче юк. Шуның өчен аңа ударник исемен бирделәр һәм ул паекны да күбрәк ала, аны безнең белән уртаклаша иде. Җәмәгать эшендә дә ул актив. Безнең тәзүчеләр колоннасының телән чыга торган газета редакторы. Кичләрен материаллар туплап утыра, ә көндезен шуны әле бер төркем эшчеләргә, әле икенчеләренә барып укый.

Аның кешелеклелегенә, бетмәс-төкәнмәс энергиясенә таң калырлык иде!

Әнә шул көннәрдә Гадел Кутуй минем ноталар альбомыма Идрис Туктарга һәм миңа багышлап шаян шигырьләрен язып калдырган. Карандаш белән язылган бу шаржларның күчермәсен сезгә тәкъдим итәм.

## Туктарга

«Шөрепсез» дә, «Полный ход» та диеп,
Бик еш көлдек синнән, Туктар, без.
Кайда төште минем шөребе? — диеп,
Кыр-суларда тордык туктап без.

Таптык, таптык шөребеңне, Идрис:
Синең шөреп казан төбендә.
Ләкин казан төбе тишек булгач,
Син туймассың монда өеңдә.

Ачуланма, Идрис, бу парчага,
Әүлиядай изге кеше син.
Мин пәрәмәч белән сыйлар идем,
Ә ашыйсың хәзер — кишер син.

4/XI.

---

[11] Бухгалтер Матвеева. Ж. Ф.
[12] Рөстәм Яхин. Әле композитор булып танылмаган чагы. Радиола аккомпаниатор булып эшли иде. Ж. Ф.
[13] Без аны продуктлар алырга Казанга җибәрдек. Ж. Ф.
[14] «Әкият» шул урында өзелә. Ж. Ф.

Бу шаржга карата түбәндәге искәрмәләрне әйтергә кирәк.

Идрис Туктарга «Шөреп», «Шөрепсез», «Полный ход» дип кушамат бирүнең мондый сәбәпләре бар:

1. И. Туктар Татарстан радиосында соңгы хәбәрләр редакциясендә эшләгәндә, Казан заводларының берсендә ясала торган шөрепләр турында хәбәр язып, ниндидер хаталар жибәрә. Аның хатасын летучкада тикшереп, үзен дусларча шелтәлиләр. Шуннан соң инде радиодагы иптәшләр аңардан «Шөреп» яки «Шөрепсез» дип көләләр иде. Барыннан да күбрәк Идрис Туктар үзе көлә. Һәм «Шөреп» кушаматының таралуына үзе сәбәп булды да.

2. «Полный ход»ка килсәк, анысы инде Чәчкапта алган «кушаматы».

Һәр эшкә кулы ята торган И. Туктар: «Туктар-туктамас!» дип Г. Кутуйдан да кызурак йөрергә ярата. Ә үзе еш кына, сулышы кысылып булса кирәк, туктап, көрәгенә таянып торырга мәҗбүр була.

«Ник туктап калдың?» дигәнгә ул:

— Полный ход барганда аягымның шөребе төшеп калган. Шуны эзлим! — дип җавап бирә. Тапкыр сүзләр ясаучы Гамир Насрый «Полный ход»ны эләктереп ала һәм ул кушамат И. Туктарга карата еш кулланыла иде.

* * *

Гадел Кутуйның икенче парчасы болай:

## Җәүдәткә

Конфет дисәң, конфет түгел, ләкин  
Балдай татлы аның сүзләре;  
Аксап-туксап гел уйланып йөри,  
— Без киттек,— дип карый күзләре.

Ул уйлаган иде көй кирәк дип,  
Көйчеләргә бар да бүләк дип.  
Ә биредә көйнең кирәге юк,  
Икмәк китерүче кыйммәт бик.

Син түгел бу, Җәүдәт бәгырем, түгел,  
Гүзәл җырың рәхәт колакка.  
Дөнья шулай инде: һич кайгырма,  
Без килгәнбез фәкать кунакка.

Әйе, мин аңлыйм уйларыңны,  
Явыз Гитлер — сәбәп бу эшкә;  
Ал да көрәгеңне, әйдә кырга,  
Тирән кабер казыйк шул эткә.

4/XI—41.

* * *

Чәчкапта безнең төп эшебез, ялгышмасам, киңлеге һәм тирәнлеге өч метрлы окоп казу. Аңлавыбызча, ул дошман танкларына каршы корылмалар өчен кирәк.

Көннәр кинәт суытып җибәрде. Җир туңган. Күбрәк лом белән эш итәргә туры килә. Норма безнең өчен зур. Минем янәшәмдә генә кирпеч заводыннан килгән Әхәт Шәкүров дигән таза егет эшли. Без барыбыз да аның осталыгына сокланабыз. Бары Г. Кутуй белән И. Туктар гына аңардан калышмаска тырышалар. Калганнарыбызга кая ул — уйлавы да көлке...

Ул көннәрдә безнең төзелештә «Кызыл Татарстан» газетасының күчмә редакциясе төзүчеләр өчен генә бер битлек махсус листовка чыгара иде. Көннәрнең берендә шул редакциядә эшләүче язучы Газиз Иделле миңа яңа номерны сузып:

— Мә, үзең турында укы! — диде.

15 ноябрьдә чыккан бу номерда Г. Кутуйның Әхәт Шәкүров һәм минем турымда язылган кечкенә генә очеркы басылган. Кай арада язган ул? «Язам», дип тә әйтмәде бит.

## Композитор һәм эшче

Караңгы төшеп килә. Эш көне тәмамлана. Кайберәүләр инде ял итәргә, өйләренә кайтырга җыеналар. Ә композитор Җәүдәт Фәйзи, үзенең бүгенге эшеннән әле канәгатьләнеп җитмичә, норманы үтәү һәм арттырып үтәү өчен, тагын да күбрәк көч куеп эшләвен дәвам итә.

Җәүдәт Фәйзи — халык арасында гаять популяр булган бик күп сандагы җырларның авторы. Ул «Комсомолка Гөлсара», «Кавалеристлар җыры», «Янгыра, безнең җыр», «Гармун» кебек гүзәл җырлар тудырган талантлы композитор. Бирегә эш вакытында да ул иҗат эшен туктатмый. Илһамлы минутларда ул бер-бер артлы яңа мелодияләр тудыра. Тик менә төзелеш эшендә үз иҗатындагы кебек зур уңышларга әле ирешә алмаганлыгы аны бик борчый. Һәм ул монда да зур уңышлыклар яулап алу өчен эшкә үзенең бөтен көчен бирә.

Аның белән янәшәдә — киң җилкәле яшь эшче Әхәт иптәш Шәкүров эшли. Бүген норманы ул 200 процентка үтәде. Иптәш Шәкүров үзенең эшен шулай бик уңышлы, оста, яхшы нәтиҗәле итеп алып бара.

— Әмма эшли дә соң! Мина да шулай эшлисе иде! — ди Фәйзи, тирән соклану белән.

— Берни түгел, дускай,— ди аңа Шәкүров,— таныш булмаган эш берьюлы барып чыкмый ул. Бара торгач, үзләштерерсең һәм мине дә узып китәрсең әле.

Һәм ул композиторны эш алымнарына, инструментлар белән ничек уңышлы эш итәргә өйрәтә башлый.

Эш барышында Әхәт «Гармун» көен сузып җибәрде. Моны ишеткәч, композиторга кинәт җиңел һәм рәхәт булып китте. Үзе иҗат иткән җырның төзелеш мәйданында шулай тирән мәгънәле, моңлы, көчле булып, стахановча хезмәткә, Ватаныбызның куәтен ныгытуга рухландырып янгыравы арганлыкны бөтенләй оныттырды, эштә һәм иҗатта яңа дәрт тудырды.

Композиторның һәм эшченең, язучының һәм колхозчының шулай кулга-кул тотынышып, үз Ватаннарын ныгытуда армый-талмый эшләүләре бүтән тагын нинди илдә булуы мөмкин!

Эш тәмам булгач, композитор һәм эшче өйләренә кайтып китәләр. Җәүдәт Фәйзи тирән уйга чумып, әкрен атлый. Аның башында хәзер яңа, патриотик җырлар туа. Аның дусты — стахановчы Әхәт Шәкүров бу яңа җырларны да ятлап алыр һәм төзелеш мәйданында көчле янгыратыр.

ГАДЕЛ КУТУЙ.

*(Боксер участогы, Игнатов колоннасы.)*

* * *

Иртүк торып эшкә киткәндә «Гөрләсен безнең җыр»ны, ә кичке караңгыда эштән кайтканда «Иделкәем»не җырлау безнең гадәткә кергән иде.

«Иделкәем»не мин Таҗи Гыйззәтнең «Таймасовлар» драмасына яздым. Ул заманнарда бик популяр булып киткән бу җырны Г. Кутуй аеруча ярата иде. Ләкин җыр сүзләренең бер сюжетка корылмаган булуы аның эчен пошырды. Ахырда, түзмәде — үзе яңа сүзләр язды. «Иделкәем алкын, суын салкын» дигән сүзләр генә сакланып, өч куплеттан торган сюжетлы яңа җыр туды. Мин дә, башка иптәшләр дә җырны бик яраттык. Хәтта Гамир Насрый:

— Татар «Катюшасы» булды бу! — дип, гадәтенчә, шаркылдап бер көлде.

Шул вакыттан бирле Г. Кутуй сүзләре бу көйдә үзләренең законлы урыннарын алдылар.

Менә ул җыр:

## Иделкәем

Иделкәем алкын, суын салкын,
Көн дә төшеп шуннан су алам;
Кояш баткан чакта, мин Иделдә
Син бәгыремне уйлап юанам.

Иделкәем, суың бигрәк җылы
Эссе көндә чумып йөзәргә;
Синең белән үткән айлы кичләр
Калды ахры сагынып сөйләргә.

Иделкәем, суың алтын-алтын,
Яр өстендә учак ягалар;
Ник кайтмыйсың, бәгырем, тиз кайт инде,
Йөргән эзләр сине сагыналар.

* * *

Декабрь урталарында мин иптәшләремне калдырып, Чәчкаптан Казанга кайтып киттем. Сәбәбе: «Башмагым»ны язып бетерергә тиеш идем. Эшем шушы хезмәт фронтына киту белән өзелгән иде. Опера театрының соравы һәм ул вакыттагы Татарстан Верховный Совет Президиумы председателе Гали иптәш Динмөхәммәтов күрсәтүе буенча, музыка язуымны дәвам итәр өчен мине өйгә кайтарып җибәрделәр.

Калган иптәшләремнән Гадел Кутуй декабрь азагында һәм калганнары январь урталарында Казанга кайттылар. Барыбыз да, радиодагы үзебезнең язу өстәлләребез янына утырып, төп эшебезгә тотындык.

«Башмагым» тиз арада языльп бетте. 1942 елның 1 мартында аның премьерасы Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә зур уңыш белән үтте. Аның шундый кыска вакыт эчендә язылуының сәбәпләре шулар дип беләм: беренчедән, хезмәт фронтында чакта ук комедиянең музыкасын күңелемдә йөрттем, роялемне сагынып кайттым; икенчедән, Тажи Гыйззәт жанрны яхшы аңлап, либреттоны тоткарлыксыз, төгәл эшләде һәм, өченчедән, сәхнәгә куючы режиссер С. Я. Сульва-Вәлиев һәм дирижер И. В. Әухәдиев бик оператив эшләделәр.

Гамир Насрый да, Гадел Кутуй да, Идрис Туктар да минем иҗат шатлыгым белән уртаклаша алмадылар. Алар үз ирекләре белән Бөек Ватан сугышы кырларына китеп, кирәк урынына кулларына корал алганнар иде инде.

1942 елның көзендә мин Гадел Кутуйдан Чәчкапны, дусларын сагынып язган хат алдым. Менә ул хат.

«Жәүдәт дус!

Өйдән язылган хат аша синең жылы сәламең иреште. Искә төшерүең өчен рәхмәт. Бу хатны алу белән теге Чәчкаптагы көйне жырлап[1] жибәр.

Иҗатыңа уңышлык телим. Гобәйгә, Кавигә, Шабайга, Мирсәйгә, Галиягә, Тәзкирәгә, Матильдага, Доброхотовага һәм башкаларга сәламемне тапшыр.

Нәҗипнең, Ключаревның һәм жырчы иптәшләрнең кулларын кыс[2].

Ут астында калганда да, яңгырда чыланганда да Казан һәм сез истә торасыз. Шул дәрт бирә, шул жылыта. Эх, синңа да бу сугышның бер күрәсе иде — мәңге онытылмаслык көй чыгарыр идең. Сугыш ифрат көчле бара. Жир яна, һава ярыла, дошман блиндажлары йомычкага әверелә.

Мин үземне үлмәм дип уйлыйм. Көч житсә, яхшы әсәр язарга исәп. Тормышның кадерен белегез, һәр минутыңны файдалы уздыр. Иң авыр минутта да башыңны имә, көчле бул.

Иренмәсәң, хат яз — укуы күңелле булыр. Озакламый яңадан сугышка сәфәр кылам, ә хатың мине эзләп табар.

Кулыңны кысып: *Гадел.*

*29.9.42».*

* * *

Бу хәлләргә чирек гасыр вакыт узып китте. Яңа яшь буын туды. Алар тыныч тормышта зур иҗади эш алып баралар. Ә без — Чәчкапта оборона эшләре алып барган 14 кеше — тәмам өлкән яшькә життек, кайберләребез безнең арада юк инде. Алар уянмас йокыга талдылар. Гадел Кутуй сугышның безнең өчен жиңү белән бетүен күрсә дә, үзенең Казанына кайта алмады. Аның данлы кабере Польша жирендә.

Гамир Насрый сугыштан соң күп кенә матур жырлар, драма әсәрләре язып, татар музыка сәнгатенә һәм әдәбиятына шактый өлешен кертеп, вакытсыз арабыздан китте.

Һәрвакытта күтәренке күңелле, ачык табигатьле өлкән язучы Идрис Туктарга 70 яшь тулу көнен Татарстан җәмәгатьчелеге җылы итеп билгеләп үтте. Тормышының бу соңгы 25 елында ул күп кенә хикәяләр, парчалар, фельетоннар язды. Ниһаять, «Ике егет» романын безгә бүләк итте.

25 ел элек бер-ике генә әсәре булган Рөстәм Яхин, минем ул чакта язылган:

> «Яшь булса да күп белә,
> Анда өмет күп кенә,
> Канатларын җәяр әле —
> Бөркет булыр, кем белә»,—

дигән юлларымны тулысы белән аклады. Хәзер ул танылган композитор.

Ә Әхәт Шәкуров кайда, кем булып эшли? Кызганычка каршы, анысын белмим.

Әйе, Чәчкаптагы альбомым күптәнге көннәр истәлегеннән хәтеремнән казып чыгарырга ярдәм итте.

*29 сентябрь, 1966 ел.*

---

[1] Сүз «Иделкаем» жыры турында бара. *Ж. Ф.*

[2] Радиода эшләүчеләр: Гариф Гобәй, Кави Нәжми, Мин Шабай, Галия Гаязова, Тәзкирә Сәмигуллина, Матильда Аксенова, А. В. Доброхотова һәм композиторлар Нәжип Жиһанов, Александр Ключарев. *Ж. Ф.*

*Абдулла Дубин,*

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Радио һәм телевидение комитеты дикторы

# ТОРМЫШ КӨЗГЕСЕНДӘ

Гади һәм матур сөйләү — бөтен бер фән ул: аның үз законнары булырга тиеш.

*К. С. СТАНИСЛАВСКИЙ.*

Диктор телевизор экранында...

Телевизорлы һәр өйдә дикторларны иске таныш, хәтта дус итеп беләләр. Дусларны исә һәркем үзенчә сайлый: берәүләргә Әминә Сафиуллина якынрак, икенче берәүләргә Елизавета Гойхман-Заһидуллина ошый төшә, башка бик күпләр Айрат Арслановны ярата. Кайсы кешеләр дәшми-тынмый гына дус итәләр, икенчеләре хатлар язалар. Хатларның да төрлесе була. Кайчакта тамашачы үзенең көнкүрешендә, семьясында килеп чыккан четрекле хәлләрне дә диктордан яшереп тормый. Сораулар куя, җавап бирүне үтенә. Күпләрне безнең тормышыбыз, хезмәтебез кызыксындыра.

«Телевидение дикторы буласым бик килә,— дип яза Свердловск өлкәсе, Югары Тура шәһәреннән Нәҗия Ганиева.— 10 нчы класста укыйм. Ничек кенә диктор булырга икән? Хезмәтегез турында сөйләсәгез һәм киңәшләр бирсәгез иде».

Диктор хезмәте турында җентекләбрәк сөйләвебезне сорап, безгә тамашачыларыбыз да, җирле радиоларның дикторлары да мөрәҗәгать итә торалар.

Менә мин өстәл артында, шул сорауларга җавап бирергә җыенып утырам. Кыен эш икән ул үз профессияң турында сөйләү. Шулай да, тырышып карарга исәп. Һәм бу эшне студия белән таныштырудан башласак, кулайрак та, уңайлырак та булыр кебек...

Без биек, иркен павильонда. Барлык почмакларда яктырту приборлары. Стеналарга чаршау корылган. Рәсемнәр белән бизәлгән щитлар, нәфис эшләнгән панно, матур мебель. Әледән-әле: «5 нче камераны бирегез», «Титрны алыштырыгыз», «Тавышны туктатыгыз», — кебегрәк боерыклар ишетелеп тора.

Өстә, стенаның буеннан-буена, тәрәзә сузыла. Ул — аппаратлар бүлмәсенең тәрәзәсе. Бу бүлмәдә идарә пульты урнашкан. Режиссерлар, аларның ассистентлары, инженерлар, тавыш һәм сурәт техниклары шуннан торып тапшыру белән идарә итәләр. Павильонда телевизион камералар, прожекторлар, рояль һәм тагын әллә ничаклы әйберләр. Беренче карашка, биредә бернинди тәртип юк сыман; чынлыкта исә һәр әйбернең иясе бар, һәр телекамера, яктылык, декорация өчен җаваплы кешеләр әзер тора; кирәк булдымы, алар барын да үз урыннарына куялар.

Тиздән тапшыру башланачак. Студиянең тапшыру барачак почмагында бар нәрсә әзер. Диктор үз урынына утыра. Операторлар, камераларын сөйрәп, ары-бире йөренәләр: мөмкин кадәренчә яхшы күрсәтү өчен, уңайлы урын эзлиләр. Режиссер соңгы күрсәтмәләрен бирә. Ул арада диктордан бераз гына сулгарак куелган контроль телевизор-мониторда сурәт барлыкка килә. Звонок шалтырый һәм «Эфир ачык» дип хәбәр ителә. Шушы минутта ук таблода: «Шауламагыз! Микрофон тоташтырыл-



*Идарә пульты.*

ган!» дигән сүзләр барлыкка килә. Күрсәтүче камерада «кызыл күз» кабына, студиядә тирән тынлык урнаша: тапшыру башлана.

Диктор прожекторлар кыздыруына да, операторларның ыгы-зыгы килеп йөрүләренә дә, режиссер һәм аның ярдәмчеләренең үз тирәсендә мәж килүләренә дә игътибар итми. Ул тыныч һәм игътибарлы. Әмма шушы җыйнаклык, телекамера алдында үзеңне иркен тоту, тапшырулар вакытында көтелмәгән хәлләр килеп чыкканда югалып калмау кебек сыйфатлар бирәүгә дә җиңел генә бирелми. Моңа ирешү өчен зур хезмәт сорала. Тәүге тапкыр телекамера алдына чыккан кешенең хәлен шагыйрь Андрей Лядов бик дөрес аңлата:

Мин куркак та түгел, ләкин кайчак
Робот сыман телекамера
Сагаласа мине, калам каушап,
Проводлар сузыла янымa
Коточыргыч зур еланнар булып.
Калтырыйлар куллар, тезләрем,
Кинәт китә тән чымырдап, туңып...
Ә камера кызыл күзләрен
Төби минем тирле маңгаема,
Прожектордан күзләр чагыла.
Ә микрофон Дамокл кылычына
Охшап тора минем алдымда.

Ихтимал, телевизор камерасы алдында беренче мәртәбә чыгыш ясаганда, безнең һәрберебез шундыйрак хәлне кичергәндер. «Куркыныч» сүзе озак вакытлар буена безнең телебездән төшми йөрде. Соңрак аны «кызыклы» сүзе кысрыклап чыгарды. Кызыксыну исә үз профессиябезнең серенә төшенү теләген уятты.

Һәр диктор үз һөнәренә үзенчә гашыйк. Миңа калса, мин аны бер урында таптанырга, тынычланырга, ялкауланырга ирек куймый торган һөнәр булуы өчен яратам. Һәр яңа тапшыру диктор өчен нинди дә булса яңалык алып килә, аның белемен һәм рухын баета. Шул ук вакытта ул аның алдына яңа таләпләр дә куя, чөнки дик-

тор кулындагы текстны укып чыгу белән генә чикләнә алмый. Ул һәр вакыйганы үзенең йөрәге аша уздырырга, коры җөмләләр белән язылган хәбәрләрне тамашачыларына йөрәк хисләрен кушып җиткерергә тиешле. Бу хәл исә дикторны туктаусыз эзләнергә, өйрәнергә, үзенең профессиональ осталыгын үстерергә мәҗбүр итә.

Микрофон алдында иҗат итүнең үзенчәлекле булуын күрсәтеп, Василий Иванович Качалов болай диган иде: «Әзерлексез-нисез, капыл гына микрофонга якын килергә ярамый. Барысы да алдан ук уйланылган, кичерелгән, үлчәнелгән булырга тиеш. Әгәр шулай түгел икән, тапшыру башлангач кына син боларның берсен дә эшләп өлгерә алмыйсың. Микрофон алдында актер өч кенә сүз әйтергә мөмкин. Әмма ул аларны шундый итеп әйтергә тиеш ки, каядыр Урал артындагы тамашачы синең һәр сүзеңә ышанып һәм ул сүзләрдән синең йөрәк тибешеңне тоеп утырырлык булсын. Минә нилектән микрофон алдында эшләүне мин өчләтә кыен һәм өчләтә җаваплы дип саныйм».

Зур тәҗрибәле бөек артист та микрофон алдында иҗат итүне «өчләтә кыен һәм өчләтә җаваплы» дип санагач, безнең күбек яшь дикторлар, бигрәк тә телевидение дикторлары, үз эшләренә никадәр кыен һәм нинди зур җаваплы итеп карарга тиешле икәнлекләре ачыктыр.

Телевидение дикторы башкара торган вазифалар байтак: ул укучы һәм әңгәмә алып баручы да, конферансье һәм комментатор да. Безгә режиссер ролендә булырга да туры килгәли. Телевидениегә чыгыш ясарга төрле профессия кешеләре килә, аларның тормыш тәҗрибәләре дә бер дәрәҗәдә булмый. Әгәр диктор кешесенә карап сораулар бирә белмәсә, чыгыш ясаучыны әйдәп барырлык әзерлеге булмаса, ул янәшәсендә утыручы героен да уңайсыз хәлдә калдыра, тапшыруның да сыйфатын төшерә.

Әйбәт диктор — киң диапазонлы иҗат кешесе. Ул актер һәм сүз остасы да, оратор, докладчы яки лектор да. Шунсыз булмый, чөнки диктор эш итә торган материаллар эчтәлекләре һәм формалары белән бик төрле булалар.

Телекамера алдында үзен никадәр гади, никадәр иркен тотса, диктор тапшыруны шулкадәр яхшы алып бара. Мондый тапшыру тамашачылар күңеленә дә бик хуш



*А. Дубин телевизор камерасы алдында.*

килә. Әмма моны әйтүе генә җиңел. Сине әллә ничә аппарат күзәтә, күзләрең исә телекамераларның «кызыл ут»ларыннан аерылмаска тиеш. Өстәвенә, телевизорлы һәр өйдә диярлек син игътибар үзәгендә — сиңа меңләгән кешеләрнең карашлары төбәлгән. Барын да онытып бетерүе — шактый кыен эш. Тик тапшыруыңның асылына төшенеп, шуңа бөтен барлыгың белән бирелеп эшли алганда гына чит нәрсәләрне онытырга һәм үзеңне иркен, табигый тотарга мөмкин. Илебездәге дикторлык сәнгатенә нигез салучыларның берсе Михаил Михайлович Лебедев: «Яхшы дикторның асыл сыйфатларыннан берсе — аның һәрчак игътибарлы булуында. Микрофон алдында чын йөрәктән укырга, ягъни укый торган текстыңа инанып, ихлас күңелдән укырга кирәк. Тапшыра торган материалларыңны яратырга, аның белән янып яшәргә кирәк. Микрофон битарафларны сөйми», дип әйтә иде.

Телеэкранда чыгыш ясаучы кешенең тамашачыларга эстетик тәэсире дә гаять зур. Бу хәл телевидение дикторына булган таләпне тагын да арттыра. Чыннан да, спектакльдә уйнаучы яки концерт алып баручы, яисә кинофильмда катнашучы актерның йөзе тамашачыга телевидение дикторыныкы кебек үк якыннан күренми. Кино актеры исә уңышсыз кадрларны кабат уйный ала. Телевидение дикторының хәле оттырышлырак. Аның йөзе дә, кичерешләре дә, рухи хәле дә — барысы да тамашачының күз алдында. Шулай икән, телевизор экранында чыгыш ясаучы кешенең һәр кыланышы, хис-кичерешләре табигый булырга тиеш. Ясалма пафос та, патетик кычкырулар да дикторның үзе сөйли торган вакыйгага битараф икәнлеген яшереп кала алмыйлар. Димәк, диктор бары тик бер нәрсә — кулындагы материалның эчтәлеген тамашачыларына түкми-чәчми һәм аларны дулкынландырырлык итеп җиткерү турында гына уйларга тиеш. Икенче сүзләр белән әйткәндә, ул телекамера алдында тапшыра торган материалы белән генә яшәргә тиеш. Бу гына да җитми әле.

Тамашачыңны төгәл билгеләми торып, эфирга чыгарга ярамый. «Гомумән» уку — адрессыз уку ул. Әгәр диктор үзе сөйләгәннәргә ышандырасы килә икән, ул конкрет тамашачыларга мөрәҗәгать итәргә тиеш.


Табигыйлеккә һәр диктор үзенчә ирешә. Әйтик, мин камера алдында утырам. Анда хәзер кызыл ут кабыначак. Кызыл ут — сөйли башларга сигнал. Мондый минутларда мин күңелемнән якын дусларыма мөрәҗәгать итәм. Кайбер чакларда, тапшыруның стиле һәм темасына карап, мин үземә бер төрле танышларымны сайлыйм һәм аларга сөйләгәндәй сөйлим. Әгәр тамашачымны нәрсәгә булса да инандырырга телим икән, мин аның зиһененә генә түгел, бәлки йөрәгенә дә ачкыч эзлим. А. П. Чеховның «Дала» исемле повестенда яшь, әле яңа гына өйләнгән, хатынына булган гыйшкыннан исергән Константин далада йөри һәм сөйгәне югында үзенең бәхетен уртаклашырлык кеше эзли. «...үзенең матур хисләрен чит кешеләргә фаш итү уңайсыз да, әмма шул ук вакытта, күрәсең, шатлыгын уртаклашырга теләк тә бик көчле иде...», — дип яза Чехов аның турында.

Тормышыбыз тудырган зур фикерләр һәм идеяләрне тамашачыларыбыз белән уртаклашу безнең дә шундый ук табигый, зарури ихтыяҗыбыз булып тора һәм булырга тиеш.

Без берьюлы йөз меңләгән кешегә түгел, бәлки йөз меңләгән мәртәбә берәр кешегә, ягъни һәр тамашачыга аерым-аерым мөрәҗәгать итәбез. Әгәр дә мин үзем белән тамашачым арасына «басма сала» алмасам, димәк, мин бушка сөйлим. Әгәр дә инде тамашачыда диктор белән киңәшү яки аның белән бәхәсләшү теләге туа икән — бу исә мин дөрес интонацияне тапканмын, аудитория белән үз арамда күзгә күренми торган, әмма ныклы җепләр сузганмын дигән сүз.

Һәр дикторның үз аудиториясе бар. Мин үзем юмор хисе булган тамашачыларны ярата төшәм. Объектив алдында утыру белән, кәефне шушындыйрак «дулкынга көйлим». Болай эшләү миңа үземне иркен тотарга һәм тапшыруны уңышлы башкарып чыгарга мөмкинлек тудыра.

Максим Горькийның шундыйрак фикере бар: чын сәнгать әсәре укучыда язучыга карата ихлас күңелдән ышану тойгысы тудыра, дигән ул. Дөрес фикер. Чыннан да, тын, караңгы бүлмәдә экрандагы кеше белән тамашачылар арасында якынлык хисе урнашырга бөтен шартлар бар. Дикторлар — тамашачыларның һәр кичне аерылмас дуслары алар, ә дуслар исә эреләнеп сөйләшмиләр. Әгәр эреләнеп сөйләшсәң, син дуслыкка хыянәт итәсең, һәм тамашачылар сине тыңламый башлыйлар — телевизор-



*Студиядә репетиция бара.*

ларын сүндерәләр. Еллар үткән саен, диктор белән тамашачылар арасында якын мөнәсәбәтләр урнаша. Без дан казанмыйбыз, без бары тик үз кешеләр була барабыз. Дикторлар театр актеры сыман тамашачы белән тыгыз бәйләнештә тормыйлар. Безнең бәйләнеш — символик характерда. Без ошаткан яки ризасызлык белдергән тавышларны ишетмибез, тамашачының канәгатьсезләнеп, программаны туктатуын да күрмибез. Әгәр дә актерның уены спектакль барганда ук тамашачының бәясен алса, телевидение дикторы исә тапшырудан соң, хатлар яки телефон шалтыравым көтә, байтак вакыт билгесезлектә йөри.

Дикторга еш кына студиядән тыш та чыгыш ясарга — предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, театрлар яки концерт залларыннан репортажлар алып барырга туры килә. Мисалга «Кичке Казан» тапшыруын китерик. Укылырга тиешле текст иң иртә дигәндә нибары бер сәгать алдан әзер була. Һәм нинди текст әле! Кинокадрлар һәм чыгыш ясарга тиеш кунаклар.

Тамашачы экранда нәрсә күрә, диктор шул хакта сөйләп барырга тиеш. Әмма фикерне җиткерү һәм тамашачыны дулкынландыру өчен, тапшырыла торган материалны биш бармагың кебек белергә кирәк. Белмәгән әйбер турында юньләп сөйләп булмый. Дөрес, редактор язган текст бар барын, ләкин ул кәгазьдә генә шәп яңгырый. Сөйли башласаң, еш кына очы-очка ялганмый. Димәк, аны укудан файда юк. Мондый очракларда дикторны тәҗрибәсе, белеме, осталыгы коткара. Бер карасаң, гадәттә артистлар көненә берничә премьерада катнашмыйлар. Ә бит дикторның һәр яңа текстны укуын үзенә бер премьера дияргә була. Премьераның да ниндие әле: чиксез аудиториясе булган телекамера алдында бара.

Тапшырулар вакытында көтелмәгән хәлләр килеп чыга, диктор исә һәрвакыт әзер булырга һәм шул хәлләрдән чыгу юлларын табарга тиеш. Кайвакыт диктор бер нәрсәне хәбәр итә, ә оператор, ялгышып, башка пленканы җибәрә: сопрано урынына бас җырлый башлый яки пленка өзелә. Дикторның бернинди гаебе булмаса да, тамашачылар аны әрлиләр, чөнки алар башка кешене белмиләр.

Мондый очракларда диктор төзәтү кертергә яки матур гына дәвам итеп китәргә әзер тора.

Шундый очракларның берсен искә төшерик.

Хатын-кызлар көне 8 мартка багышланган тапшыру бара иде. Студиягә чакырылган кунакларның берсе «игътибарлы» ир-атлардан алынган берничә котлау телеграммасын укып күрсәтергә тиеш. Дулкынлануданмы, бәйрәм мәшәкате белән башы әйләнүдәнме, әлеге кунагыбыз тәбрикләү телеграммаларын өендә онытып калдырган булып чыкты. Ни эшләргә? Тапшыруны туктатып, өйгә кайтып килеп булмый бит инде... Өстәвенә сценарий да шулай язылган — әлеге телеграммаларны һич кенә дә төшереп калдырып булмый. Бөтен тәвәккәллегемне туплап, нибар фантазиямне ярдәмгә чакырам да, очраклы рәвештә кул астына туры килгән чиста бер кәгазьне тотып, ир-ат тамашачылар исеменнән телеграммалар «укыйм». Соңыннан әйттеләр: тамашачыларга бик күңелле булган, ә шул чактагы хәлемне бер үзем генә беләм. Мин сезгә бер генә очракны сөйләдем, ә андый хәлләр безнең көндәлек эштә килеп чыккалый торалар.

Безнең тамашачылар үзләренең телевизор экраннары каршына җайлап утыргач та студиядә әле эшлекле атмосфера тукталмаганын күпләр белми дә торгандыр. Тапшырудан буш павильоннарда һәм хәтта фойеда чираттагы тапшыруларга репетицияләр бара.

Шулай да була. Казан һәм республика тамашачылары Мәскәүдән чираттагы футбол матчын яки нәфис фильм карыйлар, ә шул ук вакытта Казаннан Үзәк телевидениенең икенче программасы буенча Татарстан сәнгать осталары башкаруында спектакль яки концерт бирелә.

Менә телевизион тапшырулар тәмамланды. Диктор тамашачыларга тыныч йокы тели. Телевизорлар сүнә, ә студиядә якты юпитерлар кабына. Театр артистлары катнашы белән телевизион фильмнарны пленкага төшерү башлана. Бу иң уңайлы вакыт. Чөнки көндезен һәм кичләрен актерлар театрда эштә була.

Кайберәүләр бездән: «Кичен сез тапшырулар алып барасыз. Ә көндезләрен ни эшлисез?» — дип сорыйлар. «Өйрәнәбез, репетицияләр ясыйбыз», — дисәң, ышанмыйлар. «Аның нәрсәсен өйрәнеп торасың инде. Бик гади ләбаса», — дип ихлас күңелдән гаҗәпләнәләр.

«Бик гади...» Безнең хезмәткә шуннан да зур бәя булмастыр кебек. Әгәр дә экранда барысы да гап-гади, табигый чыга икән, димәк, уйлануларың, борчылу һәм эзләнүләрең бушка китмәгән дигән сүз. Экранда үзеңне табигый тоту: гап-гади сөйләү, тормышчан елмаю, һәр хәрәкәтеңнең килешле булуына ирешү, кыскасы, ясалмалылыктан котылу ансат түгел. Студиядә чыгыш ясаган кешеләр (хәтта профессиональ актерлар да) минем бу сүзләрем белән килешерләр, дип уйлыйм. Бу урында СССРның халык артисты М. И. Жаровның сүзләрен китерү урынлы: «Мин һәм минем сәнгатьтәш дусларым телевидениедә чыгыш ясаганда сәхнәдә уйнагандагыга караганда күп мәртәбә көчлерәк дулкынланабыз. Чикләнмәгән аудитория каршына чыгу искиткеч зур җаваплылык йөкли», дип язган иде ул «Советское радио и телевидение» журналында.

Газеталарның яңа саннары, радиодан бирелгән соңгы хәбәрләр белән танышмыйча, дикторның эфирга чыгарга хакы юк. Дикторлар бүлмәсендә репродуктор телевизор тавышыннан һәрвакыт катырак сөйли. Шулай эшләү тамашачыларны иң соңгы мөһим хәбәрләр белән үз вакытында таныштырырга мөмкинлек бирә. Моны мин телевизорның аудиториясе радионыкыннан зуррак булуын искә алып әйтәм. Диктор әзерлекле кеше булырга тиеш. Менә нилектән безнең һәммәбез белемен күтәрү өстендә эшли. Айрат Арсланов, мәсәлән, Ленинград кино, театр, музыка һәм телевидение институтының режиссерлык факультетында укый, мин үзем тиздән А. В. Луначарский исемендәге Мәскәү Дәүләт театр институтын читтән торып тәмамлыйм. Күп уку, илебезнең көндәлек тормышыннан хәбәрдар булу, халыкара вакыйгаларны белеп тору, туган телебезне өйрәнү — безнең көндәлек бурычыбыз. Шулай даими рәвештә үз өстеңдә эшләгәндә генә һөнәреңне тирәнтен үзләштерергә һәм материалны тамашачыларга тиешенчә җиткерергә мөмкин.

Тамашачы белән уртак тел табу, теләсә нинди тапшыруга да аның кызыксынуын уяту өчен, диктор сөйләү техникасын яхшырта барырга, дикциясен һәм тавышын туктаусыз камилләштерергә, төрледән төрле текстларны укуда күнегүләр ясарга мәҗбүр. Үз стилемне, үз почеркымны булдырыйм дисәң, эшләргә дә эшләргә, дикторлык осталыгы буенча иң уңай тәҗрибәләрне үзләштерергә кирәк... Аннан исә тагын яңа

максатлар туа, күтәреләсе яңа үрләр ачыла. Тагын тырышасың, яраткан хезмәтең хакына тагын тиргә батып эшлисең.

1965 ел азагында Мәскәүдә телевидение дикторларының 1 нче Бөтенсоюз семинары булды. Бу семинарда мин РСФСРның атказанган артисткасы О. С. Высоцкая, аның шәкерте В. М. Леонтьева, Ираклий Андроников һәм Ю. В. Фокин кебек атаклы осталар белән янәшә һәм алар җитәкчелегендә эшләү бәхетенә ирештем.

«Диктор экраннан үз-үзен күрсәтми, бәлки совет телевидениесе вәкиле булып чыгыш ясый. Аның сөйләме табигый, кыланышлары интеллектуаль булырга тиеш, чөнки ул ил исеменнән илебезгә сөйли. Тамашачы белән, аңа ошарга теләгән кеше булып түгел, бәлки иптәшләрчә сөйләшергә кирәк», дигәннәр иде алар. Мин аларның бу киңәшләрен хәтеремнән чыгармаска тырышам. Даими консультантым — Бөтенсоюз радиосы дикторы Алексей Иосифович Задачинга минем рәхмәтем бик зур. Аның белән дуслык миңа иҗади үсәргә ярдәм итә. Мәскәүдә булганда «Юность» радиостанциясе тапшыруларына катнашу, радиожурналларда чыгу, шул чакта радио режиссерлары белән иҗади элемтәгә керү дә экрандагы төп эшемә уңай тәэсир ясый.

Телевидение дикторы профессиясе әле бик яшь. Аның киләчәге зур. Тормыш куйган таләпләрдән чыгып, ул нинди юнәлешкә камилләшер, анысын күз алдына китерү дә кыен.

Совет телевидениесе халык интересларына, чор таләпләренә хезмәт итә. Без, совет дикторлары, капитализм дөньясының долларга сатылган, аның ялчысы булып әверелгән дикторларыннан максатларыбызның чиста, вазифаларыбызның кешелекле булуы белән аерылып торабыз. Һәм без моның белән горурланабыз.

Партиябез Үзәк Комитеты безнең пропагандабыз «хезмәт иясенә аңлаешлы һәм якын булырга, аның күңеленә тәэсир итәргә, һәр совет кешесенең зиһенә һәм йөрәгенә барып җитәргә, аңарда иң якын, иң гүзәл фикерләр һәм хисләр уятырга тиешле», дип күрсәтә. Бу таләпләр безнең хезмәтебезгә дә тулысынча кагыла. Совет хөкүмәте безнең эшебезне югары бәяли. Куптән түгел генә, 1966 елның 8 сентябрь Указы белән СССР Верховный Советы Президиумы радио һәм телевидение хезмәткәрләреннән 151 кешене орденнар һәм медальләр белән бүләкләде. Алар арасында 13 диктор бар. Бу чагыштырмача зур сан. Шул ук елның 1 октябрендә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы безнең комитет дикторлары Васфикамал Мәгъсум кызы Саттарова белән Әминә Кәрим кызы Сафиуллинага «Татарстанның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исемнәр бирде. Бүләк — бер кешенең генә түгел, бөтен коллективның эшенә бирелгән бәя, барлык дикторларның хезмәтен тану ул.

Эш процессында безгә, дикторларга, әледән-әле төрле редакцияләрдә эшләүче иҗат кешеләре, гомумән, тормышта күпне күргән, күпне үз башыннан, үз йөрәгеннән кичергән, кызыклы кешеләр белән очрашып торырга туры килә. Андый хезмәттәшләребез күп безнең: алар әдәби-драматик, иҗтимагый-политик тапшырулар редакцияләрендә дә, яшьләр редакцияләрендә дә, промышленность, төзелеш һәм транспорт бүлекләрендә дә бар. Югары культуралы, үз эшенә бирелгән, саф күңелле шушындый кешеләр белән бергә эшләү — үзе зур бәхет ул.

Соңгы теләгем итеп шуны әйтим — пропаганда, иҗтимагый-политик пропаганда, әлбәттә, җитди эш. Әмма әгәр дә без аны тагын да үтемлерәк һәм формасы белән төрлерәк итә алсак, тамашачылар рәхмәте безгә тагын да күбрәк явар иде һәм үзебезгә дә эшләргә күңеллерәк булыр иде.

—✦—

# Китап күзәтү

## Безнең Ильич

Сөекле юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның бөек исеме, якты образы дөньядагы барлык намуслы кешеләрнең күңел түрендә. Кешелек дөньясы Ленин исемен, ул сызган якты юлны турылык һәм хаклык билгесе итеп олылый.

В. И. Ленинның бөек эшләре, даһи акылы, үтә тыйнак һәм тынгысыз тормышы татар әдәбиятында да хөрмәтле урынны алып тора. Юлбашчы турында язылган шигырь-поэмалар, сәхнә әсәрләре һәм хикәяләр, истәлекләр һәм публицистик мәкаләләр, аңа багышланган аерым җыентыклар безнең матбугатта элек-электән чыга килгән. В. И. Ленин турында беренче татарча китап 1921 елда Петроградта басыла. 1924 елда Казанда «Ленин» исемле тагын бер әдәби җыентык чыккан. Бераз соңрак, 1927 елда, русчадан «Ленин турында истәлекләр» исемле җыентык тәрҗемә ителгән иде. Татар матбугатында Ленинга багышланган төрле җыентыклар моннан соң да чыга торды. Күптән түгел матур әдәбият сөючеләр кулына юлбашчыбызга багышланган тагын бер яңа әдәби җыентык килеп керде. «Безнең Ильич» исеме белән Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан бу җыентыкта татар әдипләренең, журналистларының һәм күренекле җәмәгать эшлеклеләренең иң кадерле кешебез турында язылган әсәрләре тупланган [1].

Җыентыкка язган сүз башында М. Гайнуллин В. И. Ленинның тарихта тоткан бөек роленә тукталып, Ленин идеяләренең үлемсезлеге турында илһамланып сөйли. Бер урында ул, мәсәлән, болай ди: «Халык азатлыгы һәм бәхете өчен армый-талмый көрәшкән Ленин халыкның иң күркәм, иң кешелекле сыйфатларын үзендә чагылдыра. Шуңа күрә дә аның кояш кебек якты образы миллионнар өчен җылылык һәм көч чыганагы булып тора, композиторлар, язучылар һәм художниклар өчен илһам һәм дәрт чишмәсе булып яши». Йөрәктән тирән ихтирам билгесе булып чыккан хак сүзләр болар!

Алга таба ул татар поэзиясендә, драматургиясендә, татар музыкасында һәм сәнгатендә Ленин образын тудыру буенча нинди адымнар ясалуы турында нигезле мәгълүмат бирә һәм җыентыкка тупланган әсәрләр турында кызыклы күзәтүләр, гомумиләштерүләр ясый.

Тематикалары, эчтәлекләре ягыннан җыентыкта тупланган материалларны берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Бер ише әдәби әсәрләр, аеруча шигырьләр, Ленинның туган көненә карата язылганнар. Муса Җәлилнең «Ленин туды» исемле, Шәраф Мөдәрриснең «Яз, матур яз!» дип башланган шигырьләрендә дөньяга Ленин туган көнгә — 22 апрель көненә гимн җырлана. Яз табигатькә яшеллек, яшьлек алып килгән кебек, Володяның тууы да кешелек дөньясына бәхет китерде. «Ленин! Ленин!» исемле публицистик әсәрендә Габдрахман Әпсәләмов болай ди: «Язлар килә... Язлар килгән саен без аеруча бер якынлык, горурлык һәм ярату хисе белән бөек Ленинны искә алабыз. Аны язлар, кешелек язлары тудырды. Изелгән һәм җәберләнгән хезмәт ияләренә бәхет юлын күрсәтү һәм аларга бәхет даулар өчен тудырды. Ул үсте һәм халык арасыннан кайнап күтәрелгән революцион давылларның, канлы капитализмның нигезен тетрәтүче давылларның үзәгенә килеп басты, революциянең ялкынлы трибуны, куркусыз әйдәүчесе, байрак йөртүчесе булды. Ул үзе кебек үк үлемсез Коммунистлар партиясен төзеде, беренче Совет дәүләтен оештырды һәм беренче Совет хөкүмәтенең беренче башлыгы итеп билгеләнде».

Ленин — безнең якташыбыз. Аның яшьлеге, революцион эшчәнлеге Казан, Татарстан белән бәйләнгән. Җыентыктагы әдәби әсәр-

[1] Безнең Ильич. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1966 ел. Төзүчесе М. Гайнуллин.

ләрнең күбесе бөек юлбашчы тормышының һәм эшчәнлегенең Казан чорына багышланып язылганнар. М. Ногман үзенең «Кокушкино таңнары» дип исемләнгән поэмасында Володяның кечкенәдән үк гадәттән тыш кешелекле һәм интернационалист булуын тасвирлый; кыен шартларда да хезмәт ияләренә мәңгелек яз китерү турында уйлануын, иҗат итүен, марксистик карашлар белән дулкынлануын гәүдәләндерә.

Мәгълүм булганча, В. И. Ленин үзенең революцион эшчәнлеген Казан университетында укыганда башлап җибәргән иде. Р. Ишморатның «Давылга таба» драмасы әнә шул вакыйгаларга нигезләнгән. Студентлар хәрәкәтен киң планда һәм реалистик яктыртуы белән дә, Ильичның студент елларын художестволы җанландыруы буенча да «Давылга таба» драмасын татар драматургиясе өчен генә түгел, ә бөтен совет драматургиясе өчен дә яңа сүз, кыю бер адым дип бәяләргә мөмкин.

Х. Туфанның «Ильич Татарстаны», С. Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә», З. Мансурның «Ленин күзләре», Г. Афзалның «Печәнче», С. Сүнчәләйнең «Ленин», Ә. Ерикәйнең «Ленин турында җыр» исемле шигырьләре дә күңелдә җылы тәэсир калдыра.

Җыентыкка кертелгән хезмәтләрнең бер өлеше В. И. Ленин белән очрашуның онытылмас хатирәләре — истәлекләр рәвешендә язылганнар. Болар — «Пролетариат диктатурасы һәм Ленин», «Татарстан җөмһүрияте һәм иптәш Ленин», «Онытылмас очрашу», «Онытылмас көн» дигән истәлекләр. Авторлары: Г. Ибраһимов, С. Сәетгалиев, Вл. Бахметьев һәм З. Бурнашева. Алар В. И. Ленин белән очрашуларын хаклы рәвештә горурланырлык иң бәхетле минутлардан саныйлар һәм Ильичның кешелек сыйфатларын билгеләп үтәләр. «Пролетариат диктатурасы һәм Ленин» исемле истәлегендә Г. Ибраһимов В. И. Ленинның Россия белән Германия арасында солых төзү өчен ничек көрәшкәнлеген сөйләп килә дә, болай ди:

«Ленинның иң кыйммәтле сыйфатларыннан, ана юлбашчылык биргән иң зур хасиятләреннән бере — аның төрле куәтләрнең мөнәсәбәтен үтә нечкә аңлавы, вакыйгаларның барышын алдан күрүе, иманы юлында бөтен дөньяда ялгыз калса да чигенми сугышуыдыр».

Халык өчен бөек юлбашчы яшәгән җирләр, ул файдаланган әйберләр һәммәсе дә бик кадерле һәм изге. Г. Афзалның «Ничә язда...», Ә. Исхакның «Ленин йорты», Ә. Баяновның «Ленин булган җирләр бу җирдә», С. Урайскийның «Порт-шәһәр» исемле шигырьләре әнә шул урынның кайберләрен хөрмәт белән искә алалар һәм Ленинга карата мәхәббәт тәрбияләүдә, аның тәгълиматларына игътибарны көчәйтүдә әһәмиятле роль уйныйлар.

Җыентыктагы күп кенә әсәрләр — һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы, Ә. Фәйзинең «Кара таш ник дәшми?» исемле балладасы, Ф. Кәримнең «Москва», К. Нәҗминең «Ленин яши», Ш. Мөдәррисның «Ленин турында уйлар», Г. Латыйпның «Ильич белән», З. Нуриның «Үлемсез Ленин», М. Садриның «Ленин йөрәге» исемле шигырьләре, М. Максудның «Бетмәде», С. Сабировның «Һәрвакыт безнең белән» исемле нәсерләре һәм башка әсәрләр «Ленин үлемсез» дигән темага иҗат ителгәннәр. Бу әсәрләрдә төрле мисалларда һәм төрле аспектта «Ленин үзе үлсә дә, аның эше, аның исеме, аның тәгълиматлары мәңгелек» дигән идея үткәрелә.

Бу әсәрне аерым бер китап рәвешендә төзеп, М. Гайнуллин яхшы эш башкарган. Дөрес, җыентыкны халыкның Ленин турындагы җырлары, әкиятләре исәбенә тагын да калынайта төшәргә мөмкин иде. Анда Ш. Камалның «Ленин һәм крестьяннар» дигән эчтәлекле хезмәте дә урын алырга хаклы булгандыр, бәлки. Әмма җыентык бу көенчә дә бик җылы, бик матур тәэсир калдыра. Аны — төзүченең һәм бер төркем татар әдипләренең Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгына карата укучылар өчен әзерләнгән бүләкләре дип әйтергә мөмкин.

Бу китап укучыларны ленинча укырга, ленинча эшләргә, ленинча яшәргә һәм көрәшергә өйрәтүдә бик кыйммәтле кулланма булыр.

Әхәт НИГЪМӘТУЛЛИН,
Башкортстан дәүләт университеты доценты.

# «Кукчәтау далаларында»

...Каравыл иле хәзер, шомлы бер тынлык эчендә, авыр хәсрәт белән, кышлавын, ничә язлар, җәйләр күчеп йөргән җәйләүләрен ташлап, кайчандыр күз кебек тулып торган, хәзер исә кибеп беткән Алка күленнән аерылып, иң кадерле кешеләрен мәңгелеккә үзенә алган зиратны ятим калдырып, билгесез язмышка атлый.

Нәрсә көтә аларны алда? Бәхетме? Әллә тагын да дәһшәтлерәк һәлакәтме? Шатлыкмы? Әллә йөзеп чыга алмаслык кайгы диңгеземе?..

Ибраһим Салаховның «Кукчәтау далаларында» исемле романы [1] моннан йөз ел элек казакъ даласында булып узган әнә шул фаҗигале хәлләрне сурәтләү белән башланып китә. Һәм бу прологны әсәрнең иң көчле, иң оста язылган урыннарыннан берсе дияргә була.

Романдагы төп вакыйгалар инде безнең көннәрдә — кайчандыр ташланган, кибеп-кееп хәрабә хәленә килгән Кукчәтау даласында «Алка күл» совхозы төзелә башлаган көннәрдә — бара. Анда чирәм җир күтәрүчеләрнең катлаулы характерлары, фидакарь хезмәте күрсәтелә. Әсәрдә тасвирланган шул вакыйгалар уртасыннан Сәет Батталов белән Гайшәнең катлаулы, бик гыйбрәтле һәм фаҗигале язмышы үтә.

Күп еллар элек Сәет белән Гайшә бер институтта укыганнар, яратышып өйләнешкәннәр, бергә яши башлаганнар. Ләкин хәвефле еллар башланган. Бер дә юкка, нахакка гаепләп, Сәет Батталовны кулга алалар. Шул вакыйгалардан соң 18 ел вакыт үткәч, Сәет белән Гайшә яңадан очрашалар. Тик хәзер инде һәркайсының яңа семьясы бар.

Үзенең бу ике героен язучы май уртасында, һич тә көтмәгәндә купкан буранлы төндә очраштыра. Бу — тикмәгә түгел, анда бер символик мәгънә бар. Чыннан да, бер-берсен бөтенләй оныта алмасалар да, еллар үтү белән йөрәк яралары төзәлә барган һәм, үзләренең хәзерге язмышы белән килешеп, шактый тыныч яши башлаган Сәет белән Гайшәнең күңелләрендә кинәт яңадан кабынган хисләр дә шул язгы төндә купкан давыл кебек бит. Ләкин язгы буран озакка сузылмый, басыла, табигать тына. Тик Сәет белән Гайшәгә күңел тынычлыгы яңадан кайтырмы, юкмы?

Сәетнең биографиясендә, язмышында авторның үз биографиясенә, үз язмышына охшаган яклар күп. Бу образның Гайшәгә караганда җанлырак, тулырак бирелүенең бер сәбәбе дә шундадыр, бәлки. Үзең күргән, үз башыңнан кичкән хәлләр әдәби әсәрдә аеруча ышандыргыч чыгалар бит. Тик Сәет турында сөйләгәндә, бу образ исеменнән авторга бер үпкә белдерәсе килә: «Минем аксаклыгымны нигә һаман искә төшерәсең?» Дөрес, Сәет лагерьда чакта аягын югалткан, хәзер ул протез белән, сул ягына ава төшеп йөри. Кайберәүләрнең үзенә генә хас бер гадәте, холкы була. Һәм шуны әдәби әсәрдә теге яки бу образны тулыландыручы, төсмерләтүче уңышлы деталь итеп бирергә мөмкин. Ләкин бирёдә бөтенләй башка нәрсә. Аяксыз булу — Сәетнең бәхетсезлеге, физик кимчелеге. Һәм ул хакта бер-ике мәртәбә әйтеп китү дә җитәр иде. Югыйсә аның бу физик кимчелеген күп кабатлау күңелдә авыр тәэсир калдыра, ничектер, Сәетне мескенәйткән төсле була.

Хәлбуки, Сәет Батталов мескен түгел. Күзгә ташланырлык геройлык күрсәтмәсә дә, шактый авыр шартларда ул сыгылып төшми. Карап торырга шундый юаш, шыпырт күренсә дә, көчле ихтыярлы кеше ул. Эштә дә үзе дөрес дип тапкан карашны үткәрә белә.

Ә менә Гайшә образы ничектер тоныграк чыккан кебек. Аннан соң, Гайшәнең иреннән ваз кичүе дә күңелдә аңа карата симпатия уятмый. Дөрес, ул елларда Гайшә кебек хатыннар да булмады түгел, булды. Ләкин андыйлар бик сирәк иде. Ә гомумән купчелекне алганда, «халык дошманы» дип кулга алынганнарның хатыннары искиткеч ир йөрәкле булдылар, ахырынача ирләренә турылыклы булып калдылар. Эшсез, ач-ялангач калганда да, төрлечә кимсетелгәндә дә, ирләреннән ваз кичүне уйларына да китермәделәр алар. Араларында бер генә түгел, берничә бала анасы булганнары да күп иде. Чыннан да, ихтирамга лаеклы хатыннар алар!

Аннан, Гайшә кызы Зәйтүнәгә атасының кем булуын да әйтми. Сәетнең авыр язмышы турында да сөйләми, үзенең кызы барлыгын икенче ире Тояк Беркетбаевтан яшерә. Шундый хәл мөмкинме? Мондый очракта кешенең характеры нинди булу зур роль уйныйдыр. Ләкин, ничек кенә булмасын, еллар буе шулай Гайшә кебек яшәр өчен бик көчле ихтыярлы булырга кирәк. Тик әсәрдә автор, никтер, Гайшәгә ар-

---

[1] Ибраһим Салахов. Кукчәтау далаларында. Роман. Татарстан китап нәшрияты. 1965 ел.

тык аз урын биргән. Аның кызы Зәйтүнә белән бәйләнеше дә бары бер хат аша гына күрсәтелә. Хәлбуки, Гайшә образын тулырак бирергә бик мөмкин һәм кирәк тә иде.

«Алка күл» совхозындагы вакыйгаларга, кешеләргә килсәк, анда чирәм жир күтәрү эшендәге кыенлыклар һәм аларны җиңеп чыгу моментлары тормыштагыча тасвирланган. Симка-Семафор, Иргали Арсланов, Каракүз, Вера, Вавдичлар җанлы кешеләр булып күз алдына килеп басалар.

Тик менә «Кара мәчеләр» вакыйгасы кирәк иде микән? дигән сорау туа. Кызык өчен генә кертелгән кебек тоела ул. Элекке карак Симка-Семафорның шулай тиз төзәлеп китүе, бәлки, авторның үзенә дә бик үк ышандыргыч тоелмагандыр. Әгәр шулай икән, үзенең шиген бетерер өчен, язучыга бүтән юл эзләргә кирәк иде.

«Күкчәтау далаларында» романы турында сүз барганда, андагы тагын бер үзенчәлекне әйтми үтү мөмкин түгел. Тугандаш казакъ халкына, хәтта шул халык яшәгән далаларга, тауларга гашыйк шагыйрь тарафыннан язылган әсәр бу. Андагы җырлар, үләннәр, легендалар, мәкальләр әсәргә үзенчәлекле бер яңгыраш, казакъ халкына хас үзгә бер пафос алып киләләр.

Ак күбек күперенә
кимеш суда,
Сылу кыз шул күбектән
битен юган.
Бер дә тыныч, бер дә
шау-шу күлнең өсте,
Серле әкият менә инде
шунда туган...
Китап түгел, ул әкият
мирас калган,
Бер буыннан бер буынга
күчеп барган,
Картларның бәян кылган
әңгәмәсен
Соңгылар, тыңлап торып
отып алган,—

дип башланып киткән «Күкчәтау» җыры да, Сары арканы мәдехләгән үләң дә, башкалар да һәркайсы үз урынына ятышып тора.

Салаховның охшатулары да шулай ук үзенчәлекле, кызыклы. Ходайбирган карт турында язганда, аның бармакларын катып калган саксаул ботакларына охшатуы да бик табигый, ятышлы. «Авыр болытлар һаман әле ябага йон төсле саланып өстерәләләр», ди икенче бер урында автор. Кап-кара сырма бәрхет булып сузылган кырның, кояшта җылынып, тирләп, парланып ятуы да бик җанлы күренеш. Язучының үр өстендәге ак ташны тезләнеп яткан куйга охшатуы да казакълар өчен бик табигый нәрсә.

«Казан утлары» журналының 1966 елгы 7 санында басылган «Колагир» исемле хикәясендә И. Салахов иҗатының бу үзенчәлеге тагын да ачыграк күренә. Казакъ халык әдәбиятында күренекле урын тоткан шагыйрь һәм көй чыгаручы Акан Сире исеме белән бәйләнешле «Колагир» легендасына нигезләнгән бу хикәя үзе дә гүзәл легенда рухында язылган. Акан Сиренең кайбер үләңнәре дә бирелгән анда. Шулар арасыннан:

Туры атны нярләп
менсән иде,
Өке тагып юргалатып
йөрсәң иде.
Кызлы авылның накъ
түшеннән төн буенча
Иркәң өчен янып-көеп
йөрсән иде.
Сүз салып җиңгә аша
иркә җанга,
Кордаш кызың белән
уйнап-көлсәң иде.
Ишарәләр, ымлар белән
сүз кузгатып,
Кыз серен җиңгәсеннән
белсәң иде...—

дигән үләңе аеруча ошады миңа.

Әле күптән түгел «Азат хатын» журналында (1966 ел, № 11) И. Салаховның «Төн кызы» исемле тагын бер легендасы басылып чыкты. Гаҗәп матур легенда! Бу талантлы язучының иҗаты турында уйлаганда, озак вакытлар авыр ташлар белән бөялеп торганнан соң, ниһаять, юлы ачылып, ургылып ага башлаган чишмә күз алдына килә.

Сәрвәр ӘДҺӘМОВА.

———◆———

# ХАТЛАР АКТАРГАНДА

Редакциягә бик күп хатлар килә. Аларның күбесе поэзия белән кызыксынган кешеләрдән һәм үзләре шигырь язучылардан була. Бу, әлбәттә, беренче нәүбәттә, халкыбызның шигъри әсәрләргә булган традицион мәхәббәте турында сөйли. Татар халкы элек-электән, бишектән алып, җырлар, бәетләр белән тәрбияләнеп үскән. Шуңа күрә дә ул лирик җанлы, моңлы, фидакарь, эшчән һәм тормыш сөючән.

«Җилсез яфрак селкенми», дигәннәр борынгылар. Әгәр дә поэзиябезнең халыкны дәртләндерә, рухландыра һәм дулкынландыра торган хосусияте булмаса, аның шифалы җиле күңел кылларын тибрәтеп исмәсә, мәктәп яшендәге балалардан алып ак сакаллы картларга кадәр поэзия белән дәртләнмәс иде. Бу дәрт, язмалар нинди генә сыйфатта булуга карамастан, кешенең үз хисләрен җырга, шигырьгә салып әйтеп бирүгә омтылуы ягыннан гына чыгып бәя биргәндә дә бик күркәм хәл.

Соңгы елларда без, яшьләрнең үз журналлары булмавын искә алып, мөмкинлекләребез бик чикләнгән булса да, «Казан утлары» битләрендә «Яшьләр иҗаты» дигән рубрика астында яшь талантларга шактый зур урын биреп килдек, һәм журнал киләчәктә дә бу изге эшкә үзенең игътибарын киметмәячәк.

Яшь шагыйрьләрнең автобиографиясен, рәсемен һәм шигырьләрен урнаштыру укучыларыбызны әдәбиятның яңа кадрлары белән аларның беренче адымнарыннан ук таныштырып барырга ярдәм итсә, сәләтле яшьләребезне үсү юлында рухландырып, канатландырып җибәрергә булыша торган чараларның берсе булып та зур хезмәт күрсәтә.

Шушы уңай белән, соңгы вакытларда, поэзия бүлегенә биографияле хатларның ешаюы гаҗәп хәл түгел. Ул хатларда күпләр: «Кадерле редакция! «Казан утлары»нда яшьләр иҗатын биреп баруыгыз миңа бик ошады. Мин дә шигырьләр яздым. Журналда файдалануыгызны үтенәм...» дип язалар. Шунда ук автобиография һәм рәсемнәр дә теркәлгән була. Хыялый теләк, тылсымлы өмет белән тулган бу хатларда барысы да бар, тик, кызганычка каршы, күп вакытта, иң мөһиме — шигыре генә булмый... Ә бит үзеннең рәсемен, биографиян белән күпләрне таныштырыр өчен иң элек аларга нәрсәдер бирергә, аларны үзеңнең һөнәрең белән таныштырырга кирәк, ягъни беренче нәүбәттә әсәрләрең — шигырьләрең шул син үзеңне таныштырырга теләгән күпчелек кабул итәр дәрәҗәдә әйбәт, өметле, талантлы булырга тиеш. Менә бу яктан инде күп кенә хатларда аның авторының мәсьәләне аңлап һәм уйлап җиткермәве, ашыгу, кабалануы сизелеп тора. Юкса журналыбызда шигырьләре чыккан яшь шагыйрьләрнең берсе дә безгә биографияләрен һәм рәсемнәрен үзләре тәкъдим итмиләр. Ә без редакциягә килгән йөзләгән хатлардагы шигырьләр арасыннан бер-ике сәләтле яшьне табып, аларның иң уңышлы дип саналган шигырьләрен сайлап алып, шуннан соң гына рәсем һәм белешмәләрен үзебез соратып алдырабыз.

Редакциягә килгән барлык әйберләрне дә журналда басып чыгару мөмкин булмаган кебек, шигырьләр җибәргән һәрбер авторга аерым-аерым консультацияләр язып, киң күләмдә киңәшләр бирү дә редакция шартларында мөмкин түгел.

Безгә язышкан кешеләрдә шигырь язу дәрте бик көчле булуын әйттек. Әйе, дәрт бар! Ләкин аның шул дәртне эшкә ашырлык дәрманы да булырга тиеш бит. Без түбәндә менә шул турыда әңгәмә алып барырга, килгән хатлар эченнән берничә үрнәк алып, шуларга тукталып үтәргә һәм шулай итеп монда исеме күрсәтелмәгән, моңа кадәр язган һәм язачак бик күп иптәшләргә журнал аша җавап бирергә булдык.

Хәзер турыдан-туры хатларның үзләренә күчик. Менә Пятигорск шәһәреннән иптәш Яраев хаты (аңа без шигырьләре арасыннан яраклы бер әйбер дә таба алмавыбыз турында язган идек):

«...Хатыгызны алдым. Игътибар өчен рәхмәт. Мин тырышам, киләчәктә дә тырышырмын... Сезнең сүзләргә ышанам. Менә сезгә берничә әйберне җибәрәм... Сез аларга журналның бер почмагыннан урын бирегез... Сез минем шул кечкенә теләкне үтәсәгез, минем өчен зур файда итәр идегез, миңа яңа канатлар үсәр иде...»

Күрәсез, яхшы ният, яхшы теләк. Хәзер инде шигырьләрен күздән кичерик. Хатта дүрт шигырь килгән. Алар шигырь булу ягыннан берсе берсеннән ерак китмәгәннәр. Менә шулардан «Яшь дустыма» дигәне. Ул монда тулысынча китерелә:

«Син алмаз җирендә тудың.
Синең холык асылташка кардәш.
Һәр кыен эшне син булдырасың.
Нык күкрәктә тибенә йөрәген,
Яңа уңышка омтыл, яшь ватандаш.

Һич армыйча тик алга атла,
Асылташ бөгелми, аны бел.
Яшендә, давылда адашма юлда,
Кыенлыкта дустыңа ярдәм ит».

Беренче юлда иптәш Яраев яшь дустының азат илдә, гүзәл совет Ватанында туганлыгы турында әйтергә теләгән. Ләкин шуны «алмаз илдә тудың» дип әйтү белән укучының күз алдына Ватан образы басамы? Юк, әлбәттә. Монда фәкать кемнеңдер чыннан да алмаз чыга торган җирдә туулы турында сүз бара кебек. Димәк, чагыштыру уңышлы түгел, әйтергә теләгән әйбер ачылмаган, автор үз максатына ирешә алмаган.

Икенче юлдагы холыкны асылташка кардәш, дип әйтү дә уңышсыз. Бердән, холык асылташка кардәш була алмый, аның әле асылташка охшаш булуы мөмкин. Анда да ул кирәгеннән артык купшы, җансыз чагыштыру булыр иде.

«Асылташ бөгелми, аны бел», дигән юл да сәер тәэсир калдыра. Ничек инде асылташ турында «бөгелми» дип әйтергә мөмкин? Таш бит чатный яки ватыла гына ала. Фикерне дөрес һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирер өчен сүзләрне урынлы куллана белергә кирәк.

Кулъязманың башка өлешендәге: «кыен эшне булдырасың», «яңа уңышка омтыл», «армыйча алга атла», «юлдан адашма» һәм «кыенлыкта дустыңа ярдәм ит» дигән җөмләләр шигырьгә бернинди мөнәсәбәте булмаган коры сүзләрдән торалар. Алар күп нәрсә турында сөйләргә теләсәләр дә, берни дә әйтмиләр, җанга кагылмыйлар, йөрәкне җилкендермиләр. «Алмаз», «асылташ» һәм шундый ялтыравык сүзләр тезмәсе белән генә шигырь килеп чыкмый. Шигырь сүзләрдә гадилекне, җыйнаклыкны һәм аларны урынлы куллануны, образлыҗанлы әйтүләрне таләп итә. Моннан тыш әле шигырьнең ритмы, рифмалары, үлчәве, бер камилләшкән формасы да булырга тиеш. Ә югарыда китерелгән мисалда без аларны да күрмибез. Монда фәкать тел ярлылыгы, шигъри сәләт булмавы ярылып ята. Шигырьдә аз сүз белән күпне әйтеп бирә белү, моның өчен телнең бай булуы шарт. Телне баетыр өчен күп укырга, тәҗрибәле шагыйрьләрдән өйрәнергә кирәк.

Сарман районыннан Габиди иптәш тә безгә бик еш шигырьләр җибәрә. Ул шигырь техникасын яхшы үзләштергән, рифма өчен аваздаш сүзләр табуны да белә, үлчәүне дә саклый, ритмны да тоя. Хәтта күп вакытта сүзләр дә урынында һәм җөмлә дә дөрес. Ләкин Габиди иптәш күбрәк кабатланган, моңа кадәр күп әйтелгән әйберләр турында яза. Эзләнү, үзенчә итеп әйтү, шигъри материалларны укучыга яңача итеп ачу, сурәтләүләрне ул үзенә бурыч итеп куймый. Бер-ике мисал китерик. «Хыял» дигән шигыренең икенче строфасында ул:

«Хыял!
Синең белән юлга чыгам,
Гөлләр өзәм,
Шул гөлләрдән букет тезәм,
Аны дуска бирәм,
Елмаюлы йөздә
Яңа шатлык күрәм». — ди.

Бу «гөлләр өзәм», «букет тезәм» ләр инде ни гомерләр, ничәмә-ничә шагыйрьләр тарафыннан әйтелгән, таушалган сүзләр һәм рифмалар! Ә нинди мәгънә бар соң бу строфада? Нәрсә әйтергә теләгән соң автор? Нинди тирән фикер яки тәэсирле вакыйга бар соң монда? Кызганычка каршы, төче телле, зәгыйфь юллар гына бит болар.

Ә «Көтеп алам» шигырен Габиди иптәш давыллы, яшенле көндә, кыялар ишелгәндә дә бөркетләрнең исләре китмичә бала очырулары турында сөйләү белән башлый. Монда автор үзе дә белмәгән әйбергә ышандырырга тырыша. Бөркет һич тә балаларын беренче кат канат язарга — өйрәтергә давылга чыгармый. Хәер, монысына күз йомып үтик ди. Ә соң бу күпләр тарафыннан шушындый ук итеп җырланган бөркетләр һәм давыллар турындагы юлларның хуҗасы нәрсә әйтергә тели? Менә ул үзен шул бөркетләр белән чагыштырып ничек ди:

«Мин дә
Давыл килсә
Йөгереп тышка чыгам,
Аңа каршы барам,
Юк, яшисе килми мыштым гына,
Аны көтеп алам...
Яшен атса —
Күлеп каршы алам,
Күкрәк киереп сулыйм...»

Бөркетләрнең стихия белән көрәшүләре нинди дә булса берәр ихтыяҗдан, котылгысыз шулай кирәк булганлыктан килә. Бу табигый хәл. Ә менә үз акылындагы кешенең давыллы яңгыр килгәндә, токтомалдан тышка йөгереп чыгуы уйлап чыгарылган хикмәт, ясалма әйбер генә. Бу юллар бу килеш укучыны символик мәгънә эзләргә дә юнәлдермиләр. Ә инде яшен аткач «күкрәк киереп суларга» да, «көлеп каршы алырга» да мөмкинлек калмый лабаса. Менә мондый уйланмаган, баштанаяк ясалма нигезгә корылган әйбер кешене ышандырмый, шуңа күрә дулкынландырмый да. «Телең ни әйткәнне колагың ишетсен», дигәндәй, әйтергә теләгәнеңне шигырь юлларына үлчәп, уйлап, ачык итеп тезәргә кирәк.

Пермь өлкәсеннән Ергизов иптәш редакциягә үзенең шигырьләр язган дәфтәрен җибәргән иде. Ул дәфтәрдәге язмалар, нигездә, менә шушындый юллардан тора:

«Я, туганым,
Торма катып.
Кошчык кебек
Авызың ачып.
. . . . . . . .
Җаның биреп
Эшлә, туган,
Кызганмыйча
Көчең булган.
Шуннан сиңа
Килер данлык,
Горурланып
Мактанырлык.
. . . . . . .»

Күрәбез, бу шигырь юмористик планда язылмаган. Монда көчне кызганмыйча эшләү, дан горурлык турында сүз бара. Ләкин шундый пафослы әйбердә «торма катып», «авызың ачып» кебек мөрәҗәгать итү бик сәер яңгырый. Шигырьнең настроениесына карап аның сүзләрен дә сайлый белергә кирәк шул.

Аннан шул ук строфада «кошчык кебек авызың ачып» диелә. Кошка авызы ачык булу хасмы? Аның авызы һәрвакыт ачыкмы? Юк, әлбәттә. Ләкин «карга кебек ачык авыз» дип әйтәләр. Монда инде бөтенләй башка эш. Бусы Крылов мәсәленнән алынган. Төлке хәйләләп, син матур сайрыйсың, дип карганың авызын ачтыра да җиргә төшкән сыр кисәген алып ашый. Бу инде бөтен халыкка билгеле һәм халык мәкаленә әйләнеп киткән әйбер. Болай диюгә ачык авыз кешенең халәте сурәтле булып күз алдына баса. Ә «кошчык кебек авызың ачып» дию бернәрсә дә әйтми.

Икенче строфада, булган көчеңне кызганмыйча, күңел биреп эшлә, дип әйтәсе урында, автор, «туган» белән «булган»ны рифмалаштырыр өчен, «...кызганмыйча көчен булган» дип язып җөмләнең билен шундый итеп сындыра, нәтиҗәдә берни дә аңлашылмый. Шунда ук «җаның биреп» дигән урын да бар. «Җан бирү» үлем төшенчәсе булып халыкка кергән бит инде ул. Бу урында «күңел биреп» яки «җан салып» диярге кирәк иде. Соңгы строфадагы «данлык»та сүз бозу, «дан» сүзен гарипләндерү генә. Болар барысы да шул бичара тел аксаклыгы, ярлылыгы нәтиҗәсе.

Шулай итеп, бу дәфтәрдәге шигырьләргә бездән җавап алгач, иптәш Ергизов тагын мондый хат җибәрде:

«...Сез миңа шигырь язу буенча бик күп киңәшләр бирә алырсыз дип уйлыйм. Минем шигырьләргә карата булган сезнең «йомшак» дигән сүз бик дөрес... Әгәр мин укыган татар әдәбиятын саный китсәң, куллардагы бармакларның яртысы артып калачак... Рус телендә кызыклы, мөһим әсәрләр бик күп очрый. Шуларны татар теленә тәрҗемә итүдә минем яраклылыгым килеп чыкмас микән?

...Тәрҗемә буенча эш кылганда да минем каләмем әз генә булса да шомара төшәр иде дип өметләнәм... Сез шул яклап миңа ярдәм итә алырсызмы? (Эш бирү ягыннан)».

Кайчакта мондый хатларга беркадәр аптырап та каласың. Хатның кыскартып алынган өзекләреннән күренгәнчә, иптәш Ергизов безнең «шигырьләрегез йомшак» дигән җаваптан да канәгать, теленең ярлылыгына бармак белән санарлык дәрәҗәдә әдәбиятыбызны аз укуы сәбәп икәнлеген дә әйтә һәм, ниһаять, русчадан татарчага әдәби әсәрләр тәрҗемә итеп, шуның белән телен камилләштерергә мөмкиндер дип уйлый. Бу, әлбәттә, ялгыш караш. Чит телдән татарчага тәрҗемә итәр өчен һичшиксез үз телеңне — татар телен бик яхшы белергә, аның үзенә хас булган нечкәлекләрен тирәннән аңларга, тоярга, талантлы тел остасы булырга кирәк. Юкса тәрҗемә ителәчәк тел тәэсиренә бирелеп, сукыр килеш сүзгә сүз тәрҗемә итеп бик кызганыч хәлгә калуың, татар сүзләре белән русча җөмләләр төзеп «чыктым аркылы күпер»ләр белән икe телне дә рәнҗетүең мөмкин. Телне шомарту, камилләштерү өчен фәкать үз әдәбиятыңны күп укырга, укырга һәм укырга кирәк!

НУРИ АРСЛАНОВ.

———◆———

# УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ ТУРЫНДА КАЙБЕР ФИКЕРЛӘР

Оформление ягыннан да, эчтәлеге һәм материалларының фактларга бай булуы белән дә «Казан утлары» соңгы елларда укучыларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек журналга әверелде.

Нинди генә бүлекләр, нинди генә рубрикалар юк хәзер журналда!

Миңа яңа рубрикаларның «Түгәрәк өстәл янында» дигәне бигрәк тә ошады. Аны «Ак чәчәкләр» романына карата укучылардан килгән хатлар уңае белән Г. Әпсәләмов башлап җибәргән иде. Бу түгәрәк өстәл тирәсендәге сөйләшүдән без «Ак чәчәкләр» романының нинди материалларга нигезләнеп язылганын белдек. Һәм, әйтергә кирәк, бу сөйләшүдән соң Әбүзәр абзый белән Гөлшәһидәнең безнең арабызда яшәүләренә ышанычыбыз тагын да арта төште.

Безне түгәрәк өстәл тирәсенә чакырган икенче әдип — шагыйрь Ш. Маннур булды. Ул да үзенең «Муса» исемле киң полотнолы әсәрен дөньяга чыгарганчы байтак кына җирләрдә булып, байтак кына кешеләр белән аралашканлыгын әйтеп үтте. Бу сөйләшүдән соң «Муса» романы да тулыланыбрак киткәндәй булды.

Түгәрәк өстәл тирәсендә сүз алган өченче әдип — Гариф Гобәй. «Без үскәндә» дигән әсәреннән соң Гариф ага Гобәй нигә тынып калды икән, дип эчебез поша башлаган көннәрдә журнал битләрендә «Коръән серләре» басыла башлады. Дин әһелләренә аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте бу әсәр. Кайберәүләр (шул исәптән «кераләчыгалы» динчеләр дә) мондый «кирәксез», «мәгънәсез» әсәр бастырып чыгарган өчен, журналга үпкә дә белдерделәр.

Әмма мәгънәсезме соң әсәр? Коръәннең үзеннән дәлилләр китерелгән ләбаса анда! Кирәксезме соң әсәр?

«Дин бетә», дип кычкыру белән генә дин бетми бит. Заманнар узу белән ул яңа формаларга керә, шул яңа заманнарга җайлаша. Әйтик, безнең Зеленодольск шәһәрендә генә дә күп кенә карчыклар, хәтта урта яшьтәге хатыннарның да кайберләре ураза тоталар. Яңа тормыш коручылардан никах укыту күренешләре, балаларын, шәһәрдә рәт чыкмаса, авылга алып китеп, каравыл кычкыртып сөннәткә утырту очраклары булгалый.

Шундый үзенчәлекле һәм кирәкле әсәр язган өчен Гариф ага Гобәйгә дә һәм аны бастырып чыгарган журнал редакциясенә дә чын күңелдән рәхмәт әйтәсе килә.

Журналда әдәбият сөючеләрне җәлеп итә торган икенче яңа рубрика — «Язучының иҗат портреты». Русларда мондый материаллар күптәннән басылып килә инде. Аларның атаклы Чуковскийлары, Благойлары, Наумовлары, Андрониковлары бар. Яшьләр иҗаты турында да ялкынланып сөйләүчеләре бар. Мисалга Александр Коваленковны, Владимир Федоровны күрсәтергә була.

Бездә дә язучылар иҗаты турында язардай кешеләр бар, әлбәттә. Гази Кашшаф, Р. Мостафин, мәсәлән, бик әйбәт китаплар яздылар (Муса Җәлил турында язылган әсәрләр һәм Р. Мостафинның Казанда басылган «Литературные портреты» дигән ки-

табы күздә тотыла), әмма аларның әсәрләре журнал битләрендә бик сирәк күренәләр.

«Язучының иҗат портреты» хакында сүз чыккач, Әмирхан ага Еникига тукталып китмәү гөнаһ булыр иде. Аның әсәрләрен укучылар түземсезлек белән көтеп алалар. «Кыргызларда — Айтматов, бездә — Ә. Еники», — дигән сүзләрне бик күп укучылардан ишеткәнем бар минем. Әмма, шулай булуга карамастан, аның иҗаты ничектер читтә кала. «Әгәр укучы, хикәяне укып чыкканнан соң «һай, дөрес язылган!» яки «Менә бу, ичмасам, дөрес!» дисә, бу — икенче мәсьәлә... Бу очракта... без хикәянең бөтен җире килгән булуын, бөтен нәрсәсе үз урынында торуын күрер идек», — дип язган иде Әмирхан ага үзенең бер мәкаләсендә. Аның үз иҗаты турында да шундый ук фикер әйтәсе килә. Аның кайсы гына әсәрен алып укысаң да: «һай, дөрес язылган!» — дип куясың. Геройларының нәкъ тормыштагыча булулары, кеше психологиясен бөтен нечкәлекләренә чаклы төгәл чагылдырулары, тормыш дигән катлаулы процессның четерекле якларын искиткеч осталык белән күрсәтүләре, кире образларның «мин фәлән, мин төгән» дип сөрән салмыйча гына укучылар күңелендә чиркану хисе уята алулары белән аерылып торган бу әсәрләр хакында чынлап торып, киң диапазонда сөйләшер вакыт җитмәде микән?

Киләчәктә журнал моны да искә алыр дип ышанабыз.

Инде журналның «Әдәби тәнкыйть» дигән бүлегенә карата берничә сүз. Бусы яңа рубрика түгел, шулай булса да, тәнкыйтьнең тиешле югарылыкка күтәрелеп җиткәне юк әле. Тәнкыйтьчеләр әле ашыгыбрак ташлыйлар да, каш ясыйм дип, күз чыгарып куялар, әле ташбака сыман акрын кыймылдыйлар да, теге яки бу әсәрне бөтенләй хәтердән чыгарып ташлыйлар. Тәнкыйтьчеләрнең кистәннәре я агач кашык кебек җиңел, я бер сугуда язучыны «теге дөньяга» озатыр дәрәҗәдә авыр була. Ә бит тәнкыйтьнең чын максатын тәнкыйтьчеләр бездән яхшырак аңлыйлар. «Халыклар дуслыгы» журналы үз канаты астына алмаса, А. Гыйләҗевнең укучылар яратып каршылаган «Өч аршын җир» повесте, белмим, нинди язмышка дучар булган булыр иде. Рәхмәт инде Фәрит Хатиповка, соң булса да уң булсын дигәндәй, әлеге гүзәл әсәр турында матур гына тәнкыйть мәкаләсе белән чыкты. Журнал бу мәкаләне урнаштырып бик яхшы эшләгән. Тәнкыйть бүлегендә миңа бигрәк тә И. Нуруллин һәм Н. Юзиев мәкаләләре ошый.

Тәрҗемә әсәрләреннән Н. Арсланов, З. Нури, Ә. Исхак, Р. Гәрәй, Н. Мадъяров тәрҗемә иткән шигырьләр үзләренең колоритлы, оригиналга якын торулары белән күңелне җәлеп итәләр. Бигрәк тә мине Лермонтовның Н. Арсланов тәрҗемә иткән «Мин ялгызым гына юлга чыгам...» шигыре таңга калдырды. Әйтерсең, Лермонтов үзе татарча белгән дә, үзе татарча шигырь язган.

Журналның «Истәлекләр» бүлеге дә сокландыргыч дәрәҗәдә баеды. Бу бүлектә бигрәк тә Гайнетдинов белән Гайнетдиноваларның Фатих Әмирхан турындагы, Галимуллинаның Тукай турындагы истәлекләре, әллә фантазия-фәлән кушылмаганга шунда, гаруча җылы тәэсир калдырдылар. Әдипләрне үз күзебез белән күргәндәй булдык. Аларның моңарчы без белмәгән сыйфатлары ачылды.

Аннары журналның кайсыдыр бер санында «Авыл тормышы турында әсәрләр аз», дип зарланып язылган хат урнаштырылган иде. Редакция дә бу фикерне хуплап чыкты. Әмма бу бик үк дөрес түгел, минемчә. Нигә дигәндә, И. Салаховның «Күкчәтау далаларында», Ф. Хөснинең «Асылмалы лампа», М. Маликованың «Кыр ягы», «Юлдашлар», А. Гыйләҗевнең «Үги ана яфраклары», Г. Мөхәммәтшинның «Дулкыннар» һәм башка язучыларның әсәрләре нәкъ менә бүгенге авылны, аның кешеләрен чагылдыралар ич. Ә менә завод эшчеләр тормышы турындагы әсәрләр чыннан да аз. Бу теманы Барлас Камалов яктырта алыр иде шикелле. Гомумән, Б. Камалов үзенчәлекле, инде әллә кайчан үз укучысын тапкан талантлы язучы. Киләчәктә журналда аның зур-зур әсәрләрен укырбыз дип ышанабыз.

Йомгаклап әйтәсе сүз шул: киләчәктә журнал өлкән язучылар турында да, яшь язучыларның теге яки бу әсәре хакында да киңрәк мәгълүмат биреп барсын иде. Аннары, әлбәттә, бу юбилей елында халкыбызның героик көрәш юлын чагылдырган әсәрләр дә күбрәк булсын иде.

Фаил ШӘФИГУЛЛИН, эшче,
Зеленодольск шәһәре.




*Әхәт Фазылҗанов*

# БӘХӘС

Тау куышы авызына озын кара чәчләрен тузгытып, юантык кына һәм ярым шәрә бер хатын чыгып басты. Йокыдан әле генә уянган булса кирәк, шешенә төшкән күзләрен угалады, киерелеп иснәп куйды. Аннары ялкау гына түбәнгә, иртәнге кояш нурларында җәйрәп, ялтырап яткан күлгә таба атлады. Гәүдәсенең билдән түбән өлешенә итәк формасында уралган агач кайрысын салып ташлады. Иртәнге тынлыкны бозып, суга сикерде. Агач башларында йокымсырап утырган кошлар өере дәррәү куркышып күккә күтәрелде. Күлнең аргы ягындагы куе агачлыклар арасында ботаклар шытырдап сынды, дөп-дөп басып нииндидер авыр гәүдәле җәнлек узды. Мамонт иде, ахры.

Бармаклары белән чәчен тарап, тездән суда басып торган хатынның карашы тау куышына текәлеп калды. Йөзенә кинәт кыргый ачу билгеләре чыкты, нидер мыгырданып, шыңшып куйды. Баш хәрәкәте белән генә чәчләрен артка чөйде. Кайры итәген дә киеп тормастан, ашыга-ашыга өскә үрмәләде. Әле генә үзе чыккан куышны узып, янәшәдәге караңгы куыш авызына кереп югалды. Ул арада, бер кулыннан җитәкләп, үзеннән чак кына яшьрәк, күрер күзгә тыгыз гәүдәле бер хатынны җилтерәтеп алып чыкты. Үзе артыннан барырга ишарә ясады. Болай вакытсыз уятылуының сәбәбен аңлап бетермәгән булса кирәк, тегесе теләр-теләмәс кенә бара, кулын ычкындырмак була. Куркынган күзләре сорау, аптырау белән тулы.

Юантык хатын, үз куышына килеп җитәрәк, текә таш стена буенда тукталды. Стенага зәвыксыз, бик тупас итеп чукып ясалган сурәтләргә бармагы белән төртеп күрсәтте. Нәрсәләр генә юк монда! Рәсемнәрнең кайберләре кулларын, аякларын як-якка җәеп торган кеше кыяфәтендә.

Икенчеләре этне, үгезне, мамонтны, тагын әллә ниләрне хәтерләтә. Рәссамы шактый тәҗрибәсез күренә.

Юантык хатын бик тырыша-тырыша, кулларын болгый-болгый, төрле ишаратләр белән күршесенә аңлатырга тели: менә, синең юньсез малаеңның эше бу. Күр, бөтен стенаны пычратып бетергән. Адәм мәсхәрәсе. Алай кулы бик кычытса, әллә аңа кыя ташлары беткәнме! Кешенең моннан бер атна гына элек мең бәла белән казып кергән куышын мәсхәраләү бит бу! Нигә үзенекенә ясамый?

Яшь хатын да алай гына бирешергә теләми әле, тере тора. Чын-чынлап бәхәскә керә. Янәсе, минем малайдырмы, синекедерме? — анысын белгән юк бит әле. Алай бик чәчрәп ябышма әле син. Күрдеңме соң ясаганын? Нигә тотып китермәдең? Беләсең килсә, синең малайлар да андыйга кимен куймыйлар. Кулларына берәр каты нәрсә генә эләксен, дөньяңны чуарлап бетерерләр.

Өлкән хатын тагын да кыза төшә. Үзенекенә тел-теш тидергәнне яратмый. «Минем малайларның андый кирәкмәгән нәрсә белән шөгыльләнгәннәрен кайда, кайчан күргәнең бар? Ник күрмәгәнне әйтәсең?! Менә аудан аталары гына кайтсын, алла боерса...»

Бәхәс ахыр чиктә кыргый ызгышка әверелә. Берсе биш ишарә ясаса, икенчесе унны ясап ташлый.

Тотылмаган карак — карак түгел. Стенага кирәкмәгән сурәтләрне кем һәм кайчан ясаган — берсе дә күрмәгән, белмәгән. Ясаучысы кулын куеп калдырмаган. Хатыннарның һәркайсысы үз фикерләрендә кала.

...Бу вакыйгадан соң инде ун меңнәрчә еллар үтте. Әмма бәхәс бүгенгәчә дәвам итә. Хәзер инде галимнәр арасында, әлеге рәсемнәрне кем һәм кайчан ясаган — һаман ачыклый алмыйлар.

## БУШ БАШ

Кайда мин? Әллә, югыйсә, «теге дөнья» дигәннәре шушымы, ходаем? Кузгалырга да куркып ятам.

Тик шунысын ачык абайлыйм: һәрхәлдә, үз өемдә түгел. Ап-ак урынҗир. Чиста. Аста җәймә, өстә җәймә. Одеялы да үземнеке түгел — әллә нинди каты кыллы, кычыттыра торган. Түшәм-стеналар да ап-ак. Безнеке — агач йорт, ә мин таш стеналар эчендә ятам. Кем китереп ташлады соң әле мине монда? Табут эче дисәм, бик иркен күренә.

Аяк очында кояш нурлары уйный. Димәк, теге дөнья түгел. Шушы яшемә җитеп, анда да кояш бар дип ишеткәнем юк.

Бераздан аяк бармакларын селкетергә батырчылык иттем. Селкенәләр. Карават башына тидереп карадым — тимер салкынын да тоялар. Бик саклык белән куркып кына башымны сулга бордым. Борыным тумбочкага килеп төртелде. Тумбочка өстендә фарфор кружкадан градусник башын күрсәтеп тора. Ул арада борынга йод исе килеп бәрелде.

Хәзер инде аз гына да шигем калмады: мин больницада, бүтән бер җирдә дә түгел. Мин исән!

Бөтенләй хәтердән чыгып киткән: кичә кичтән минем баш миенә операция ясадылар бит. Менә әле искә төшә башлады. Өстәлгә менеп ятканымны беләм. Аннан авыз-борынга бик авыр исле чүпрәк китереп капладылар. Ни өчендер санарга куштылар. Әллә, югыйсә, сырхау башта булгач, саный да белмидер дип уйладылар микән? Үзләренчә сынап караулары дыр... Аннан соңгысын һич кенә дә хәтерләмим. Якты дөньядан киткәнеңне белми калуың да бар икән, әй.

Җәһәт кенә ике кулым белән башымны учлап алдым. Я, алла! Анысы да үз урынында. Тик марля белән урап бетергәннәр. Башны күтәрә төш-

тем. Шулкадәр җиңеләйгән. Әйтерсең, эчендәге бөтен нәрсәсен алып ташлаганнар. Эче куш кабакмыни! Әллә, югыйсә, бүтән кеше башы белән алыштырып куйганнармы? Хәер, анысы өчен кайгырмыйм. Баш урынына баш булгач, бик җиткән. Элеккесеннән дә начар түгелдер әле. Исәнлек кадерле. Димәк, яшибез дигән сүз. Мин исән!

Баксаң-күрсәң, председатель Габбасов минем үлүемне дә теләгәндер әле. Аннан көтәргә мөмкин. Яратмаганы — мин. Беркөн нәрсә дип тора бит: имеш, синең шикелле агрономның булмавы хәерлерәк. Гарьләнеп үләрсең! Юк, алай гына үлмибез әле. Бик ансат котылмакчы. Ашыкма! Баш исән, димәк, әле көрәш тәгәлләнмәгән. Мине эштән алу Габбасовның кулыннан киләме соң! Ул куйган агроном түгел.

Баш исән!

Шулай да операциядән соң ми эшчәнлеген тикшереп карарга кирәк әле. Тулы акыллы кешеме мин хәзер? Шөкер, моңарчы да акылдан авышканым булмады анысы. Тик соңгы вакытта нишләптер баш сызлап йөдәтте. Менә монда пычак астына китереп тыкканы да шул булды.

Хәзер инде иң авыры артта калды. Моннан соңгысы да әйбәт булырга тиеш. Менә кеше шикелле фикерлим ич әле. Анысы шик калдыра икән, эксперимент ясап карарга мөмкин.

Менә өстәл өстендә карабодай боткасы тора. Иртәнге аштыр инде. Бер сынык икмәге дә бар. Күмәч, кайберәүләр уйлаганча, агач башында үсми. Бодай оныннан пешерелгән. Ә бодайны безнең ише кешеләр басуга чәчеп үстерәләр. Карабодайны да шулай. Бөртекле культурамы ул, әллә сызма культурамы?.. Менә анысын ук әйтә алмыйм икән. Хәтерләмим. Хәер, операциягә кадәр дә белми идем. Үзең үстереп карамагач, кайдан беләсең. Габбасов киләсе елдан әбизәтелни чәчә башлыйбыз дип хыялланып йөри.

Бер стакан сөт тә кертконнәр икән әле. Анысы турында сорагыз — тулы җавап бирә алам. Сөтне сыер бирә. Сөттән май атлыйлар, сыр, эремчек ясыйлар. Тагын ни кирәк? Димәк, ми нормаль эшли.

Шатлыктан идәнгә сикереп төшеп, бер тыпырдап аласы килде хәтта. Әмма анысы ук рөхсәт ителмидер әле. Болай да баш түбәсен ара-тирә чәнчеп ала...

Чыелдап ишек ачылды. Ап-ак халаттан күзлекле бер кеше күренде. Танымый торам: кичә миңа операция ясаган хирург ич бу. Фамилиясен дә хәтерләдем: Забывалов. (Кем әйтер минем баш начар эшли дип!)

Зур канәгатьләнү белән елмаеп куйды. Минем исән калуыма куануыдыр инде аның да. Уен-муен түгел, баш хәтле башка операция ясасыннар әле. Әгәр шунда үлеп киткән булсам? Аның да башыннан сыйпамаслар иде, нибуч.

Кыяр-кыймас кына минем аяк очына килеп утырды. Йөзе кинәт җитдиләнеп калды. Яхшы ук талчыкканы сизелә. Төне буе мине саклап йокламый чыккандыр әле. Ә үзе, нишләптер миңа туры караудан да курка кебек. Җаймә очын имән бармагына чорный. Әйтерсең, минем алда шундый катлаулы операция ясаган хирург түгел, әйбер урлап тотылган сабый утыра.

— Кәефегез ничек? — дип сорап куйды, ниһаять, ярым пышылдап. Гүя, мин аның бу соравына каршы хәзер: «Үләм, бетәм!» дип кычкырырга тиеш идем.

— Бик яхшы! — дидем мин булдыра алган кадәр күтәренке күңел белән. — Рәхмәт, доктор!

Забываловның миннән мондый көр җавап ишетүгә аз гына да өмете юк иде, ахры, гаҗәпләнүе соң дәрәҗәгә җитте. Күзлеген кулына алды.

— Рәхмәте соңыннан, — диде бик тыйнак кына һәм ни өчендер куркынган кыяфәт белән як-ягына каранып алды. Миңа таба иелә төште. — Беләсезме нәрсә: бик зур гаепле бит мин сезнең каршыда. Зинһар...

Мин аның сүзен бүлдермичә булдыра алмадым:

— Сез ни сөйлисез, доктор!

Доктор тагын да серлерәк итеп пышылдады. Колагыма кайнар сулышы керде.

— Сезнең башыгызны тагын бер тапкыр ачарга туры киләчәк бит.

— ? ? ?

— Кичә зур ялгышлык киткән... — Забывалов, әйтеп бетерергәме, юкмы дигәндәй, тотлыгып калды. Ниһаять, чыраен сытып (әйтерсең үзенең баш капкачын куптаралар), телгә килде: — Операциядән соң баш миегезне кире урынына салып куярга оныткнбыз, понимаешь...

Менә хәзер чыннан да «Үләм, бетәм!» дип кычкырасым килде. Кабат пычак астына керергәме? Юк, беркайчан да. Әле беренчесеннән исән калуыма да ышанып бетми ятам. Алар тагын башны актармакчы. Кабак түгел лә ул сезгә. Кичә ми онытылып калса, бүген пычакларын да онытып калдырырлар алар, ышаныч юк. Әйтәм аны, баш бик җиңеләеп калган. Хикмәте бар икән. Хәер, җиңел булса, аннан ни зыян? Муенга көч азрак төшәр. Башмы? Баш! Хирургның үзенеккеннән аз гына да ким эшләми. Үзегез күрдегез.

Юк инде, күрә торып үлем кочагына барып кереп булмас. Безгә шушы баш та ярап торыр. Хикмәт башта гынамыни! Бездә аның башкасы да бар бит әле.

Ниһаять үземнән бигрәк, тораташтай катып калган хирургны тынычландырырга теләп:

— Борчылмагыз, доктор, минем диплом бар! — дидем.

—✦—

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## СӘНГАТЬ БӘЙРӘМНӘРЕ

Февраль елның иң кыска ае булса да, кызыклы вакыйгаларга, төрле тантаналарга бай үтте.

Татарстан җәмәгатьчелеге 1 нче февральдә Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрының оешуына 60 ел тулу көнен билгеләп үтте.

Тантаналар тантанага ялганып китте. Г. Камал исемендәге театр артистлары Казан шәһәре җәмәгатьчелеге белән бергә, 4 нче февральдә Ленинградтан килгән кунакларны каршыладылар. Октябрьның илле еллык юбилеена багышланган сәнгать фестивале үткәрергә дип Казанга төньяк балкышы шәһәреннән күп кенә сәнгать осталары килде.

А. С. Пушкин исемендәге Ленинград дәүләт драма театры артистлары, Ленинградның халык инструментлары оркестры коллективы, «Дуслык» ансамбле үзләренең чыгышларын халыклар дуслыгы тантанасына багышладылар.

Сәнгать фестивале эстафетасы сәнгать осталарыннан язучыларга күчте. 13 февральдә Татарстан язучылары Ленинградтан килгән каләмдәш дусларын — В. Торопыгин, В. Абрамкин, А. Чепуров, Е. Вечтомова, Л. Хаустов, С. Давыдов, Г. Гобовскийларны каршыладылар.

Ленин каласыннан килгән язучылар бөек юлбашчының яшьлеген күргән шәһәрне кызыксынып карап йөрделәр. Владимир Ильичның беренче сөрген урыны булган Кокушкинога бардылар. Килгән кунаклар язучылар, галимнәр, эшчеләр, хәрби хезмәткәрләр, студентлар, укучылар алдында күп санлы чыгышлар ясадылар. Әлмәт шәһәрендә — нефтьчеләр янында булдылар.

Быел март аенда күренекле язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тула. Аның туган көнен Мәскәүдә, Уфада, Казанда һәм илебезнең башка шәһәрләрендә билгеләп үттеләр.

12 нче февральдә язучылардан А. Шамов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Л. Ихсанова, Ш. Галиев, Р. Гатауллиннар Башкортстанга Г. Ибраһимов юбилеен үткәрергә бардылар. Башкорт язучылары Н. Нәҗми, Ф. Исәнголов, филология фәннәре докторы Ә. Харисовлар белән бергә алар әдипнең туган авылы Солтан Моратта булдылар. 400 кеше сыешлы бик шәп яңа клубта көндез укучылар, кичен колхозчылар белән очраштылар. Язучылар Казаннан Г. Ибраһимов тормышына багышланган күчмә күргәзмә алып килгәннәр иде. Колхозчыларга күрсәткәннән соң аны мәктәпкә, Г. Ибраһимовка багышлап укучылар төзегән музей бүлмәсенә бүләк итеп калдырдылар. Район үзәге Талбазыда һәм Уфада да юбилей кичәләре булды. Язучылар Уфада Г. Ибраһимов булган җирләрне карап йөрделәр, әдипнең туганнары, замандашлары белән очраштылар.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Язучылар әледән әле халык арасында булалар, язылачак геройлары белән очрашалар. Ә. Исхак, И. Гази, Т. Җуравлев, З. Мәҗитов, Я. Венецкий, В. Монасыповлар Казан химия-технология институтында студентлар белән очраштылар. Ә. Бакиров, М. Хөсәен, Җ. Тәрҗеманов, М. Мазунов, Г. Мөхәммәтшин язучыларның Тукай клубында, Н. Дәүли Казан шәһәре пионерлар сараенда, Г. Бакиров Татарстан дәүләт музеенда чыгышлар ясадылар.

Балалар язучысы Әминә Бикчәнтәева 35 нче мәктәп укучылары янында булды.

Дербышка поселогы культура сараенда шагыйрь М. Хөсәеннең иҗат кичәсе үткәрелде. Бу кичәдә язучылардан М. Садри белән К. Латыйпов та катнаштылар.

Февраль башындагы каты салкыннар Буа районының «Тельман» һәм «Гигант» колхозы колхозчыларын куркытмады, алар клубка чуваш язучылары белән очрашуга җыелдылар. Бу күңелле мәҗлескә Чабаксардан П. Хузангай, Г. Ефимов, Г. Орлов,

И. Малгай һәм Казаннан А. Талвир килгән иде. Алар колхозчыларны үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар, күп төрле сорауларга җаваплар бирделәр.

Казан шәһәренең 121 нче мәктәп залында ул көнне халык гадәттән тыш күп булды. Укучылар һәм аларның әти-әниләре язучылар белән очрашуга килгәннәр. Шагыйрьләрдән С. Хәким, Ә. Исхак, Н. Дәүли, Н. Арсланов, А. Сәләхетдинов, К. Фәсәхов, Р. Гатауллин, М. Саттаровлар бу кичәдә яңа шигырьләрен укыдылар.

Февраль аеның башларында язучы Фатих Хөсни һәм яшь шагыйрь Рәдиф Гатауллин Норлатта (Зеленодольск районы) булдылар. Норлат китапханәсендә Ф. Хөснинең «Утызынчы ел» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде; язучы романның язылу тарихы турында сөйләде. Сорауларга җавап бирде, иҗат планнары белән таныштырды. Соңыннан Рәдиф Гатауллин үзенең шигырьләрен укыды.

Шундый ук очрашу Норлат урта мәктәбендә дә булды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт районының Комсомольск поселогында «Әдәбият һәм хезмәт геройкасы» дигән темага кичә үткәрелде. Бу кичәгә күп кенә яшь нефтьчеләр җыелган иде. Язучылардан Ә. Маликов, Г. Ахунов, Г. Афзал үзләренең әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән таныштырдылар.

Бөгелмә шәһәрендә сукырлар җәмгыяте клубы язучы Г. Ахуновның «Хәзинә» романы буенча укучылар конференциясе үткәрде. Конференциядә автор үзе дә катнашты.

Язучы Әдип Маликов Әлмәт районының Салкын-Алан мәктәбендә, шагыйрә Энҗе Мөэминова Елховой авылы мәктәбендә укучылар белән очраштылар.

Әлмәт районының Мактама авыл клубында һәм Бөгелмә районының Карабаш культура сараенда язучылардан Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов, Г. Афзал, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, С. Кальметов, яшь авторлардан Х. Сафина, Ф. Гыйззәтуллиналар әдәби кичәләр үткәрделәр.

Сарман районы культура йортында хезмәт иясләренең язучылар белән очрашуы булды. Очрашуда Г. Афзал, С. Кальметов, С. Сөләймановалар катнаштылар.

## КАПИТАЛ ХЕЗМӘТ

Мәскәүдә, «Искусство» нәшриятында «Совет драма театры тарихы» дигән хезмәтнең беренче ике томы басылып чыкты. Бу китапларда граждannар сугышы чорында һәм 20 елларның беренче яртысында СССР халыкларының театрлары турында очерклар урнаштырылган. Безнең укучыны Идел буе халыкларының театрлары турындагы хезмәтләр аеруча кызыксындырыр. Татар театры турындагы очеркларның авторы филология фәннәре кандидаты, Язучылар союзы члены Бәян Гыйззәт. Бер үк вакытта Б. Гыйззәт бу алты томлык хезмәтнең редколлегия члены булып та тора.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

24 нче февральдә язучылар бер еллык әдәби хезмәтләренә йомгак ясау өчен Тукай клубына җыелдылар. Проза буенча Г. Ахунов, поэзия турында Р. Башкуров, тәнкыйть буенча З. Мәҗитов һәм балалар әдәбияты турында Ф. Ибраһимова иптәшләрнең докладлары тыңланды. Язучылар әдәбиятыбызның теге я бу мәсьәләләре буенча чыгышлар ясадылар.

Үзенең сүзендә тәнкыйтьче Бәян Гыйззәт узган әдәби ел эчендә яңа пьесаларның бик аз булуын әйтте. Аннан соң А. Расихның «Ике буйдак» әсәре буенча эшләнгән спектакльгә, А. Гыйләҗевнең «Җиргә тапшырылган серләр», Р. Ишморатның «Шаулыйлар дулкыннар» дигән пьесаларына тукталып, аларның уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтеп үтте. Татар драматурглары әсәрләренең илебезнең башка сәхнәләрендә аз баруын әйтте.

Ф. Хөсни 1966 елда басылган әсәрләрдә халык язмышы турында чын күңелдән борчылу сизелмәвенә басым ясады. Кеше хисләрен зур осталык белән күрсәтә белеп тә, иҗтимагый мәсьәләләргә игътибарны киметмибезме, дигән фикер әйтте.

Г. Бакиров чыгышын балалар әдәбиятына багышлады. Ул балалар әдәбиятына күп кенә яшь авторларның килүен, шуңа күрә бу өлкәдә зур, тәҗрибәле язучыларның иҗади ярдәме бик кирәк булуын күрсәтеп үтте.

Г. Халит татар прозасының борылыш чоры кичерүен һәм бу чорның бик тирәннән барып, дистәләгән елларга дәвам итәргә мөмкинлеген сөйләде. Әдипләрнең кешенең эчке дөньясын ачарга тырышулары әдәбият өчен уңышлы юнәлеш, классикларның традицияләрен дәвам итүнең үрнәге булып тора, диде.

М. Әмир татар әдәбиятының һәр жанрында да алга китеш, шактый уңышлар барлыгын билгеләп үтте. Бигрәк тә ул поэзиягә үз тавышларын яңгыраткан яңа, яшь каләмнәр килүен шатланып әйтте. Аннан соң Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәренә тукталып, аның сәнгать әсәре буларак бик көчле язылуын билгеләп үтте һәм шул ук вакытта кайбер йомшак якларын да тәнкыйтьләде.

Әдәби тәнкыйтькә тукталып, ул тәнкыйтьчеләрне бүгенге көн герое мәсьәләсен нигезләбрәк тикшерергә, әсәрләрне иртәге көн таләпләренә карап өйрәнергә чакырды. Халыкта патриотик тойгылар тәрбияләү әсәрләребездә беренче планда торсын, дип белдерде.

Җыелыш ахырында язучыларның әдәби-иҗат эшчәнлегенә ярдәм итәрлек күп кенә тәкъдимнәр кертелде.

### ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Тәрҗемәчеләр секциясендә язучыларның журналистлар белән берлектә үткәрелгән утырышы булды. Анда рус теленнән татар теленә тәрҗемә принциплары турында филология фәннәре кандидаты К. Фасеев доклад ясады. Ул үзенең мисалларында вакытлы матбугатта басылган әсәрләргә күбрәк тукталды. Утырышта Н. Исәнбәт, И. Гази, Х. Гобәйдуллин, Ш. Байчура һ. б. иптәшләр кызыклы гына чыгышлар ясадылар.

Шагыйрьләр секциясе февраль аенда җыелган утырышын Гөлшат Зәйнашеваның иҗатына багышлады. С. Хәким, Н. Дәүли, И. Юзиев, Ш. Галиев, Р. Гәрәй һ. б. шагыйрәнең соңгы елларда язган әсәрләренә уңай бәя бирделәр, шул ук вакытта аңа күп кенә киңәшләр дә әйттеләр.

### ЛАЕК БҮЛӘК

Татар әдәбиятын үстерүдә күп еллар армый-талмый эшләгән язучы И. Газины, тууына 60 ел тулу көне уңае белән, хөкүмәтебез «Почет билгесе» ордены белән бүләкләде. Бу вакыйга бөтен татар әдәбияты өчен зур шатлык булды. Без, аның каләмдәш дуслары, Ибраһим агага ныклы сәламәтлек, иҗатында тагын да зур уңышларга ирешүен телибез.

### ТАТАР КЛАССИКЛАРЫ РУМЫН ТЕЛЕНДӘ

Редакциягә көн саен күп кенә хатлар алына. Менә соңгы хатларның берсе. Аны Румыниядән Бухарест университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ассистенты Шукран Вуап-Мокану яза. Шукран ханым безнең күптәнге танышыбыз. Ул 1956 елның февралендә Казан университетына укырга килә. Шау-шулы студент еллары тиз генә үтеп тә китә. Университетны тәмамлап туган иленә кайткач та Шукран Вуап-Мокану Казан белән элемтәсен өзми. Ул татар әдипләренең әсәрләрен румын теленә тәрҗемә итә. Әле менә бу юлы да Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ын тәрҗемә итүе турында язган һәм безгә румын телендә чыга торган «Әдәби газетаның» бу елда басылган 2 февраль санын җибәргән. Газетаның бу санында Шукран ханым тәрҗемәсендә, татар әдипләренең шигырьләре басылып чыккан икән. Без түбәндә Шукран Вуап-Мокануның хатын тулысынча китерәбез.

«Сайгылы редакция,
шушы, Румыния язучылар союзының атналык органы «Әдәби газета»ның соңгы битендә, уң ягында «Атлас лирик», аннан соң, «Татар антологиясе» дип язылган. Тукайның «Шагыйрь», «Өзелгән өмет» һәм «Кыйтга» (көчләремне мин кара...), Дәрдмәнднең «Кораб» һәм Сагыйт Рәмиевнең «Ул» шигырьләренең румын телендә тәрҗемәләре урнаштырылган. Бу румын укучысының күренекле татар шагыйрьләре белән беренче танышуыдыр.

Мин бик шат. Шатлыгымнан сезгә дә «Әдәби газета»ның бер номерын җибәрәм».

*Бухарест, 3. II. 1967 ел.*

### КОТЛЫЙБЫЗ

24 февральдә Татарстанның халык художнигы Бакый ага Урманчыга 70 яшь тулды. Шул көнне художниклар йортында юбилярның иҗатына багышланган зур кичә уздырылды. Бакый аганы тәбрикләргә шәһәребез җәмәгатьчелегенең күп кенә вәкилләре килгән иде. Татарстан хөкүмәте художникның күп еллык хезмәтенә югары бәя бирде. Аны Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләде.

Татар халкының яраткан җырчысы Гөлсем Сөләймановага 60 яшь. Танылган халык музыкантлары, күренекле композиторлар белән иҗади дуслыкта утыз елга якын гомер үткән. Халык артисткасы Гөлсем Сөләйманованың эчке моңга бай тавышы илебезнең кайсы гына шәһәрендә яңгырамаган да, аны кем генә яратып тыңламаган. Әмма каты авыру бу талант иясен сөекле эшеннән китәргә мәҗбүр итте. Тик аның җырлары һаман да эфирда яңгырап тора. Аның замандашлары, яшь җырчылар, музыка сөючеләр әледән әле Гөлсем ханым квартирасында булалар, музыка белгечләре, фольклорчылар аның янына киңәшкә киләләр, уңышлары белән уртаклашалар.

—✦—

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!**

«Казан утлары» журналы үзенең битләрендә татар совет язучыларының иң яхшы әсәрләрен, тугандаш халыкларның әдәбият үрнәкләрен биреп бара. Журналда тел һәм әдәбият мәсьәләләренә кагылышлы фәнни хезмәтләр, әдәбият тарихына караган яңа материаллар, илебезнең батыр кешеләре турында очерклар, яңа китапларга рецензияләр һ. б. күп кенә материаллар басыла.

«Казан утлары» журналы алдагы саннарында

А. Расихның **«Хөсәен Ямашев»** исемле романын,

Г. Бәшировның **«Туган ягым — яшел бишек»** дигән автобиографик повестен,

Ә. Еникинең **«Җиз кыңгырау»** исемле күләмле хикәясен,

Ф. Хөснинең **«Бар иде Балтачта бер этәч»** дигән юмористик хикәясен,

Х. Вахитның **«Соңгы хат»** исемле пьесасын,

Агитбригадалар өчен репертуар, бер пәрдәлек пьесалар, скетчлар,

Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Давыдов, Х. Камал, И. Юзеев, Ш. Галиев, С. Сөләйманова һ. б. шагыйрьләрнең шигырь һәм поэмаларын басып чыгарачак.

Бөек Октябрьның илле еллык тантанасы уңае белән илебезнең үткәне һәм хәзергесе турында һәр номер саен күп кенә кызыклы материаллар урнаштырыла.

**КАДЕРЛЕ УКУЧЫБЫЗ!**

Әгәр сез журналга ярты елга гына язылган булсагыз, аны ел ахырына кадәр озайта аласыз.

Елның икенче яртысы өчен майның 25 еннән дә калмый язылырга кирәк. Әлегә кадәр журналны алдырмаган иптәшләр елның икенче яртысыннан башлап языла алалар.

**ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ:**

**бер елга — 4 сум 80 тиен,**
**ярты елга — 2 сум 40 тиен,**
**өч айга — 1 сум 20 тиен.**

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/II-1967 ел. Басарга кул куелды 25/III-1967 ел. ПФ 09014. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 58146 экз. Заказ М-288. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

# *БЕЗНЕҢ ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕБЕЗ*

Эшлекле һәм тантаналы итеп ел саен киң күләмдә шигырь бәйрәме үткәрү бездә моннан берничә ел элек үк инде гадәткә керде. Әдәбиятның, шул җөмләдән аның иң оператив һәм иң нәфис жанры поэзиянең дә тәрбияви ролен күтәрүдә, халыкка художество тәрбиясе бирүдә, яңа әсәрләрне пропагандалауда бу бәйрәмнәрнең әһәмияте гаять зур.

Быел безнең шигырь бәйрәмебез, Октябрьның 50 еллыгына багышлап, тагын да тантаналырак төстә уздырылачак.

Шигырь бәйрәме халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай туган көндә, ягъни 26 апрельдә үткәрелә. Бәйрәмнең үзәге — Тукай һәйкәле янында поэтик митинг оештырылачак: шагыйрьләр үзләренең иң яхшы дигән яңа шигырьләрен укыячаклар, классик поэзиядән үрнәкләрне сәхнә осталары һәм мәктәп балалары башкарачак. Шул ук көнне культура сарайларында, клубларда, вузлар һәм мәктәп залларында уздырылачак поэзия кичәләрендә дә шулай ук шигырь тантана итәчәк. Шагыйрьләрнең автографлары белән шигырь китаплары сату һәр җирдә оештырылачак. Аларны урыннардагы культура учреждениеләрендә, мәктәпләрдә, китапханәләрдә һәм китап сәүдәсендә эшләүче иптәшләр бик зур тырышлык белән алдан ук хәзерләргә тиеш булалар. Газета битләрендә, радио һәм телевидение тапшыруларында ул көнне шигырьгә аеруча киң урын биреләчәк. Шагыйрьләр үзләренең быел язган иң яхшы әсәрләрен «Шигырь бәйрәме» дигән аерым китапка туплап, киләсе елның поэзия көненә багышлап чыгарачаклар.

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!**

**БАРЫГЫЗ ДА ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕНӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!**

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

(ОГНИ КАЗАНИ)

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

Индекс 73210